ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2002




# «КАЗАН УТЛАРЫ»НА 80 ЕЛ




Быел «Казан утлары» журналының чыга башлавына 80 ел тула.

Әгәр исәпне гасыр башында чыга башлаган **«Әлгасрел-җәдид», «Шура», «Аң»** басмаларыннан санасак, татар әдәби-иҗтимагый журналының юбилей саны 100 елга якынлашыр иде. Әмма, шул чорның сәяси кануннары таләп иткәнчә, әдәби-мәдәни журналның чишмә башын совет чорыннан исәпләү гамәлгә кергән.

1922 елның май аенда Казанда татарча әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси басма—бүгенге «Казан утлары»ның башлангычы саналган «Безнең юл» журналының беренче саны дөнья күрә.




**«Безнең юл»**—татар халкының классик әдибе, күренекле җәмәгать эшлеклесе **Галимҗан Ибраһимов** инициативасы белән чыга башлый. Журнал тиз арада җәмәгатьчелекнең яраткан басмасына әверелә. Ул елларда язучыларны берләштергән махсус оешмалар булмый әле. «Безнең юл» исә, төрле юнәлештә иҗат итүче күпсанлы әдипләрне һәм галимнәрне туплаучы бер органга әйләнә.

«Безнең юл» айга бер мәртәбә чыга һәм аның беренче саннары 1000—1500 данә тираж белән дөнья күрә. Журналның нигезен әдәби әсәрләр тәшкил иткән. Татар укучылары Һ. Такташ, Ш. Камал, Ш. Усманов, К. Нәжми, Г. Кутуй, Д. Фәтхи кебек язучыларның күп әсәрләре белән иң әүвәл шушы журнал аша танышканнар.

«Безнең юл» 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп имласында басыла.

# Казан утлары
# Qazan utları

*2002*

**1**

**(951)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***


*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).


---


420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа елда янарган уйлар ........ 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Гарасатлы юллар. *Повесть.* ........ 8
Илдар ЮЗЕЕВ. Яңа шигырьләр. ........ 78
Рашат НИЗАМИ. Ике мөһаҗир. *Шигырьләр.* ........ 103
Рәмис АЙМӘТ. Кая бакма—җәйрәп ята ирек... *Шигырьләр.* ........ 131
Нурулла ГАРИФ. Кыска хикәяләр. *(Мәгъсум Хуҗинның кереш сүзе белән.)* ........ 136

**ЯЗУЧЫ АЙДАР ХӘЛИМГӘ 60 ЯШЬ**

Айдар ХӘЛИМ. Бөркетле баганалар. *Хикәя.* ........ 82

**ТАРИХ**

Солтан ШӘМСИ. Низаглы йортта. ........ 111
Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. «Яңа милли юл» журналы һәм Тукай. ........ 168
СОЛТАН. Габдулла Тукай. ........ 174
Хөсәен ГАБДҮШ. Бөек «Кушлавыч» ятиме. ........ 176

**ҺӘР ТӨБӘКТӘ—БЕЗНЕҢ КАЛӘМДӘШЛӘР**

Фоат МОРТАЗИН. Ялтадан хатлар. *Шигырьләр.* ........ 153
Ирек САБИРОВ. Сез һәм мин. *Шигырьләр.* ........ 156
Фирдания ГЫЙЛФАН. Туган йортка сәяхәт. *Шигырьләр.* ........ 158

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Марат ЗАКИР. Йомшак агачны корт баса. ........ 160
Фәрит ХАТИПОВ. Традициядән тайпылып. ........ 165

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

19—Мәрьям сүрәсе ........ 180

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Факил САФИН. Татарныкымы, әллә... ........ 184

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Мәсгут ГАЙНЕТДИН. «Яшәүне ул миндә калдырды...» *(Шагыйрь Разим Вәлиуллинга 60 яшь.)* ........ 186

**БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Болын чәчәкләре күп булсын. *(Галимҗан Латыйпның туувына 90 ел.)* ........ 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 190

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


«Колонка главного редактора»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Старо-новые мысли в Новом году»
«Проза и поэзия»: Повесть З. ЗАЙНУЛЛИНА «Тяжелые версты»; рассказ А. ХАЛИМА. «Орлиные столбы» *(с предисловием к юбилею писателя)*; короткие рассказы Н. ГАРИФА *(с предисловием М. Хузина)*; стихи И. ЮЗЕЕВА, Р. НИЗАМИ, Р. АЙМЕТА.
«История»: С. ШАМСИ. «В скандальном доме» *(страницы истории Золотой Орды)*; Х. МИННЕГУЛОВ. «Журнал «Яна милли юл» и Тукай»; перепечатка из этого журнала статей Султана и Х. Габдуша о творчестве Г. Тукая.
«Поэтические голоса наших земляков»: стихи Ф. МУРТАЗИНА, И. САБИРОВА, Ф. ГИЛЬФАН.
«Литературная критика»: статья М. ЗАКИРА «Слабое дерево гниет с корня»; статья Ф. Хатипова «Отклонившись от традиций».
Коран на татарском языке.
«Книжное обозрение»: Ф. САФИН рецензирует книгу Д. Загидуллиной «Литературные законы и время».
В номере отмечается 60 летие поэта Р. Валиуллина.
«Наш календарь»: 90 лет со дня рождения Г. Латыпа.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Вид вечерней Казани; поэт Вазих Фатихов.


# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*


"The column of chef aditor": R. FAIZULLIN «The old and new ideas in New Year».
"Prose and Poetry": Z. ZAINULLIN'S narrative «The hard way»; A. KHALIM'S story «The eagles post» (with preface), N. GARIF'S short stories (with M. KHUZIN'S preface); the verses of I. USEEV, R. NIZAMI, R. AYMET.
"History": S. SHAMCI "In scandalous house" (the history pages of Gold Orda); Kh. MINNEGULOV "The new national way" magazine and Tukay" reprinting of SULTAN'S and Kh. GABDUSH'S article about G. Tukay creative works.
"Our reader's verses": verses of F. MURTAZIN, I. SABIROV, F. GILFAN.
"Literary criticism": M. ZAKIROV'S article "The weak tree is rotting from roots", F. KHATIPOV'S article "Digressing from traditions".
"Koran in Tatar language".
"Books review": F. SAFIN'S review of D. Zagidullina's book "The literary laws and time".
Our jubilees: 60th anniversary of poet R. Valiullin.
Our calendar: 90th anniversary of G. Latip.
The diary of social and cultural life.
In our covers: The view of night Kazan, poet Vazikh Fatikhov.



★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.12.2001 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70Х108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8765 Заказ А-581
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълумат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2002 ел.

*Баш мөхәррир сүзе*

# ЯҢА ЕЛДА ЯҢАРГАН УЙЛАР

Һәр яна адым—аякларның бер-берсенә таянып алга ыргылганы кебек, һәр Яңа ел да—Искесенең алгарышка таба дәвамы ул. Яңа елда, кичәге-бүгенге мәшәкатьләрдән онытылырга тырышып, матур киләчәк турында күпме генә хыяллансаң да, үткән ел гамәлләре сине барыбер ычкындырып бетерми, ихтыяримы-юкмы, аларны янә бер күңелеңнән кичерәсең.

Үзгә бер алгысыну белән көтелгән, яңа бәхет-шатлыкларга өмет ителгән Яңа гасырның беренче елы ничек үтте? Теләкләребез кабул кылындымы, фаразлаганнар тормышка ашты мы? Һәркем үзенчә җавап бирер. Шулай да, галәми-гавәми фикер йөртсәк, болайрак әйтергә мәҗбүрбез: шомлырак башланып китте бу XXI гасыр дигәннәре. Бер кар китеп, икенче кар яткан аралыкта, бигрәк тә җәй-көз фасылларында, дөнья масштабындагы хәвефле, канлы вакыйгалар артыгы белән күп булды шул. «Глобаль катастрофалар булмагае» дигән шик күңелләргә үтеп керде. Өченче бөтендөнья сугышы башлану чигенә җителде (БМО мәгълүматларына караганда, җирдәге халык бер ел эчендә илле млн. чамасы кешегә арта икән. Димәк, җир тыгызлана, яшәү пространствосы кысыла, кояш астындагы урын өчен көрәш-дау көчәя, терсәккә терсәк ныграк тия, йөрәкләр ярсурак тибә!..). Тулы бер кыйтгалар, системалар, диннәр арасында нәфрәт дивары пәйда булды. Американың һәм Көнбатыш христиан илләренең мөселман дөньясына элек-электән килгән кырын карашы үткән ел үзенең апогеена житте. Илбасар-атаман державалар «террорга каршы көрәш» сылтавы белән аерым бер халыкларны, дәүләтләрне юк итү гамәленә керештеләр. Сугыш, үлеш-кырылышлар, нигездә, диндәшләребез яшәгән җирләрдә бара. Ничә дистә елларга сузылган Әфганстандагы мәхшәр, Чечня-Ичкериядәге геноцид, ватаннары «диннәр бишеге» булган фәләстыйнлылар язмышы. Шуңа өстәп, Балкандагы албаннар, Кытайдагы уйгырлар, Һиндстандагы кашмирлыларның аяныч хәлләре... Һәр илнең, һәр халыкның үзгә ярасы, үзгә фаҗигасе. Тик бер уртаклык: атышлы-орышлы сугыш хәлләре, нигездә, таулы илләрдә бара. Янар таулар... Яралы халыклар... Янаулы йөрәкләр...

Үз ватаныбыздагы үткән елгы вәзгыять-хәлләрнең дә күбесе күңелләргә бәлзәм булып ятты димәс идем. Милли җанлы татар кешесенең дәртен сүндерерлек байтак акция-гамәлләргә, борчу-мәшәкатьләргә юлыктык. Моннан ун еллар элек күңелләребездә горур бөркет булып очкан мөстәкыйльлеккә бәйсезлеккә омтылыш хисе соңгы елларда күшегеп, бәләкәйләнеп, хәлсезләнеп калды. Татарстан күп дистә еллар буе СССРдагы союздаш республикалар хокукына дәгъва кылса (халыкара масштабта алар кая ыргылдылар да, без кайда калдык...), хәзер элеккеге автономия кысаларына (түбәнрәк булмаса!) тәмам әйләнеп кайтты бугай. Халык ихтыяры һәм парламент кабул иткән Конституциянең күп маддәләре (алар кырыктан артык) капылт үзгәртелсен хәтта кайберләре мәхкәмәгә бирелсен әле! Хәтта Татарстандагы мәктәпләрдә татар теле укыту мәсьәләсе дә суд залларында күтәрелде. Кыскасы, 90 елларда яулап алынган хокуклар кире тартып алынды, кануннар коллык психологиясенә туры килә торган итеп тәмам «тәңгәлләштерелде». Татар халкын рәсми рәвештә, ачыктан-ачык төрле этник төркемнәргә ясалма бүлгәләү бара. Хәтта, нинди графикада язу-язмау кебек һәр халык фәкать үзе хәл итә торган мәсьәләләр дә «Ак патша» пайтәхете кулына күчте. Кайбер

шовинистик сәясәтчеләр, үз башына ашкынган козгын кебек, Татарстанның республика булып яшәренә күп калмады инде дип тә каркылдыйлар...

Дөньяга һәркем үз оя-мөнбәреннән бага, биеклегенә карап офыкларны ачыклый, ихтыяҗына күрә максат-таләпләр куя. XXI гасырның өермәле чатына чыгып җиткән татар язучысын, гомумән, каләм ияләренниләр борчый соң бүген, яңа һәм алдагы еллардан ниләр өмет итә? Гомумән, язучының җәмгыятьтәге роле нинди дә хезмәтенең хаҗәте ни дәрәҗәдә? (без үскәндә «язучы булам!» дию—хәтта якын кешеңә дә әйтергә базылмый торган татлы хыял иде! Бармы хәзер андый хыялый үсмерләр?)

Язучы—асылда, елъязмачы ул. Язучы—үз халкының тарихын язарга тырыша, аны бүтән милләт-кавемнәрдән ким итеп күрмәскә тели. Әлбәттә, үзенең табигый миссиясен үтәү өчен аңа да, кәгазь-каләмнән тыш, тән-җан саулыгы, горур басып йөрерлек дәрман-барлык, һәм ахыр чиктә, киләчәккә ныклы ышаныч кирәк бит! Чын язучы милләт язмышы белән яши. Ә милләт кая бара? (Бәлкем, кеше дигән «homo sapiens» заты клонлаштырылган заманда бу төшенчә кемнәргәдер анохронизм булып яңгырыйдыр? Шулай да, кытай, немец, япон, гарәп, һинд, инглиз кебек кавемнәр үзләренең кан белән яратылган исемнәрен һич тә онытырга теләмиләр бугай!) Безнең өчен әлегә җавапсыз ин кыен сораудыр бу. Ни өченме? Гомум ил күләмендә үткәрелә торган кайбер реформа-акцияләрдән туа бу сораулар. Әйтик, үткән ел федераль дәүләт төзелешенең асылын тәшкил иткән—Үзәк белән регионнар арасындагы демократик мөнәсәбәт күрсәткече—үзара шартнамәләр юкка чыгарылды диярлек. Федерация төзү үрнәген күрсәтә башлаган Татарстанның пионерлык әләме кыйшаеп авып кала язды... Янә бер факт: үткән ел Россиядә милли мәсьәләләр буенча министрлык (ул болай да кутәрәмгә калган, вәкаләтләре юк дәрәҗәдә булган идарә структурасы иде) бетерелде диярлек. Шомлы сигнал бу! Димәк, империя стратегиясенә андый идарә-мәшәкатьнең кирәге юк. Димәк, милли проблема да юк! Бүгенге Россиядә миллилеккә күпмедер дәгъва кылучылар кемнәр? Әлбәттә, беренче чиратта, сан ягыннан икенче урында торучы татарлар... Өстәвенә, көтмәгән-уйламаганда, газет-журнал, басма-нәшрият әһелләрен аптырашта калдырып Татарстанның үзендә матбугат министрлыгы бетерелде. Безне, ягъни матбугат органнарын, аларда эшләүчеләрне элемтә министрлыгы карамагына тапшырдылар, авылдагыча әйтсәк, «пушта»га беркеттеләр. Матбугат, ничек кенә димәсеннәр, иң әүвәл идеология, тәрбия үзәге. Һәрхәлдә шулай булырга тиеш. Матбугат—безнең шартларда дәүләтчелекнең нигезен тәшкил иткән милли идеяне формалаштыручы бер мөһим үзәк тә әле ул. Шуна күрә, элемтә, идеологияне үткәрүдә мөһим бер хуҗалык структурасы булса да, бу очракта, рухи әйдәүче ролен һич тә үти алмый.

Хәер, бүгенге артык буталчык сәяси сәнәгать хәлләренә бик артык тирән кермичә, язучының төп хезмәт нәтиҗәсе булган китапка кайтыйк әле. Мәгълүм хакыйкать: китапсыз—язучы юк. Китапка мөнәсәбәт—язучыга мөнәсәбәт, һәм безнең шартларда тарихка мөнәсәбәт дигән сүз. Шөкер, теләгән кеше өчен бүген китап бар. Яхшылары да житәрлек. Үткән ел, һәм классикадан булсын, һәм бүгенге әдипләр булсын, байтак яхшы китаплар дөнья күрде. Шулай да, китап дөньясындагы проблемалар кимемәде. Беренчедән, нигездә татар яшәгән җирдә—авылларда китап сәүдә системасының җимерелүе сәбәпле, китапларның укучыларга барып җитүе авырлашты. Икенчедән, китап дөньясы үзе бик чуарланды, художество-эстетик кыйммәте булмаган чүп-чар чын җәүһәрләр белән бер шүрлеккә менде (кыргый базар китапка килеп керде, җөмлә төзи беләме-юкмы, акчасы һәм амбициясе булган байтак адәм үзенең язмасын басма итеп тәкъдим итә башлады). Өченчедән, критерийларның югалуы, әдәби тәнкыйтьнең юк дәрәҗәсендә булуы, әдәбият белән кызыксынучыларны, бигрәк тә яшьләрне авыр хәлгә куйды. Өстәвенә, гомумтенденция—телевидение, компьютер системасы һәм башка замана могҗизалары китапны кысрыклавын да искә алсак, уйланырлык хәлләр күп. Безнең өчен китапны югалту—милли генетик мирасны югалту, киләчәкне югалту дигән сүз ул. Безнең өчен һәр ел Китап Елы булырга тиеш. Һәм

быелгы бу елыбыз да. «Без китаплы халык!» дибез үзебезне; әгәр ахырзаман килә торган булса, ахыргача китап белән бергә булыйк! Коръән сүрәсендәге сүзләр искә төшә: «һәр халык үзенең китабы янына чакырылып китерелер...».

Яңа Елда языла торган мондый башсүз-язмалар, гадәттә, «ел буена житәрлек» дәрт бирә торган оптимистик рухта була. Бәлки ул шулай кирәктер дә. Минеке күңелләргә беркадәр гамь-шом сала торганрак булып чыкты шикелле. Нишлисең, бүгенге халәтебез, вәзгыятебез, күрәсең, шулайрак. Әмма күңелләр төшенке үк димәс идем. «Көл күңел! Дөнья моны бер безгә генә мени!» Җанны беркадәр тынычландыра торган бер нәрсә—уртаклык. Ни булса да, ил белән, Дөнья белән хәзер. Адәм балалары бер-берсе белән шул кадәр чәбәләнеп бәйләнеп беткән хәзер. Дөньяның бер читендәге яра икенче бер полюстагыларның җаннарында сызлау булып инри (Чечнядагы сугыш бөтенроссияне яраламадымы?). Бүгенге заманның тагын бер үзгә ягы: күңелләребездәгене ачыктан-ачык әйтә-белдерә алабыз. Шул җөмләдән, халкыбыз язмышы турында да. Әрни-әрни үзебезгә үзебезчә «диагноз» куя алабыз. Димәк, төзәлүгә, терелү-яңаруга өмет бар дигән сүз (Ә безнең шартларда тулы бер буыннарга бөтенләй тәтемәгән ирек бит!). Әйе, без һәммәбез дөньяга сыналыр өчен яратылган. Һәр аерым затка гына түгел, милләт-халыкларга да карый бу. 2002 ел, һичшиксез, яңа сынау-сыналулар елы булачак. Җиңел булмастыр. Хәер, егылып-торып җиңәргә өйрәнгән халык бит без! Әнә, әле кайчан гына Казанның 800 еллыгы дигәннән көпсенеп үткәрмәскә каршы төшкәннәр иде, хәзер 1000 еллыгын үткәрергә әзерләнеп мәш киләбез! Моннан 20 еллар элек Кремль диварларыннан Колшәриф мәчете кебек гүзәл корылма күтәрелер дип кайсыбыз гына уйлый алды икән! Быел бөтендөнья татарларының чираттагы Конгрессы булачак. Бергә туплану, уртак максатларны барлауда мөһим бер этап булыр дигән ышаныч зур. Быел халык санын исәпкә алу да булачак бит әле. Ничек кенә санамасыннар, жир йөзендә татар кимемәс ул.

Әдәби хуҗалыгыбызда да быел истәлекле бәйрәмнәр, зур юбилейлар, киңәш-оештыру җыеннары узачак. Безнең өчен иң мөһим чараларның берсе—ул «Казан утлары»ның чыга башлавына 80 ел тулу юбилее. Бу дата милли матбугат үсешен күрсәтә торган зур бер әдәби-мәдәни бәйрәм булыр дип уйлыйбыз. Быел, шулай ук, татар язучыларының чираттагы корылтае узачак. Бу олуг җыенда да әдипләрнең әдәбият турында әдәпле фикер алышулары булыр, киләчәккә бару юллары ачыкланыр дип ышанасы килә. Өстәп шуны да әйтеп узыйк: журнал үз укучыларын җуймыйча керде бу Яңа елга. Киләчәктә әбүнәчеләребезнең тагын да ишәюе насыйп булсын!

Кешене өмет яшәтә. Өмет ышанычны тудыра, ышаныч—хыялландыра. Ә хыяллар тормышка ашса, бәхет шул инде ул. Ә бәхетле кеше илһамланып иҗтиһат итә: балалар тудыра, иген үстерә, йортлар төзи, үлемсез әсәрләр яза. Адәм баласының яшәү мәгънәсе дә Үлемсезлеккә омтылышта бит! «Күңел һаман алгысына— Матурлыкның алгысына!»

Хәерле Яңа еллар Сезгә, кадерле укучыларыбыз, хөрмәтле каләмдәшләребез!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**

*Татарстанның халык шагыйре,*
*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире*



## Зәки Зәйнуллин

# ГАРАСАТЛЫ ЮЛЛАР

ПОВЕСТЬ

**1952** елның март бураннары котырган көннәр. Мин—унсигез яшьлек буй җиткереп килгән егет кисәге—Куганакбаш җидееллык мәктәбендә математика һәм физика укытам. Үзем урта белемле. Мин укыткан җиденче сыйныфтагы ике укучы үземнән дә зурлар: Мидхәт Ишморатов егерме яшьтә, ә Вәли Каюповка—егерме бер. Икесе дә кочкә-көчкә өчлегә укып йөриләр. Тынлаучаннар—шунысына рәхмәт.

Мәктәп директоры Зәйни абый Вильданов Ватан сугышының беренче көннәреннән 1945 елның март урталарына кадәр чыкмастан сугышкан. Шул вакыт эчендә, өч мәртәбә каты яраланып, госпитальләр аша үткән. Дүртенче госпитальдән соң инде фронтка эләгә алмаган. Качып киткән дә булыр иде, сугыш бетеп куйган. Ватан сугышыннан бик нык ватылып чыккан кеше ул. Хатыны Җамал апа безнең Эстәрлебашныкы. Ике баласын алып, «өченчегә бәбиләргә» дип, Эстәрлегә әнисенә кайтып киткән чагы иде. Зәйни абый ялгызы гына яшәп, укытып, колхозда парторг булып та эшләп йөри. Ул яшәгән кечкенә агач өйгә мин җомга көннәрендә аның янына шахмат уйнарга керәм. Шимбә көнне Эстәрлегә кайтып китәм. Шахмат уйныйбыз, арзанлы гына кызыл аракы эчкәлибез. Зәйни абыйның сул кулы каты җәрәхәттән соң бөтенләй йөрми диярлек. Кирәк чагында ул аны уң кулы белән күчереп куя. Андый чакларында авызын ера да: «Йөрмәсә дә кул исәпләнә әле ул»,—ди. Аяклары, күкрәге һәм башында сугышларда алган немец ярчыклары—осколоклар байтак. Безгә барометр кирәкми. Буран, янгыр буласын абый 3-4 көн алдан әйтеп куя. Башы, аяклары сызлый башлый аның.

Һәр җомга көнне мин абый янына аулак өйгә керәм. Ул примусын сынар кулы белән көйләп кабыза да анарга зур таба куя. Мин бәрәнге әрчим. Абый исән уң кулы белән бүлмә уртасындагы идән тактасын божрасыннан тотып ача да, базга төшмичә генә аның эченә тыгыла.

---

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН *(1933)—язучы, галим, техник фәннәр докторы . «Полковникны озату», «Ник ямансу бу күзләр?», «Агыйделнең аръягында...» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Анда, баз уртасында зур мичкә белән тозлы кәбестә утыра. Кулын мичкә эченә батыра да, идәндәге табакка сулары агып торган тозлы кәбестә сала. Табак эче бер салуда туп-тулы була. Тозлаган кәбестә белән тәмле-тәмле примуста кыздырылган итле бәрәңге ашыйбыз. Аннан соң ярты төн узганчы шахмат уйныйбыз.

Тышта шулай март бураннары котырган бер кичне Зәйни абый йортында без өчәү булдык. Куганакбашка комсомол эшләре белән райкомсомолның беренче секретаре Минлебай Фәйзуллин килгән. Ул 1925 елгы. Сугышта сержант-артиллерист булып катнашкан. Зәйни абый белән азрак туганлыклары да бар, дуслар да. Эстәрледә урамча кушаматы «Бишпот Минебай.» Ул мине «кодаларга» килгән. Сүзенен тәмен белеп, кабаланмый гына сөйли:

—Бик жалкы, абыен Гариф кайта алмады сугыштан. Илләмә дә яхшы комсомол вожагы иде ул. Ике көн элек кенә бюро булды. Мин сине август аенда буласы конференциядә комсомол райкомынын икенче секретаре итеп сайларга тәкъдим иттем. Әтиен—кызыл партизан, абыен—сугышта һәлак булган лейтенант-артиллерист. Үзен белемле, тырыш егетсен. Вильданов абый мактый үзенне. Син риза бул. Бер елдан мин китәм по возрасту. Син беренче секретарь булырсын дип уйлыйбыз...

Зәйни абый стаканнарга кызыл аракы сала да, өсти:

—Синен тәкъдимен бик әйбәт, Минлебай! Зәки ул бик шәп математик. Физиканы да, тарихны да су кебек эчә. Русчасы да әйбәт. Укырга китәргә, белемен үстерергә кирәк аңарга. Райкомсомолдан укырга керүе дә ансатрак булыр дип уйлыйм...

Минлебай абый, салган эчемлекне сөзеп кенә эчә дә, җөпли:

—Уйлашыгыз! Мондый тәкъдим теләсә кемгә ясалмый. Район өчен Зәкинен киләчәк перспективасы зур булырга охшаган. Минем кул арты жинел—китәр үсеп...

Икенче көнне Минлебай абый Эстәрлегә кайтып китте. Дәресләр бетүгә Зәйни абый мина йомыш куша:

—Бар, Зәки, ике кызылны ал әле! Бүген кич икәү генә утырыйк әле сөйләшеп.

Бер шешәне бушаткач, ул мина киңәш бирә:

—Син, туганым, мине яхшы итеп тынла әле. Институтка керерсен син. Белемен шәп. Кергәч, сина кем ярдәм итәр? Ничек укырсын? Әтиен-әнием картлар бит. Колхоз түләми—сине укыта алмаслар. Апаннын үз гаиләсе, үз тормышы, кече абыен Мансур армиядә. Укуын тугызда ук ташлады, укуга теләге бик чамалы иде анын. Син бары тик үзенә генә ышанып көн күрергә тиешсен. Барырсын райком комсомолга икенче секретарь булып. Биш-алты елдан яшен чыгар. Китәрсен аннан. Ә кая? Минлебай әнә бүген уйлана инде, кая һәм нинди эшкә китәргә иде дип. Белеме сай—тугыз класс барлыгы. Синен математик сәләтен зурдан. Комсомол работнигы булам дип, син ул сәләтне югалтып ташлама. Минлебайнын тәкъдименә риза булма, барма райкомга...

—Ә нәрсә эшләргә соң? Хәзерге заман өчен ун сыйныф әлләни зур белем түгел бит инде.

—Мин дә шуны сөйлим бит сина. Быел сина унтугыз яшь тула. Шулай бит?

—Әйе! Июль аенда.

—Син Зәки хәрби училищега, офицерлыкка укырга кит. Авиациягә, йәисә артиллериягә. Икесендә дә математиканы белү кирәк. Физиканы да. Башын шәп эшли, тырышлыгын да житәрлек. Син анда укып кеше булырсын. Ул яктан минем шигем юк. Курсантларны яхшы киендерәләр, әйбәт ашаталар. Укыганда да, хезмәт иткәндә дә һәммәсе хөкүмәт исәбенә. Ашарга каян юнәтим дип кайгырып яшәгән ач студент булмыйсын инде анда. Менә дигән курсант буласын да китәсен...

—Ай-һай, Зәйни абый! Егерме биш ел читтә йөреп хезмәт итәргә кирәк булачак бит!

—Булса соң? За то—офицер! Аннан бит әле бөтен илне күреп чыгасың хезмәт иткән чакта...

Шулай итеп, 1952 елның август аенда мин Иркутск авиация хәрби училищесының курсанты булдым да куйдым...

Зәйни абый белән дуслыгыбыз гомерлеккә китте. Мин авылга ялга кайткан чакларда аны күрмичә калмый идем. Куганакбаштан соң, ул утыз елдан артык Бакый исемле авылда мәктәп директоры булып эшләде. Читтән торып укып, югары белем алды. Хатыны Җамал апа белән бер малай, өч кыз үстерделәр. Минем армияда ирешкән уңышларга бик тә шатланып, үз уңышлары кебек итеп кабул итә торган иде. Армия хәлләрен төпченеп сораша иде ул. Сагына торган иде сугышта узган яшьлек елларын. Сугыш кырларында туган төп фикере: «Ничек кенә тере калырга!?»

Соңгы мәртәбә 1998 елның җәендә Бакый авылында, Зәйни абыйның йортында очраштык. Абый нык йончыган иде:

—Бирешәм, Зәки. Баштагы осколоклар бик нык җәфалый башлады. Үтерепләр сызлый инде баш. Озакламам, ахрысы. Рәхмәт сиңа, онытмыйсың мине, кайткан саен киләсең. Бик шәп язучы булдың. Бирелеп укыйм синең әсәрләреңне. Иң шәбе «Ат каралары»дыр дип уйлыйм.

Менә Ягъфәр Байморатов турында да, минем турыда да язар идең. Тотынсаң, булдырасың инде син аны. Белсен иде кешеләр сугышта без күргән җәфа-михнәтләрне...

Зәйни абый исән чакта язып булмады. Хәзер ул юк инде. 1999 елның язында 79 яшендә вафат булды...

Бу повесть Зәйнулла Гыйззәтулла улы Вильданов һәм аның дусты Ягъфәр Динислам улы Байморатов истәлегенә багышлап, алар турында язылды. Урыннары оҗмахта булсын. Амин!

* * *

**1940** елның октябрь урталары иде. Уфа вокзалыннан кичен Мәскәү ягына кузгалган хәрби эшелонның «телячий» вагоннарының берсендә, ап-ак такталардан ясалган сәндерәләрдә күрше булып япь-яшь ике егет ята. Берсе—Эстәрлебаш районының Куганакбаш авылы егете Зәйнулла Вильданов. Икенчесе, Куганак елгасыннан су агымы белән өч чакрымнар югарырак урнашкан башкорт авылы Йомагуҗадан Ягъфәр Байморатов дигән башкорт иде. Алар инде алты елдан артык дуслар. Башта бишенчеҗиденче сыйныфларны бергәләп Куганакбаш җидееллык мәктәбендә укыдылар. Аннан соң, ике ел элек кенә урта мәктәп ителгән Эстәрлебаш мәктәбенә килеп укырга керделәр. Сигезенче сыйныфка.

Уку елы башланып, атна тирәсеме үтүгә алар янына унынчыда укып йөргән Зәйнуллин Гариф белән Шәмсиева Сылу килеп керде. Апак күлмәк, кара чалбар, ялтыратып шомартылган кара ботинкалар кигән Гариф бик ыспай һәм чибәр егет иде. Артка каратып таралган, дулкынланып торган кара чәч, коңгырт күзле, кыйгач кашлы, алсу көләч йөзле, таза, көчле гәүдәле егет иде Гариф. Акыллылыгы, затлылыгы йөзеннән үк күренеп торадыр иде. Сөйләгән сүзләре төпле, нигезле. Аның янындагы сөлектәй зифа буйлы, азрак кара тут йөзле Сылу да бик чибәр кыз. Икесе дә азрак дулкынлана.

Сүзне Гариф башлады:

—Безнең мәктәптә иң беренчеләрдән булып комсомол оешмасы барлыкка килде. Ул безнең авыл өчен дә беренче. Мин шул оешманың секретаре булам инде. Сылу—менә бу чибәр кыз, минем урынбасарым. Ә сез инде безнең мәктәпкә сигезенче сыйныфка укырга килдегез. Бүген сезнең сыйныфта да комсомол оешмасы булдырырбыз. Безнең киләчәгебез—якты коммунизм. Кешене кешегә эшләтеп эксплуатацияләүне без бетерербез. Эстәрлебаш мәктәбе укучылары да комсомол эшләрендә катнашып, коммунизмның якты киләчәген төзүдә актив катнашырга тиешләр. Мәктәпне тәмамларсыз, урта белемегез булыр...

Егет елмайды:

—Анысы инде бездән соң булачак. Мәктәпне тәмамлагач, техникумнарга, институтларга укырга керерсез. Зур белем алырсыз. Укытучылар, төрле урыннарда эшли торган кешеләр булырсыз. Бәлки араларыгыздан летчиклар, инженерлар, командирлар да чыгар әле. Һәм шулай булачак та...

Көләч йөзен балкытып тагын елмайды ул:

—Без Сылу белән сезнең сыйныфта азрак оештыру эше уздырдык инде. Кичә, өч кешедән торган комсомол ячейкасы төзедек. Сезнең сыйныфның беренче комсомоллары: Байморатов Ягъфәр, Вильданов Зәйнулла һәм Ибәтуллин Гәбделхәй. Басыгыз, егетләр!

Өч егет тә торып басты. Икесе озын гына, берсе урта буйлы. Өчесе дә чандыр, ябыклар.

—Утырыгыз! Ягъфәр, син утырмый тор. Киңәшкәч, без мондый карарга килдек: сезнең комсомол ячейкасының секретаре итеп Байморатов Ягъфәр Динислам улын тәкъдим итәргә...

Тавыш-тынсыз гына игътибар белән тыңлап утырган укучыларга карап, Гариф сүзен дәвам итте:

—Бүгенге көннәрдә яшьләр ничек җырлый әле:

Ачыла да ябыла,
Клуб тәрәзәләре.
Язылыгыз комсомолга,
Зур бит дәрәҗәләре,—дипме?

Дәрәҗәсе, чыннан да, зур комсомолның. Шуның өчен комсомол булган кеше яхшы укырга, актив булырга, пөхтә киенеп йөрергә, тәртипле булырга тиеш. Язылыгыз комсомолга! Укыгыз яхшы итеп, белем алыгыз. Алдагы елларда сезне актив, бик кызыклы тормыш көтә...

1938 елның җәендә Эстәрлебаш урта мәктәбе унынчы сыйныфының беренче чыгарылышы булды. Гариф белән Сылу да бар иделәр мәктәпне тәмамлаганнар арасында...

Ягъфәр Байморатов Эстәрлебаш мәктәбенең комсомол оешмасы секретаре итеп сайланды...

Ягъфәр Байморатов кебек егетләр турында, килмәгән җире юк, диләр. Урта, чандыр гәүдәле иде Ягъфәр. Җырчы, гармунчы, сабан туйларында йөгереш ярышларында иң алдан килә торган егет иде ул. Аның әтисе Динислам—тирә-якларда дан тоткан оста тимерче. Әтисеннән өйрәнгән Ягъфәр дә тимер эшен бик шәп белә. Атлауларына, сөйләшүләренә кадәр сөйкемле аның. Шулар өстенә укуга бик тә хирыс, сәләтле булды. Дәресләрен өстән-өстән генә караган кебек булса да, һәрчак тик «отлично» һәм «яхшы» билгеләренә генә укып барды. Ә инде тальян гармунын күтәреп сәхнәгә килеп чыкса, зал тып-тын булып кала, могҗиза көтә... Һәм могҗиза туа да! Көчледән булмаса да, үтә дә моңлы бу башкорт баласының тавышы. Башта ул гармунда татар моннарын уйнап, үзе кушылып җырлый. Берничә көй уйнаганнан соң, залга карап елмая да, тальян гармунын янында торган урындыкка куя. Гармунсыз-нисез генә башкорт моңнарына күчә. Залда «Җирән кашка», «Ирәндек», «Йәнбикә», «Таштугай» җырлары яңгырый. Аннан соң Ягъфәр сәхнә артына борылып кулын селти. Аның дусты Зәйни аңарга курай чыгарып бирә. Башкорт кураеннан гыжылдап агылган башкорт моңнары залда утырганнарның барысын да әллә нинди сихри дөньяларга алып китә. Тамашачылар дөнья нужа-михнәтләрен онытталар, искиткеч моңнар дөньясында йөзә башлыйлар. Йөзләр уйчанлана, алсулана, күзләр нур сибә, башлар ял итә. Бу мизгелдә залда утырганнар арасында бер генә булса да начар кеше бардыр дип әйтәсе килми...

* * *

1940 елны ун сыйныфны тәмамлап, кулларына таныклык алгач, Зәйнулла, Ягъфәр, Гәбделхәй күрше авылларга балалар укытырга тәгаенләнделәр. Тик озак эшли алмадылар...

Октябрь азагында Зәйни Вильдановны Кызыл Армия сафларына алдылар. Уфага алар районнан утыз кеше китте. Эстәрле военкоматына «каралырга» килгән Зәйнине ишек алдында кемдер шатланып, исеме белән дәшеп каршы алды:

—Зәйни-и! Исәнме?! Бире ки-ил!

Үзен күрмәс борын ук куанып китте Зәйни: «Ягъфәр бит бу!»

Ишек алдындагы саргайган көзге үлән өстендә авызын ерып Ягъфәр утыра иде. Кочаклашып исәнләштеләр.

—Бергә эләгергә тырышырга кирәк безгә, Зәйни. Мин монда сораштым инде. Урта белеме булганнарны ел ярым гына хезмәт итә торган командага жыярга тиешләр икән. Сорыйк—икебезне дә шунда жибәрсеннәр. Ел ярымнан командир дәрәжәсе бирәчәкләр, ди.

—Безнең егетләрдән тагын бармы?

—Юк. Августта Гәбделхәйне, Солтанны алганнар. Урта белемлеләр без икәү генә синең белән...

Командирлыкка укыта торган шул ел ярымлык командага эләктеләр. Уфада, Карл Маркс урамындагы дүрт катлы кирпеч йортта (Казарма диләр икән!) атнадан артык кандала ашатып яттылар. Шуннан соң «телячий вагонга» тыгызлап тутырып Мәскәүгә озаттылар...

Ноябрь башларында аларны Литваның Сяда исемле кечкенә шәһәрчегенә китереп житкерделәр. Килгән көнне үк мунча керттеләр, кызылармеец киемнәре бирделәр, күн итек кидерделәр. Видзянов фамилияле рота старшинасы яңа гына килгән кызылармеецләргә чолгау урау дәресләре бирде. Ул бик тә катлаулы нәрсә икән тагын үзе. Аягыңны шул чолгауга урап итек эченә тыккач, синең аягың итек эчендә «йөрергә» тиеш түгел икән. Әгәр «аяк йөрсә» ул уелып, күпертмә барлыкка килә икән дә, син инде «полноценный» кызылармеец түгел, ә аксак аягың белән «дошманнарга ярдәм итә башлыйсың» икән.

Ике-өч көн узгач беленде, старшина Видзянов үзе милләте белән мари икән дә, бик шәп иттереп татарча да сукалый икән. Тик Зәйни белән Ягъфәрне кисәтеп куйды:

—Урыслар бар жирдә тик аларча гына лакылдагыз!

Аның ул сүзләреннән нилектәндер өчесе дә елмаештылар...

Ротада 152 кызылармеец, бер старшина, өч взвод командиры һәм бер рота командиры икән. Соңгысы иң зур командир икән. Дәрәжәсе старший лейтенант, фамилиясе Гринин[1]. Төз, озын гәүдәле кеше. Кабаланмый гына, тавышын бик күтәрмичә генә сөйли. Сугыш тәжрибәсе дә бар. Японнарга каршы Халхин-Гол сугышында катнашып, Кызыл Йолдыз орденына лаек булган. Ротада һәрчак тәртип, пөхтәлек, төгәллек булганны ярата. Килгәннәренең икенче көнендә ротаны урындыкларга тезеп утыртты да, Гринин аларның ел ярым хезмәт үтеп, кем буласыларын аңлатты.

—Барыгызда да ун сыйныф белем. Бүгенге көнне мондый роталар Литвада өчәү генә. Шушы өч рота, капитализмда яшәп интеккән литвалыларга безнең илдәге белемле кешеләрне күрсәтергә тиеш. Монысы бер. Икенчедән: сез ике ел ярым урынына тик ел ярым гына хезмәт итәчәксез. Шул вакыт эчендә сез пехотадагы взвод командирына хәзерлек үтәчәксез. Винтовканы, револьверны, ике пулеметны һәм берничә төрле граната, миналарны өйрәнерсез. Атарга күнегүләр уздырырсыз. Окоп, блиндаж казуларны үтәрсез. Үзегез казып өйрәнерсез. Ел ярым үткәч, сезгә кече лейтенант дәрәжәсе биреләчәк. Теләгәннәрегез Кызыл Армия сафында командир булып калыр. Ә бүтәннәрегез кайтып китәрсез. Шул

[1]Видзянов һәм Грининнын үз фамилияләре бирелде.

ел ярым эчендә тәртип бозулар булмаска тиеш. Аракы эчү тулысынча тыела.

Увольнениега чыккан вакытларда литвалылар белән бернинди дә конфликтка кермәскә. Аларның кызлары белән аралашмаска тырышыгыз. Мондагы кешеләрнең әле күпчелегендә буржуаз карашлар бик көчле. Кайда гына булсагыз да, кем белән генә очрашсагыз да, үзегезнең хезмәтегез турында бернинди дә мәгълүмат бирмәскә...

Литвада рота нибарысы ай ярым гына булды. Яна ел алдыннан аларны «походным порядком» Ленинградка алып киттеләр.

Походка бер атна әзерләнделәр. Полк штабындагы күпне белүче писарь халкының «сер итеп кенә» әйтүләренә караганда, имеш, Гитлер үзе Сталинга ультиматум җибәргән: «Прибалтикада бик күп гаскәр туплыйсыз. Бигрәк тә Литвада. Кыскартыгыз».

Урта белемле кызылармеецлардан торган өч рота җәяүле походка әзерлек уздыра башлады. Итек-чолгаулар тагын бер мәртәбә тикшерелде. Мылтык-противогазлар аерым-аерым каралды. Төнлә унбиш чакрымлы марш-бросок ясап, аяклар, итекләр, чолгаулар сыналды...

1918-23 елларда Кремльдә большевиклар хакимиятен саклауда катнашкан 115 нче укчы дивизия тулысынча Сяда—Шяуляй—Рига—Таллин—Кингиссеп—Сланцы маршруты белән җәяүләп походка чыкты... Исәпләре—1940 елның декабрь башларында Ленинградка барып җитү иде.

Сядага килгән көнне үк Зәйни белән Ягъфәр икесе ике ротага эләкте. Бергә эләгергә тырышып батальон командирына мөрәҗәгать итеп тә караган иделәр, файдасы чыкмады. Батальон командирының «талканы коры» булды:

—Кайсы ротага билгеләгәннәр, шунда хезмәт итәсез. Тагын бер мәртәбә шушындый юк-бар сорау белән минә керсәгез, гарнизон гауптвахтасына ябып куярга боерык бирермен, анда икегез бергә булырсыз! На полную катушку—ун тәүлеккә. Армия бу! Өйрәнмәгез соранып! Кругоом марш!

Ягъфәр Байморатовны, авылдан алып килгән тальян гармунын күтәртеп, Зәйни Вильданов хезмәт иткән беренче рота алдына бастырдылар. Сяда гарнизонынннан кузгалган чакта ул «Интернационал» уйнап җибәрде. Кечкенә кала урамнарының яртысын узгач, базар янында җыйналган байтак халык арасыннан литвалылардан кемдер кәр тавыш белән яңгыратып кычкырып калды:

—Скатертью дорога, русские оккупанты-ы! Топайте быстро в свой Рязань вонючий!

Сафта атлаган кызылармеецлар кычкырган якка бердәм булып башларын бордылар. Күпләп җыелган кешеләр өстендә берничә йодрык та чайкала иде. Атлаган сафларны карап басып торган литвалыларның йөзләре тулы ачу, нәфрәт. Зәйни тетрәнеп китте: «Безне монда яратмыйлар икән бит!» Бу аның өчен ачыш иде. Чөнки Сядада булган ай ярым эчендә ул бер генә мәртәбә дә казармадан чыгып шәһәрдә йөрмәде, литвалылар белән аралашмады. Һәм мондагы жирле халыкның Кызыл Армия, СССР турында нәрсәләр уйлаганыннан хәбәрдар түгел иде...

Походның беренче көнендә егерме биш чакрым ара уздылар. Төнне бер литва мәктәбендә уздырдылар. Авыр винтовка күтәреп килгән куллар арыган, жилкәләр, билләр талган. Аяклар чынлап сызлый. Кичен Ягъфәр тальянын уйната башлаган иде, төрле яктан «ысылдап» аны туктаттылар.

—Нинди музыка тагын?! Йокларга! Йокларга!

Кем кайда түнкәлгән, шунда йокыга киттеләр. Ярый әле ашаттылар. Җылы да иде...

Ленинградка кадәр алар шулай җәяүләп ике айга якын атладылар да атладылар. Инде беренче көнне батальон алдыннан «Интернационал» уйнап барган Байморатовны да үз ротасына бастырдылар. Тальянын аякларын уйдырган кызылармеецлар янына санитар машинасына тыктылар. Әче телле берәү Ягъфәрдән көлеп тә алды:

—Байморатов, синең гармошканың да теле үелгән булып чыкты, ахрысы, аягы үелгәннәр белән бергә ята...

Кышкы юллардан атлаулары бик авыр. Ярый әле төнгелеккә куна торган урыннарын әйбәтләп хәстәрләп куялар. Матрас, одеял, мендәрләрне йөк машиналарына төяп алдан озаталар. Поход кухнялары дә тиешенчә тәмле генә пешерә. Ашау мул, туклыклы. Итне дә байтак өләшәләр...

Рига каласын узгач, дингез яры буйлап сузылган таш җәелгән юлдан бара башладылар. Инде поход шартларына күнегеп, тәүлегенә илле чакрымны да үтә иделәр. Таллинда төн кунып, тагын өч көн атлагач, Кингиссеп дигән каланы үтеп Сланцыга якынайдылар.

Бу инде Ленинград өлкәсе иде. Сланцыга керер алдыннан Ягъфәр Байморатов юлда егылды. Башта сул аягы абынган кебек булып китте. Трехлинейка винтовкасы бозланган ташлы юлга нindидер кызганыч тавыш чыгарып барып төште. Ягъфәр үзе урталай сынган кебек кинәт бөгелде дә, маңгае белән юлга төртелде. Аны иптәшләре, күтәреп алып, роталар артыннан килгән санитар машинасына кертеп салдылар. Шинелен салдырып, гимнастерка изүен чиштеләр дә, нашатырь спирты иснәттеләр. Ул авыр итеп тын ала, башкача атларлыгы калмаган иде. Ленинградка кадәр калган юлны ул машинада барды. Берәр сәгатьтән урынының да кузгалып караган иде. Тик юан, симез зур түшле маржа-санитарка аны чыгармады. Зур түшләренә кочаклап кысты да, кире урынына яткырды:

—Ят! Чыгарга ярамый сиңа! Ят! Тынычлан! Шинелең дә юк өстеңдә! Бирмим.

—Иптәшләр сафта атлаганда, ятуы оят бит!

—Ятсаң, тизрәк терелерсең! Тыныч кына ят! Йокла!

Ә Зәйни бирешергә уйламады да. Инде үзләренең отделениесендәге ике егет белән дуслашып та өлгерде. Икесе дә урыслар. Берсе—Долгушев Николай, ә икенчесе—Стародубцев Алексей.[1] Икесе дә Зәйнинең яшьтәшләре, 1920 елгылар. Долгушев Курск өлкәсеннән, ә Стародубцев Байкал күле буйларыннан, Баргузин дигән урыннан иде. Казарма һәм хәрби хезмәт авырлыкларын өчәүләшеп бергә җиңәргә өйрәнеп киләләр. Отделениеләрендә Фартушный фамилияле телгә беткән бер украин да бар. Килгән көннән үк шул хохол Зәйнидән көлә башлады. Иң ярәтканы, Зәйнине кайда гына күрсә дә, кычкырып команда бирә:

—Один татарин в две шеренги станови-ись!!!

Шунардан үзе эче катып көлә. Дүрт-биш көн эчендә Фартушныйның ул «шаянлыгы» барлык отделениены туйдырды. Бер көнне Долгушев Зәйнигә әйтте:

—Син ничек түзәсең аның шул тупаслыгына?! Сук та ек! Үзеңнең генә көчең җитмәсә, мин сиңа ярдәм итәрмен.

—Һы! Сугышкан өчен баштан сыйпамаслар бит! Казарма!

—Сук та ек! Көчең бар! Ә без күрмәбез дә, ишетмәбез дә. Сине яклап кына сүз әйтербез!

Тәвәккәлләде бер көнне Зәйни. «Дегтярев» кул пулеметына кора торган патроннарны дүрткелле тимер тартмада йөртәләр икән. Патроннары тулы чагында авырлыгы сигез кило. Патроннарын бушаткач, 400 грамм чамасы гына кала. Зәйни тартма эченнән соңгы патронын алып, пулемет дискына куеп тора иде. Каяндыр авызы колакларына кадәр ерылган Фартушный килеп чыкты. Пулемет дискы белән маташкан Вильдановны күргәч, зур авызы тагын да ныграк җәелеп китте:

—Один татарин в...

«...две шеренги» дип, тезеп өлгерә алмады «татаринны»! Зәйни бушап калган тимер тартманы уң кулы белән эләктереп алды да, шуның яссы ягы белән Фартушныйның колакчынлы бүрек кигән башына китереп тә орды. Тимер тартма «гонк» дигән кебегрәк көчле яңгыравык тавыш чыгарды. Авырттырудан бигрәк тавышы көчле килеп чыкты бу сугуның.

[1] Икесенең дә исем-фамилияләре үзгәртелмәде.

Фартушный казарма идәненә очып барып төште.

—Си-ин нәрсә?!—дип, урыныннан тора-тора, Зәйнигә акыра башлады. Вильданов аның изүеннән сул кулы белән эләктереп «торырга ярдәм итте» дә ун кулының зур йодрыгы белән ияге астына китереп тондырды. Фартушный юылган казарма идәне буйлап әллә кайларга—башта очып, аннан шуып китте. Дүртаяклап тора башлаган иде, артына Долгушев итеге белән китереп типте. Фартушный тагын очты. Торыргамы, юкмы дип, куркып яткан Фартушныйга карап Стародубцев өстәде:

—Торма, ят азрак. Ял ит! Торсаң тагын эләгер үзенә.

Фартушный кечкенә күзләрен кыскалап, йомгалап азрак ятты да, кинәт кенә сикереп торып, тышка ташланды...

Шул көннән соң Фартушный бер татарны ике шеренгага тезүдән тукталды. Тора-бара, көннәр үтә-үтә ачыкланды: үзе болай әйбәт кенә егет тә икән әле ул.

Яңа 1941 елны поход маршы белән атлап каршы алдылар. Батальон командиры боерык биргән: «Яңа елны походта каршы алырга! Исләрендә калсын гомерлеккә!» һәм шулай эшләделәр дә. Егерме яшьлек бу егетләрнең күбесенең соңгы яшәеш елы иде бу 1941 ел... Аларның күбесе киләсе яңа елны күрә алмаячак иде...

Литвадан башлап җәяү атлаган 115 нче дивизия 1941 елның 12 гыйнварында Ленинград каласына килеп керде. Санитар машинасында азрак хәл алган Ягъфәр Байморатов үз ротасы алдында Ленинград урамнары буйлап тальянында тагын «Интернационал»ны уйнатып атлый иде...

Ленинград каласында алар Беренче Майга кадәр яшәделәр. Ленинградның көньяк кырыенда урнашкан борынгы кирпеч казармалар зур, иркен иде. Беренче Май көнне Дворцовая исемле зур мәйданда хәрби парадта булдылар.

Өченче май төнендә, тревога белән торгызып, дивизияне машиналарга төяделәр дә, Ленинградны аркылыга үтеп, фин чигенә табан юнәлделәр. Сартовала дигән элекке фин каласын узгач, яңа финсовет чигеннән өч кенә чакрымда урнашкан Энцо исемле кечкенә поселокта тукталдылар. Шул Энцоның көнчыгыш кырында җәйге лагерь ясап яши башладылар...

Май башы. Куе, яшел чыршы, карагай, нарат урманы. Зур күл. Сандугачлар. Ике ай буена туктамастан атлап поход узган, дүрт айга якын сасы казарма эчләрендә яткан кызылармеецлар оҗмахка эләккәндәй булдылар. Энцо тирәсе, менә дигән ял урыны иде шул. Тыныч. Кешеләр юк диярлек. Фин халкы моннан тоташы белән китеп беткән икән.

Көн аралаш «Максим» һәм «Дегтярев» пулеметларыннан атулар башланды. Патроннарны да, мишеньнәрне дә кызганмадылар—корал күп иде. «Дегтярев» кул пулеметы бер кеше генә атар өчен җайлап ясалган. Анардан яткан хәлдә дә, басып та, йөгергәндә дә атып була. Зәйнигә иң ошаганы шул «Дегтярев» пулеметы булды. Пулемет та аның зур гәүдәсенә сыланып, килешеп тора. Башта Зәйни ул пулеметны сүтәргә һәм җыярга өйрәнде. Ун-унбиш көн үтүгә шул кадәр остарды, хәтта башын читкә борып, пулеметка карамыйча да сүтә-җыя башлады. Зәйнинең уйнап торган оста кулларына карап Долгушев тәкъдим ясады:

—Зәйни! Әйдә күзләреңне бәйлик! Ә син эшлә!

Сөлге белән Вильдановның күзләрен бәйләделәр. Могҗиза карарга барлык взвод җыйналды. Зур өстәл өсте буп-буш. Пулеметтан башка бернәрсә дә юк. Эчке күлмәгенең җиңен сызганган, күзләре сөлге белән бәйләнгән Вильдановны өстәл янына бастырдылар. Ул чалбар каешы янындагы «пистонка» дип йөртелгән ике бармак кына сыярлык кесәчектән «Киров» сәгатен чыгарды да, Долгушевка тоттырды:

—Вакытны карап бар!

Өстәлне уратып баскан кызылармеецлар тынып калды. Зәйнинең кәрәктәй зур куллары пулеметка ябышты. Ул нәрсәгәдер баса, тарта, этә, пулеметның нәрсәләрендер бора башлады. Пулемет күзгә күренеп, үзеннән-үзе сүтелгән кебек, тарала да тарала. Пулеметтан аерып алынган,

яисә өстәлгә төшкән детальләрне Зәйни үзе генә белгән тәртип белән өстәлгә тезә бара...

—Ике минут та унике секунд!—дип тантаналы игълан итте Долгушев, пулемет сүтелеп беткәч. Ике кашы арасында бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан Вильданов тавыш-тынсыз гына өстәлдәге пулемет детальләрен куллары белән капшап, барлап чыкты. Азрак уйланып торган кебек булды да, иптәшенә дәште:

—Николай! Янадан җыйный башлыйм!

Тын казарма эчендә пулемет җыйганда ишетелгән, шыкылдаган-чыкылдаган тавыштан башка бер тавыш та юк иде. Пулемет детальләре Зәйнинең кулларында җанлы кебек тыңлаучаннар. Күзләре бәйләнгән хәлдә пулеметны сүтеп-җыючыны ротада беренче мәртәбә күрәләр иде...

Пулемет җыелып бетте. Зәйни затворын артка тартты да, курокка басты. Затвор шапылдап алга китереп сукты.

—Өч минут та биш секунд!—дип хәбәр итте Долгушев. Һәм шатланып өстәде:

—Кем шул рәвешле сүтеп-җыюда азрак вакыт күрсәтергә тели? Рәхим итегез!

Барысы да кутәрелеп көлделәр. Тик ротада «телгә беткән» исеме чыккан чуаш Никонов кына әйтеп куйды:

—Ачык күз белән карап торып та мин болай тиз җыя алмыйм. Татар гына булдыра ала моны...

Тагын көлделәр. Чуаш өстәп куйды:

—Әйдәгез, тәмәке тартырга чыгыйк. Менә мин анда татарны узам да узам инде! Һичшиксез! Әйе!

Май азакларында, июнь башларында Энцо тирәсендә ниндидер киеренкелек сизелә башлады. Фин милләтеннән булганнарның барысын да 1940 елны, теләсәләр теләмәсәләр дә, Финляндиягә озатып бетергәннәр. Бушап калган йортларга Петрозаводск, Олонец, Лодейное Поле якларыннан урысларны, карелларны китереп тутырганнар. Яңа күчеп килгәннәр арасыннан фин телен белгән кареллар төннәрен юкка чыгалар икән. Барлы-юклы йорт җиһазларын төяп, кайсысы йөк машинасы, кайсысы ат, бер дә булмаса, кул арбасы белән элекке яшәгән якларына качалар икән. Берничә гаиләне НКВД хезмәткәрләре юлда тотып кире кайтара алганнар. «Нигә тормыйсыз монда, кире китәсез?»—дигән сорауга җаваплары кыска булган:

—Безнең ата-бабалар җире түгел. Финнарныкы. Кеше җирендә яшәү гөнаһ. Бәрәкәтле булмый!

Торып калганнар арасында шомлы сүзләр йөри башлады: җәйгә сугыш башлана! Шуна күрә кача моннан кареллар!

Комиссар-политруклар политинформация уздырган чакларда карелларның качуын кызылармеецларга болай аңлаттылар:

—Германия белән безнең араны бозу өчен эшләнә бу гамәлләр. Дошман агитациясе бу. Франция белән Англиянеке. Немецлар безнең яхшы союзниклар алар. Дуслар!

Кызылармеецларның күңелләрендә барыбер шомлы тынгысызлык уяна башлады. Комиссарлар берне сөйләсәләр дә, тормыш икенче иде!

15 июнь төнендә полкта тревога булды. Энцо местечкосын уратып алга узып, куе урман эчендә, фин чигеннән километр ярым гына урында өч сәгать яттылар. Боерык кыска иде: «Тавыш чыгармаска! Ятар өчен сай окоп казырга! Тәмәке тартмаска!»

Йомшак комда сапер көрәге белән сай окоп казуы бары ун минут чамасына сузылды. Брустверын, кырларын яшел мүк белән каплап, маскировка ясадылар. Төреп бәйләнгән шинельләрен, ягъни шинель скаткаларын Долгушев тәкъдиме белән чишеп аларны окоп төбенә җәйделәр дә... йокларга яттылар. Әллә кайдан агачлар арасыннан старшина Видзянов күренде. Гаҗәпләнгән тавыш белән сорады:

—Скаткаларны чишеп окоп төбенә җәяргә кем рөхсәт итте?

Егетләр аякларына бастылар.

—Взвод командиры!—диде Долгушев, күзен дә йоммыйча.—Без, старшина бар бит әле, дип әйтеп караган идек. Ә ул әйтә, старшина югарыракмы, минме, ди?

Старшина фуражкасын козырегыннан тотып алгарак тартты да, авыз эченнән генә нәрсәдер әйтеп китеп барды.

Окоп эченә кереп яттылар.

—Ну, Коля!—дип көлде Стародубцев.—Үз үлемең белән үлмәссен син! Старшина бетерер сине! Инде взвод командиры әйтмәгәнне дә белеп алса?!

—Ну-у!—дип сузды Долгушев.—Чираттан тыш наряд бирсә—монда казарма идәне дә, туалеты да юк юарга, тазартырга. Утырта, дисенме? Тревога барганда гауптвахтага утыртмыйлар. Зур җинаять ясасаң гына утырталар. Скатка чишү җинаятькә керми ул. Ә аннан соң безнең взвод командиры медсанбатка медсестра янына китте...

—Кайсысы янына? Анда алар өчәү бит!

—Иң юаны бар бит—Дарья. Шуның янына инде. Бер-ике сәгатьсез кайтмый ул. Ә аңарчы старшина скатка турында онытачак. Чөнки аның башка эшләре дә муеныннан. Тәккә аны рота старшинасы димиләр бит инде!..

Көлештеләр. Рәхәт иде уйсыз-нисез окоп эчендә, скатка өстендә зәңгәр күккә карап ятулары...

Кичке аштан соң аларны палаткалар алдындагы үләнле мәйданга полк комиссары җыйды. Ярты сәгатьлек чыгышында халыкара хәлләргә ныклап тукталды. Гитлер җир йөзендә бик зур көчкә ия булды, диде. Иң соңыннан чыгышын тәмамлаганда әйтте:

—Хәзер өстәмә сораулар бирмәвегезне үтенәм. Һәркайсыгыз үзен әзер тотсын, шушы көннәрдә безгә сугышырга туры килер дип уйлыйм. Бу өстәгеләрдән әйтелгән сүз түгел, шәхсән минем үземнең генә уем. Мин гражданнар сугышын күргән кеше. Финнар белән дә сугыштым. Шушы җәйдә сугыш булачак. Бик каты итеп, үз-үзегезне аямыйча, ил өчен, халкыбызның иреге өчен сугышырга туры киләчәк. Бетте! Таралыгыз!

Комиссарның сөйләгәне күпчелек кызылармеецлар өчен көтелмәгән яңалык булды. Һәрберсе дәшми генә үз алдына уйлана иде. Йокларга ятканда тик Стародубцев кына үзалдына сөйләгәндәй нәтиҗә ясап куйды:

—Нинди сугыш ди тагын?! Булмый сугыш! ТАСС провокацияләргә бирешмәскә кушып белдерү ясады. Германия безнең союзник. Ә финнар инде тотынмаячаклар. Алдылар бездән кирәкләрен!..

Аңарга каршы сүз әйтүче дә, аның сүзләрен хуплаучы да табылмады. Сүзсез генә йокларга яттылар. Комиссарның сөйләгәннәре барысының да башына ныклап кереп утырган иде...

21 июнь кичендә Зәйни Вильданов каравылдан кайтты. Полк байрагы янында беренче постта торган иде. Трехлинейка винтовкасын тазартып майлады да, пирамидага куеп, кичке ашка әзерләнде. Аннан соң кино карадылар да йокларга яттылар.

Иртәгә якшәмбе иде. 22 июнь, 1941 ел...

Батальон быргысының «тревога» уйнаганына Вильданов сискәнеп уянып китте. Чалбарына үрелде. Тирә ягында ыгы-зыгы килеп иптәшләре кабаланып киенәләр иде. Башы аша гимнастеркасын киде дә, җиннәрен эзли-эзли пирамидага йөгерде. Берничә минут үтүгә, рота йөгерә-йөгерә Энцо местечкосының көнбатыш ягына ашыга иде инде. Хәлләре-тыннары бетеп барып җитеп, оборонага дип казылган окопларга кереп тулдылар. Бу окоплар бик җентекләп, тирән итеп казылганнар иде. Күп урында диварлары такта белән, яисә читән үреп ныгытылганнар. Өсләре берничә кат юан бүрәнәләр белән капланган байтак кына блиндажлар да бар. Пулеметларга «оялар» төзелгән. Алда 100 метр арала башлары төрле төсләргә буяулы таяклар утыртылган. Алары инде аткан чакта прицел планкасын дөрес итеп куяр өчен.

25 июньгә кадәр фин чигенең теге ягында шылт иткән дә тавыш ишетелмәде. Бер генә фин солдаты да күренмәде. Чик буйлап йөри торган пограничниклары да юкка чыктылар. «Күзәтүче» кызылармеецлар хәбәр итеп тора: аркаларына кара букчалар таккан овчарка этләр бер сәгать саен чик буена салынган сукмактан чабып каядыр ашыгалар икән. Болар инде хәрби боерыклар ташый торган элемтә этләре иде. Финнарның радиолары 25 июньгә кадәр тукталды.

24 июнь кичендә өч дус дозорга билгеләнде—Вильданов, Долгушев һәм Стародубцев. Тирән итеп казылган, эче читән үреп ныгытылган иркен, биш кешегә исәпләнгән окопта өчәү урнаштылар. Брустверга бик юаннан булмаган, юынган бүрәнәләрдән ясалган «пулемет оясына Зәйни «Дегтярев-ДС» пулеметын бик тырышып урнаштырды. Пулемет урнашкан бруствер астына казылып, такта түшәлгән урынга патроннар белән тутырылган дүрт дискны куйды. Өсләрен солдат плащ-палаткасы белән каплады. Ком коелмасын! Дисклар өстенә пулемет өчен ике запас көпшә урнаштырды. «Дегтярев» пулеметының көпшәсе «Максим»ныкы кебек су белән суытылмый. Шунлыктан, аткан чакта бик нык кыза һәм еракка атуы начарая. Чөнки кызган көпшәнең пулялар чыга торган канал тишеге зурая. Туры ату да кими. Пулеметтан чыккан пулялар читкә сибелә башлый. Шуңа күрә кызган көпшәне тиз генә борып алып, аның урынына икенчесен, кызмаганын куярга кирәк була. Алып ташланганын, мөмкинлек булса, суга тыгып суыталар.

25 июнь таңы атып килгәндә йокламый күзәтчелек иткән Стародубцевның пышылдаганы ишетелде:

—Егетләр! Финнар килә!

Зәйни белән Николай сикерешеп тордылар да, бруствер аша карадылар. Сыек кына итеп җәелеп килгән таң яктысында, томан эченнән фин солдатлары атлыйлар иде. Кара карачкылар булып, ак томаннан бик күп булып килә иде алар.

—Пограничникларны пычаклар белән алганнар болар!—диде акрын гына Долгушев.—Атканнары ишетелмәде бит.

Дозорга старший итеп билгеләнгән Стародубцевка төртте ул:

—Нәрсә эшлибез инде хәзер, Алексей?!

—Ничек инде, нәрсә эшлибез?! Атабыз, сугыш башлыйбыз. Егерме биш метрга җибәрик без аларны. Зәйни, син пулеметта!

—Есть, пулеметта!

—Мин офицерларын алам!—диде Долгушев. Ул винтовкадан ата иде.

—Ничек атлыйлар—парадта киләләрме!

Стародубцевның «Пли!» дигәненә буйсынып, бер пулемет, ике винтовка ут ачтылар. Финнар өчен көтелмәгән хәл булып чыкты бу. Ин алдан килгән алты фин солдатын Зәйни пулемет уты белән кисеп ташлады. Утны икенче тезмәгә күчергәндә, тегеләр ята башлаганнар иде инде.

—Гранаталар!—дип боерды Стародубцев.

Яткан финнар өстенә гранаталар очты.

Мондый кискен каршылыкны көтмәгән финнар сикерешеп тордылар да, азрак иелә биреп, килгән якларына йөгерә башладылар. Пулемет бер туктаусыз «такылдап», качкан финнарга пулялар яудырды. Тегеләрнең берничәсе егылып калды.

—Чигенәбез! Әйдәгез рота окопларына! Үзебезнең иптәшләр янына!

Окоптан чыгып, куакларга кадәр шуышып бардылар да, аннан соң торып йөгерделәр. Аларга атучы һәм эзәрлекләүче булмады. Окоптагы иптәшләре аларны шатланып каршы алдылар. Зәйни патронлы дисклар тутырылган солдат капчыгын окоп төбенә куйды, пулеметын окоп диварына сөяде. Мангаеннан аккан тирен зур учы белән сыпырып төшерде дә, кыска гына итеп көлде:

—Ну бирдек ак финнарга!

Әле фин солдатларын күрмәгән окоптагылар инде сугышып та

өлгергән иптәшләренә батырлар итеп сокланып карыйлар иде. Окоп буйлап команда килеп житте:

—Кызылармеец Стародубцев, рота командирына-а!

Рота командиры ничек сугышканнарын жентекләп сорашты. Сөйләп бетергәч, Стародубцев командирга үз уен әйтте:

—Финнар дәрт белән сугышмыйлар һәм ут астына керергә атлыгып тормыйлар...

Икенче көнне рота позициясен өч самолет утка һәм бомбага тотты. Самолетларның канатларына тәре, ә коерыкларына фашист свастикасы төшерелгән иде. «Фашистла-ар!»—дип сөрән салдылар окоплардан. Һәм кем нәрсә белән булдыра ала, шунын белән ата башладылар. Тик винтовкадан, «Дегтярев» пулеметыннан гына атып самолетларга бер зыян да китерә алмадылар. Ә немец самолетлары ажгырып улап, окопларга пике ясап, берсе артыннан берсе һөҗүм иттеләр. Һавада безнен самолетлар бөтенләй юк иделәр...

Энцо өчен сугышлар ике көн барды. Финнар артиллереяләрен китереп утыртып, кызылармеецлар яшәгән казармаларга, алар качып яткан окопларга һәм боеприпаслар урнашкан лагерь складларына аттылар. Бигрәк тә йөдәткәне күпсанлы миноментлары булды. Миномент шундый корал икән ул—илле метрга да ата ала. Зур коерыклы минасы окоп эченә һавадан текә итеп улап килеп төшә. «Каз бәпкәсен эләктерергә төшкән тилгән кебек икән боларнын минасы!»—дип уйлады Зәйни, окопнын читән диварына сыена-сыена. Жир тишеге булса кереп китәр иде! Юк бит!

28 июньдә финнар окопларга алты танк жибәрделәр. Каршы атарга бер генә пушка да юк иде. Танклар артыннан, шуларга ышыкланып немец автоматлары белән коралланган фин солдатлары атлый. Автоматларын корсакларына терәгәннәр дә бертуктаусыз пулялар янгыры яудыралар. Үзләре урысчалап акыралар:

—Рус Иван, здравствуй! Отдай финскую землю обратно! Иди домой!

Кичкә табан чигенергә боерык булды. Ике аягы да чарпаланган рота командирын плащ-палаткага салып күтәргән дүрт кызылармеец ин беренчеләр булып күл ягына йөгерә-атлый китеп барды. Алар артыннан каты жәрәхәтлеләрне ташый башладылар. Аннан сон инде, төн карангылыгыннан файдаланып, ротанын тере калган кызылармеецлары чигенде. Үлгәннәр окоп төпләрендә аунап ятып калдылар. Чигенгәннәрдә үлеләр кайгысы юк иде инде. Чигенгән рота калдыгы үзенен һәлакәтенә каршы бара иде...

Икенче көнне финнар, танклар ярдәмендә өч яктан кысрыклап, ротаны күл суына терәп камап алдылар. Баштагы ике көнне финнар һөҗүмгә күтәрелмәде. Авиация һәм артиллерия кулланып, рота урнашкан урынны аркылыга-буйга бомбалар, снарядлар, миналар белән «сөреп» чыктылар. Шунын өстенә финнарнын снайперлары да бик күп икән. Алар бик төз атып, ин беренчеләрдән командирларны чүпләделәр. Рота белән командалык итәргә, старшина Видзяновка торып калды. Ул тәжрибәле һәм акыллы кеше—гимнастеркасынын петлицасын кисеп ыргыткан. Кем икәне беленми дә. Яна командирнын беренче боерыгы яртылаш жимерелеп беткән окоплар буенча пышылдап кына тапшырылды.

—Гимнастерка петлицаларын кисеп ташларга!

Бу боерык барысына да кагыла иде. Гимнастерка якаларын кискәләп ыргыттылар. Инде фин снайперлары өчен кем сержант, кем кызылармеец кына икәнне аерып алу мөмкин түгел иде. Шунлыктан алар, кем күренеп кала, шуларны чүпли башладылар.

Тылдан, күл аша ярдәм килмәде. Элемтә дә юк иде. Ашау дигән нәрсә онытылды. Рота командирын һәм каты жәрәхәтлеләрне саллар белән күл аша озатканнан сон, ротанын калдыгы тагын өч көн сугышты...

Ротада алты кул пулеметы һәм өч станковый «Максим» пулеметы бар иде. Инде ротанын калган өлешен юк итү исәбе белән янадан

атакага ташланган финнарны шул пулеметлар уты белән шактый күп кырдылар. Ике тәүлек үткәч, берсе ак флаг тоткан ике фин күренде. Флаг тотканы аны һавада селки-селки кычкырырга тотынды:

—Ике кеше сөйләшергә чыгыгыз!

Старшина Видзянов якындагы Стародубцев белән Долгушевны җибәрде. Вильдановка боерык бирде:

—Икесен дә прицелга утырт!

—Ераграк бит! Алып булмас!

—Шулаймы?

—Әйе.

Видзянов окоптан калка биреп кычкырды:

—Якынрак килегез! Курыкмагыз, атмабыз!

Финнар артларына борылып нәрсәдер әйттеләр. Рөхсәт сорадылар, ахрысы. Окопларга якынлаша башладылар. Стародубцев белән Долгушев өсләреннән тузаннарын каккалап, винтовкаларын окопта калдырып финнарга каршы атладылар...

Финнар икесе дә аксыл чәчле, зәңгәр күзле, гәүдәгә бик таза егетләр иде. Флаг тотканы урысчалап сүз башлады:

—Һәлак булган иптәшләребезне җыеп алырга мөмкинлек бирүегезне сорыйбыз. Җирләргә кирәк, исләнәләр бит...

Елмайгандай итте:

—Без кабаланмыйча гына җыярбыз. Без дә, бигрәк тә сез дә, сугышны туктатып, аз гына булса да тын алырбыз...

Фин туктагач, Долгушев окоплар ягына китте. Карарны старшина кабул итәргә тиеш иде. Стародубцев Долгушевка әйтте:

—Йөгермә! Атып куюлары бар.

—Юк!—диде фин.—Атмаячаклар. Полк командирының боерыгы, нәрсә генә килеп чыкса да, атмаска.

Долгушев китте. Финнар һәм Стародубцев бер-берсенә текәлеп басып калдылар. Финнар әйбәт киемнән, чырайлары тыныч һәм бер төрле дә арыганлыклары күренми иде.

Озак та үтмәде, Долгушев әйләнеп тә килде. Туктамас борын ук сорау бирде:

—Күпме вакыт кирәк сезгә?..

—Өч сәгатьтән дә ким түгел.

—Безнең полк командиры биш сәгать, диде.

«Полк командиры» дигәне старшина Видзянов иде инде.

—Шуңа риза булсагыз, ярты сәгатьтән тотыныгыз. Провокация булмас дип ышанабыз.

—Без риза. Бернинди дә провокация булмас. Без бит финнар, безнең сүз һәрчак ышанычлы була...

Финнар честь бирделәр. Стародубцев белән Долгушев кузгалгач кына борылып киттеләр...

Биш сәгать вакыт узганчы җәрәхәтлеләрнең күбесен саллар ясап күл аша озаттылар. Җиңелрәк яралыларны ишәргә куйдылар. Инде окопларда калганнарның язмышы үзләре өчен дә билгеле иде. Барысын да үлем көтә. Шуны аңласалар да, паникага бирелүчеләр табылмады. Һәлак булганнарны окопларның бер тармагына җыеп, бер-берсенә тәрәп тезеп салдылар. Өсләрен плащ-палаткалар, чыршы, нарат ботаклары белән каплап, күмеп куйдылар. Атып, салют биреп тормадылар—патроннар сугыш өчен кирәк иде...

Килешенгән буенча финнар үлек солдатларының гәүдәләрен җыйнап алдылар. Һәлак булган финнар өч зур йөк машинасы булды...

Үлгән кызылармеецларны күмеп, яралыларны күл аша озаткач, старшина тере калганнарга соңгы тапкыр мөрәҗәгать итте:

—Кадерлеләрем минем! Без инде соңгы бәрелешкә тотынабыз...

Күбесе җәрәхәтле иптәшләрен күздән кичереп чыкты:

—...Патроннар, гранаталар бетеп бара. Безгә ярдәм булмаячак. Күлнең

теге ягында да эшләр бик шәптән түгелдер. Андагы канонаданы үзегез дә ишетеп торасыз. Без чолганышта һәм котылу юлы юк. Тагын бер тәүлеккә сузсак ярый инде. Безнең үлем шушы күл буенда. Мин санарга тырыштым: финнар 97 солдатларын тәяп алып киттеләр. Ә без сугыша башлаганда 155 сугышчы идек. Тагын житмешләп финны юк итәсе бар. Шуны булдырыр өчен, тагын да ныграк сугышырга, бер-берегезгә булышып ярдәм итеп сугышырга кирәк булыр. Старшина булып хезмәт иткәндә, бәлки, кайберләрегезгә тиешеннән күбрәк эләккәләгәндер дә. Армия бит—миннән генә тормый. Нарядлар артыграк бирелгәннәрдән гафу үтенәм. Бу минем сезгә соңгы сүзем. Тагын атакалар башлангач сүз сөйләп торып булмас—сугышу кирәк булачак...

Тагын бер мәртәбә карап чыкты барысын да:

—Кем ничек булдыра ала, котелокларда чәй кайнатыгыз. Ашаган юк бит. Ә чәй бар. Һичьюгы чәй эчик үлемебез алдыннан...

Ротадан калган халык тагын тәүлек ярым сугышты. Финнар жибәргән өч танкны, окопларны тигезләп таптап йөргән чакларында, сыеклык тутырган шешәләр белән яндырдылар. Шул танкларны юк иткән чакта старшина Видзянов һәлак булды. Шешәсен ыргытып өлгерде өлгерүен. Тик яна башлаган танк аны гусеницасы астына тыгып сытты. Окопларга бәреп кергән фин солдатлары патроннары беткән кызылармеецларны автомат уты белән кыра башладылар. Тик берничә жирдә генә кыска-кыска кул сугышы булып алды. Сүгенү, акыру тавышлары тына башлады. Зәйни, Долгушев, Стародубцев—өч дус, сүз берләшеп тормыйча, окоптан сикерешеп чыктылар да, иннәрен бер-берсенә терәп, штыкларын алга сузып, финнарга каршы үзләре ташландылар. Тик финнар да сугыша беләләр икән. Аларны кыры тешле штыклы өч фин солдаты каршы алды. Егетләрнең штык һөжүмен кире кага-кага, чигенә башладылар. Сугышып күзләрен кан баскан өч кызылармеецны финнар бик тиз уратып алдылар да, кулларындагы винтовкаларын сугып та төшерделәр. Прикладлар белән бәргәләп, аякларыннан да тәгәрәттеләр. Винтовкаларын читкә тибеп очырдылар. Аннары тәрткәләп-типкәләп, өчесен дә аякка бастырдылар. Стародубцевның сул кулы камчы кебек асылынып төшкән—штык белән нык кына кадаганнар. Бармакларыннан кан тама. Долгушевның уң күзе тоташ шешенеп ябылган. Башына приклад белән тондырганнар. Зәйнинең башындагы каскасы яньчелеп ярылган. Аңарга да приклад белән биргәннәр, ахрысы. Ара-тирә окопларда урыс маты белән акырган, жан ачысы белән ыңгырашкан тавышлар ишетелә. Соңгы кызылармеецларны юк итү бара иде. Рота яшәвеннән туктады...

Тере калган, барысы да жәрәхәтле сигез кызылармеецны бер урынга жыйдылар. Бастырып тезеп маташканда Фартушный аяктан егылды. Торгызып азапланмадылар, автоматтан кыска гына чират бирделәр дә, гәүдәсен сөйрәп читкәрәк ыргыттылар. Басып торган жиде кызылармеецның кесәләрен актарып документларын, вак-төякләрен бушаттылар. Фин офицеры аларның таныклыкларын жентекләп карап чыкты. Аңа кызык иде, ахрысы—беренче әсирләр бит! Урысчасы ярыйсы гына иде финның:

—Батырларча сугыштыгыз! Тик, сез бит батырлыгыгызны без финнарның жирен тартып алу өчен күрсәтәсез. Сез басып торган жир урыс жире түгел, ә Финляндиянеке. Сез ике ел элек аны басып кердегез...

Әсирләр дәшмәделәр. Тик Стародубцев кына баскан урынында кузгалып куйды. Офицер аңа якын ук килде:

—Урыс солдаты әллә риза түгелме?

—Түгел. Урыс солдаты баскан жир һәрвакыт Русия жире булачак!

—Оккупация дип атала ул, урыс солдатының чит жиргә басуы!—диде фин офицеры тыныч кына.—Ок-купа-ация-а! Башка халыкның жирен басып алу һәм талау дип атала ул.

—Ну и что?!

Файдасы юкны аңлады фин, жавап биреп тормады. Кулындагы таныклыкларның берсен ачты:

—Кем була Вильданов Зәйнулла Гыйззәтулла улы? —Финның үз исемен акцентсыз әйтүенә Зәйни сискәнеп куйды. «Фин булганга шулайдыр инде!»—дип уйлады. Җавап бирде:

—Мин булам Вильданов.

—Чык сафтан!

Зәйни ике адым алга атлады да, сафка табан йөзе белән борылып басты. Фин аның каршысына килеп, күзләренә карады:

—Исән каласың киләме?

—Әлбәттә, килә! Мин бик яшь бит әле, егерме бер дә тулмаган. Тамагына төер утырган иде—көчләп йотты.

Фин күнелле итеп, мыскыллагандай елмайды:

—Яшисең килсә, мин сиңа ярыш тәкъдим итәм.

—Нинди ярыш инде ул тагын?

—Штык сугышы. Син трехлинейкаң белән, ә мин фин винтовкасы белән. Штык сугышында мине җинә алсаң, ирекккә җибәрәм.

Зәйни каушый төште. Ирексездән иптәшләренә карады. Алексей сизелерлек кенә итеп баш селкеде: «Алыш!»

—Мин риза. Тик ничек сугышабыз, беребез үлгәнчеме?

Фин көлде:

—Минем дә үләсе килми бит әле. Кулдан винтовканы сугып төшергәнче алышабыз. Ризамы?

—«Риза» дидем бит инде...

Фин үз телендә нindider команда бирде. Фин солдатлары автомат һәм винтовка затворларын тартып кордылар. Әсирләрне тörtкәләп азрак читкә күчерделәр. Офицер җирдә яткан трехлинейкага ымлады:

—Ал кулыңа! Чык миңа каршы!

Зәйни яньчелгән каскасын башыннан салып җиргә ыргытты. Кулларының баш бармакларын каешы астына тыгып, гимнастеркасының җыерчыкларын артка куды. Изүе чишелгән иде—каптырып тормады. Винтовкасына суккалап комын койды, учы белән сөрткәләп алды. Кул бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырый иде. Фин, үрелеп бер солдатның кулыннан фин винтовкасын алды. Бармагы белән басып магазинын ачты да, биш патронны алып солдатка сузды. Кыр сумкасын һәм кобурасы белән «Вальтер»ын салып, шул ук солдатка тоттырды. Кабаланмый гына уртага чыкты. Винтовканы җайлырак иттереп ике куллап тотты да Вильдановка карап кузгалды. Зәйни анарга каршы атламыйча баскан хәлендә көтеп калды. Фин килгән унайга ук туктап тормады, кискен кыска һөҗүм ясады. Зәйни финның штыгын үзенеке белән читкә тибәрде. Фин, туктап тормастан, винтовкасын тиз генә борып, прикладык белән Зәйнинең башына сугарга омтылды. Зәйни винтовка көпшәсен аркылыга куеп, приклад белән селтәнгән һөҗүмне дә каршы алып өлгерде. Фин артка сикерде. Ул штык сугышына бик оста иде, ахрысы. Вильдановның һәр адымын, һәр борылуын бик тиз тоеп-сизеп ала, аның алымнарына каршы шунда ук оста җавап кайтара. Ротада уздырган штык сугышы ярышларында Зәйни иң осталарның берсе санала иде. Малай чагыннан ук ат йөгенә, кибәннәргә көлтәләр ыргытып, көч җыеп үскән егет иде бит ул. Куллары озын, көчләләр һәм тиз хәрәкәт итә иде. Берничә мәртәбә Зәйнинең прикладык белән сукканын фин мылтыгын аркылы куеп, көчкә-көчкә генә котыла алды. Шуннан соң Зәйни өстенлек ала башлады. Фин офицерына төрле алымнар ясарга ирек бирмичә, аны түгәрәктә куып йөртә башлады. Офицерлары отыла башлагач, фин солдатлары шаулашырга тотынды. Янау тавышлары ишетелде. Офицер бер генә кычкырды—шау-шу шунда ук басылды. Инде үзенең җинеп чыгуына Зәйнинең шиге калмады. Вакытыннан алда «йомшау» харап итте дә аны. Нык ышаныч белән финны «җинәргә тотынды». Башта «Коротким коли!» алымын үткәреп, аннан соң «Длинным коли!» белән фин кулындагы тешле штыклы винтовканы читкә алып очырырга тиеш иде ул. Кабаланды. Турыдан-туры, финга якынлашып

бетмичә, «Длинным коли!» алымын үткәрмәкче булды. Гәүдәсе белән алга ыргылып, финнның винтовкасына штыгы белән селтәнде. Офицер бар көчен җыеп, җитез генә сулга сикерде һәм буш һавага селтәнеп калган Вильдановның башына арт яктан прикладлы белән китереп тә чәпәде. Сугу артык көчле булмаса да, шактый каты иде. Зәйни винтовкасын кулыннан ычкындырып, башы белән комга барып мәтәлде. Шул вакытта берничә автомат тавышы ишетелде. Стародубцев, Долгушев һәм башка кызылармеецлар ярдәм булып финнарга ташланганнар икән. Тик фин солдатлары уяу торганнар. Әсирләр ыргылу белән аларны кырып кына салдылар. Әсирләрнең икесенең җаны бар иде әле. Аларының маңгайларына терәп пуля җибәрделәр. Шул соңгы икәүнең берсе Николай Долгушев иде...

Зәйни зур авырлык белән генә аякларына баса алды. Бер фин солдаты аның кулларына су койды. Зәйни күзен, битен югандай итте, комнан арынды. Шаулашкан-көлешкән фин солдатлары уртасында япа-ялгызы басып калды. 155 кешелек ротадан шулай берүзе калган иде ул. Приклад суккан башы чыңлый, авырта. Күз алларында кара бөҗрәлар,ниндидер аллы-гөлле утлар йөзә. Офицер винтовкасын хуҗасына тоттырды да, боерык бирде. Солдатлар җыелып тезелә башладылар. Офицер кабаланмый гына кобуралы каешын буды, кыр сумкасының каешын җилкәсе аша киде. Кобурасыннан «Вальтер»ын чыгарды да, Зәйнигә күл ягына күрсәтте:

—Атла! Шунда атам мин сине!

Урыныннан авыр кузгалып, күл ярына табан атлады Зәйни. Башында курку да, берниңди уй да юк иде. Чалкан яткан Долгушев белән Стародубцев янында тукталды. Иелеп, күзләрен йомдырды, чигәләреннән сыйпады.

—Хушыгыз, дусларым!

Солдатлар сафка тезелеп Энцо ягына киттеләр. Офицер «Вальтер»ын уң кулында тоткан килеш Зәйнине алдан атлатып, тал куаклары арасыннан узган киң сукмакка алып керде. Күл суына җитәргә 10-15 метрлар чамасы кала боерык бирде:

—Тукта!

Зәйни туктады.

—Борыл миңа карап!

Борылды.

Фин «Вальтер»ын кобурасына тыкты да Зәйнигә якын ук килде.

—Йөзә беләсеңме?

—Беләм.

Үзе татарчалап җавап биргәч кенә Зәйнинең башына барып җитте: Фин: «Йөзә беләсеңме?»—дип татарча сорады бит!

—Фин татары бит мин, Вильданов! Хәкимҗан минем исемем. Татар мин. Мөселманмын...

Вильдановның сорарга да, дәшәргә дә дәрманы калмаган иде. Бу көтелмәгән хәлдән ул коелып төште. Дөм караңгылыкта еракта, бик тә еракта җемелдәгән черпи ут кебек кенә булып өмете кузгалды: «Бәлки җибәрер бу мине!?» Сукмак читендәге үләнгә чүгәләде, башын тотты. Үтереп сызлый иде приклад белән суккан башы.

—Авыр булса да, син аякларыңа бас. Теге якка йөзеп чыгарга тырыш. Монда калсаң, концлагерь инде сиңа. Аннан тере чыга алмассың. Турыга йөзсәң, ике йөз метрлар чамасы булыр. Ә инде яр буйлап йөзеп китсәң, ял итә-итә бара аласың. Күл читенә чыгып. Тик анда безнең солдатлар күп—атып үтерүләре бар. Миңа монда озакка калырга ярамый. Сине атарга алып киткән кеше бит мин. Приклад белән ныграк җибәрдем, ахрысы—гафу ит, сугыш бит, үзең беләсең...

Иелеп, Зәйнине күтәреп аякларына басарга ярдәм итте.

—Бас аякларыңа. Итегеңне, гимнастеркаларыңны сал. Менә таныклыгың. Исән калырга тырыш. Безнең генерал Маннергеймның яшерен боерыгы бар: «Фин гаскәрләре иске чикне үтмәскә тиеш. Хуш. Башкача

очрашмабыз инде без. Онытма мин татарны. Бар, төш суга. Йөзеп кит...

Акырын гына аркасыннан төрткәндәй итте:

—Үзегезнекеләргә чыккач, ничек тере калганыңны сөйләмә. Һушымны югалтканмын, шул коткарды, диген...

Итеген, гимнастеркасы белән чалбарын салып ташлады Зәйни. Тавыш чыгармаска тырышып, кабаланмый гына суга керде. Артыннан Хәкимҗанның акрын гына әйткәне ишетелде:

—Аллага тапшырдык! Бисмилланы укы йөзгәндә. Хуш иттек!

Күлнең суы салкын, төбе тоташ таш иде. Кулларын су өстенә чыгармыйча, йөзгән тавыш булдырмаска тырышып йөзеп китте Зәйни. Бәхетенә, күк йөзен тоташ болытлар каплаган, инде ныклап караңгы төшеп беткән иде...

Туып үскән Куганакбаш авылы ике кечкенә инеш бергә кушылган җирдә утырган. Авыл очында—су тегермәне. Аның бик тә тирән, бик тә зур буасы бар. Шунда чумарга, йөзәргә өйрәнеп, суда чыныгып үстеләр авыл малайлары. Араларында Зәйни иң шәп йөзүче санала иде. Буаны туктамастан буена өч тапкыр әйләнеп йөзеп чыга иде ул. Менә хәзер исә йөзеп җанын коткарырга тиеш. Кабаланмый гына, аяк-кулларын бер җайга эшләтеп йөзде дә йөзде Зәйни. Үлеме артта калды. Әгәр күлне йөзеп чыга алса—тормышы алда әле аның. Су салкынлыгыннанмы, башы авырткан азрак басылды. Йөзгән саен аяк-кулында, тәнендә көч арткан нан артты. Тын алуы да бер уңайга салынып, сулышы иркенәйде. Күлнең уң ягында үскән урман караңгылыгын чамалап йөзде Зәйни. Аркасына ятып ял итте. Тагын йөзде. Күпме вакыт үткәндер, тезен су астындагы ташка бәреп авырттырды. Күлнең төбе ташлы иде. Су астындагы ташлар үзләре йомрылар, үзләре бик зур иделәр. Шома ташлар өстеннән аяклары белән шуа-шуа ярга якынлашты. Яр буенда куе агачлык. Судан чыкмыйча гына төнге тынлыкны тыңлап байтак басып торды. Шылт иткән тавыш та юк иде. Әллә инде финнардан куркып, безнекеләр качып киткәннәр. Тик Зәйни ярга чыгып берничә метр да атлап китә алмады, якында гына урысчалап дәштеләр:

—Тукта!

Туктап тавыш килгән якка табан борыла башлады. Тавыш кабатланды:

—Кулларыңны күтәр! Урыныңда гына басып тор! Кузгалсаң, атам! Вася, бар, тенте!

Агачлар арасыннан кара шәүлә күренде. Кечерәк буйлы кызылармеец икән. Винтовкасын сул кулында тоткан хәлдә уң кулы белән Зәйнине сәрмәп чыкты. Йөрәк турысына, эчке күлмәккә тегелгән яшерен кесәне тапты. Тыгылып, кызылармеец таныклыгын һәм комсомол билетын тартып чыгарды. Өшүдән Зәйнинең тешләре шыкылдый башлады.

—Төшер кулларыңны! Тик кузгала күрмә берүк. Аттык куйдык!

Борылып, Зәйнине ялгызын гына калдырып куаклар ягына китте. Анда кечкенә электр уты пәйда булды. Ул Зәйнинең документларын капшап чыкты да сүнде. Инде куаклар арасыннан ике шәүлә күренде. Тавышы җылы иде сораучының:

—Син әллә беренче ротаданмы? Күлнең теге ягыннан чыктыңмы?

—Беренче ротадан. Теге яктан мин.

—Ничек анда рота? Исәннәр бармы әле?

Вильдановның тавышы өзгәләнде:

—Бет...те сугышып рот-таа! Тоташы белән бетте. Рота юк хәзер. Мин... берүзем калдым тереләрдән...

—Әйдә штабка. Атла Вася артыннан.

Вильдановтан сәгатьтән артык сорау алдылар. Ярый әле кергәч тә коры кием бирделәр, аркасына иске генә шинель салдылар. Зәйни шул шинельгә төренгән килеш, эссе чәй уртлый-уртлый, сорауларга җавап бирә башлады. Полкта берничә мәртәбә күргән, тик кем икәнлеге бик сирәкләргә генә мәгълүм булган капитан алды сорауны. Беренче соравы шомлы иде:

—Ничек итеп берүзегез генә тере кала алдыгыз?

Сорау бирелгән унайга ук Зәйнинең исенә фин офицеры Хәкимҗан килеп төште: «... Ничек тере калганыңны сөйләмә! Һушымны югалтканмын, шул коткарды, диген...»

Зәйни шуны исендә тотып җавап бирде:

—Кул сугышыннан аңымны югалткан идем. Нәрсә булганын хәтерләмим. Аңыма килгәндә, тирә-ягымда яткан үлек гәүдәләрдән башка бер кем дә юк иде. Чишендем дә суга төштем...

—Башка иптәшләрегез нишләп беттеләр?

—Окоп эчендә каты бәрелеш булды. Шунда кырдылар финнар безне автоматларыннан...

—Син ничек сугыштың? Окоп эчендәме, тыштамы?

—Без өчәү: Стародубцев, Долгушев һәм мин, окоптан чыгып финнарга ташландык. Патроннар беткән иде, без штыклар белән...

Дусларны автомат белән алдылар, ә мина арттан бик каты итеп башка суктылар. Ахрысы приклад белән бирделәр...

Капитан азрак алга иелә биреп утырган Вильдановка бик озак сүзсез генә карап торды. Зәйнинең башы чалма кебек иттереп ак марля белән уралган иде. Байтак утырганнан соң капитан сорау алу тонын үзгәртте. Сөйләшүе азрак «җылынгандый» булды:

—Башың нык авыртамы?

Зәйни елмаерга тырышты.

—Азрак басылды инде. Кичә күл суына кергәнче бик хәтәр чатнап сызлый иде. Хәзер инде сулкылдый гына. Бик алай авыртмый.

—Өчәү бергә штык атакасына ташландык, дидең. Шул иптәшләреңнең Фамилияләрен-исемнәрен кабатла әле тагын!

—Стародубцев Алексей һәм Долгушев Николай. Дуслар иделәр минем.

—Калган ике ротаның язмышын беләсезме?

—Юк. Белмим.

—Ике ротаны да Ленинградка озаттылар. Окоп эчләреннән алып. Взвод командирлары кирәк. Бик кирәк. Ә сезнең ротаны чакырып ала алмадылар. Җибәргән фельдсвязь үтә алмаган, ахрысы. Энцода юк иткәннәр булса кирәк.

Капитан урыныннан торды да, Вильданов янына килде. Зәйни торып басты.

—Сезне бернәрсәдә дә гаепләргә теләгем юк. Сөйләшү шулай булырга тиеш теге яктан чыга алганнар белән. Бик каты эләккән сиңа, браток. Госпитальгә кереп азрак дәваланып, йоклап чыгасыңмы, әллә Ленинградка Стрельня дигән урынга җибәрикме? Үзең сайла инде хәзер. Сезнең рота Стрельняда яна программа белән тиз генә укып бетереп, сезгә кече лейтенант дәрәҗәсе бирергә тиешләр иде. Ә рота... юк...

Вильданов уйга калды. Ә капитан аңарга киңәш итте:

—Син госпитальгә кереп азрак дәваланып, ял итеп чык. Сугыш безнең барыбызга да житәрлек булачак.

—Юк!—диде Вильданов дулкынланып.—Мин госпитальдә яткан арада сугыш бетеп куйса? Мин бит сугыша алмыйча торып калам. Миңа үз илем өчен батырлык, кыюлык күрсәтергә кирәк. Мин Стрельняга китәм болай булгач. Башның сөягенә зарар килмәгәндер дип уйлыйм. Төзәлер, әллә кая китмәс әле. Дусларым өчен үч аласым бар минем...

Икенче көнне азык ташый торган «полуторка» кузовына утырып Вильданов Ленинградка китеп барды.

Стрельняда ул ике генә төн кунды. Өченче көнне иртән аның кулына «Командировочное предписание» тоттырып Ленинградның Малоохтинская дигән урынына озаттылар. Андагы «Строевой отдел» башлыгы Зәйнинең ак чалма кебек уралган башына аптырабрак карап алды да сорады:

—Сез кайдан килдегез монда?

—Фронттан. Фин границасыннан. Энцо местечкосыннан.

—Әллә яраландыгыздамы инде?

—Бар¯азрак. Аннан көн дә жиләсрәк бит бүген, баш авыртыбрак тора.

Лейтенант башкача төпченмәде...

Укый башлап, берничә көн узгач, Малоохтинскаяда хәтәр хәбәр таралды: Немецлар һавадан десант төшереп Стрельняны алганнар!

Сугышка кадәр Малоохтинскаяда ике катлы бинада урта мәктәп булган. Шунда кече лейтенантлыкка укулар башланды. Шунда ук ашадылар, йокладылар, укыдылар. Атна тирәсе үтүгә Зәйнинең башыннан марляны алып ташладылар. Фин татары Хәкимжанның истәлеге булып башының арт ягында приклад суккан жөй генә торып калды. Истәлек!

1941 елның 8 сентябрендә фон Лееб командалык иткән немец гаскәрләре Ленинград каласын божра ясап уратып алып, блокада булдырдылар. Ленинград өчен 1944 елның башына кадәр ачлык, канлы сугышлар, зур югалтулар башланды.

1941 елның өченче ноябрендә укулар тәмам булып, Зәйнулла Вильдановка кече лейтенант дәрәжәсе бирделәр. Һәм аны шул көнне үк Ленинградның бусагасына килеп терәлгән канлы фронтка озаттылар.

* * *

Немецларның Ленинград каласының көнчыгыш ягында башланган һөжүмнәре бик уңышлы булды. Һәм яхшы нәтижә бирде. Кабаланып, ярты-йорты гына казылган окопларда патронсыз трехлинейка тотып утырган кызылармеецлар немец танкларын күрү белән арттагы урман арасына йөгерешеп кереп китеп, төрле якларга сибелеп юкка чыктылар. Немецлар Ленинградны көнчыгыштан утыз километр чамасы урап үтеп Ладога күле ярына чыгып терәлделәр. Ленинград каласы тулысынча чолганышта торып калды...

Немец гаскәрләре белән командалык иткән фон Лееб Ладога күленен ярына чыгу белән Ленинградтан һөжүм итүгә каршы оборона төзергә боерык бирде. Немецлар кыска вакыт эчендә оборонаны ике якка да каратып, бик оста иттереп ныгыттылар. Ул урыннар сазлык иде. Танклар тик юллардан гына йөри алалар. Анда да, юлларның күп урынын бүрәнәләр салып ныгытканнан соң гына. Танклар йөрерлек урыннарда немецлар танкка каршы ата торган артиллерия тупладылар. Калкурак урыннарда урманны кисеп, ул жирләрдән танклар үтмәслек иттеләр. Кызыл Армия командованиесе Ленинградның яңа ясалган блокадасын көнчыгыштан өзәргә тырышачагына Фон Лееб дөрес бәя бирә алган. Ул чыннан да шулай булды. Һәм немец гаскәрләре блоканы өзәргә дип һөжүмгә күчкән урыс гаскәрләрен яхшы оештырылган оборонада каршы алдылар. Һөжүм беренче көнне генә уңышлы кебек барды.

1941 елның 26 сентябренә каршы төндә Ленинград каласының көнчыгышында Ленинград фронты гаскәрләре Нева елгасын Невская Дубравка исемле тимер юл поселогы янында кичеп чыктылар. Һәм Нева елгасының сул як ярында плацдарм яулап алдылар. Плацдарм өчен көнтөн туктамастан канлы сугышлар барды. Кызыл сугышчыларны командирлар, комиссарлар, үзләре ут астына бик кермичә генә немец пулеметлары өстенә кудылар да кудылар. Нева елгасын кичкәндә үк безнекеләр ач иделәр. Аларга азык бирмичә, тик боеприпас кына тутырдылар. Комиссарларның ашау турында сүзе кыска булды «һөжүмгә барасыз—немецтан алып ашарсыз. Шуның өчен аны жиңәргә кирәк. Ашарга күп немецта! «Бу инде урыс патшаларыннан ук калган төшенчә иде. «Ач кешенең ачуы яман!»—дигәннән чыгып, урыс сугышчысы һәрвакыт ач булды. Шунлыктан, дошманныкын тартып алып тамак туйдыру исәбе белән урыс сугышчысы һәрвакыт һөжүмгә зур теләк белән керә торган иде. Комиссарлар да яхшы аңлыйлар: «Ач сугышчы зәһәррәк

сугыша. Тукка караганда. Ач килеш атакага керүнен тагын бер өстенлегён анлаталар: «Корсагына пуля йәисә штык эләксә, эчәкләрен буш. Шулай булгач, җәрәхәтне эшкәртү җинелрәк—эчендә азык юк!»

Ярга бәреп чыккан унайга ук аяк астында су тулы немец окопларында кул сугышы китте. Тар, бормалы окопта озын трехлинейка белән сугышу җайсыз иде. Шунлыктан безнекеләр сапер көрәген ныграк хуп күрәләр. Ике кыры да игәп үткерләнгән көрәк белән немец штыгын читкә селтәп тә була һәм анын белән чабып ярырга да була немец муенын. Окоплар эчендә ах-ух килеп кычкырулар, акырып сүгенүләр, ату, граната шартлаулары, тимер чыңлаулары ишетелә. Үтереш бара! Ә Нева елгасы аша катерларга, баржаларга, салларга төялгән күпсанлы «пушка ите» агыла да агыла. Тырышып-тырмашып, патриотик лозунглар белән бик нык сугарылган солдат, җанын бирергә әзер хәлдә ярга, үлеменә каршы омтыла, ыргыла, суга сикерә. Ике көн, ике төн туктаусыз кара-каршы барган канлы кул сугышлары нәтиҗәсендә Ленинград фронты гаскәрләре кечкенә плацдарм кисәге яулап ала алдылар. Плацдармның фронт буенча озынлыгы дүрт чакрым тирәсе булып, киңлеге сигез йөз метрлар чамасы гына иде. Шул, солдат теле белән аталганча, «Пятачок»ны яулап алуда 115 нче укчы дивизия сугышчылары һәм диңгез пехотасының 4 нче бригада моряклары катнаштылар. Дивизия белән генерал-майор Коньков, ә диңгез бригадасы белән генерал-майор Ненашев командалык итте. Гомумкомандалык итү генерал-майор Коньковка йөкләтелде.

Атнадан артык барган канлы сугышлары нәтиҗәсендә немецлар плацдармның яртысын юк итә алдылар. Теше, тырнаклары белән сазлыкка ябышкан совет сугышчылары ярты плацдармны бирмәделәр. Сугышкан мәйданда үле гәүдәләр әрдәнә-әрдәнә булып түшәлеп ята иде...

Өченче ноябрьдә кече лейтенант дәрәҗәсе алган Зәйнулла Вильдановны караңгы төшкәч «пополнение» иттереп «Невский Пятачокка» китереп тыктылар. Кечкенә катер белән Нева елгасын кичкән чакта алар алты офицер иделәр. Барысы да бүген генә кече лейтенантлар булган егетләр. Шул көннән алып Зәйни Вильданов «Невский Пятачок»та сугыша башлады.

Көн саен әле бер як, әле икенче як һөҗүмгә ташлана. Кул сугышлары һәр көнне булып тора. Немец һөҗүмгә килгән чагында артка үзенен шәп һәм тиз ата торган «МГ» (Машиненгевер) пулеметларын көйләп куя. Кул сугышында автоматларындагы диска патроннары бетә башласа, алар сугыш кырын ташлыйлар да, бердәм булып, калган патроннарын аткалап, килгән якларына кире йөгерәләр. Аларның качканын каплап пулеметлары ут ача. Алар артыннан кызып йөгергән безнең солдатларга трехлинейкадан берәр патрон аткалап, сүгенү генә торып кала инде.

«Невский Пятачок»та һәлак булганнарның исәбе-хисабын алырлык, санап-бетерерлек түгел иде. Вильданов килгәндә взводта 18 кеше булса, берничә көннән шулардан 11 кеше торып калды. Җиде кеше, кайсысы һәлак булды, кайсысы җәрәхәтләнеп Ленинградка озатылды. Һөҗүмнәрнең көненә 7-8 гә җиткән чаклары да бар. Сугыш бетеп, җину килгәч, СССРның хәрби тарихчылары санаячаклар: Невская Дубравка—«Невский Пятачок» плацдармында немецлар бер тәүлеккә 50 мең снаряд, мина, бомба ташлаганнар. Невский Дубравкада бүген дә су һәм мүк астында ярты метрдан артык тимер катламы ята. Бомба, снаряд, мина кыйпылчыклары, винтовка, пулемет пулялары...

Кыш килгәч, сазлыклар азрак туңа башлау белән сугышлар тагын да катыланды. Шулай да, нинди генә суыклар булмасын, сазлык урыннар тоташ туңмадылар. Сай окоп төпләрендә су, блиндаж, землянка эчләрендә дә су. Ятсаң да су, торсаң да су. Бер генә юаныч бар—киртәләрдән тезеп ясалган ятак урыннар. Төрле зурлыктагы тимер мичкәләрдән ясалган иләмсез мичләр тәүлек буена туктамастан ягылалар. Ә аларга ягарга утын, күмер кирәк. Янарга яраклы барлык нәрсәләр шул мич авызына кереп китеп янып көл-күмергә, җылылыкка әйләнә. Чолгауларны, өс-

башларны киптереп киеп өлгермисең, тагын һөҗүм башлана. Тагын чыгып сулы окопка тәгәрисең. Түзә икән адәм баласы түзсә дә! Землянка, окоп эчләрендә Гитлерның үзен, анасын искә алып агылган урыс матының иге-чиге юк. Барлык аналар арасында урыс маты белән иң күбе Гитлерның анасы сүгелгәненә бераүнең дә шиге юк.

«Невская Пятачок»та безнекеләрнең төп ашаган азыгы үлгән ат ите булды. Ат үләксәсе. Блокаданы өзү өчен, Нева елгасы туңу белән «Пятачок»ка ат белән тарттырып бик күп туплар китереп тутырдылар. Тик божраны өзү өчен кирәк хәтле көч тә, сугышны белүче оста командирлар да юк иде. Артиллерия атлары, аларны яшереп куяр ышык урыннар булмаганлыктан, атна-ун көн үтүгә барысы да бомбежка, артналет вакытларында кырылып бетте. Өстәвенә атларга түгел, кешеләргә дә ашатырга ризык юк иде. Ленинградтан тик боеприпас кына ташыдылар. Чөнки Ленинградның үзенә дә ашарга юк иде. Калада ачлык башланды. Агач кайрысы кимергән хайваннарга карап, күпчелеге авылдан килгән сугышчыларның йөрәк майлары сыкрап сызлады. Зәйнулланың да атларның ачлыктан нарат кайрысын зур тешләре белән кимергәннәрен күреп күзләреннән яшь килде. Җәрәхәтләнгән атларның күбесен атып бетерделәр. Берничәсен Зәйни мөселманча суйды. Ул атларның ите бик тәмле иде. Атларны аткан чакта берсе әйтте: «Сез котылыгыз, хайваннар, бу мәхшәрдән. Без калган, без күргән дә җиткән!» Шул ат үләксәләре белән тукланып яшәделәр. Ярый әле ул үлгән атлар байтак иде.

Декабрьнең икесе иде. Кече лейтенант Вильдановны батальон командиры блиндажына чакырдылар. Блиндажга кереп честь биреп, килгәнен әйткәч, капитан урыныннан тормыйча гына кече лейтенантка урындык күрсәтте:

—Утырып тынла.

Йокысызлыктан кызарган күзләрен алдында утырган Вильдановка текәде дә, акрын гына тавыш белән әйтте:

—Бүген күрше полкка барыгыз. Анда пополнение килергә тиеш. Безнең полкка 32 кеше. Шулар арасында өчесе кече лейтенантлар. Буран башлана, хәзер китсәгез дә була. Немец буранда блиндажында ята кофе эчеп, сосиски ашап. Иртәгә иртән, яктырганчы алып кайтыгыз. Сораулар бармы?

—Юк, иптәш капитан.

—Барыгыз. Әйбәт кенә йөреп алып кайтыгыз.

—Есть!

Торып честь бирде дә, чыгып китте Зәйни.

Бу «командировка» ике йөз метрлар ераклыкта гына иде. Бомбежкадан барлыкка килгән воронкалар арасыннан салынган бормалы сукмактан, авыз эченнән генә «Темная ночь» җырын шыншып бара торгач, Зәйни килеп тә житте. Сукмакның ике ягында тезелгән төрле зурлыктагы блиндажлар арасыннан атлый-атлый, як-ягына каранды: кайда боларның «командный пункт»лары? Каршы очраган ике сугышчыдан сорады. Икесе дә, честь бирмичә генә, таныш булмаган командирны бик җентекләп тикшереп карадылар. Күз карашлары тулы шик иде: кем булдың син әле син? Сорашасың өстәвенә! Гәүдәгә зуррагы телгә килде:

—Бүрегегезгә караганда командирга охшагансыз болай. Документларыгызны күрсәтегез әле!

Полкта ныклы тәртип иде. Чит кешене тиз абайладылар. Таныклыкны карагач, алда бер блиндаж күрсәттеләр. Берсе китеп барды, икенчесе блиндаж янында басып торган часовойга кадәр озатып куйды. Инде блиндажга керергә дип часовой белән сөйләшә башлаган иде, арттан шатланып кычкырып җибәрделәр:

—Зәйни-и! Вильданов! Син бит бу!

Тавыш килгән якка ялт итеп борылып карады да, кычкырган кешегә ыргылды ул:

—Ягъфә-әр! Җанкисәккәй-йем минем!

Ул кеше, чыннан да, Ягъфәр Байморатов иде. Кочаклаштылар да сүзсез генә басып тордылар. Ягъфәр, Зәйнинең кочагыннан чыгып, кулларын аның биленнән алмыйча куанып сөйләнде:

—Исәнсең бит, мунча ташы! Исәнсең бит! Менә сина мә! Сезнең ротаны Энцода финнар камап алып тоташ юк иткәннәр, диделәр бит. Син ничек тере кала алдың? Әйдә минем блиндажга. Бер туйганчы сөйләшеп утырыйк ичмасам. Безнең гомер шушы «Пятачок»та өзелер пожалуй. Киттек мина креп...

Төн буена Ягъфәрнең блиндажында спирт эчеп, үлгән ат итеннән кыздырылган «жаркое» ашап, гәп корып утырдылар. «Жаркое» бик тәмле иде. Зәйни көлеп сорады:

—Ничек пешерәсез сез бу атны? Без пешерәбез—үләксә-үләксә инде. Төсе дә кап-кара була. Моның төсе дә иткә охшаган бит. Юньләп ит тәме дә булмый без пешергәндә. Ә бу нәстән бик тәмле.

—Әтием Динислам өйрәткән иде үлгән ат итен пешерергә. Бер кат кайнап чыккач, суын түгеп, икенчегә саф су саласың. Тагын кайнатасың да, шул суда пешерәсең. Пешеп бетәр алдыннан алып табада кыздырасың. Шул була инде «жаркое». Аннан минем ротада унга якын татар бар. Бер теге кысык күзле якут та бар. Шулар бик осталар итне әтмәлләүдә. Кайнатканда иттә калган каны суга чыга икән... Табада кыздырырга май булса шәп тә бит. Юк май. Су саласың да шунда кыздырган кебек итеп пешерәсең инде. Мин үзем болашмыйм. Рота командиры бит мин хәзер. Атнадан артык инде. Ординарецым бар. Шул кайгырта тамак ягын...

Ярты төн җитеп килгәндә Ягъфәр мут итеп елмайды:

—Кызлар чакырыйммы, Зәйни?

Зәйни кызара башлаганын сизде:

—Әллә бармы?

—Мин бит хәзер рота командиры. Ә ротада санитар маржалар җитәрлек. Мактаныйм әле сиңа. Кара минем нәрсәм бар!

Туныының изүен ачты. Ягъфәрнең күкрәгендә Кызыл Йолдыз ордены ялтырап тора иде.

—Ягъфәр абзаң хәзер шухрый-мухрый түгел—орденоносец! Алганга өч кенә көн әле, үзем дә ышанып бетмим. «Минеке микән бу?»—дип, тун аша сәрмәштереп карыйм тегене. «За умелую организацию обороны и успешное отбитие вражских атак!»—диелгән наградной листта.

Сүзне икенчегә борды:

—Тальянда уйнайыммы?

—И-эх!—дип куанычын белдерде дусты.—Нигә мин килгән көенә тотынмадың инде. Ал тизрәк!

—Сагындыргансың, дус! Сөйләшеп утырасы бик килгән иде...

«Тальян» сүзе чыккач, Ягъфәрнең «кызлар» дигәне онытылды. Тунга төрелгән гармунны нардан үрелеп алды да, каешын кулбашына киеп җайлады. Берничә аккорд алды. Гармун тавышы элеккечә көмеш кебек матур итеп чыңлап тора иде. Блиндаж эченә татар рухы тарала башлады. Ягъфәр гармунын сузып җырлап та җибәрде:

А-а-агиделгә төшә язды-ым,
Төшә язды-ы-м.
Томады-ын беләге-емнә-ән, Мәрфуга-а!
А-айли-и! Гөлмәрфуга, бар суга!
Гөлмәрфуга барса-ан суга-а,
Сөйләшербе-ез барсын да-а...

Сүзләр тынуга гармун тавышы көчәеп, блиндаж эчендә хуҗа булып, моңны арттырды. Күнелләргә сугыш алды еллары, авылның кичке аулак җылы өйләре, тыгыз түшле татар кызлары искә төшеп, моң артыннан моң өстәделәр.

Ягъфәр моңаюын дәвам итте:

Та-амыр жәйгә-ән гөлләр кебек,
Гөллә-әр кебе-ек,
Чы-ыкмыйсың йөрәгемнән, Мәрфуга-а!
А-ай-ле-ей, Гөлмәрфуга, бар суга!
Гөлмәрфуга-а, барсаң суга!
Сөйләше-ербе-ез барсын да-а!
Гөлмәрфуга-а барсаң суга-а,
Сөйләшербез барсын да-а...

Гармунын кочаклаган килеш туктаЛды жырдан Ягъфәр. Сагыш тулган конгырт күзләрен тимер мич эчендә жилпенеп-жилпенеп талпынган ут ялкынына текәп байтак утырды. Ул сөйли башлагач, Зәйнинең тәне буйлап дулкын йөгереп үтте. Чөнки Ягъфәрнең тавышы иксез-чиксез сагыш белән сугарылган иде:

—Зәйни, исендәме? Узган елның мартында Эстәрлененң «Сигезенче март» исемле колхоз клубы сәхнәсендә «Галиябану» пьесасын куйган идек...

—Сон, истә булмыйчак?! Син Хәлил, ә Хәтимә Фәйзуллина диган кыз Галиябану иде. Иллә дә шәп куелган иде дә инде!..

—Хәтимәне сагыныплар үләм инде, Зәйни!!! И-эх, мала-ай! Көтәм сине!—дип хатлар яза миңа. Почта килгәндә унарлап алам хатларын. Эчләре тулы Хәтимәнең җылысы әй! Күрепләр булырмы икән инде—белмим. Бик нык кырыла бит халык бу «Пятачок»та. Тере калулар безгә насыйб булмастыр инде. Кайтып бер генә күрергә кирәк иде дә, һичьюгы кулларыннан гына тотып, күзкәйләренә карап басып торырга иде-е...

Туктады сөйләүдән. Башын иеп азрак утырды да, гармунын сузып жырлап жибәрде. Тавышы бик тә, үтә дә моңлы иде Ягъфәрнең. Аның жырлаганын Зәйнулланың соңгы мәртәбә тынлавы иде. Ягъфәр «Галиябану»ны жырлый иде:

Чи-итән аша төшкә-ән ча-акта-а,
Бүрәнәгә абы-ынды-ым.
Ми-инуты ай, сәга-ате ел,
Галия-лә-бануы-ым, сылуы-ым-иркә-әм,
Шул кадәрле сагы-ынды-ым...

Иртән Зәйни «пополнение»ны алып китте. Пополнение төнлә генә килгән иде. Ягъфәр белән кочаклашып аерылдылар. Икесенең дә күңеле монсу иде...

Ягъфәрне соңгы тапкыр күрүе иде Зәйнинең...

1941 елның 30 декабренә кадәр Зәйнулла Вильданов Алланың каһәре төшкән шул «Невский Пятачок»та сугышты да сугышты. Рота командиры аны биш пулемет белән житәкчелек итәргә билгеләп куйды. Икесе станковый пулемет «Максим», ә өчесе кул пулеметлары «ДС» иде алар. Кыш каты булуга карамастан сазлык астыннан чыккан жылы су ана туңып бетәргә ирек куймый. Аяк астында, окоп төбендәге су һәрчак «чапылдап» тора. Шунлыктан аякка киез итек киеп йөреп булмый. Ә пулеметлар шыкраеп, бозланып ката. «Пулемет гнездолары» агач ботакларыннан, тартма кисәкләреннән өеп ясалганнар, су сибеп тундырылганнар. Нык булсыннар өчен. Блиндаж эчендә дә су. Пополнение килгән көннәрдә басып та ял иткән чаклары бар. Тик андый хәл күпкә бармый. Бер-ике бомбежка, шуна артналет та өстәлсә, урыннар артып ук кала башлый. Мичне ягып ныграк кыздыра башласаң, түшәмнән, блиндаж диварларыннан парланып су ага. Аз булса да Ленинградтан чи балчыкны хәтерләткән, кеше башына тәүлеккә 400 грамм ипи кебегрәк нәрсә килә. Башкача азык жибәрми Ленинград. Чөнки юк! Ә немец тук. Оборонада ятканнарга иң авыры—жил немец ягыннан искән вакытлар. Жил һәрвакыт кофе, колбаса, эссе аш исен алып килә. Өстәвенә ватып-жимереп немец ягыннан радио аша урысча акыралар:

—Иф-фа-ан! Иди кушайт. Водка тфой, куша-айт мо-ой! Иди бистро, бистро-о! Закуска-а!

Кайберәүләр ачлык ачуын чыгарырга тырышып ата башлыйлар. Ә немецка шул гына кирәк тә. Радиодан тантаналы тавыш тагын да көчлерәк яңгырый:

—Ай-ай, Ифа-ан! Ни нада аппетит портит! Ай-ай!!!

* * *

**29** декабрьдән 30 декабрьгә каршы төндә «Невский Пятачок»та төне буена сугыш барды. Төнге сугыш! Яхшы, җылы киенгән, колбаса, сосиски ашап корсакларын тутырып туенган немец солдатлары, кофе эчеп ләззәтләнгәннән соң чыгып, һөҗүмгә күтәрелгәннәр. Ул төнне алар яхшы гына хәмер дә эчкәннәр иде. Шинельләрен салып ташлап, тычкан тиресе төсендәге мундирларының җиңнәрен сызганып, автоматларын корсакларына терәгән хәлдә ут сиптереп, төне буена һөҗүмнәрнең берсе артыннан берсен кабатлап тордылар. Үзләренең раштуа бәйрәменә «Невский Пятачок»ны юкка чыгарырга боерык алганнар иде алар. Снаряд, миналар шартлаганнан чыккан билдән түбән саз суында яткан Зәйни Вильданов исерек фашистларның акырып йөгергән тезмәсенә «Максим» пулеметыннан атты да атты. Немецлар да кызганнан кыздылар. Пуля тиеп егылган иптәшләренең гәүдәләренә баса-баса, безнекеләр яткан окопларга омтылдылар. Егылганнары урынына яңалары пәйда була торды. Барысы да бер төстә—соры тычкан төсендә иделәр...

Таң ата башлаганда гына һөҗүм тукталды...

Пулемет артыннан кузгалып торырга итте Зәйни—булдыра алмады. Икенче номер да хәлсезләнеп, тора алмыйча азаплана иде. Башын азрак борып Зәйни аякларына карады. Аяклары су эчендә итек белән бергә боз кисәкләре белән аралашып каткан иде. Иптәшләре балта белән чапкалап, аны боздан азат иттеләр дә күтәреп, медсанбатка алып киттеләр. Анда ике итекне дә үткен пычак белән ярып, аякларын куптарып алдылар. Ике аяк та боз эчендә шыкырдап туңган иде...

* * *

**1942** елның гыйнвар башлары. Брезент белән ябылган йөк машинасы кузовында яралылар тезеп салынган. Бик тә искергән, таушалган йөк машинасы, ватылып таралып китимме икән, әллә тагын азрак кына булса да барыйммы икән дигәндәй, һаман алга тәгәрәргә тырышып тырмаша. Яралылар арасында, тезгә кадәр туңган аякларының сызлавына ыңгырашкалап Зәйни Вильданов та ята. Йөк машинасы, яралыларны Ладога күле аша янарак кына салынган «Тормыш юлы» буйлап «Зур җир»гә алып чыгып бара. Ходай кушып, ярый әле көн буранлы—фашист самолетлары күренмиләр. Юлга чыгар алдыннан һәр яралыга йөз иллешәр грамм спирт эчерделәр дә, кечкенә чи ипи кисәге тоттырдылар: «Чыккач ашарсыз! Икмәкле җиргә киттегез инде!»

Ладога күленең бозы өстеннән салынган «Тормыш юлы»н үткәч, машина ярга үрмәләп менде дә, ярты чакрым чамасы баргач туктады. Яралыларны күтәреп кузовтан төшерә башладылар. Олы гына яшьләрдәге санитар хатын ярдәмендә Вильданов көчкә атлап, зур землянкага килеп керде дә, ыңгырашып, ишек төбендәге топчанга тәгәрәде. Озак та үтмәде котелок белән эссе аш күтәргән санитар хатын килеп керде:

—Тор! Ашап ал! Тор! Тор!

Зәйни бүреген салды да алюмин кашык белән котелокка тыгылды. Котелоктан килгән аш исенә башы әйләнә башлады: бәрәңгеләп, макаронлап пешерелгән итле аш иде котелокта. Кайнар ашны авызын пешерә-пешерә бик тиз ашап бетерде. Котелокны янына куйды да, бүреген баш астына кыстырырга йоклап та китте...

Вагон тәгәрмәчләре шыкылдаганга уянды Вильданов. Тимер юл вагоны эчендә кай тарафкадыр алып баралар иде. Сорыйсы да, сөйләшәсе дә килмәде. Аның өчен иң мөһиме—вагон фронттан еракка-рак тәгәри

иде. Озак ятты ул уйланып һәм эченнән генә куаныч кичерде: котылды «Невский Пятачок» тәмугыннан! Поезд аны фронт утыннан еракка өстери!

Вагон эчендә тулганган олы яшьтәге ике санитар аның уянганын күреп алдылар.

—Әйдә, тот моны! Уянды бу!—диде берсе икенчесенә.

Анадан тума чишендерделәр. Машинка белән кытырдатып чәчен-йоннарын алып ташладылар. Бет белән мыжгып торган эчке күлмәк-ыштаннарын сасы исле бер тимер бакка тыктылар да, үзен күтәреп бүлем-диварның икенче ягына алып кереп киттеләр. Анда ниндидер сасы сыекча белән тәненә сөрткәләделәр дә тамбур аша күрше вагонга күтәреп чыктылар.

Вагон эче зур, җылы. Бер генә бүлеме дә юк. Урта бер җирдә идәннән бер метрлар чамасында зур өч өстәл кебегрәк топчаннар калкып тора. Шуларның берсенә Вильдановны китереп салдылар. Ул тоташ ялангач иде. Шуны гына көткән кебек, ак халатлы, урта яшьләрдәге бер ир белән яшь кенә чибәр бер кыз килеп керде. Алар икесе дә Вильданов яткан өстәл-топчан янына килделәр.

—Кече лейтенант Вильдановмы?—дип сорады ир.

—Так точно!—дип җавап лады Зәйни, азрак каушый төшеп. Ул балачактан ук ак халат кигән табиб халкыннан шүрли иде. Бигрәк тә алар ясый торган уколлардан. Ак халатлы ир чибәр кызга ым какты. Тегесе кәкре кайчы алды да, аяктагы бинтларны сүтеп тормыйча, кисә башлады. Тунганнан тиресе уелып төшкән аяк итенә ябышып каткан иде бинт. Ниндидер сыекча белән юешләп куптара башладылар. Зәйни түзә алмыйча ыңгырашып куйды.

—Ну-у!—дип сузды ир табиб.—Си-ин нәрсә инде тагын? «Невский Пятачок» батыры үзең—ыңгырашырга итәсең. Тукта!

Зәйни көлкегә әйләндереп карады:

—Аяк «Пятачок» батыры икәнен аңлап бетерми, ахрысы—авырта бит!

—Авырткач, әйбәт инде ул! Авыртуны сизәрлек булгач—үлмәгән!

Тездән түбән тиресе юкка чыккан кып-кызыл чи ит булган аякларына күзе төшкәч, Зәйни тетрәнеп китте. Табиб аякларга бармаклары белән баскалап карады. Алар икесе дә шешкән иде. Икесен дә мул итеп спирт белән сөрттеләр. Шуннан соң тәмле исе килеп торган сары төстәге майга калын марля манчып аякларга яптылар. Киң бинт белән кат-кат урадылар. Урап бетермәс борын ук аякларның сызлавы басыла башлады.

—Нинди май ул?—дип сорады шәфкать туташыннан.

—Облепиха мае. Пешкәннән, туңганнан бик файдалы.

Ике тәүлек бара торгач, аларны Вологда каласына алып килеп, бер госпитальгә урнаштырдылар. Шул госпитальдә кече лейтенант Вильданов бер айга якын ятты. Терелә башлаганнарны Вологданың дүрт госпиталеннән җыйнап, санитар поездына тутырдылар да, көнчыгышка алып киттеләр. Унике тәүлек өстерәлеп бара торгач, февраль урталарында Алтайдагы Бийск каласына алып килеп житкерделәр. Бийск госпиталендә Зәйни тагын ике айга якын ятты...

* * *

Зәйнинең аяклары өшеп, шуның өстәвенә контузия алып Ленинградка озатылганын Ягъфәр Байморатов тик ай чамасы узгач кына белде. Шул хакта анарга дустын эзләп килгән бер төнне әйттеләр. 1942 елның гыйнвар ае бетеп килгән чакта Ягъфәр Байморатов лейтенант дәрәҗәсе алып, күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены янына «За Отвагу» медален дә таккан иде. Полкта Ягъфәр иң кыю, уйлап сугыша белә торган рота командиры исәпләнә иде. Яна гына егерме бер яше тулып үткән яшь командирны сугышчылары дә нык хөрмәт итә һәм сугышчыларда гына була торган сүзсез ярату белән

яраталар иде. Чөнки лейтенант үзенең кул астындагы сугышчыларны үлемнән саклап сугыштыра белә иде. Табигать биргән акылы, зиһене һәм һәр нәрсә турында да тик үзенчә генә фикер йөртә белгән башкорт егете шуны яхшы аңлады: ул инде «Невский Пятачок»тан тере чыга алмас, ахрысы. Ярый да, Зәйни кебек, аяклар туңып җәрәхәт алсаң? Алай да гарипләнеп, эшкә ярамаслык булып калсаң? «Ничек тә тере калырга тырышырга!»—дигән уй урынына, Байморатовның башында икенчесе туды: «Бик тиз үлмәскә тырышырга!» Немец һөҗүмнәре тукталып торган араларда, ул кулына тальянын ала. Ерακта, Урал тауларының көньяк итәгендә утырган авылы Йомагужа белән, картаеп килгән әтисе-әнисе белән һәм өй тулы торып калган ыбыр-чыбыр энеләре, сеңелләре белән бердәнбер бәйләнеш булып калды аның тальян гармуны. Өстәвенә ул гармун атаклы Вараксин тальяны бит әле! Кеше үтерергә өйрәнеп автомат курогына, пулемет гашеткасына басарга күнегеп бетеп ката башлаган бармакларын бер-берсенә ышкып, аларны азрак йомшартып язган кебегрәк итә дә, сакланып кына тотынып тальян гармунын кулларына ала. Гармунга куллары тию белән бөтен тәне буйлап ләззәтле җылылык тарала башлый. Тальян телләренә басмастан элек үк Ягъфәрнең күңеле җырлый, моңая башлый. Үзенең бәйрәмен башлый. Һәм үз көенең моңлы тавышына тальян моңын китереп куша. Тышта кар бураны улый, агач башларын шаулата. Землянка яна гына җылына башлаган, аның эче тулы ачлык һәм шомлык. Караңгы һәр почмагына өшегән үлем кереп утырган да, яшеренеп тә тормыйча, тешләрен ыржайтып каткан килеш басып тора. Һәр мизгелдә озын, салкын кулларын сузып бугазыңнан эләктереп буарга әзер. Һәр секундта, һәр минутта кем дә булса җаны белән хушлаша бу Алланың каһәре төшкән «Дуңгыз Пятачогы»нда. Йә ул җанны немец снайперы ала, йәисә бомба, снаряд, мина, граната ботарлап ташлый. Шул бомба-снарядлар шартлаганда әле генә мылтыгын корып болашкан кешедән төтенләп, парланып яткан, пычрак чүпрәкләр белән актарып ботарланган ит, сөяк кисәкләре генә аунап кала...

Тышта салкын, өермәле, карлы буран улый. Окоплар алдына, үлемнән котылыр өчен җир урнына әрдәнәләп өелгән, нык булсын өчен өсләренә су сибеп катырылган солдатларның мәетләре. Алар инде окоп брустверы булып, тере калганнарның җаннарын саклап сугышырга ярдәм итәргә тиешләр. Үлгән кеше дә сугышырга тиеш монда! Ә кышкы буран шул мәетләрдән өелгән бруствер ышыгына тырышып-тырышып көрт сыртлары өя. Маскировка уздыра. Көн-төн сугышудан, ачлыктан, суыктан өшәнгән, талчыккан, йончыган сугышчыларның күңелендә буран улавы өметсезлек тудыра, аны үстергәннән үстерә...

Ягъфәрнең дә арыганлык, сагыну, өметсезлек, сагыш, моң тулган күз-күңеле үзенә урын таба алмый, барлык өметен тальянга салып аңардан юаныч эзли. Бармаклары шул юаныч көен эзләп тальян телләре буйлап өстән аска, астан өскә йөгерәләр, эзләнәләр. Тальяннан җанга ятышлы булып, аның авырткан җирләрен сыйпап, җәрәхәтле урыннарын дәвалап татар моңнары агыла башлый. Берничә ел азапланганнан соң гына аңлады Ягъфәр: тальян гармун башкорт җырлары, башкорт моңнары өчен үзенең табигате белән туры килми икән шул. Тальян гармун да, саратски гармун да чын татар гармуннары! Ул гармуннарда урыс та, башкорт та, үз көйләрен уйнап, моңландыра алмыйлар. Ул гармуннарны уйлап чыгарган кешене дә татар моңының тәмен белгән татар егете булган! Шуңлыктан Ягъфәр, тальянын кулына алса, татар моңнары дөньясына кереп чума, шунда хыялларына юл ача. Йөрәге, башы белән Эстәрле авылының колхоз клубы сәхнәсенә кайтып китә. Шунда «менә дә», тальянын сайратып җырлый башлый: күз алдына сөйгән кызы Хәтимәнең сылу буе, чибәр йөзе килеп баса. Ягъфәргә кушылып көмеш тавышы белән Хәтимә дә җырлый. Хәтимәнең сылу гәүдәсен күзләреннән ычкындырмыйча, тальянын сайратып Ягъфәр «Галиябану» моңының чишмәсенә чума:

Чи-итә-ән аша төшкә-ән ча-акта,
Бүрәнәгә-ә абынды-ым.
Ми-инуты ай, сәгате ел,
Галия-бануы-ым, сылуы-ым иркә-әм,
Шул каләрле са-агынды-ым...

Монайган егетнең күз алдына кечкенә елга ярына терәп салынган тимерлек килеп баса. Күн алъяпкычын чишә-чишә жир башлы тимерлектән чалара башлаган сакал-мыеклы әтисе Динислам күренә. Улы Ягъфәрне күрүгә үк елмая башлый. Ике бичәсеннән туган ундүрт баласы арасында Ягъфәр улы иң яраткан баласы ата кешенең. Ә тальян, истәлекләргә алып кайтып китеп, салкын землянканы жылытып моңая да моная. Ягъфәр Байморатов соңгы көннәрен, атналарын яшәгәнне сизгәндәй уйный тальянында. Моңая гармунын уйнатып башкорт баласы...

Бер кичне нилектәндер тыныч булды. Икенче көнне генә беленде: фашистларның раштуа бәйрәмнәре булган икән. Ул кичне хәтта жил дә басылган иде. Ап-ак пәрдә булып, һаваны тоташ каплап ап-ак кар ява. Берничә адымнан бернәрсә дә күренми—тик ак кар гына ява. Ап-ак кар, кешеләр үзләре уйлап чыгарып, үзләре өчен үзләре ясаган ямьсезлекләрне, явызлык эшләрне, мәетләрне, бомба-снаряд чокырларын каплап бетереп, тирә-якка сафлык бирергә тырыша. Бик каты бомбежкадан соң күпсанлы яралыларны тылга озатып, ат үләксәсеннән чабып алган итне ординарецы кертеп өстәл кебек нәстәгә куйгач, Ягъфәр тамак ялгап, кайнаган суны чәй итеп эчкәч, гармунын кулына алды. Өч кешелек блиндажда ул япа-ялгызы калган иде.

Тышта үзе жил дә юк, тик нилектәндер акрын гына ишек шыгырдады. Снаряд гильзасыннан, филтәсе тышка чыгарып ясалган сукыр лампадан землянка эченә зәгыйфь кенә яктылык таралган. Ишек ачыла башлаганнан ут теле талпынып куйды—һава агымы кагылды аңарга. Ягъфәр башын күтәреп ишек ягына карады да дертләп куйды. Ишек төбендә кулларына автомат тоткан ике немец солдаты басып тора иде. Ак маскировка халаты капюшоннарыннан кып-кызыл битләре генә күренә. Тиз генә Ягъфәрне, землянка эчен күздән кичереп чыктылар. Ягъфәр бу көтелмәгән «кунакларны» күргәч каушый төшкән иде. Шулай да аптыравын, каушавын яшереп урыныннан кузгала башлады. Алдарак басып торган немец автомат көбәген идәнгә каратып борды. Перчатка кигән сул кулын аз гына өскә табан күтәрә төште. Елмая биреп, сәер, үтенечле тавыш белән акрын гына әйтте:

—Шпиеле зие битте, музикен! Зеер гут! Битте! Битте! *(Тагын уйнагыз әле музыкагызны! Бик матур! Зинһар! Зинһар!)*

Ягъфәр аның нәрсә сораганын абайлады. Һәм уйнаудан башка чара калмаганын да аңлап алды. Йә үтереп китәләр болар, яисә авызына чүпрәк тыгып, «тел» итеп алачаклар. «Ни булса да булыр!?»—дип уйлады да, түмәренә кире утырды. Бер аккорд алды да, жырны яңадан башлады:

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән?
Үтеп киткәч борылып карый,
Галиябануым, сылуым-иркәм,
Әллә ярата микән?..

Үз тавышыннан үзе көч алып жырлады Ягъфәр. Немец тыныч кына әйтеп куйды:

—Зеер гут, камрад! Зеер гут! *(Бик матур, иптәш! Бик матур!)*

Читән аша төшкән чакта,
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Шул каләрле сагындым...

Жыр тынды, гармун уйнаудан тукталы. Немецлар икесе дә гаепләре бар кешеләр кебек ишек төбендә таптанып алдылар. Тазасы тагын телгә килде:

—Битте, нох ейнмал! *(Зинһар, тагын бер мәртәбә?!)*

Иреннәре белән көчәнеп урыс сүзләрен китереп чыгарды:

—Пжалста! Песня-а! Нох ейнмал!

—Битте! Нох ейнмал!—диде Ягъфәр елмая биреп. Немец теле укытучысы Сыртланов абыйсының дәресләре исенә төште. Барлык белгән сүзләрдән хәтерли-хәтерли алып китте:

—Диезе зингер һабен наме Галиябану! *(Бу җырның исеме Галиябану!)*

Салкын землянка эчендә тагын «Галиябану»ның җылы моңнары агылды.

Киеренкелектән Ягъфәрнең аркасы буйлап бөрчек-бөрчек тир ага башлады. Тукталды җырлаудан. Немец сорады:

—Диезе зингер нихт руссиш? *(Бу җыр урысларныкы түгел бит?)*

—Найн! Диезе зингер ист татариш зингер! *(Бу җыр татар җыры!)*

—Унд зие зинд татариш? *(Сез дә татармы?)*

—Йа! Их бинд татариш! *(Әйе! Мин татармын!)*

Үзенең башкорт икәнен әйтеп тормады. Әллә белә немец башкортны, әллә юк!

Немец куенына тыгылды, бер зур плитка шоколад чыгарып, агачтан юнып ясалган өстәлгә куйды. Елмайды:

—Вир коммен цюрюк! Данке шөөн! Зеер гут музика! Ауф виедер зеен! *(Без киттек! Зур рәхмәт. Музыкагыз бик матур! Күрешкәнгә кадәр!)*

Немец йодрыклаган уң кулын азрак һавага күтәрде дә... икесе бер булып борылып, землянкадан чыгып киттеләр. Ә землянка эчендә аларга ияреп кергән суык, өстәлдә бер плитка шоколад, һәм аптырап басып торган рота командиры лейтенант Ягъфәр Байморатов кына торып калды...

Чирек сәгать чамасы узгач, тунын киеп Ягъфәр землянкадан чыкты. Эзләреннән чамалады: немецлар дүртәү булганнар! Бераз кар яуганны карап басып торды да, часовойларны тикшерергә китте. Часовойларның берсе дә юк иде. Суыкка, ачлыкка постта торганнарның күбесе чыдамый—землянкаларга поса иде. Лейтенант аларны ачуланмыйча гына постларына чыгара башлады. Тавышсыз, каршылыксыз чыга бардылар. Тик өлкән яшьләрдәге берсе генә сөйләнеп куйды:

—Немец раштуа бәйрәм итә бит бүген. Йөрмәс инде ул безнең ачтан какланган землянкалар янында. Ат үләксәләре арасында. Шнапс чөмерә булыр ул...

1942 елның язы җитеп, Нева елгасында боз кузгалгач, «Невский Пятачок» плацдармын немецлар тоташы белән юк иттеләр. «Пятачок»ны саклаган сугышчыларның бик азы гына әсир төште, күпчелеге кырып салынды. Ул болай булды.

29 апрельгә каршы төндә Невада боз шартлап ярылды һәм елга бозында салынган юл юкка чыкты. «Невский Пятачок»ка азык, боеприпас китерү тукталды. Боеприпассыз калган сугышчылар плацдармда тагын бер атна сугышып каршы тора алдылар. Немец авиациясе аяз көннәрдән файдаланып «Невский Пятачок»ны һавадан аркылыга-буйга бомбага тотты, пушка-минометлардан снаряд, миналар яудырды. Теткәләнгән җирләргә кабаланмый гына пехота кертеп, андагы ярым тере сугышчыларны юк итә барды...

Бер аягы тубыктан, икенчесе тездән өзелгән Ягъфәр Байморатовны землянкага кертеп салдылар. Ягъфәрнең хәле юк, башы әйләнә, күз алдында утлы божралар йөзә. Ул инде соңгы сәгате килеп җиткәнне яхшы аңлаган иде. Землянкада соңгы сугышка әзерләнде. Аркасы белән землянка диварына сөялде. Кабаланмыйча гына, әтисенең төсе итеп авылдан алып килгән чалгы пәкесе белән битен баса башлаган кара сакал-мыегын кырды. Бик җентекләп, ике мәртәбә кырды. Шомарган битен сыйпап көлеп куйды. Бит ябык булса да, бик шома итеп кырылган

иде. Гимнастерка түшендәге Кызыл Йолдыз ордены, «За отвагу» медален һәм «Ворошиловский стрелок» дигән значогын ялтыраганчы, җентекләп ышкыды. Документларын, Хәтимәдән килгән хатларны, агач саплы чалгы пәкесен янган мичкә тыкты. Хәтимәсенең бердәнбер фоторәсемен йөрәге турысына, гимнастерка кесәсенә кадерләп кенә салды. Соңгы тапкыр үпте.

—Киткән чакта үптермәгән идең. Барыбер үптем үзеңне... Хәтимәбануым...

Ата комсомол булуына карамастан, олы әсәйе өйрәткән бердәнбер белгән догасын—«Әлхәм»не өч мәртәбә укып чыкты. Кыйбланы чамалап битен сыпырды. Мич өстендәге чәйнектә җылынган суга сөлге чылатып тәненең барлык җирләрен ышкып, сөртеп чыкты. Үлеменең землянка ишеген ачып килеп керәсен ул белә һәм аны тыныч кына, чын ирләрчә горур итеп каршы алырга әзерләнеп беткән иде...

Өстәл артына куллары ярдәмендә өстерәп гәүдәсен алып кереп утыртты. Тальян гармунын кулына алды. Артындагы шүрлектән үрелеп соңгы граната-лимонкасын алып чалбарының сул кесәсенә тыкты. Ике куллап тальян гармунын тере җан кебегрәк иттереп сыйпады:

—Соңгы мәртәбә уйныйбыз хәзер, дус! Мин дә, син дә бетәбез! Сине немецка бирә алмыйм—гафу ит...

Сугыш, атыш тавышлары землянкага якынлашалар иде. Тик алар бер сәгать элегрәк булган кебек зәһәр түгелләр иде инде. Плацдарм юк ителеп, инде аны саклаучыларны бетерү генә бара иде.

Ягъфәр мендәре астыннан фляжка белән спирт чыгарды. Аңа бераз карап торды да, ачмыйча топчан астына ыргытты:

—Һәрчак чын ир-егет булдың, Ягъфәр. Эчмәгән хәлдә үлемнең йөзенә карап кит. Тикмәгә генә атаклы башкорт Байморат нәселеннән димиләр сине. Чын башкорт бит син!

Яраткан көйләре «Гөлмәрфуга», «Салкын чишмә»не башкаргач, соңгы тапкыр башкарганын яхшы аңлап, акрын гына «Галиябану»ны уйнап җибәрде:

Минуты ай, сәгате ел,
Галия лә Бануым, сылуым-иркәм,
Шул кадәрле сагындым...

Шулчак, тыштан каты типкәнгә землянка ишеге шар ачылып китте. Анда кеше үтереп кызган немец солдатлары күренде. Өстәл артында утырган лейтенантны күреп берсе команда бирде:

—Штеен ауф! Хенде хох! *(Басыгыз! Кулларыгызны күтәрегез!)*

Ягъфәр алардан күзләрен алмыйча җырлавын дәвам итте.

Сөюләрең чыннан булса!
Хәтимә бәгърем, сылуым-иркә-әм,
Үлемнәрдән тартып ал!
Сөюләрең чыннан булса-а...

Сул кулы белән гранаталы кесәсенә тыгылды. Шул ук мизгелдә ишек төбендә немец автоматы озын чират биреп тырылдарга тотынды. Пулялар тальян гармунны, һаман җырлаган Ягъфәрнең күкрәгән теткәли башладылар. Гармун озын, авыр, моңлы тавыш чыгарып ыңгырашты.

Немецлар чыгарга дип борыла башлаганнар иде, землянка баскычыннан кабаланып төшеп килгән аяк тавышларын ишетеп, башларын күтәреп тышка карадылар. Полкның атаклы разведчигы, таза гәүдәле Иоган Штеллер үзенең ике иптәш разведчигы белән икән. Штеллер землянка эченә алга үтте дә, утырган килеш җан биргән лейтенант янына килеп тукталды. Башыннан юка сукнодан теккән ике колаклы бүреген салды:

—Соңга калдым шул. Сугыш бит. Бу офицер бик әйбәт татар музыканты иде. Җыры да, музыкасы да бик матур иде. Җырының исеме... э-э... «Бану» исемле иде. Кызганыч, килеп житә алмадым...

Кызыл Армиянең 1942 елдагы тоташ унышсызлыклары «Невский Пятачок»та, апрель азакларында башланып китеп, ноябрь аена кадәр барды. Ватан сугышында дүрт ел буена һәлак булган халыкның яртысына якыны шул каһәрле 1942 елның языннан алып кара көзенә кадәр кырылды...

1942 елның кышын Ленинград блокадасын өзәргә дип һөҗүм башлаган Икенче Удар Армия, Волхов-Новгород сазлыкларында чолганышка эләгеп, җәй айларында яшәүдән тукталды. Тулысынча диярлек чолганышта калгач, бик азлары гына аннан котылып чыга алдылар. Халык телендә Мясной Бор дип кара даны чыккан урында берничә көнгә генә километр ярым озынлыкта итеп божраны өзә алдылар. Тик ул озакка бармады. Икенче Армиянең яртысыннан күбе әсирлеккә төште. Шулар арасында кече политрук, татар халкының инде сугышка кадәр үк атаклы шагыйре булган Муса Җәлил дә бар иде. Әсирлек, төрмә-концлагерьлар аша, кыйнаулар, кимсетүләр, сатылулар аша татар шагыйре палач балтасына һәм мәңгелеккә әйләнәчәк данына каршы әсирләр колоннасында атлый иде...

Ә Икенче Армия белән 1941 елда Мәскәү сугышларында дан алган, Сталинның яраткан генералларының берсе булган генерал-лейтенант Власов Андрей Андреевич командалык итә иде. Ул да шул чолганыштан чыга алмыйча, әсирлеккә эләкте. Һәм... 1943 елдан алып Гитлерга тугрылыклы сатлык хезмәткә күчеп, Совет Армиясенә каршы сугышучы Российская Освободительная Армия дигән хәрби оешма төзеде, шуның Башкомандующие булды. Советлар Союзына, Русияга каршы сугышкан Власов Армиясенең хәрби байрагы бүген Русия кабул итеп, үзенең Дәүләт флагы итеп кулланган байрак иде...

Кызыл Армия командованиесы 1942 елның 26 сентябрендә Невская Дубравка кырында, инде Московская Дубравка дигән урында тагын десант төшерде. Тегесеннән дә кечкенәрәк бер плацдарм яулап өлгерделәр. Тик, исәпсез-хисапсыз халык кырылудан башка, анысының да файдасы булмады...

Башлары су үтмәслек итеп күн белән ямалган һәм калын итеп күн табан тегелгән киез итекләр кигән кече лейтенант Зәйни Вильданов март азакларында госпитальдән чыкты. Әле шешенгәне кайтып бетмәгән, юка гына кызыл тире белән капланган аякларына күн итек тә, ботинка да киярлек түгел иде шул. Кул тигәнгә дә авырта торган аякларын зур киез итекләргә сакланып кына тыга-тыга, эченнән генә көлеп куйды: «Чабаталар булса-а! Илләмә дә шәп булырлар иде йөрергә! Чабата киеп һөҗүмгә күтәрелсән—немец авызын ачып, атарга да онытып басып ката бит инде! Штык белән минем чәнечкәнне көтеп!» Госпитальдән чыгарга бер көн кала сорадылар:

—Себер дивизиясе оеша. Монда—Алтайда. Руссовский исемле бер зур авылда. Теләгегез булса, шунда озатабыз. Әгәр инде теләгегез булмаса, Новосибирскига озатабыз. Уйлагыз!

Вильданов сорарга җөрьәт итте:

—Бер генә атнага булса да өйгә кайтарыгыз. Чак йөрим бит, күреп торасыз.

—Сез нәрсә-ә?!—диделәр анар.—Нинди өй ди ул. Сугыш бара!

—Анысы шулай да... Тик минем хәлне күреп торасыз бит. Бу аяклар белән мин ничек сугышыйм ди инде?!

—Фронтка барып җиткәнче кимендә ай ярым үтәчәк. Шул вакыт эчендә аякларыгызга ныклап басачаксыз. Сөякләренә зыян килмәгән бит. Тылга түгел, ә патриот булып фронтка омтылырга кирәк!

Бу сүзләрне ярыйсы гына корсак үстергән госпиталь комиссары әйтә иде...

Себер дивизиясенә китәргә дип, госпитальдән алар өчәү чыктылар. Зәйни җайлап кына атлап хәрәкәт итә ала иде. Тик аякларының үкчәсен үкчәгә китереп куя алмый. Аның белән госпитальдән бергә чыкканнарның икесе дә батальон комиссарлары. Яна оеша башлаган дивизия штабы

монда—Бийскида икән дә, ә личный состав каладан 32 километрда утырган Руссовский исемле авылда икән.

8 март көнне дивизия штабына килеп үзләренең килгәннәре турында әйттеләр. Дивизия командиры подполковник Улитин, ә дивизия комиссары Никитин икән. Дивизиянең штаб начальнигы подполковник Комлев бик тә житди кеше икән. Штаб начальнигы өчесен дә кабул итеп, алар белән тиз генә танышты да дивизия яшәгән Руссовский авылына китәргә боерык бирде:

—Уңышлар телим яңа дивизияда!—диде.

Шул кичне шәһәр кунакханәсенә кереп кундылар. Икенче көнне дивизиягә китәргә кирәк иде. Тик ике комиссар да иртән гарнизон ашханәсенә кергәннән соң, кич булганчы шуннан чыкмадылар. Көне буена аракы эчеп, бер-берсенә зарларын сөйләп утырдылар. Урамда караңгы төшеп килгән вакытта бер-берсен танымаслык хәлгә килеп житкәннәр иде. Көч-хәл белән кунакханәне табып (урам аша гына!), йокларга яттылар. Икенче көнне иртүк алар тагын хәрби ашханәдә иделәр һәм... кич булганчы тагын шунда хәмер чөмереп көнне уздырдылар. Өченче көнне дә шул ук хәл кабатланды. Зәйни Вильдановның бу күренеш белән беренче мәртәбә очрашуы иде. Муллалы-мәчетле татар авылында үскән егетнең «кара эчү» белән эчкән урысларны беренче мәртәбә шулай якыннан күрүе иде бу. Андый күренешне урыслар бер генә сүз белән атыйлар икән: «Запой!» Дүртенче көнне төнге уникенче яртыда сәрмәнеп кайтып кергән ике исерек комиссарның кесәләреннән документларын алып, үзенең мендәре астына тыгып ятты. Иртән иртүк тегеләр уянмас борын торып юынды да, дивизия штабына юнәлде. Штабта дежур булган капитанга комиссарларның документларын сузды:

—Иптәш капитан! Инде бүген бишенче көн китә—туктамастан эчәләр. Дивизиягә баруны уйламыйлар да. Мин берүзем китәм бүген. Бу документларны дивизия штабы начальнигына бирегез. Комиссарлар икесе дә хәрби ашханәдә утыралар. Көнозын. Шуннан табарсыз. Минем фамилиям кече лейтенант Вильданов. Хушыгыз.

Зур авырлык белән булса да, жәяүләп чыккан иде. Кала читенә житә башлаганда чаналы ат куып житте. Руссовский авылына кадәр шул чанага утырып барды. Авылга барып житкәч, андагы штабны тиз тапты. Бийскида күрергә насыйп булмаган дивизия командирын мондагы штабта күрде. Штаб буенча дежур өлкән лейтенант Вильдановның документларын алып «Комдив подполковник Улитин Н. Н.» дип язылган ишеккә кереп китте. Минут чамасы да үтмәгәндер, әйләнеп тә чыкты:

—Керегез!

Зәйни кабинетка керде дә, сакланып кына басып өстәл янына килде. Честь бирде:

—Иптәш подполковник! Кече лейтенант Вильданов сезнең тарафка хезмәт итәргә килде!

Подполковник урыныннан торып өстәл арасыннан чыкты. Кече лейтенантның аякларының үкчәләрен бер-берсенә терәп басмаганын, «устав бозып» торганын күреп акырып жибәрде:

—Үкчәләренне бергә куеп, тиешенчә ба-ас!!!

Вильданов тоныкы кына тавыш белән подполковникның күзләренә карап жавап бирде:

—Булдыра алмыйм! Аяклар жәрәхәтләнде минем—тыңлап бетермиләр!

Подполковник каушап төште. Зәйнигә якын ук килеп күрешергә кулын сузды:

—Әллә фронтовикмы?

—Так точно! Ленинград фронтыннан мин!

Подполковникның каушавы тагын да артты:

—Мин бик хөрмәт итәм фронтовикларны. Гафу ит мине! Ленинградлыларны бигрәк тә хөрмәтлим. Утыр! Утыр! Нәрсә, осколокмы, пулямы?

—Юк шул! Ике аяк та өшегән иде, пулемет артында немец һөҗүмен кире кагып атып ятканда. «Невский Пятачок»та...

Алдындагы кәгазьләрне читкә этәреп куйды комдив:

—Бик вакытлы килдегез безгә. Бер полкта огнемет взводы оештырырга боерык бар. Шул огнемет взводы командиры итеп билгеләрбез сезне. Полк командиры майор Сычев...

—Ут взводы? Нәрсә була ул?

Подполковник көлеп куйды:

—Үзем дә белмим, лейтенант. Ут сиптерә торган кораллар белән коралланган взвод булырга тиеш дип уйлыйм. Тик коралларын күргәнем юк, күз алдына да китерә алмыйм. Дивизиядә андый коралның әле берсе дә юк. Булырмы—билгесез. Ә взвод булырга тиеш һәм мин инде взвод бар дип өстәгеләргә язма рәвештә хәбәр итәргә дә тиешмен. Син полк командирына гына турыдан-туры буйсыначаксын. Батальон командирлары белән бертигез буласың, буйсыну буенча.

—Һм! Иптәш подполковник! Мин бит ул коралларны белмим дә... Ничек иттереп мин андагы халык белән командалык итәрмен?

—Армияне беләсең бит инде! Коралы килсә, инструкциясе да килә. Укырсың, белерсең, кулланырсың. Белемен ничек? Җиде сыйныф бармы?

—Урта белем минем.

—Ну-у, Вильдано-ов! Урта беле-ем! Булды болай булгач. Бу белем белән сугыш вакытында синнән генерал ясап була.

Өстәл артына кереп утырды да, сүзен дәвам итте:

—Син билгеләнгән полк әле урман кисә. Бер төрле дә корал юк хәзергә. Шунлыктан хәрби әзерлек тә үткәрелми. Тик окоп казырга гына өйрәтәбез...

Үзенең дивизия командиры булганы исенә төште:

—Ярар, огнеметларны читкә куеп торыйк. Син фронтта ничек сугыштың һәм нәрсә эшли беләсең?

—«Дегтярев» һәм «Максим» пулеметларын яхшы беләм. Окоп, блиндаж төзелешләрен дә яхшы гына өйрәндем дияргә була. Кул сугышын беләм. Бик күп кул сугышларында катнашырга туры килде. Үзебезнең автоматны да, немец автоматы Шмайссерны да яхшы беләм. Аннан немецларның «МГ» дигән пулеметын да беләм. Шәп пулемет.

—Әллә «Максимнан»да әйбәтме?

—Әйбәт шул. Патрон лентасы корычтан ясалган «МГ»ның. Ә «Максим»ның патрон тутыра торган лентасы юка брезенттан. Юешләнсә, пулемет эченә керми башлый шул. Атып булмый шуннан соң... Сугыш күрсәтте—һәр полкта бер взвод автоматчылар һәм бер взвод пулеметчыларны оештырырга кирәк. Аларны немец бәреп керә башлаган урынга ташларга, дошман һөҗүмен кире кагу өчен кулланырга була.

Подполковник азрак уйланып утырды да, үзенең уйларын әйтте:

—Сез, лейтенант, сугыш утын үткән офицер. Ә без әле немецны күргәнебез дә юк. Мин дивизия офицерларын клубка җыеп утыртыйм һәм ул сезнең белән очрашу булсын. Ничек сугыша башлагансыз? Финнар нинди, немецлар ниндидер—сөйләрсез! Бигрәк тә аларның сугышу ысулларына туктарсыз! Авиацияләре, артиллерияләре ниндирәк? Иң мөһиме: немец солдаты ничек коралланган һәм ничек итеп сугыша белә. Басып керүләренә караганда, оста сугышчылар булырга охшаган. Чөнки безнең пропаганда тиз җинәбез немецны дип... э-э...

Тәвәккәлләде:

—... тиз җинәбез дип шапырынудан туктады...

Подполковник үз башы белән уйлап яши торган шәхес иде бугай. Яшь кенә кече лейтенанттан тырыш укучы кебек сугыш турында төпченде дә төпченде. Вильдановның сөйләгәннәрен тыңлаган саен аңар хөрмәте артты. Тулысынча «сез»гә күчте:

—Беләсезме нәрсә, Вильданов?! Корал килә башлау белән мин сезгә бер группа командирлар һәм сержантлар бирермен. Шуларны

үзегезнең тәҗрибәдән чыгып корал белән, бигрәк тә пулеметлар белән эш итәргә өйрәтерсез. Сезнең дивизиягә килүегез минем өчен зур уңыш! Минем өчен генә түгел, барлык дивизия өчен. Сез—беренче фронтовик! Сезнең полк урман кисә. Сезне ул эштән азат итәм. Аерак тирә-якка карап ял итеп алыгыз. Шулай ук өч батальоннан кешеләр сайлап алып исемлек төзеп, огневой взводны булдырыгыз. Исемлеккә Сычев кул куйсын. Алай-болай комиссия килеп төшсә, күрсәтербез шул исемлекне. Взвод булгач, махсус коралын да сорарбыз.

Сычев—майор. Фин сугышының беткән бер атнасын гына сугышып калган. Ул командалык иткән полк Боровлино исемле авылда, шуннан ике генә чакрым урында, таулар арасында урман кисә. Ул эштән дивизия командирының кушуы буенча азат ителгән кече лейтенант Вильданов Руссовский авылында бер карт белән карчыкта фатирга урнашты, көннәр буена бернәрсә дә эшләмичә, күбрәк вакытын йоклап үткәрә башлады. Шунда гына аңлады: «Невский Пятачок»тан ул бик нык арып, ватылып чыккан икән. Күрәсең, госпитальдә дәвалану да аны савыктырып бетермәгән. Атна-ун көннәр узгач кына Зәйни аякларына ныклап басып, авыл урамнарында йөри башлады. Комдив кушканча, батальоннарны урман кискән җирләрендә йөреп чыкты. Исемлек төзеде һәм огнемет взводын кәгазьдә булдырып та куйды. Исемлекне тырышып төзи торгач, бер ай эчендә бу взводта илле ике кеше санала иде инде. Кәгазьдәге исемлектә генә булса да...

Апрель урталары җитеп, язгы сулар кузгала башлаганда, ике көн эчендә дивизияга күп итеп корал һәм житешмәгән халыкны китереп тутырдылар. Китте көн-төн тревога белән алып чыгып китеп, йөгертә-атлый марш-бросоклар ясау, штык сугышына өйрәнүләр, винтовкадан, автомат-пулеметлардан атулар, граната ыргытырга күнегү үткәрүләр... «Ура» акырып, авыл тирәсендәге кечкенә булса да, текә тауларны штурмлап атакага йөгерүләр...

1942 елның 1 май иртәсендә Бийскидан дивизия халкы тутырылган беренче эшелонның «телячий вагоннары» көнбатышка—фронт ягына чыгып та китте. Шул эшелонда «Максим» һәм Дегтярев пулеметлары белән коралланган «Ут взводы» да, аның командиры кече лейтенант Вильданов Зәйни дә бар иде. Ул инде аякларыннан киез итекләрен салган, аларны үзе яшәгән фатир хуҗасына калдырган. Аякларына зур, 45 нче размер күн итекләр киеп алды. Йөргән чакта аяклары авыртса да, түзәргә, күн итекләргә өйрәнергә кирәк иде. Җәй житеп килгәндә фронтка киез итекләрдән барып булмый бит инде.

Хәрби эшелон Бийскидан Казан аша Воронежга юл тотты. Атаклы Кабан күлен Зәйни вагон тәрәзәсеннән генә күреп калды...

Эшелон Урал тауларын кичкән көннәрдә безнең гаскәрләр Харьков каласы янында зур һөҗүмгә күчкән, коточкыч каты бәрелешкә очрап, бик ныклы чолганышка эләккән. Шунда җинелүгә дучар булган берничә армия тигез далада юк ителә башлады.

1942 елның башында Кызыл Армиянең Генераль Штабы начальнигы маршал Борис Михайлович Шапошников докладына ышансаң, Германия Армиясе 1942 елның җәендә Мәскәү каласына башка һөҗүм итмәячәк икән. Җәйге немец һөҗүменең төп юнәлеше Ростов аша Кавказга булачак. Һөҗүмнең төп максаты Кавказ нефтенә Германия хуҗа булырга тиеш! Германиянең Генераль Штабы планы буенча үзләренең танк һөҗүмнәрен кин итеп алып барыр өчен СССРның көньяк далалары аша Кавказга ыргылырга кирәк. Нефтьнең төп чыганагы булган Кавказ яулап алынгач, немецлар Кавказ тауларын көньякка табан кисеп чыгып, Иранга бәреп керергә тиеш. Һәм андагы нефть промыселларына да Германия контроле булырга тиеш. Сугышны җиңү белән тәмамлау өчен Германиягә нефть житешми иде.

Даһи Сталинның фәрманы буенча Кызыл Армия язгы ташулар үтү белән Харьков янында зур һөҗүмгә күчәргә тиеш һәм дошманны тар-

мар итеп ташларга тиеш. Ә Шапошников тәкъдим иткән һөҗүмгә күчмичә «актив оборона» гына оештыру белән Сталин килешмәде. Чөнки даһи кеше даһи бит инде ул—анын белмәгәне юк. Анын өчен картаеп барган маршал Шапошников кем ул? Кичәге көн! Анын уйларын исәпкә алмаска да мөмкин!

Дала юллары кибеп бетмәс борын ук Харьков тирәләрендәге өч фронт һөҗүмгә күчә. Кызыл Армия «полководецларынын» мемуарларында 1942 елнын язындагы ул һөҗүм турында бер генә мәгълүмат та табып булмый. Әйтерсен лә, андый фаҗига бөтенләй булмаган да.

Кайсысы дөрестер—бүген дә ул хакыйкать бездән яшерелгән. Бер фараз буенча Кызыл Армиянен ул һөҗүме турында планны немец разведкасы шул елнын февраль аенда ук үз кулына төшерә алган. Икенчесе, имеш, безнен элемтә офицеры шул планны самолет белән алып барган чакта, тегеләр аны бәреп төшергән һәм план алар кулына эләккән.

Беренче фараз дөреслеккә туры килә. Чыннан да, апрельдә башланган Кызыл Армиянен һөҗүмен фашистлар бер ай эчендә йомшак пирог кискәләгән кебек тураклап ташладылар. Алар башта чигенгән булып кыйланып, зур «капчык» ясадылар. Һәм безнекеләр шунда кереп чумгач, капчык авызын бәйләп куйдылар да аларны юк итәргә тотындылар. Безнен гаскәрләрнен күпчелеге шул «капчык»тан чыга алмады. Әсир төшкәннәрнен саны гына да 1,5 миллионнан артып китә. Харьков катастрофасыннан сон Мәскәүгә көньяктан Воронеж аша юл ачыла. Ә инде немец Сталинград яныннан Иделгә килеп чыккач, Мәскәүгә тагын бер юл барлыкка килә. Сталинградтан Идел буйлап. Тик немецнын төп максаты 1942 елнын җәендә Мәскәүне алу түгел, ә Ростов-Дон аша Кавказ нефтенә барып чыгып, шуна хуҗа булу!

Харьков янындагы җинелүгә өстәлеп, Кырымдагы Керчь каласын югалту зур фаҗига була. Керчь каласын алып, шундагы гаскәрләрне тармар итү өчен атаклы немец полководецы фельдмаршал Фон Манштейн үзенен талантын да, көчен дә күп куя, ул кискен һәм тәвәккәл хәрби операция үткәрә. Севастопольны штурмлау белән дә ул житәкчелек итә. Севастопольне штурмлаган немец гаскәрләренен пехотасынын 70 процентка якынын кичен машиналарга төятә дә, Керчь ягына озата. Авиация, танкларнын барысы да диярлек икенче көнне иртән Керчь һәм Феодосия калаларына ябырылалар. Шул калаларга каршы бик күп артиллерия да кулланыла. Ул операцияга «Дүдәк ауы» дип исем бирелә. Севастопольгә ярдәмгә дип төшерелгән Керчь-Феодосия десанты юк ителә.

Акыллы, тәвәккәл фельдмаршал Фон Манштейн Гитлердан «Дүдәккә ау» өчен өстәмә бер генә солдат та сорап алмый. Гитлер үзе дә бирми.

Брезент белән кузовы капланган йөк машинасына төялгән унике башкисәр немец солдаты Таманьга чыга торган биш чакрым кинлектәге бугазга ашыга. Шул бугаз ярында утыра да инде Керчь каласы. Машинанын арттан тенты төшерелгән—кем утырганы күренми. Машина кабинасында—икесе дә мундирларын салган шофер белән немец фельдфебеле. Башка сыймаслык кыю боерык бирелгән аларга: Керчь крепостен басып алырга. Ул крепость Керчь каласыннан 15 чакрымда Кавказ ягына караган урында. Ул урын Ак Борын дип атала. Нәкъ шул Ак Борын янында Азау дингезе белән Кара дингез очрашалар да инде. Шул ике дингез очрашкан урыннын кинлеге биш чакрым гына. Бугазнын Кырым ярында Керчь крепосте утырган, ә инде Кавказ ярында Тамань исемле крепость басып тора. Бер дингездән икенче дингезгә керү-чыгу тулысынча шушы ике крепость тарафыннан тикшерелеп, рөхсәт итеп кенә башкарыла.

Керчь крепосте 1762-70 елларда төрек солтаны тарафыннан салынган булган. Яр артиллериясенен алты зур калибрлы туплары бер дингездән икенче дингезгә рөхсәтсез тыгылырга маташкан дингез корабларын юк итү өчен куелганнар да инде.

Унсигезенче гасырнын икенче яртысында Төркия белән сугыш

алып барган чакта, урыслар вакытлыча, сугыш беткәнче генә дип акча түләп, Кырым ханын алдыйлар. Хан үзенең алтынга комсызлыгы өчен ханлыгы белән түли. Урыслар сугыш беткәч тә Кырымнан чыкмыйлар. Төрек крепостьләре булган Судакны, Керчьне ачлык белән буып, бирелергә мәҗбүр итәләр. Кырым тулысы белән урыс кул астына эләгә. Соңгы Кырым ханы берничә елдан Франциягә чыгып китә. Гәрәй Ханнарның нәселе шунда француз каны белән буталып юкка чыга.

Унике башкисәр белән командалык иткән фельдфебель инде Франция, Польшаны яулап алуда катнашкан бик тә оста, куркуны белмәс сугышчы булып исәпләнә. Һәм ул шулай да! Ул үзенең кечкенә кыю отряды белән һәрвакыт алгы сызыкта, һәм иң кискен эшләрне башкара белә. Бүген дә шулай—алар Керчь крепостен алып, немец гаскәрләре килеп житкәнче аны үз кулларында тотарга тиешләр!

Фельдфебель дә, аның шоферы да урысчаны яхшы беләләр.

Ә фельдфебель Керчь кирмәненең төзелешен яхшы белә. Кичә кич боерык биргән чакта аңарга кирмәннең кечкенә схемасын да тоттырганнар. Тиз хәрәкәт итеп кирмәнне алу операциясе жентекләп әзерләнгән була. Керчь каласы ягыннан килгәндә кирмәнгә керә торган ике зур тимер капка бар. Кирмән диңгез яры белән 200 метрга сузылган һәм анда тагын ике капка бар. Капкаларның барысы дүртәү. Кирмән диварлары Әче Мөшкә (Урыслар ул урынга Аджимушкай дип үзләренчәрәк исем биргәннәр) ташыннан салынганнар. Диварларның киңлеге 4-5 метр чамасы булып, биеклеге 13-15 метрларга житә...

Немец десантчылары кала ягындагы бер капкадан туктамастан кирмән эченә килеп керәләр. Машина тизлеген азрак акрынайта биреп, сулга, икенче капка ягына борыла башлый. Арттан тент ачылып китә дә, аннан кулларына автоматлар тоткан өч солдат сикереп төшә. Дүртенче булып «МГ» пулеметы күтәргән таза гәүдәле солдат сикерә. Ул шунда ук пулеметын өчаякка утырта да, аның артына сузылып ята. Автоматлы солдатлар капка тирәсендә утырган, яткан, тулган совет гаскәрләренә кискен боерык бирәләр:

—Хинде хох! Кулларыгызны күтәрегез!

Биш-алты минут та үтмәгәндер—дүрт капка да эчтән ябылып бикләнә. Диңгез ягына чыккан ике капка башына, диварга ике «МГ» пулеметы утырталар. Фельдфебель кирмән эчен күзләреннән кичерә дә, автоматын корсагына терәп, кирмән эчендә аны-моны уйламыйча арлы-бирле йөренгән сугышчыларга ут ача. Шуны гына көткән дүрт пулеметтан, автоматлардан кирмән эчендәге халыкны кыра башлыйлар. Ыңгырашу, кычкыру, акыру, кая керергә белмичә йөгерешү—кирмән эчендә паника башлана. Фельдфебель чехолыннан ракетница алып, һавага ракета жибәрә. Пулемет, автоматлардан ату туктала. Немец кулындагы автоматын һавага күтәрә дә, көчле тавыш белән кычкырып сөрән сала:

—Рус Иваннар! Сез тулысынча уратып алынгансыз! Крепостьтан чыга алмыйсыз! Капкалар ябык! Коралларыгызны ташлагыз! Һәм барыгыз да диңгез ягындагы дивар буена төшеп утырыгыз. Сез бөек Германия әсирләре булдыгыз! Каршы торганнарны һәм алар белән бергә башкаларны да атып юк итәчәкбез! Ике минут вакыт сезгә. Ике минуттан кем кулында корал кала, ул атылачак. Дивар янына төшмәгәннәрне дә атачакбыз!..

Берәүнең дә пулеметлар уты астында үләсе килми! Сан ягыннан меннән артык совет сугышчылары бердәм булып, коралларын ташлап, диңгез буендагы дивар ягына агыла башлый. Берничә урында командир-комиссарлар каршы торуны оештырырга тырышып карыйлар. Күбесен үзебезнекеләр үк урыннарында аталар, кайберләрен прикладлар белән сугып егып коралсызландыралар. Керчь-Феодосия десантының сугышчылары шулай тар-мар ителә...

Унике батыр немец солдатын һәм алар белән житәкчелек иткән фельдфебельне, шофер солдатны бер ай чамасы узгач Фюрер үзе кабул итә! Рейхсканцеляриядә! Барысын да кочаклый, кулбашларыннан

шапылдатып яратып чыга. Һәм барысына да Вермахтның солдат өчен булган иң зур орденын тапшыра. Ул—Имән яфраклы солдат тәресе. Солдатларының күкрәгенә тәреләрне үз кулы белән тагып чыга Гитлер...

1942 елның 4 июнендә Кызыл Армия Севостопольне дошманга калдыра. 2 июньдә, төнге унике узгач, Севостополь оборонасы белән житәкчелек иткән адмирал Октябрский үзенен штабына дивизия командиры генерал Новиковны чакыртып китерә. Новиков—керәшен татары. Һәм аның шулай икәнен штабта бар да беләләр иде. Чөнки жае чыккан саен генерал Новиков «без татарлар» дип мактангалап сөйләшергә ярата торган кеше иде. Төтеннән, снаряд-бомбалар шартлаудан өс-башы, биткуллары кап-кара булып беткән, берничә урыннан киеме ертылган. Новиков штабка килеп кергәндә анда генераллар, адмираллар, полковниклар бар иде. Күпчелек Новиковка карамаска тырыша—аны ни өчен Октябрский чакырганны беләләр. Новиков тоткарланмыйча Октябрский кабинетына узды.

Адмирал анарга утырырга тәкъдим итеп тә тормады. Сүзне кыска тотты:

—Иптәш Сталиннан радио аша боерык бар: Севастопольне тагын өч көн бирмәс өчен сугышырга. Кырым синең... фәлән ителгән татар республикасы. Син дә татарсын. Менә минем урынга кал да, бирмә Кырым республиканны фашистка. Үтә Сталинның боерыгын! Ә без—Оборона житәкчеләре ярты сәгатьтән су асты көймәсе белән Кырымнан китәбез. Оборона сиңа йөкләтелә!

—Китмисез сез, ә качасыз!—диде Новиков карлыккан, жирәнечле тондагы тавыш белән.—Сталинның «тагын өч көн оборона» дигәне сиңа су асты көймәсе белән качарга рөхсәт түгел. Шушында Севастопольне яклап үләргә боера ул сиңа. Сугышып үләргә ул боерык!

Октябрский кулында «ТТ» пистолеты пәйда булды:

—Атып үтермәс борын бар чыгып кит! Сугыш! Герой булырсың! Посмертно! Татарин е...!!!

Новиков адмирал кулындагы пистолетка мыскыллап карады:

—Әйе, татар мин. Тик синең кебек куркак жан түгел. Һәм Кырым республикасы да—татар республикасы. Сугышырмын! Боерыгына кул куеп бир!

Октябрский артында штаб начальнигының куркынган йөзе күренде. Ул Новиковка кул куелган боерыкны тоттырды. Генерал аны укып та тормыйча, берничәгә бөкләп түш кесәсенә тыкты да, честь бирмичә, хушлашмыйча чыгып китте...

Севастополь урамнарында, Сталин таләп иткән өч көн урынына, тугыз көн, тугыз төн туктаусыз сугышлар барды. Октябрский штабы тарафыннан сугышчыларның күпчелеге, корабльләр житешмәгәнлектән, Севастопольдә ташлап калдырып кителгән иде. Тормышларына кул селтәгән ул сугышчылар үз-үзләрен аямыйча сугыштылар да сугыштылар. Моряклардан гына торган соңгы төркем Граф Пристане дип аталган урында кул сугышында һәлак булды. Иң соңгылардан булган, жәрәхәтләнеп кара канга баткан биш матрос «Варяг»ны жырлап, бердәм булып соңгы һөжүмгә ташланды. Немец солдатлары аларны шул Граф Пристаненың баскычларында автоматлардан атып үтереп бетерделәр. Севастополь бирелде...

Урамнарны тутырган ватык кирпечләрне аралап машина узарлык кына тар юл ачтылар. Фон Манштейн жиңелгән Севастопольне машинасыннан төшмичә генә карап чыкты. Шәһәрнең ватык кирпечләре белән аралашып матросларның, солдатларның үле гәүдәләре ята иде. Тере кала алган әсирләр үлекләрне йөк машиналарына төяп, дингез пристаньнарындагы баржаларга ташыйлар. Манштейнның боерыгы кыска: дингезгә батырып бетерергә!

Севастопольне карап чыккач, фельдмаршал «Гавана» сигарасын кабызды да үзенең штаб начальнигына мөрәжәгать итте:

—Әсирләр әйтүенчә, адмирал Октябрский су асты көймәсе белән

качкан. Севастопольдәге соңгы урам сугышлары белән генерал Новиков командалык иткән. Тере булса да, үле булса да—генералны табарга! Әсирләрне барлап, карап чыгыгыз. Тере булса, миңа алып килегез. Ә инде һәлак булган булса, батыр сугышчыга тиешле хөрмәт белән күмүне оештырыгыз. Мин дә катнашырмын...

—Йаволь!

Тик генерал Новиков тереләр арасында да, мәетләр арасында да табылмады. Имеш-мимешләргә караганда, әсирлеккә төшмәсен өчен аны, имеш, янындагы НКВД капитаны атып үтергән. Кирәге беткәч...

Татар халкының батыр улы генерал Новиковның язмышы бүгенге көнгә кадәр билгесез. Кирәге беткән, татар генералы булганы өчен аны инде «данлыклы урыс тарихы» онытты...

Июль аенда немец гаскәрләре Сталинградка һәм Ростовка һөҗүм башладылар. «Группа Б» дип йөртелгән гаскәрләре Дон елгасының тамагында утырган Ростов каласы аша Кавказга ыргылдылар. Бу аларның 1942 елның җәендә уздырыла торган төп максатлары иде. Кавказны яулап алганда шул максатка ярдәм итү өчен алар Сталинградны алырга карар кылдылар. Иделдән нефтьне Үзәккә ташуны киссәләр, Советларның озак яшәмәячәген алар яхшы аңлыйлар иде.

Июль аеның урталарында инде Сталинградка 100 километрдан да аз ара калган иде. Әмма шул дала озынлыгын фашистлар ике айга якын үтә алмады. Чигенүче һәм аларга ярдәмгә тылдан ашыгучы Кызыл Армия частьләре канлы оборонадан бертуктаусыз контр һөҗүмнәргә күчеп, каты сугышлар алып барды. Украина далаларыннан алып Сталинградка кадәр булган кырлар ике яктан да һәлак булган солдат, офицер мәетләре белән түшәлде. Дошманның оста оештырылган сугышларыннан рухы сынганнар корал ташлап кача башлады. Менә шул чакта Сталинның үтә дә мәкерле, хәйләкәр акылы 1942 елның 28 июлендә 227 номерлы атаклы боерыгын китереп чыгарды. Фронт халкы ул боерыкка исемне төгәл һәм кыска гына итеп такты: «Ни шагу назад!» Шул 227 нче боерыкны тормышка ашыру өчен, оборона тоткан, яисә һөҗүмгә барган гаскәрләр артына яхшы коралланган, яхшы киендерелеп, яхшы ашатылган НКВД частьләре куела башлады. Окоп ташлап качучыларны арттан «үзебезнең» НКВД кешеләре атып юк итә иделәр. Сугышмыйча гына кара! Чигенгән частьләрнең командирларын, берниндиі дәлилләргә дә карамыйча, атарга хөкем итеп, үз сугышчылары сафы алдында атып үтерделәр. Сугышырга сәләте булмаган Кызыл Армиянең урта, югары командованиесының һәм бөек Сталинның «даһи наданлыгын» гади сугышчылар каны белән юа башладылар. Ныклап, сугыш бетеп, җиңү көне килеп житкәнче!

1942 елның башында ук җәйге һәлакәтне булдырмаска тырышкан Генштаб начальнигы маршал Борис Михайлович Шапошниковның да язмышы фаҗигале булып бетте. 1941 елны сугыш булмый дигән кебек, 1942 елны немец һөҗүме турында Сталин тагын ялгышты. Тик ялгышкан өчен Сталинны урыныннан куарга кеше юк иде шул. Үзен-үзе куа алмый бит инде?!

Язгы җиңелү тулысынча ачыклангач, Шапошниковка Генштабтан китәргә тәкъдим ясадылар. Маршал көзлегән салды да, кадрлар белән шөгыльләнүче генералга күзләрен текәде:

—Ни өчен мин китәргә тиеш?

Штаб эшеннән куылса, маршал үзенең озак яшәмәсен яхшы аңлый иде.

Генерал уңайсызланганын яшерер өчен йөткергәләгәндәй итеп алды:

—Э-э... Үзегез дә аңлыйсыздыр... Язгы компания турында сезнең концепция дөрес булып чыкты. Шунлыктан сезне һәркөнне күреп эшләү... э-э-... Главнокомандующийга... э-э... җинел булмаячак...

Шапошников шулай итеп, Генштабтан куыла. Ел ярым вакыт үткәч, барлык кешеләр тарафыннан онытылып, үзенең кабинетында дөнья белән хушлаша. Кирәге бетте!

Аның урынына генштаб начальнигы итеп генерал Васильевский Александр Михайлович билгеләнә.

«Доннын зур борылмасы» дигән урын Сталинградтан 60 километрлар чамасында. Ул урын—Дон елгасының Иделгә ин якын килгән урыны. Немец гаскәре, Донны шул урында 25 июньдә кисеп чыгып, Идел ягына һөҗүмнәрен көчәйтте. Шул 60 километрга сузылган далада бер ай буена канкойгыч каты сугышлар барды. 6 августта, караңгы төшә башлагач немец танклары Сталинградтан 3 километр төньяктарак Идел елгасы ярына килеп чыктылар...

Сталинград сугышы башланды. 23 августта таң белән башлап, караңгы төшкәнче немец авиациясе Сталинград каласын бомбага тотты. Шул көн эчендә Сталинградка 2000 (ике мең!) самолет очышы ясалды. Сталинград һава һөҗүменә каты каршы торды. Немец авиациясе бер көн эчендә 120 самолетын югалтты. Сталинградта бик каты янгыннар башланды. Яртысыннан күбесе агач йортлардан торган шәһәр август эссесендә дары сипкән кебек кызып янырга тотынды. Эсселек кала эчендә шулкадәр иде, хәтта тик торганнан телеграф баганаларына да кинәт ут кабына торган булды. Эсседән, бомба тиюдән шартлаган нефть цистерналарыннан аккан нефть Идел өстен каплап яна иде...

13 сентябрьдә Сталинградта урам сугышлары башланды. Һәм алар 1943 елның февраль башына кадәр туктамастан барды. Ул сугышлар турында фашистларның үзләренең язганнарыннан, сөйләгәннәреннән:

—Сталинградны берничә көндә алып бетерәбез!

—Большевиклар крепосте фюрерның аяк астында!..

—Шәһәр соңгы көннәрен яши!!!

31 август көнне Гитлер язма боерык бирә: «Сталинградта яшәүче ирләрне юк итәргә! Хатын-кызларны шәһәрдән куарга!»

Үлгән немец солдаты кесәсеннән табылган хаттан: «Кадерле Эльза! Тиздән, бәлки иртәгә үк мин Волгадан су эчәчәкмен! Җиңү якын!!!»...

Тик җиңү немец солдатына күренгән кебек кенә якын түгел иде шул! Сталинградта урам сугышлары көчәйгәннән-көчәя генә барды. Сугыш йортлар өчен генә түгел, ә йортның катлары, хәтта бүлмәләре өчен дә бара иде...

Харьков, Керчь, Сталинград, Кавказ сугышлары турында язуыбыз, яңа гына госпитальдән аяклары төзәлеп тә бетмәгән килеш чыккан егерме бер яшьлек Зәйни Вильдановның нинди зәһәр «иттурагычка» килеп кергәнен аңлату өчен кирәк иде алар. 1942 елның май башларында 115 нче Себер дивизиясе, Воронеж каласыннан кырык чакрымнар чамасы төньяктарак Дон елгасын көнбатышка табан кисеп чыгып, Воронеж—Мәскәү юлының ике ягында биш километрлы оборона урыны алды. Огнемет взводына ут ата торган корал килмәде. Шуңлыктан дивизия командирының күрсәтмәсе буенча Зәйни Вильданов төзегән взвод «Огневой взвод» исемен йөртсә дә, тик пулеметлар белән генә коралланган иде. Воронежны сулда калдырып, дошманның «А» группасы Сталинградка, ә «Б» группасы Кавказга керер өчен һөҗүмнәрен җәелдергәч, зур уңышларга ирешә башлады.

Майор Сычев командалык иткән полк Воронеж—Мәскәү шоссе юлы узган урында «Таш вату калкулыгы» дигән урынны сакларга тиеш иде. Бу таудан Воронежны төзү өчен дә, юллар салу өчен дә, бу якларга урыслар килеп төпләнә башлаганнан бирле таш чыгарганнар. Моннан йөз еллар элегрәк 600 метрлар чамасындагы тауны урталай ярып, 100 метр чамасындагы киңлектә итеп таш ала башлаганнар. Ташны күп чыгарганнар һәм җир астыннан күпсанлы чишмәләр бәреп чыга башлагач кына таш чыгаруны туктатканнар. Урысларның кайсысыныңдыр акыллы башына уй килгән. Һәм Воронеждан Мәскәүгә үтә торган кәкре юлны турайтып, шушы тауны казыган чокыр аша үткәрергә карар кылганнар. Бу турылау нәтиҗәсендә Мәскәүгә бара торган юл илле чакрым чамасына кыскарып та куйган.

115 нче Себер дивизиясенең бурычы бер генә: дошманны Воронеж юлыннан Мәскәүгә үткәрмәскә! Артиллеристларның алты пушкасын һәм «Огневой взвод»нын унике пулеметын тауның ташын чокып, шунда урнаштырдылар. Пулемет-пушкалар алдына калын итеп таш катламы өелде. Ата торган амбразуралар гына калдырылды. Взвод командиры кече лейтенант Зәйни Вильданов һәр пулеметтан үзе атып карады, ориентирларның ераклыгын берничә мәртәбә үлчәп чыгып, пулеметчыларга шул саннарны ныклап ятлатты. Тауның Мәскәү ягына чыккан урынында кечкенә инеш ага. Шунда суга йөри иделәр.

15 июль иртәсе иде. Кичә кич Вильдановка лейтенант дәрәҗәсе бирергә дигән боерык килде. Аны дивизиядән полк командиры майор Сычев алып кайткан. Шуны «юып», Зәйни кичен землянкада иптәшләре белән азрак «салып» утырган иде. Кояш белән бергә торып тиз генә юынды да, сул як флангта иң кырыйда урнаштырылган «Максим» пулеметын барып карарга дип землянкасыннан чыкты. Таш, куак араларына поскалап, йөгерә-атлый китте. Шулчак башындагы каскага көчле иттереп китереп суктылар сыман булды. Зәйни тәгәрәп китте. Егылган урынында хәрәкәтсез ята башлады—«үлде!» Егылганда зур таш артына туры килгән икән—атып тидерерлек түгел. Башын аз гына таш читеннән калкытып дошман ягын күзәтә башлады. Оборонада иң мөһиме—трехлинейкаң үзең белән булсын. Зәйни винтовкасын якынрак тартып алды. 60-70 метрлар немец ягында утырган юан өч имәннең уртадагысының бер жирендә акрын гына ботак селкенеп куйды. «Снайпер!» Күзләрен кыса-кыса озак текәлеп карый торгач, ботак-яфраклар арасында кеше гәүдәсен чамалап алды Зәйни. Каядыр китеп барган «рус швайн»ы немец снайперы өчен үлгән иде инде. Немец утырган жиреннән кабаланмый гына муенын сузып сулгарак карый һәм снайпер мылтыгын да шул якка жайлый иде. Зәйни дә сакланып кына винтовкасын таш читенә жайлап куйды да, тавыш чыгармаска тырышып, патронникка патрон күчерде. Тын алудан да туктады, жентекләп төзәп атып жибәрде. Ботаклар арасыннан башта снайпер винтовкасы килеп төште. Мин дә синнән калмаска тиеш бит инде дигәндәй, винтовкасы артыннан гөрселдәп хужасы да жиргә тәгәрәде.

Икенче көнне артобстрел, миномет уты бик көчле булды. Полкның химия хезмәте начальнигы капитан Жабраилов Максутның ике аягы тин снаряд кыйпылчыклары тиеп каты жәрәхәтләнгән иде. Үлеп эчәргә су сорый. Ә су юлын дошман бик каты пулемет утында тота. Зәйни шуышып булса да суга барырга уйлады, суны каска белән генә алып килергә булды. Кечкенә канау буйлап шуышып, калкулыкка күтәрелде. Калкулыктан соң тигез ялан-кыр китә иде. Басуга карагач Зәйни көлеп жибәрде: помидор басуы! Күбесе йодрыктан зур кып-кызыл помидорлар. Араларында ярылып, агып утырганнары да байтак. Туйганчы ашады да, гимнастеркасын салып, анын муенын каеш белән бәйләп, эченә помидор тутырды. Кирегә помидор тулы гимнастеркасын өстерәп шуышып кайтты. Жабраилов помидор ашаган арада хәнжәр белән анын итекләрен кисеп, ике аягын да бинт белән урады. Озак тотмыйча медсанбатка озатты.

—Сугыш беткәч, Кавказга кил. Минем туган авылым имам Шамил авылы. Гуниб исемле. Шунда сорашып табарсың. Кунак булырсың. Хуш, Зәйнулла. Рәхмәт сина! Хуш!

Атна үтүгә лейтенант Вильданов «За отвагу!» медале белән бүләкләнде. Бу анын булачак күпсанлы орден-медальләренең беренчесе иде. Снайпер пулясы Зәйнинең каскасын урталай ярып, баш тиресен аз гына сыдырып киткән икән. Медсанбатка барып та тормады. Сыдырылган тире янындагы чәчне азрак кырдылар да, «дәвалауны» йод сөртеп бетерделәр.

1942 елның декабрендә Воронежны сулда калдырып, безнең гаскәрләр һөжүмгә күчте. Фельдмаршал Паулюсның 6 нчы Армиясе Сталинград казанында юкка чыгып, агония үткәргән көннәре иде.

Сталинград янында башланган һөҗүм Харьковны янадан алып, Синельниково тимер юлы станцасына кадәр барды. Тик 1943 елның февраль азагы—март башларында Фон Манштейн каты контрһөҗүм ясады. Харьковны да кире алды һәм Кызыл Армия частьләрен дала буйлап тагын Сталинград ягына куа башлады. Дошманны Курск-Белгород калалары янында бер оборона сызыгында көчкә-көчкә туктата алдылар. Авыр канкойгыч сугышлардан соң ике як та хәлдән таеп туктады. Совет гаскәрләре туң җирне тешләре белән кимереп казып дигәндәй, оборона ныгытмалары төзеделәр. Туктаттылар Манштейнны! Һәм шул җирләрдә 1943 елның җәендә «Курск Дугасы» дигән зур сугыш булачак кәкре бер оборона сызыгы барлыкка килде. Шул Курск Дугасында булачак каты сугышлар көтә иде 115 нче Себер дивизиясен...

* * *

1943 елның март азакларында полк командиры подполковник Сычевны күрше дивизиягә күчерделәр. Дивизия командирының урынбасары итеп. Аның урынына кырык биш яшьләр чамасындагы яңа полк командиры килде. Ул милләте белән... немец иде. Бакыр мыеклы, калын таза гәүдәле, ялтырап торган кырган башлы иде подполковник Штельмах Рихард Иванович. Сычевны яраткан полк аны сагаеп каршы алды. Тик шинелен салгач күрделәр—күкрәгенең сул ягындагы ике орден янында кызыл бант белән уратылган Кызыл Байрак ордены кызыллы-аклы булып ялтырап тора. Андый кызыл бантлы орденнарны тик Гражданнар сугышы елларында гына искиткеч батырлыклар күрсәткән өчен генә биргәннәр. Яңа полк командирын дивизия командиры полковник Улитин үзе алып килгән. Полк офицерларын җыйдыртты да, кыска гына итеп яңа командир белән таныштырды:

—Сезгә яңа полк командиры иптәш Штельмах Рихард Ивановичны тәкъдим итәм. Кызыл Армиядә 1918 елның февраленнән бирле. Псков янында барган сугышларда яңа гына оеша башлаган Кызыл Армия ягына үзе теләп чыккан. Ике елдан артык сугышкан. Перекоп-Чонгар операциясе өчен Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән. Шунда каты җәрәхәтләнгән. Инде тагын үзе теләп 1941 елдан бирле сугышта. Әле каты җәрәхәттән соң госпитальдән чыгып безгә хезмәткә килеше. Милләте белән немец...

Елмайды да өстәде:

—Иптәш Эрнест Тельман кебек немец. Коммунист. Ышанып, яхшы итеп кабул итегез...

Курск Дугасында җирне көн-төн казыдылар да казыдылар. Дивизиянең җәйге сугышларга әзерлеген карарга дип, май азакларында фронт командующие армия генералы Рокоссовский үзе килде. Озын зифа буйлы, төскә-башка бик тә чибәр һәм сөйкемле кеше икән командующий. Дивизия командиры белән полк позицияләрен карарга да сугылды. Командующий машинадан чыга башлагач, аны полк командиры доклад белән каршы алды:

—Иптәш армия генералы! Миңа тапшырылган полк оборонага хәзерлек белән шөгыльләнә. Полк командиры подполковник Штельмах!

Рокоссовский честь бирә башлаган кулын күтәрергә дә, төшерергә дә онытып, Штельмахка караган көе шаккатып басып тора бирде. Ул нилектәндер нык кына каушый төшкән кебек иде:

—Се-ез...э-э-э... си-ин?..

Штельмах шатланып сүзсез генә баш селкеде.

—Рих-ха-ард! Син бит бу!—дип кычкырып колачын җәеп җибәрде фронт командующие.—Син теремени-и?! Штельма-ах! Син бит бу чыннан да, ә?!

Алга атлады да полк командирын кочаклап алды. Нык итеп кысып кочаклады ул аны, аркасына шапылдатып суга башлады.

—Ну и ну-у! Мин бит синең Чонгарда һәлак булганыңны үз күзем белән күрде-ем! Кавалерия һөҗүме вакытында снаряд сиңа туп-туры тиеп шартлады бит! Ә син тересең, өстәвенә полк командиры икәнсең бит әле!

Ике куллап кулбашларыннан тотып, Штельмахны аз гына арткарак этте дә яратып карап тора башлады:

—Бездә күптәнме? Нишләп мин белмим синең безнең фронтта икәнеңне?

—Мин яңа гына госпитальдән килдем. Килгәч сезнең урынбасарга күрендем инде. Сез Мәскәүгә—Ставкага киткән идегез. Мин үземнең кем икәнлегемне әйтеп тормадым. Ничәмә еллар үткән бит—әллә мин исегездә, әллә юк...

Күңелле итеп көлде:

—Фронт командующие да, армия генералы да... Костя Рокоссовский!

Командующий үзләрен уратып, аптырап тамаша кылып торганнарга аңлатма бирүне кирәк тапты, ахрысы:

—Гражданнар сугышында елдан артык бергә сугыштык. Кавалеристлар идек икебез дә. Бик тә башкисәр егетләр идек инде. Кавказлылар кебек бик кыю һәм баш белән уйлап сугыша белә торган командир иде Штельмах...

Яшьлек дустыннан сорады:

—Ничек тере кала алдың син?! Атың белән бергә снаряд сине ботарлап ташлаган иде бит!

—Күмүчеләр командасында кемдер мине тере дип уйлаган да, госпитальгә озатканнар. Харьков госпиталендә егерме икенче елның азагына кадәр яттым. Ел ярым аякка да баса алмадым. Сөякләр тоташ сынган иде. Ялгадылар, тектеләр. Тагын сындырдылар, дөрес ялганмаган дип. Тагын ялгадылар, тагын тектеләр. Күрдем инде мин ул госпитальләрдә күрмәгәнне. Бүген дә организм тимер-томыр белән туп-тулы...

Рокоссовский дивизия командирына борылды:

—Полковник Улитин! Сез рөхсәт итсәгез, мин Штельмахны иртәнгә кадәр алып китәр идем. Иртән китереп куярлар. Зинһар, минем үтенечемне кире какмагыз! Бик якын дуслар идек без...

Фронт командующиеның полковниктан үтенүе гаҗәп иде. Рокоссовский әнә шундый зыялы, итагатьле кеше иде. Әйе, Рокоссовский сирәк очрый торган чын кешеләрнең берсе иде...

* * *

Июль ае килеп житкәнче, Курск Дугасында күпсанлы ДОТлар[1], ДЗОТлар[2], блиндажлар төзеп, тирән окоплар һәм шуларның барысын да тоташтыручы таррак окоп юллары казып, бик нык эшләделәр. Инде солдатлар җәйге кояш астында кызынып (курорт!), йокы «симертеп», сугыш юктан «зарлангалап»... немецне сүгә башлады. Анасын искә алып!

—Гитлерларының анасын с ...!!! Кая инде аның немец-фрицләре?! Нигә һөҗүмгә күчми Гитлер һаман?! Күпме күтәргә тиеш ди инде без аны монда?! Җәй үтеп бетеп бара бит! Окоп казырга жир дә калмады—эш юк!!

Июнь аенда окопларга бик күп итеп яңа пополнение китереп тутырган иделәр. Күпчелеге 1925 елда туган малай-шалай гына булып чыкты. Һәр взводка әле мыек та чыкмаган дүрт-бишәр малайны бирделәр. Күпчелеге автоматчылар икән. Винтовка белән коралланганнары бөтенләй юк. Араларында пулеметчылар да бар иде.

Дошман көньяктан Белгород каласына карап, төньяктан Курск шәһәрен алып, Курск Дугасындагы Совет гаскәрләрен «капчыкка алу»

---

[1]ДОТ—долговременная огневая точка.

[2]ДЗОТ—долговременная земляная огневая точка.

максаты белән һөҗүм башлады. Ул һөҗүм 5 июльнең яктыра башлаган таңында кузгалды. Аңа кадәр ике сәгать кала Рокоссовский боерыгы буенча һөҗүмгә әзерлек үткәреп, алгы сызыкка чыга башлаган дошманга артиллериядән ут ачтылар. Шул сәбәпле, дошман үзен яңадан тәртипкә китереп һөҗүмгә күчкәнче тагын берничә сәгать үтте. Бу артиллериянең сугуы алар өчен көтелмәгән яңалык булды: «Руслар немец һөҗүменең башланган көнен-сәгатен дә беләләр икән!»

Немец һөҗүменең иң катысы подполковник Штельмах полкына туры килде. Өч көн-өч төн туктамастан немец танклары полк позицияләрен таптап-изеп, полкны юк итәргә омтылдылар. Һөҗүм башлар алдыннан немец артиллериясе уздырган артналеттан соң окопка яңа килеп кергән 18 яшьлек малайларның берничәсе куркудан йөрәкләре ярылып окоп төбендә җан биргән.

Икенче тәүлек үтеп барган кичне немец, Штельмах полкының бер батальонын уратып алып, вак кына куаклыкка китереп кысты. Каты яраланып һушын югалткан рота командирын плащ-палаткага салып өч солдат белән бергә күтәреп чыккан лейтенант Вильданов исән калганнарны шул куаклыкка алып керде һәм «түгәрәк оборона» оештырды. Кораллары житәрлек иде. Күбесе төрлечә яралы сугышчылар бер сәгать чамасы узуга тирән генә окоплар да казып өлгерделәр. Беркемнең дә үләсе килми—Вильдановка ияреп йөгерешкән сугышчыларның һәркайсы йә патрон тулы тартма, йәисә гранаталар тулысын күтәргән. Сугышчы ин элек корал турында кайгырта. Ач булсаң да сугышып була, ә инде корал бетсә—башың да бетте! Күңел төшенкелеге, безне нык кыйныйлар бит әле дип уйлау бөтенләй юк! Немецны жинәчәкләренә дә берәүнең дә шиге юк.

Төне буе яңа окоплар, пулемет ояларьі, йөрү юллары казылды. Иртән таң атып килгән чакта кояш белән бергә кузгалган дошманны яхшы оештырылган ут яңгыры ачып каршы алдылар. Тагын өч көн-өч төн туктаусыз сугыш барды. Өсләреннән үтәргә маташкан тәреле алты танк кара мазут төтене чыгарып яна иде. Ара бик якын булганлыктан, фашист самолетлары бомба ташлый алмый. Зәйни Вильданов командалык иткән сугышчылар төркеме, тырнак астына кергән чәнечке үләне кебек, немец тылында калса да, аларга тынгы бирмичә сугышты да сугышты. Хәлиткеч мизгелләрдә лейтенант Вильданов: «За Родину!», «За Сталина-а!» дип кычкырып, сугышчыларны һөҗүмгә күтәрде. Ул немецның кул сугышын яратмаганын яхшы белә иде.

11 июль көне ничектер сәеррәк башланды. Таң атты, кояш чыкты. Ә немец һөҗүме юк та юк иде. Лейтенант инде янып бетеп төтенләүдән туктаган немец танкы эченә үзенең ике разведчигын жибәрде. Шуларның берсе—сержант Никонов Иркутск кешесе иде. Алардан да бертөрле дә хәбәр юк. Вакыт-вакыт үзләренең исән икәнлеген белдереп кенә танкның алдагы люгыннан кайсысыныңдыр каска түбәсе генә күренгәли. Окоплар өстендә, алар алдында инде дошманның тугыз танкы үзләренең үлемен тапкан иде. «Эх, тагын берәү булса—ун итәбез инде!»—дип комсызланып уйлап куйды Вильданов. Танкларның берничәсен озын көпшәле мылтыктан, ә күпчелеген сыеклык тутырылган шешәләр һәм танкка каршы кулланыла торган авыр гранаталар белән алдылар. Төш вакыты житәрәк немец... чигенә башлады. Окоплардан муеннарын сузып караган сугышчылар соры болыт булып көнбатышка агылган дошманны үзләренең кечкенә калкулыгыннан күзәтә башлады. Бик күп иде алар. Кемдер ут ачарга тәкъдим итте. Тик Вильданов рөхсәт итмәде:

—Беренчедән, немец бездән ерак—әлләни зыян китерә алмабыз. Икенчедән, безнең боеприпаслар бик аз калды. Үзләре һөҗүм итә башласа, оборона өчен кирәгрәк. Китә бирсеннәр. Без аларны болай да шәп кыйнадык. Карагыз окоп алларын.

Анда чыннан да соры төстәге киемле бик күп немец солдатлары аунап ята иде. Немец танклары да чигенде...

Озакламый безнең кавалеристлар күренде. Атлары белән чабып үткән унайга елмаеп, окопларыннан чыгып баскан сугышчыларга азык-төлек, фляжка-фляжка спирт ыргыттылар. Тик лейтенант Вильданов фляжкаларны «конфисковать» итеп җыеп алды:

—Полкка кайткач, азрак хәл алгач эчәрсез. Без әле полкны эзләп табарга тиешбез. Ә хәзергә бер тамчы да бирмим. Нервларыгыз нык какшаган, аяусыз. Ашагыз! Тик комсызланмагыз!

Өч йөз кешедән артык булган батальоннан тик унҗиде кеше генә исән калган иде. Үлгәннәрне кичкә кадәр бер урынга җыйдылар. Баш киемнәрен салып хушлашып, окопның бер почмагына күмделәр. Мәетләр арасында рота командирының да гәүдәсе бар иде...

Икенче көнне өйлә житеп килгәндә генә полк штабының бер авылда икәнен белделәр. Немец ташлап киткән бер йөк машинасына төялделәр. Машина руленә Зәйни үзе утырды. Сорашып, берничә авылны үткәч, уртача гына зурлыктагы бер авылда үзләренең полк штабын таптылар. Исән-имин торып калган биш тәрәзәле зур гына йортта икән штаб. Шакып тормыйча гына лейтенант Вильданов эчкә атлады. Башы һәм сул кулы бинтлар белән уралган подполковник Штельмах нәрсәдер язып утыра иде. Ул күтәрелеп тә карамады. Лейтенант честь бирде:

—Иптәш подполковник! Сезгә буйсынган полкның икенче батальонын чолганыштан алып чыктым. Сафта 15 кеше, икесе каты яралы, госпитальгә озатылды. Огневой взвод командиры лейтенант Вильданов.

Башын күтәрә башлаганда подполковник Штельмахның зәңгәр күзләре түгәрәкләнә башлаган иде инде. Урыныннан торырга талпынды, тик икенче талпынышта гына аякларына басты. Сугыш көннәрендә бомба шартлаган дулкын аны окоп диварына бик каты китереп бәргән иде. Лейтенантка табан аксый биреп атлады. Исәнләшергә дип кулларын сузган иде, түзмәде, ике куллап кочаклап алды.

—Ну, лейтенант! Без инде монда сезне батальоныгыз белән тоташ кырылып беткәнсездер дип уйлый идек. Сезнең барыгызны да «Батырларча үлде»ләр исемлегенә кертеп, өйләрегезгә кайгылы хәбәр җибәрергә кул куеп утыра идем...

Өстәл ягына карап алды да кулын селтәп, шатланып көлде:

—Синең үле хәбәреңә кул куйган идем инде мин. Кире эзләп алырга кирәк. Официально син тере түгел инде хәзер...—Артка чигенебрәк тагын карап алды:—Мәңге үлмәячәксең син, Вильданов. Кая, тагын кочаклыйм әле үзеңне!

Шатлык тулган күзләре белән Зәйнине тишәрдәй итеп карады:
—Йә сөйлә барысын да! Тукта! Мин, сөйлә дим дә бит. Синең сугышчыларың мондамы?

—Әйе, сафта басып торалар.

—Әйдә, чыгыйк. Тере калулары белән котлап, рәхмәт әйтим әле.

Ишек алдына чыктылар. Сафта басып торганнарның күбесе яралы иде. Подполковник саф алдына басты да, дулкынланып честь бирде:

—Исәнмесез, иптәшләр!

—Здрам... Жела-ем, товарищ под-полковник!!!

Штельмах сафта басып торганнарның барысын да кочаклап чыкты. Үзенә ияреп йөргән штаб начальнигына боерык бирде:

—Хәзер үк ашатыгыз, эчертегез! Бик тиз генә мунча булсын. Эссе суны өстәмә рәвештә урамда, яисә күрше йортларда кайнатыгыз. Яна күлмәк-ыштан, гимнастерка-чалбар, итекләр бирегез. Берсенә дә ботинка бирмәгез. Бу егетләр обмотка урап йөрергә тиеш түгелләр. Лейтенант, тиз генә юынып чыгыгыз да, штабка кереп, миңа рапорт язарсыз. Юк, рапорт түгел, ә батальон командиры вазифаларын үтәүче булып, сугышчан донесение язгыгыз. Тере калганнарның тулы исемлеге дә булсын...

Кичкә табарак ундүрт сугышчы төялгән йөк машинасы полк штабыннан алты километрда урнашкан Подгорная Калиновка исемле

авылга юл алды. Штаб бинасында Штельмах лейтенант Вильдановка соңгы күрсәтмәләр бирде:

—Син инде бүгеннән батальон командиры вазифаларын үтисен. Бу кадәр ут эченнән батальонның үзәген алып чыга алгач, син инде аның белән командалык та итә алырсың. Мин шул турыда боерык әзерләп, дивизия командирыннан раслатырмын. Полковник Улитин һәлак булды. Дивизия белән бүгенгә штаб начальнигы командалык итә...—Елмаеп лейтенантка карады:—Машина хәзергә синең карамакта булсын. Иртәгә иртүк монда кил. Тугыз танк бәргәнсез бит! Ну и ну-у! Мин бүген киңәшим әле: сине Советлар Союзы Героена тәкъдим итәргә кирәк дип уйлыйм. Дивизиядә мондый нәтиҗә белән сугышкан башка офицер юк. Син генә, татарин! Иртәгә сиңа документлар тутырырбыз дип уйлыйм...

Зәйни югалыбрак калды: Советлар Союзы Герое! Битенә бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты.

—Һы-ы! Геройга-а!!! Исән кала алдым—шуна бик тә шатмын. Герой?! Нинди Герой инде миннән?!—Ул үзен-үзе белештерми сөйләнә иде.

—Геройның иң чыны син, Вильданов! Иң чыны! Өстәвенә гәүдән белән дә туры килеп торасың әле! Ике метрга якын! Иң шәбе гәүдәнең! Шундый батырлык күрсәтеп, чолганышта калып, бирешмичә алты тәүлек буена сугышып, тугыз танк юк итеп?! Ә күпме немецны кыргансың инде син анда?! Санадыңмы?

Икәүләшеп көлделәр. Зәйни кул селтәде:

—Кая ди инде анда санап торырга вакыт?!

—Минем кулымнан килсә, Герой Йолдызын бүген үк күкрәгеңә тагып һичьюгы, бер унбиш көнгә ял биреп, авылыңа кайтарып җибәрер идем. Кызлар тоткалап килер иден азрак...

Кулын сузды:

—Ярар, лейтенант! Күп сүз—буш сүз! «Армияңны» Калиновкага алып бар! Колхоз исән булса, рәисен тап. Әгәр инде власть булмаса, җитәкчелек итүне үз өстеңә ал. Хәрби идарә игълан ит. Кулдан язып булса да, боерык элеп куй. Урыслар боерык белән генә яши торган халык бит алар. Яхшылап йокла, ял ит, яхшы аша. Табылыр ашарга. Моннан алырсың. Немец азык күп калдырган...—Көлде:—Яшь кенә берәр Марфуга табып ал үзеңә. Урыс хатыннары ал якларына йомшак алар... Хатын-кыз белән ятканың бармы соң? Ничек икәнен беләсеңме?

Зәйни кызарып чыкты. Тотлыга биреп җаваплады:

—Бийскида, госпитальдән чыккач, бер медсестра үзенә алып кайткан иде...

—Ну-у! Алай булгач беләсең икән инде! Тик авылда эчеп, тәртип бозып йөрмәгез. Авыл халкын җәберләмәгез! Хатын-кызга көчләп ябышмасыннар—яхшылап аңлат! Хатыннар ирсез болай да сусаганнар. Үзләре үк егылып торалар сезнең өчен. Сезгә түгел, әле без картларга тынгы юк. Хәер, анда немец солдатлары булган авыллар... Кем белә инде хатын-кызны—сугыш бит!

Кояш баер алдыннан елга буйлап бер генә урам булып сузылган, егермеләп кенә йорттан торган авылга килеп керделәр. Машина туктап, аның кузовыннан төрле якка сибелеп сикерештеләр. Юл тузанын каккалап, тәмәке көйрәтеп кенә җибәргәннәр иде, җир астыннан чыктылармы—машина янына авыл халкы җыйнала башлады. Күпчелек бала-чага, хатын-кыз. Шулай да сирәк-мирәк кенә ирләр дә күренгәли иде.

—Исәнмесез!—диде Вильданов, гимнастеркасын буган каешы астындагы җыерчыкларны баш бармаклары белән артка куып сыпыра-сыпыра.—Тормышлар ничегрәк?

—Так себе, сынок!—диде сакал-мыегы чаларган бер карт.—Ходайга шөкер—немецны кудыгыз. Рәхмәт! Колхоз алып килдегезме тагын да?!

Күңелсез генә көлгән кебек иттеләр. Шул ук карт сорады:

—Сез кемнәр? Каян килдегез?

—Курск Дугасыннан без. Сугышчылар, тере чыга алган. Сезнең

авылда пополнение күтеп, азрак хәл алырга иде исәп.

Урта яшьләрдәге хатын лейтенантның җиненнән тартып үзенә борды:

—Безнең авылда дүрт полицай булды. Дошманга хезмәт иттеләр. Шуларның берсе, Козлов фамилиялесе аларның начальнигы булып йөрде. Бер ел эчендә бик күп явызлык эшләп, бик күп җәфа салды авылга. Унүнике яшьлек кыз балаларны да көчләп бетерде. Алардан зурларын әйткән дә юк инде—немец солдатлары астына салды.

Күзләре коры һәм зәһәр иде хатынның:

—Үзебезнең урыслар тегеләрдән дә хәшәрәтрәк булды. Козлов минем ике кызымны да көчләде. Ундүрт яшьлек Машам асылынып үлде. Ул полицайлар барысы да авылда. Немец белән китеп өлгермәделәр. Өйләрендә яшеренеп яталар барысы да. Үзебезнекеләр килгәч, доброволец булып сугышка китәбез, безгә сугышырга кирәк, диләр. Ышанмасагыз, Козловның хатыны Аграфенадан сорагыз. Ул да монда, безнең белән...

Күзләре кайгы-сагыш белән тулган, бер яшьләр чамасындагы ыштансыз малай кисәге күтәргән сары чәчле хатынны этеп лейтенант янына чыгардылар. Аграфеналары шул икән. Ул да өстәде:

—Шушында атсагыз да, «ых» та итмәячәкмен. Авыл алдында күзләремне күтәреп карый алмыйм. Ике улым урамга уйнарга да чыкмыйлар—оят! Дөньяда яшәмәс тә идем—балаларымны гына кызганам. Ул сабыйларның ни гаебе бар инде, аталарының шундый сволочь булганына?!

Утыз-кырык минут үтүгә кайсысын атлатып, кайсысын йөгертеп, берсен машинага салып дүрт полицайны китереп тә житкерделәр. Өчесе салмыш, берсе лаякыл исерек иде. Өчесе курыккан кебек итеп бер өер булып басып торсалар, дүртенчесенең авызыннан чыкканны эт жыймаслык иде. Машинадан төртеп төшереп, лейтенант алдына бастырып куйган уңайга сырлап-сырлап сүгенә башлады. Кем алдында басып торганын аңламыйча, һаман да немец хакимияте вакытындагыча тота иде үзен. Бу кеше Козлов иде. Зәйни кизәнеп тормыйча гына, уң кулының уч төбе белән полицайның сүгенүдән зур булып ачылган авызына берне кундырды. Козлов юл тузанына очып барып төште. Ике кулы белән артына, жиргә таянып торырга маташып карады—булмады. Юл тузанына ике теше белән бергә кан түкерде. Аякларына көч-хәл белән басты да, бармак янап, лейтенантка табан атлады:

—...твою мать!

Хатын-кызлар түзмәде, полицайга ташланды. Чәчләрен өзгәләп, битләрен тырнап, киемнәрен ерткалап кыйный башладылар. Өч полицай куркышып, лейтенантка якынрак килеп елышты. Берничә ир бакча киртәсен каерып ала башлады. Зәйни билендәге кобурадан «Вальтер»ын тартып чыгарды да ике мәртәбә һавага атты. Кыйнау тукталды, кечкенә мәйдан тынды. Тик жирдә Козлов кына аунап ята иде...

—Тынычланыгыз! Иртәгә район үзәгенә озатырбыз. Анда шушындый сатлыклар белән шөгыльләнә торган кешеләр бардыр. Ә хәзергә ябып куярга кирәк!

Сугышка кадәр кибет булган таш йортка яптылар...

Тик өч көн үтүгә, сатлык җаннар белән шөгыльләнергә тиешле «Смерш» оешмасы лейтенант Вильданов Зәйнулла Гыйззәт улы белән шөгыльләнә башлады...

Чаларган сакал-мыеклы карт кайчандыр колхозда бригадир булган икән. Кызганып тормады, исән калган ике чучкасының берсен килгән сугышчыларга бирде:

—Ашагыз! Сезгә бу чучка. Өстәвенә—әнә минем бакча. Кыяр, помидор, бәрәңге—күпме телисез! Суган, сарымсак та житәрлек. Авыл очында буа бар. Сазан, карп... Җәтмә бирәм—сөзегез!

Кичен карт өендә Зәйни азрак «салып алды.» Азрак спирт эчкәннән «йомшарган» карт «немец астында яшәгәннәрен» сөйләде:

—Өч кешене немец билгеләде полицай иттереп. Ә Козлов үзе

чыкты, доброволец булып. Сугышка хәтле ул участковой милиционер иде. Утыз тугызынчы елны эчкән өчен, уйнаш иткән өчен кудылар милициядән. Партиядан да кудылар. Тире, йомырка, йон жыеп, эчеппычранып йөри иде шунда. Совет властена ачуы би-ик зурдан иде, конечно! Бер ел эчендә безгә бик күп күрсәтте нужа-михнәтне. Кыз балаларны тоташ көчләп бетерде. Ике хатын немец комендантына жалу белән барганнар иде баруын, тик файдасы чыкмады. Карга күзен, карга чукымый! Шул хатыннарны көчләп, урам буена ат коерыгына тагып өстерәп йөртте Козлов. Аннан чишендереп чыбыркы белән кыйнады. Икесе дә балаларын алып авылдан юк булдылар. Мина калса—Козловны монда атарга кирәк, авылда. Шуны авыл халкы күрсен...

Сон гына йокларга яттылар...

Иртән кояш чыгып кына килгән чакта лейтенантны сержант Никонов уятты:

—Иптәш лейтенант, уяныгыз! Бәла бездә!

Зәйни тормыйча гына күзләрен ачты:

—Нәрсә булды?

—Козлов качкан! Часовойның башына таш белән бәргән дә, качкан!

—Часовой исәнме?

—Исән. Бина диварына куйдым сөяп. Утыра ыңгырашып.

Тавышка хужа карт та уянды. Өчәүләшеп кибет ягына киттеләр. Часовойның башын бинт белән урап куйганнар. Кибетнен тимер ишеге йозаксыз. Йозак салынып торган ишек келәсенә эленгән. Лейтенант ишекне ачып кибет эченә үтте. Өч тоткын бердәм булып күтәрелде.

—Сез мондамыни? Нигә качмадыгыз?

—Ә нигә качарга? Без халыкка да, Совет хөкүмәтенә дә бер зыян да китермәдек.

—Полицайлар булгансыз бит?!

—Немецлар атар дип курыктык. Яшисе килә бит! Балалар...—Берсе өстәде:

—Полицай булгач, гаеп бар, әлбәттә. Шунлыктан без «СМЕРШ»та штрафбатка жибәрүләрен сораячакбыз. Тик безне дә бит узган ел немец карамагына ташлап киттегез...

—Козлов кайчан качты?

—Бер сәгать чамасы булыр.

—Ничек булды ул хәл?

—Иртән уянып тышка чыгарга сорады. Часовой ишек аркылы көлә: «Шунда гына жибәр!»—ди. Козлов: «Минем зурдан бит. Иптәшләр монда рөхсәт итмиләр!»—ди. Часовой ачты шуннан соң. Козлов чыгып китте дә, башкача кире әйләнеп кермәде. Без ачып карарга да курыктык...

Хужа карт Зәйнинең жиңеннән тартты:

—Минем сарайда колхозның нәсел айгыры бар. Ияре дә бар. Атлан да шуңа, эзләнеп йөреп кайт тирә-яктан. Начальствога әйтерсең, шулай, шулай, эзләдем, дип. Ерактыр инде ул, алай да эзләп карарга кирәк...

Армиягә киткәннән бирле ат менгәне юк иде Зәйнинең. «Ятып калганчы, атып кал!»—дип уйлады да, атны иярләп менеп, авылдан чыгып китте. Кибет артыннан ук зур көнбагыш басуы башлана икән. Басу сапсары чәчәктә утыра.

Көнбагыш басуы бер якка өч чакрым, икенче якка бер чакрым чамасына сузылган. Басуда жилнең әсәре дә юк. Бик тыныч дип әйтеп булмый шулай да. Чөнки умарта кортлары, шөпшәләр зыңлап очып бал жыялар. Аларның зыңлап очулары немец пулялары тавышына охшаш булып ишетелә. Шуның өстенә полицайның качу шомы йөрәккә тынычлык бирми...

Сәгатькә якын менгән аты белән көнбагыш басуында йөрде Зәйни. Сары басу аның күңеленә әкренләп тынычлык урнаштырды. «Качып кая бара инде! Барыбер эләгер әле!»—дип уйлап, атын кайтуга табан борды. Аз гына узарга да өлгермәде, якында гына бер көнбагыш башы селкенеп

куйды. Һәм... тынды. Зәйни кобурасыннан «Вальтер»ын чыгарды да, селкенгән көнбагыш ягына каратып өч мәртәбә атты:

—Чык! Атып үтерәм югыйсә! Күтәр кулларыңны!

Тып-тын утырган көнбагышлар арасыннан башта күтәрелгән ике пычрак кул күренде, аннан соң полицай Козловның башы калыкты. Күзләрен курку алган иде. Макмыры каты булгандыр, ерак китәргә хәле калмыйча, ятып йоклаган, ахрысы. Күзләре тулы ачу, нәфрәт, курку иде полицайның.

—Атла авылга! Кулларыңны төшерсәң, йәисә кача башласаң—атам!

Полицай авызы эченнән генә нәрсәдер мыгырдады. Сүгенде бугай. Борылды да, авылга карап атлады...

Кибет алды халык белән тулган иде. Гөрләп тора. Кибет ишеге төбенә сержант яңа сакчы куйган. Кулларын күтәргән Козловны күргәч, халык бер мәлгә генә тынып калды да тагын да ныграк шаулый башлады. Аттан төшкән лейтенантны берничә хатын уратып алды. Берсе алгарак чыкты:

—Валентина Николаева мин. Авыл урамы буйлап Козлов чыбыркы белән кыйнап шәрә килеш йөрткән хатын. Ирем фронтта. Старшина. Сугыша немец белән. Ул кайткач ничек яшәрбез—белмим. Авыл белән үтенеп сорыйбыз сездән, атыгыз Козловны! Мылтык бирсәгез, үзем атам! Бирмәсәгез, сәнәк белән чәнчеп үтерәм мин аны...

Хатынның кулларында ялтырап торган өч җәпле сәнәк иде. Козловны һәм Вильдановны уратып алган бөжра кысыла башлады. Аягына бастылар, ахрысы, бер бала елап җибәрде. Бәлки, аттырмыйча, районга озаткан да булыр иде полицайны Зәйни. Тик Козлов кан баскан күзләрен күтәрде, акырышкан, кычкырышкан, йодрыкларын һавада селкеп чәрелдәгән хатыннарга карап акырып җибәрде:

—... мин сезнең барыгызны да-а! Һәм исән кала алсам, мин сезне тагын да с... әле-е! Сволочла-ар се-ез! Сволочла-аррр!!!

Халык зур бер ерткыч кебек үкерергә тотынды. Вильданов берничә тапкыр һавага атты. Берничә сугышчы бөжра эченә бәреп кереп лейтенант белән полицайны уратып алды. Кулларында автоматлар иде. Козлов туктаусыз сүгенергә, үзен уратып алганнарны мәсхәрәләргә тотынды. Акырып көче бетә башлады, ахры, Вильдановка борылды:

—Барыбер немец пулясы юк итәчәк сине! Подохнешь!

Зәйни сержантка боерык бирде:

—Терәгез кибет диварына. Ал ике автоматчик! Атыгыз!

Шуны гына көткәндәй, сержант автомат прикладының яссы ягы белән полицайны колагына китереп сукты. Полицайның икенче колагыннан кан шаулап ага башлады. Никонов автоматчиклар чакырып тормады, полицайның якасыннан тотып, кибет ягына өстерәп алып та китте. Тегесе карышты. Сержант чак кына читкә тайпылды да, зур итеге белән Козловның эченә китереп типте. Полицай урталай бөгелде, башкача карышмады. Ул инде үзен нәрсә көткәнне аңлаган иде. Сержант аны аркасы белән кибет диварына терәде дә, берничә адым гына артка чигенде. Автомат затворын үзенә тартты. Козлов башын күтәреп авылдашларына карады. Авыз кырыннан аккан кан белән акрын гына соңгы сүзләре килеп чыкты:

—Бул...дыра алсагы-ыз... гаф-фу ит-ттегез!!!

Полицайны урталай кисеп автомат тырылдады. Бу чакта Козлов йөзе белән диварга борыла башлаган иде. Ул башы белән таш диварга бәрелде, кулларын күтәрә башлады... сул ягына гөрселдәп барып төште. Үлем таләп итеп акырган халык төркеме Козловка карап сүзсез генә катып калды. Берничә секунд үтүгә тын гына тарала башладылар...

Авылда Козловны күмәргә теләүче табылмады. Авылдан ярты чакрымда тау башында урнашкан үләксә базына илтеп ташладылар. Ике аягын бергә китереп сүс аркан белән бәйләделәр дә, арык кына бер ат белән өстерәтеп алып киттеләр. Атны Валентина Николаева җитәкләгән иде...

Кибеттә ябылып тотылган өч полицайны Вильданов йөк машинасы белән район үзәгенә озатты. Җибәрер алдыннан полицайларның исемлеген язды. Козлов фамилиясенә каршы: «авыл халкы таләп итү буенча атылды» дип язып куйды. Лейтенант Вильданов, дип аска кул куйды да, исемлекне сержант Никоновка тоттырды:

—Районда милиция юктыр әле. Булмаса, «СМЕРШ»ка тапшыр. Юлда качмасыннар.

—Кача торган полицайлар түгел болар. Хыяллары—штрафбат! Бичара бәндәләр инде. Кем нәрсә куша—шуны үтәп өйрәнгән бер мәхлүк җаннар.

—Эчеп йөрмәгез анда. Кайткач, үзем сыйлармын.

Никонов елмайды:

—Мин бит старовер гаиләсеннән. Эчкәнем юк бер дә. Алтайдан мин.

Кичкә урап та кайттылар.

—«СМЕРШ»ка тапшырдык. Ә райком, милиция әле төзелеп кенә ята.

Елмайды сержант:

—Милициядә өч кенә кеше. Берсе формадан. Төрмә бар уже. Шунда яптылар өчесен дә.

Көннәр бер-берсенә охшап үтә башлады. Козловны атканның икенче көнендә йорт хуҗасы Кузьмич лейтенант дустына «сер ачты»:

—Без авыл белән аптырашта әле, лейтенант. Узган ел кырлардан җыйган ашлыкның, бәрәңгенең яртысын немец алды. Ә яртысы авылда, халыкта калды. Үзара бүлешеп алдык. Иген бик күп тиде безгә. Икешәр йөз поттан артык. Ә колхоз егерме-егерме биш поттан артык бирмәде беркайчан да. Инде ул иген белән нәрсә эшләргә? Алай-болай белеп калсалар! Бүген-иртәгә райком төзелеп бетсә, хәзер килеп житәрләр авылга. Дошманга эшләгәнсез дип, безне бит утыртып куюлары да бар. Нәрсә эшләргә, ә?

Лейтенант көлеп куйды:

—Соң инде, син, Кузьмич, үзең уйлап кара! Ни эшләп сезне утыртсыннар инде? Без сугышырга дип китеп барабыз. Сез бит үзегез генә торып каласыз. Сөйләмәгез берәүгә дә ул турыда. Мина да юкка сөйлисең син!

—Шулаймы?

—Әйе!

—Алай да бездә иген барын белеп калсалар?! Ә?

Зәйни уйланды да сорады:

—Авылыгызда ничә йорт?

—Егерме өч барлыгы.

—Һәр йорттан унар пот иген җыегыз да, ярдәм дип, безнең дивизиягә тапшырыгыз. Шуна документ алыгыз. Дивизия китәр, ә документ сездә калыр. Килгән һәр начальникка шуны күрсәтерсез. Печате бар, имзасы бар. «Каян алдыгыз?» дип сорасалар, «урлап яшердек, үзебезнекеләргә» дип җаваплагыз.

Кузьмич күнеллеләнә төште:

—Барып чыгар дип уйлыйсынмы?

—Нәрсә булса да эшләргә кирәк бит инде. Йөреп чык авылыгызны.

Кузьмич таягына таянып чыгып китте дә, көнозын авыл йортларын йөреп кайтты. Кичкә табарак сап-сары чәчле, зәңгәр күзле унөч-ундүрт яшьләр чамасындагы ялан аяклы бер малайны ияртеп иде ул.

—Сиклитар минем. Иван Кузовкин.

Кич буена кем, күпме биргәнне язып исемлек төзеделәр. Ут алгач, исемлек язылган дәфтәрне күлмәге астына тыгып «сиклитар» соң гына кайтып китте. Малай чыгып киткәч, почмактагы икона артыннан Кузьмич бер шешә самогон тартып чыгарды:

—Көн дә синекен эчәбез. Минекен дә тәмлик әле. Синең спирттән ким түгел катылыгы...

Берне тотып куйгач, карт әйтте:

—Син иртәгә машинаңны һәм дүрт солдатыңны бир инде миңа. Алар сиклитар белән йорттан-йортка йөреп иген җыйсыннар. Ә без синең белән икәү синең дивизия начальствоңа барып килик. Син әйткән документны эшлик инде. Бик акыллы киңәш бирдең син безгә,—диде.

Һәм шулай эшләделәр дә. Өйлә житеп килгәндә иске кибеттә һәркем үз тамгасын салган капчыкларда шыплап тутырылган бодай җыйналды. Һәммәсе 76 капчык бодай иде. Дивизия командирының урынбасары җибәргән «Студебеккер»га төяп дивизияга озаттылар.

Икенче көннең иртәсендә кояш яңа гына чыгып, җир өстен җылыта башлаган вакыт иде. Кибет янына американски «Виллис» килеп тукталды. Аның эченнән таза гәүдәле, көяз киенгән, яшь кенә булуына карамастан, инде корсак та үстерә башлаган өлкән лейтенант төште. Аның артыннан ике автоматчы. Алар төшү белән шоферлары машинасын кибет күләгәсенә куйды да, фуражкасын күзләренә төшерә биреп, күзләрен йомды. Йөргән бер җирендә йокларга өйрәнгән кеше иде, ахрысы. Өлкән лейтенант кулына чыбык тоткан үтеп барган хатыннан сорады:

—Мондагы команданың лейтенанты кайда яши?

—Кузьмичларда. Әнә йортлары! Бакчаларында сирень...

Корсагына каты иттереп типкәннән Зәйни уянып китте. Сикереп тора башлаган иде, иягенә каты гына чәпәделәр. Башы белән диварга бәрелде дә, алдында басып торган кешегә аптырап карады. Шома кызыл битле, таза гына гәүдәле таныш булмаган өлкән лейтенант.

—Син нәрсә-ә?!—диде бугазыннан кысылып чыккан ачулы тавыш белән Вильданов.—Нәрсә өче-ен?!

—Синме Вильданов?

—Мин лейтенант Вильданов.

—Син арестован!

—Нәрсә өчен тагын?

—Козлов фамилияле Советлар Союзы гражданинын син аттырдыңмы судсыз-нисез?

—Аттырмадым. Мин аны үзем аттым.

—Судсыз?

—Әйе, судсыз. Авыл халкы таләп итүе буенча.

Өлкән лейтенант пистолетын сул кулыннан уң кулына күчерде. Иелеп Зәйнинең күлмәк изүеннән бөтереп тотты да, өстерәп торгызып өстәл янына этте:

—Киен, сволочь! «СМЕРШ»та сөйләшербез ничек итеп Совет законнарын бозуың турында. «СМЕРШ» вазифаларын үтәргә сиңа беркем дә хокук бирмәгән! Өч минут сиңа! Киен!

Зәйни кабаланмый гына чалбарын, гимнастеркасын киде. Үзе күзләре белән өлкән лейтенантны сагалады. Аның эчендә ут дөрли иде: «Сволочьлар! Курск Дугасында юк сез! Тылда! Мине, сугышчан офицерны кыйнарга! Дугада немец ала алмады мине! Монда «СМЕРШ» кыйный! Гомерендә окоп күрмәгән, җир казымаган «смершник»!

Кабаланмый гына уң итеген киде. Сул итеген алырга диеп иелде дә, юлбарыс җитезлеге белән тураеп, каршысында пистолет тотып басып торган «смершникка» ташланды. Зур йодрыкның сугуыннан өлкән лейтенантның тешләре бер-берсенә шакылдап каты итеп бәрелделәр. Өлкән лейтенант үзе Зәйни йоклый торган караватка очып барып төште. Башы белән диварга нык кына бәрелде дә башын кыйшайтып кырынаеп ятты.

—Суккач менә шулай бирәләр аны!—диде Зәйни, өлкән лейтенантның кулыннан идәнгә төшеп киткән пистолетны күтәреп алганда. Бер сугу җитте старлейга. Күзләре йомык, иреннәренең сул ягыннан нечкә генә булып кан агып чыкты. Вильданов пистолетның обоймасын алды да, мич артына ыргытты. Күрше бүлмәгә чыга торган ишек шыгырдап аз гына ачылды. Анда Кузьмичның куркынган күзләре ялтырады.

—Яп ишекне, Кузьмич! Син бернәрсә дә күрмәдең! Яп!

Ишек бик тиз ябылды. Вильданов иелеп өй базын ачты. Өлкән лейтенантны күкрәгеннән, чалбарыннан тотып күтәрде дә базга тыкты. Старлей ике куллап баз читенә ябышты.

—Си-ин нәрсә-ә?—дип ыңгырашты ул.—Атуны телисеңме-е? Син минем кем икәнне беләсеңме-е?

Зәйни ун итеге белән старлейның бармакларына басты. Теге кулларын баз кырыннан ычкындырды.

—Ят базда! Уйла кемгә эләккәнеңне! Сине базга ябучы, Курск Дуга тәмугын узган Зәйни Вильданов дигән татар егете булыр. Синнән кыйнатa торган кеше юк монда. Ят базда!

Баз капкачын япты да, мич янында торган ларны кулбашы белән этеп баз капкачы өстенә бастырып куйды. «Чыгып кара инде хәзер! Күтәрә алсаң! Зәйни Вильдановка кул күтәрә бит, чучка!»

Башына уй килде: «Тукта, кем белән килгән бу?» Каешын биленә буды, пилоткасын киде дә урам якка чыкты. Капка төбендә офицерлар гына киенә торган яшел сукнодан тегелгән гимнастерка-чалбардан, фуражкадан ике автоматчы «Казбек» папиросы көйрәтәләр иде. «Безгә махорка да юк!»—дип, хурланып уйлап куйды Зәйни. Ләкин бик күнелле итеп елмайды:

—Егетләр! Сезме өлкән лейтенант белән килгән автоматчылар?

Автоматчылар да «СМЕРШ»та бозылган халык икән—якынлашкан офицерга җавап урынына баш кына кактылар.

—Без өлкән лейтенант белән азрак утырып алырга булдык. Әйдәгез минем белән. Сержант Никонов сезгә ялны яхшы оештырыр. Машинагыз кайда?

—Мәйданда, кибет янында!—диде автоматчыларның берсе шатланып.

Зәйни аларны сержант Никоновка тапшырды. Өч фляжка спирт тоттырды да пышылдады:

—Тәгәрәгәнче эчер. Хатыннар тап өчесенә дә!

—Булдырабыз аны!—дип авызын ерды сержант, энҗе тешләрен күрсәтеп.—Булдырабы-ыз!!!

—Алар иртән тормас борын миңа килеп җит. Сорасалар, әйт: Козловны кибет диварына терәп лейтенант үзе атты, дип. Аңладыңмы?

—Так точно!

—Бар! Эшлә!

Өйгә кайтты. Ишек төбендә аны агарынган Кузьмич каршы алды.

—Кемне яптың син базга? Акыра ямьсез иттереп. «Атам барыгызны да» дип акыра. Мин «СМЕРШ»тан, ди. Сине юк итәләр бит моның өчен!

—Ничего, Кузьмич! Бог не выдаст, свинья не съест! Мин бит татарин! Тиз бирешә торганнардан түгел без!

Базны ачты.

—Документларыңны бир монда!

—...твою мать!!! Яшәү туйдырдымы?! Мин сине блядь.... мать!!!

—Бир яхшылык белән документларыгызны! Югыйсә базга хәзер спирт сибеп ут ташлыйм. Бир!

«СМЕРШ» баздан документын сузды. Зәйни аны алды да карап та тормыйча өстәлгә ыргытты. Баздан чыга башлаган старлейны-башына басып кире базга төшерде. Бер фляга спирт, бер кисәк сало һәм ярты буханка ипи ыргытты. Эткә ыргыткан кебек итеп.

—Пей! Жри! Не шуми! Подожгу!

Базны ябар алдыннан сорады:

—Пычагың бармы?

—Пәкем бар.

—Бик әйбәт. Гуляй! Спирт кирәк булса, сора—бирермен. Курск Дугада сугышып тере калган Вильдановның кем икәнен күрсәтим әле мин сиңа.

Өлкән лейтенантның тавышында үтенү сизелә башлады:

—Чыгар яхшылык белән. Бетәсең бит син!

—Погибать, так с музыкой! Чыкмыйсың!

Урамга чыгып сөйләнеп йөрмәсен дип, Зәйни Кузьмичны да лаякыл исертеп, йокларга яткырды. Базга фляжка белән спирт биргәнгә бер сәгать чамасы узуга аннан өлкән лейтенантның җырлаганы ишетелә башлады. Тавышы моңлы иде каһәрнең:

По ди-иким степья-ам Забайкалья-а,
Где зо-олото ро-оют в гора-ах!
Бродяга-а, судьбу проклиная-а-а,
Тащился с сумо-ой на плеча-ах х!!!

Кич була башлагач ул баз капкачын эчтән шакыды.

—Нәрсә кирәк?

—Туалетка чыгар!

—Хәзер, чыгарсың! Аз гына сабыр ит!

Зәйни базга кечкенә сапер көрәге ташлады. Өстәп берничә газет тә ыргытты.

—Базның бер почмагында үзенә туалет әтмәллә. Чыкмыйсың беркая да. Чыгармыйм мин сине!

Караңгы төшеп килгәндә капка төбенә чыгып тәмәке кабызды да, Кузьмич ясап куйган эскәмиягә утырды. Урамның уң ягыннан ерак та түгел гармун тавышы ишетелә һәм аңарга кушылып ирләр, хатыннар берничә тавыш белән бик матур иттереп җырлый иде:

Ка-ак бы мне, рябине-е,
К дубу перебраться-а!..

Урамнан узып барган карчык лейтенантка «мәгълүматләр» биреп китте:

—Синең сержантың күңел ача анда. Бүген килгәннәрнең берсе бик оста гармунчы икән...

Китә башлап берничә адым үтте дә, тукталды:

—... Ә гармун Козловныкы. Хатыны да шунда... җырлый... Үлгән артыннан үлеп булмый бит инде! Әйе! Җырласын! Козлов белән бер генә дә рәхәт күрә алмады, бичара. Җырласын!

Сержант Никонов оештырган «күңел ачу» өч көн буена барды. Гармун янына килмәгән авыл кешесе калмады. Бар да җырлап, биеп күңел ачалар иде. Бер көнне лейтенант күрмәгәндә яхшы гына салмыш Кузьмич та барып кайтты «гуляние»га. Кайткач лейтенантка «үз уен чыгарып салды»:

—Йәисә аталар сине, йәисә син инде генерал буласың. Дөньяда синең кебек гади кеше булырга тиеш түгел. Мин синең барлыгыңа хәзер ышанып бетә алмыйм. Ышанмый-йм! Син булырга тиеш түгелсең! Юк! Түгелсең! Шабаш!

Базда утырган старлейның тәүлек нормасы бер фляжка спирт иде. Өч көн-өч төн узгач, базданн тик ялвару тавышлары гына ишетелә башлады:

—Вильданов! Зинһар, гафу ит мине! Гафу-у и-ит! Мин сиңа бер генә начарлык та эшләмәячәкмен! Җибәр мине, зинһар! Бүген, иртәгә мине эзләп киләчәкләр барыбер. Тыныч кына, дуслар булып аерылыйк! Сүз бирәм—тимәячәкмен!

Зәйни базны ачты:

—Чык! Карап карарбыз, ничекләр итеп сүзеңдә торырсың икән?

—Чын «СМЕРШ»ник сүзен бирәм.

—Чык! Чык! Утыр өстәл янына! Яз мин әйткәнне!

Өч тәүлек буена спирт эчеп исереп, сакал-мыек баскан старлей суга төшкән йолкыш әтәчне хәтерләтә иде. Хәтта корсагы да юкка чыккан.

—Яз! «Икенче август, 1943 ел» диеп куй башта. Яздыңмы?

—Яздым.

—Мин өлкән лейтенант ... фамилияңны, исемеңне, әтиеңнең исемен

куй. «СМЕРШ»та кем булып эшләгәненне яз. 31 июль көнне лейтенант Вильданов З. Г. ны йоклаган жирендә кыйнадым. Бер тапкыр типтем, ике мәртәбә суктым. Шунын өстенә урыс маты белән сүгеп мәсхәрәләдем. Татаринны... Мат сүзләрен ачыктан-ачык үзен яз...

... Вильданов мине базда тотты өч көн. Һәркөнне эчәргә 700 грамм су кушылмаган спирт бирде һәм ашатты. Баз эчендә үзем өчен үземнән туалет казытты...

... мине исерек килеш урамда күрмәсеннәр һәм «СМЕРШ»нын авторитетын төшермәсен дип, урамга чыгарып йөртмәде, кешегә күрсәтмәде. Вильдановка претензиям юк.» Кул куй.

—Куйдым.

—Хәзер уң кулыннын баш һәм имән бармакларын карага ман да, имзаң астына бас шуларны.

—Анысы нәрсәгә инде?

—Син, бәлки, имзаңны алдап, бозып куярсың. Кем белсен сине. Булдымы?

—Әйе.

—Менә пистолетын. Патроннарынны бирмим. Менә документларың. Автоматчыларынны, шоферынны кибет янына китерерләр. Аларнын да патроннары юк. Эчеп бетерделәр өч көн буена. Автоматлары гына калды. Башкача минем күземә чалына күрмә. Тай моннан...

—Йөз генә грамм сал инде. Юл аягы булсын.

—Мин синен белән эчә торган егет түгел. Юлга бирермен спиртен дә, закускасын да. Эчкәч, кире борылып килә күрмә.

Кибет янында «Виллис»ына утырып китте «смершник» старлей. Шоферы, азрак салмыш булса да, рульдә утырырлык иде. Ә ике автоматчысы дисксыз автоматларын кочаклап машинанын арткы урынында йоклап утыра иде. Өч көн «сыйлану» бушка китмәгән—алар ябыкканнар, үзләрен сакал-мыек баскан иде...

Икенче көнне Вильданов Зәйнулла Гыйззәт улын «смершниклар» өерләре белән килеп кулга алдылар. Ике немец бронетранспортерына төялгән егермеләп «смершник» авылнын ике ягыннан бер үк вакытта килеп керде. «Операция» белән бер подполковник житәкчелек итә иде. Старлейнын «докладына» караганда «дошман» бик куркыныч икән. Бронетранспортерларнын берсе лейтенант яшәгән йорт янында тукталды. Башнясыннан немец пулеметын йортка каратып төзәделәр. Икенче бронетранспортер таш кибет янында калды. Анысынын пулеметы урамга карап муенын сузды. Бронетранспортерлардан сикерешеп төшкән автоматчылар йортны уратып алдылар, авылнын капка төпләренә бастылар. Бер кешегә дә урамга чыгарга рөхсәт ителмәде. «Смершниклар» арасында Зәйни базга ябып тоткан өлкән лейтенант та бар иде. Ул подполковниктан бер тотам калмыйча ияреп йөри һәм аңарга күрсәтмәләр бирә. Подполковник анын күрсәтмәләрен кабаланып үти һәм бик тә тырыша. Зәйни яшәгән йортка автоматчылар бәреп кергәндә лейтенант Вильданов Кузьмич белән кәрт уйнап утыра иде. Кергән унайга ук подполковник пистолетын Зәйнигә төзәп акырып жибәрде:

—Кулларыгызны башыгызга куегыз! Аякларыгызга басыгыз!

Кузьмич песи житезлеге белән кабаланып аякларына басты, кулларын башына күтәреп куйды. Зәйни кәрт бутап утырган жиреннән ирония тулы күзләрен «смершник» старлейга төбәде. Сүзләре тулы көлү белән нәфрәт иде:

—Ә-ә, «Смершник», с большой честью! Сәлам!

Старлей кизәнде, тик Вильданов аңарга сугарга ирек бирмәде:

—Әгәр суксан, шушында бетерәм мин сезнен барыгызны да. Минем сугышчылар засадада утыра. Хәзер йортны гранаталар белән юк итәчәкләр. Сезнен белән бергә мине дә.

Подполковник агарып чыкты:

—Син-ин... Сез арестован!

—Киттек!—диде Вильданов. Үзе Кузьмичка борылды.—Син мине өч мәртәбә калдырдың. Ә мин бер генә тапкыр. Мин кире кайткач тагын уйнарбыз. Бурычны түләрмен дип уйлап китәм.

Өй эчен бетереп тентеделәр. Тик старлей эзләгәнен таба алмады. Мичкә сөялеп басып торган Зәйнигә якын ук килде:

—Кая куйдың миннән яздырып алган кәгазьне?

—Нинди кәгазь ул тагын?

—Пистолет белән куркытып, син мине көчләп яздырдың. Имза куйдырдың, карага манчып бармакларны бастырдың имза янына.

—Алдашма. Минем пистолетым юк. Әнә бит, «Вальтер»ны гына алдыгыз. Мин синнән бер нәрсә дә яздырып алмадым. Баздан тартып чыгарганда син исерек, бернәрсә дә аңламый идең. Мине башка кеше белән бутыйсың бугай.

Старлей Зәйнинең күзләре алдында уң кулының бармакларын тырпайтты:

—Менә бит бармакларның карасы да бетеп житмәгән...

Вильданов күңелле итеп елмайды:

—На кой черт мина синең бармакларың! Ну и фантазия синдә-ә!—Каушап басып торган подполковникка борылды:—Мин сезне бу өлкән лейтенантка буйсындырып җибәргәннәрдер дип уйламыйм. Алырга килгәч, алып китегез инде мине. Туйдырды бу дурак старлейыгыз! Арестован, так арестован! Киттек, әйдәгез!

Урамда курка-курка гына, як-якларына карана-карана, бронетранспортерларына тиз генә төялделәр дә, «җинаятьче лейтенант Вильдановны «Смерш»ка алып киттеләр. Лейтенантны алып киткәнне сержант Никонов кына күрше йорт тәрәзәсеннән карап калды. Башка сугышчылар өч көн гармун белән «типтергәннән» соң әле йоклыйлар иде...

«Смерш»ның һәр эш-гамәле: «Бей своих, чтобы чужие боялись!»—дигән принципка нигезләнеп башкарыла иде...

Ике көннән лейтенант Зәйнулла Вильдановны фронтның хәрби трибуналы атарга хөкем итте. Гаебе бик зурдан язылган иде: «Совет гражданы Козлов В. Н. ны сатлык булуда гаепләп тикшерүсез, судсыз үз кулы белән авыл халкы алдында атып үтергән. Шул очракны тикшерергә барган һәм тыныч кына сөйләшә башлаган «Смерш» хезмәткәре өлкән лейтенант Долматов В. В. ны ерткычларча кыйнап, ач көенә өч көн үзе яшәгән өй базында ябып тоткан. Бу акцияләрне үткәргән чакта Вильданов һәр көнне исерек булган. Әгәр Долматов В. В. качып котылмаган булса, эзен югалту өчен Вильданов аны атып үтергән дә булыр иде. Авыл уртасында, көпә-көндез Совет гражданын судсыз атып үтерү урындагы халыкны Совет хөкүмәтенә каршы күтәрү өчен эшләнгән.

Вильданов З. Г. үз гаебен танымады.

*...Фронтның хәрби трибуналы 1921 елда туган, өйләнмәгән элекке лейтенант Вильданов Зәйнулла Гыйззәт улын атарга хөкем итте. Хөкемне трибунал карарын фронт командующие раслаганнан соң үтәргә!*

*Трибунал рәисе—Подполковник Романов С. Н. Трибунал әгъзалары: Майор Намитов Е. А. Капитан Белых Я. В. 12. август 1943 ел.»*

Трибунал карарын укыгач, подполковник Романов сорау бирде:

—Соңгы үтенечегез бармы?

Ике ел эчендә күп үлемнәр белән очрашкан яп-яшь татар егете Зәйни тыштан бик тә тыныч иде. Фин чигеннән алып, менә бу Курск Дугасына кадәр ничәмә тапкырлар үлемне җиңеп чыга алды ул. Инде менә үлем аны «Смерш» кулы белән бугазыннан эләктереп алды, ычкыну мөмкинлеге юк. Шунлыктан соңгы минутында бу дөньядан егет булып китәргә кирәк! Тик үлеме сугыш кырында түгел, ә үз кешеләренең канын эчеп яшәгән капкорсак старлей аркасында булачак. Трибунал рәисенең соравына Зәйнулла:

—Бар минем үтенечем. Әти-әниемә соңгы хатымны язарга телим,— диде.

Рәиснең җавабы әзер иде. Ул мондый теләк белән көн саен очрашып тора:

—Үтенечегез кире кагыла. Трибунал атарга карар чыгарса, туганнар һәм әти-әни белән хәбәрләшү катгый тыела.

«Смершник»лар лейтенант Вильдановны авылдан алып киткүгә сержант Никонов йөк машинасының шоферын эзләп авыл буенча йөгергәләде. Печәнлектә бер хатын белән йоклап яткан җирендә таба алды:

—Семен! Тор! Киттек әйдә!

Шофер авыр уяна иде:

—Киттек! Киттек! Кая барабыз инде тагын? Бер тынгы юк!

—Полк штабына! Тизрәк кыймылда инде-е! Вильданов боерыгы!

—Шулай диген син! Киттек әйдә!

Полк штабында сержант дежурныйга мөрәҗәгать итте:

—Иптәш лейтенант! Безнең батальон командиры лейтенант Вильданов полк командирына донесение җибәрде. «Бик срочно!» диде. Командирның үз кулына тапшырырга боерды.

—Бир! Кертеп тапшырырмын.

—Юк! Үз кулына полк командирының.

—Шулаймы?

—Так точно!

Берничә минут үтүгә сержант Никонов полк командиры подполковник Штельмах алдында басып тора иде. Бүлмәдә штаб начальнигы һәм таныш булмаган тагын бер майор бар. Сержант честь бирде дә, өзеп әйтте:

—Лейтенант Вильданов шәхсән сезнең кулга гына тапшыра торган донесение җибәрде һәм сүз белән дә әйтергә кушты. Тик сезгә генә...

Штаб начальнигы белән майор сүзсез генә чыгып киттеләр. Сержант дулкынланып лейтенант Вильданов белән булган хәлне подполковникка сөйләп бирде. Никонов сөйләгән саен Штельмахның йөзе карала барды. Лейтенантны юк итәчәкләрендә аның инде шиге юк иде. Вильданов өчен иң йомшагы—штрафбат. Ә аннан инде тере чыгу шансы бик аз! Никонов сөйләүдән туктагач сорады:

—Бетердегезме?

—Так точно! Лейтенант, әгәр «Смерш» үзен кулга алса, Сезгә тапшырырга дип, миңа бер документ биреп куйды. Йорт хуҗасы Кузьмичның әйтүенә караганда, «смершник» өлкән лейтенант бик нык эзләп караган ул документны. Тентү ясап.

Штельмах сержант биргән «документ»ка күз йөртеп чыкты. Бер урынын укыган чагында тыела алмады, елмаеп куйды. Базда, старлейдан туалет казыткан урын булды, ахрысы, укып чыккач, алдында басып торган сержантка кул бирде. Каты итеп кысты Никоновның кулын:

—Рәхмәт, сержант! Бу чыннан да шәп документ! Килгәнсең—молодец! Бар, кайт! Тавыш-тынсыз гына яшәгез! ЧП китереп чыгарсагыз, лейтенантка өстәмә начарлык эшләгәнбез дип белегез! Аны Вильдановка каршы кулланачаклар. Сак булыгыз!

Сержант чыгып киткәч, штаб начальнигын чакыртты Штельмах.

—Сергей Семенович! Мин дивизиягә киттем. Аннан, бәлки, фронт штабына китәрмен. Минем кая киткәнне беркемгә дә белдермә. Мин, бәлки, бүген кайтып та өлгермәм. Борчылмагыз. Калсам, шалтыратырмын.

Дивизия штабында озак тормады. Дивизиянең яңа командиры полк командирын дәшми генә тыңлады да, соңыннан сорады:

—Бу бит Геройга тәкъдим ителгән лейтенант? Ялгышмыйммы?

—Шул үзе. Ялгышмыйсыз.

—Кызганыч. Шәп офицер. Мин риза сезнең белән. Турыдан-туры Рокоссовскийның үзенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Коткарса, ул гына коткара ала лейтенантны. Трибунал карарын расламаганга кадәр барып

өлгерергә кирәк. Рокоссовский белеп торсын Вильдановның кем икәнлеген. Вакыт бар. Уныш телим сезгә!

Фронт штабында Рокоссовский үзе юк иде. Дежурный аның кайдалыгын белмәмешкә салышты. Ә белгәне күзләреннән үк күренеп тора иде. Инде нәрсә эшләргә дә белмичә штабның эчендә, тышында сәгатьтән артык тулганды Штельмах. Урам якта басып тәмәке көйрәткән жирдән исеме белән дәштеләр:

—Рихард! Син бит бу!?

Хәрби Совет әгъзасы генерал Телегин икән. Штельмах папиросын читкә ташлап, честь бирде. Рокоссовскийда, Курск сугышы башланыр алдыннан бер тәүлек «кунак булганда» танышкан иде Телегин белән.

—Син нәрсә эшлисең монда?

Штельмах кыскача гына килүенең сәбәбен аңлатты. Иң соңгы уй итеп өстәде:

—Бик батыр, тәвәккәл офицер. Юкка һәлак булуы мөмкин. Гаеп үзендә дә бар—бик кызу. Тик төп сәбәп «Смершник»ларның буш амбициясы, минемчә...

Генерал Телегин икеләнгәндәй башын иеп тыңлап бетерде дә, ни булса шул булыр дигәндәй, Штельмахның колагына иелә биреп пышылдады:

—Киноактриса Валентина Серова монда...

Телегин әйткәннен асылын аңламады Штельмах. Ахмаграк сорау бирде:

—Булса инде?!

Телегин үзенең уйлап бетермичә әйтеп ташлаганын аңлады. Тик анарда Штельмахка ярдәм итү теләге көчлерәк иде.

—А-а!—дип кулын гына селтәде.—Үтермәс әле! Әйдә киттек!

Тимер юл тупигындагы бик шәп йокы вагоны янында тукталдылар. Телегин вагон эченә кереп китте дә, азга гына юк булып торды. Елмаеп кире чыкты, вагон баскычыннан төшмичә генә Штельмахны керергә чакырды:

—Мен әйдә!

Күпсанлы орденнарын таккан мундирын кигән Константин Константинович Рокоссовский яшьлек дустын елмаеп каршы алды:

—Азга гына булса да фронт ыгы-зыгысыннан аерылып, ял итеп алырга иде исәп. Сине кабул итмичә булмый инде. Әйтүең бар, Костя читләшә, зур шәхес булган дип. Өстәвенә Телегин бик үтенеп сорый синен фамилиянны әйтеп. Штельмах юк эш белән йөрмәс дип уйлап куйдым. Сөйлә, нәрсә китерде сине монда? Тыңлыйм!

Штельмахның сөйләгәнен йөзенең көләчлеген бозмыйча тыңлады. Кәефе шәп иде генерал Рокоссовскийның. «Смершник» тан яздырган «документ»ны укыгач, көлеп жибәрде:

—Бу бит чын-чыны белән әдәби әсәр! Базда туалет казыткан! Культуралы офицер!—Житдиләнгән күзләрен Штельмахка текәде:

—Килүең дөрес! Тик атарлар лейтенантны! Берияның якын ярдәмчеләренең берсенең фамилиясе Долматов. Генерал-лейтенант. Бу өлкән лейтенант шунын улы булырга охшаган. Инициалы туры килә. Долматовның үзен мин Камчаткада утыз тугызынчы ел башында күргән идем. Ул чакта әле полковник кына иде. Камчаткадагы концлагерь начальнигында шофер идем мин. Долматов Кызыл Армия командирлары булган концлагерьда утырган уникe кешенең исемлеген алып килгән иде. Мин дә бар идем шул исемлектә. Безне бик ашыгыч Мәскәү төрмәсенә күчерергә тиешләр иде. Дүртебезне бирмәде начальник. «Авырулар» дип, хастаханәгә яшерде. Барыбыз да һушсыз яттык. Долматов кайтып киткәч кенә чыктык. Мәскәүгә алып киткәннәрнең барысын да атканнар...

Истәлекләргә бирелеп азрак дәшмичә уйланып торды да, өстәде:

—Фронт «Смерш»ының начальнигы белән минем мөнәсәбәтләр бик әйбәт әйбәтлеккә. Ләкин...

Кулын хушлашырга сузды:

—Үзгәрмисен, Рихард! Молодец! Ә мин менә күбрәк дәшмәскә өйрәнеп бетеп барам инде. Авыр...

Штельмахның кулын кысты:

—Коткарырга тырышырмын! Нәрсә килеп чыкса да, үпкәләштән булмасын!

* * *

Фронт «Смерш»ының начальнигы икеләнде:

—Генерал Долматов ул бит Бериянең үзе инде дигән кебегрәк. Шуның улын кыйнап базда тоткан бит бу лейтенант. Аңлагыз шуны, Константин Константинович!

Рокоссовскийның бармаклары өстәлдә тыпырдап алдылар:

—Ә кече Долматов баздан чыккач язган кәгазь? Ә? Шул кәгазь Лаврентий Павловичка барып эләксә, аллә ул Долматовны башыннан сыйпар дип уйлыйсызмы? Без, фронтта сугышучы генераллар бик тә кирәкбез бүген. Йосиф Виссарионович безне күбрәк тыңлый, безнең сүзгә колак сала. Без аның аяклары астына Курск Дугасы җиңүен ташладык. Дошманны без сындырдык бүгенге көннәрдә!—Күзләре уйчанлады:—Ә лейтенант Вильдановка Геройны бирмибез. Өстәвенә, мин аның погоныннан бер йолдызын алып ташлап, кече лейтенант итәм әле...

Алдында утырган, күп үлемнәр күргән «Смерш» генералына карап алды:

—Коткарыйк үлемнән лейтенантны. Сугышның беренче көненнән үк фронтта. Ике мәртәбә яраланган. Бик батыр сугышчы һәм... тәвәккәл егет...

* * *

Ул көннән лейтенант Зәйни Вильданов житәкчелегендә Курск Дугасыннан чолганыштан чыккан 14 сугышчы барысы да Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнде. Орденнар тапшырырга яңа гына полковник дәрәҗәсе алган Штельмах үзе килде. Орденнар өләшенеп беткәч, башын иеп уйланып утырган Вильдановны аяк үрә бастырып кочаклады:

—Ну... лейтенант! (Кече лейтенант димәде!) Сине тере калуың белән котлыйм. Генерал Рокоссовскийга рәхмәтле бул. Герой да булырсың, хәрби дәрәҗәләрне дә алырсың. Тик тере, исән генә бул!

Өч ай узгач, полковник Штельмах Рихард Ивановичка полкы белән Курск Дугасында күрсәткән батырлыгы өчен СССРның Югары Советы указы нигезендә Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Указны ишетеп барлык дивизия халкы шатланды—Штельмахны, немец булса да, бар да ярата һәм хөрмәт итәләр иде.

* * *

Чигенүләр, алга барулар, кул сугышлары, бомбежкалар, артналетлар, бик күп үлемнәр күрде өч ел ярым эчендә Зәйни Вильданов. Радиосы, электры да булмаган читәнле, салам башлы өйләрдән торган татар авылында чабата киеп үскән татар баласы, сугыша-сугыша, кайсы җирләрдә атлап, башкаларында шуыша-шуыша, Европаның үзенә килеп керде. Донец, Днепр елгаларын кичте. Витебск, Смоленск өчен барган каты сугышларны үтте. Бик күп калаларны, авылларны азат итүдә катнашты. Тагын ике мәртәбә каты яраланды. Берсендә Иркутск каласында Ушаковка исемле елгага терәп салынган госпитальдә ятты, икенчесендә Себер уртасында, Новосибирск каласындагы бик зур госпитальдә дәваланды. Окопта яткан чакларында, унбиш-егерме көннәр чамасы сугышлар тынып торган чакларда үзенә урын таба алмыйча, тизрәк

сугыш башланганны тели торган булды. Бик ныклап кеше үтерергә өйрәнде. Хәер, фашист аның өчен кеше исәбеннән йөрми иде инде. Чөнки ул фашистлар ясаган бик күп явызлыкларны күрде. Ил тоташы белән таланган, жимерелгән иде.

Сугыш Зәйни Вильдановның һөнәренә әйләнде. Сугыш юлларында тагын бер һөнәре артты—артык ялындырмыйча бирә торган хатын-кызны күз карашларыннан таный башлады. Чөнки үлем белән һәр көнне очрашып торган фронт хатын-кызлары, бүген исәнмен, шунардан файдаланып калыйм тизрәк, дип уйларга күнеккән иде. Ә фронтта үлем белән еш очрашканнарның кануннары да тик үзләренчә: «Фронт все спишет!» Һәм фронттагы халык женси элемтәгә тиз кереп, тиз аерылып китәргә өйрәнде.

1945 елның март башында дивизия Чехословакияга барып керде. Зәйни Вильданов—капитан. Күкрәгендә дүрт орден: Ике Кызыл Йолдыз, Ватан сугышының Беренче дәрәжәсе һәм Хәрби Кызыл Байрак ордены. Шуларга өстәп—унга якын медальләр. Капитан Вильданов инде бик ныклы сугыш тәжрибәсе туплаган, куркынычның сугыш кырында кай тарафтан янаганын алдан ук сизүче «ата бүрегә» әйләнде. Үзе өчен бер ачыш та ясады: сугыш барган көннәрдә башы шәбрәк эшли икән үзенең! Менә бит ничек тә була икән әле ул! Баш чыннан да, тирә-якта пулялар сызгырганда, снаряд-бомбалар шартлаганда тере калу юлларын бик тиз исәпләп китереп чыгара икән. Үзеннән үзе көлеп тә куя: бары тик 1945 елның гыйнвар аенда гына 1943 елның августында ирешкән дәрәжәсенә килеп житә алды—яңадан батальон командиры булды. Белоруссияда үткәрелгән «Багратион» операциясе уңышлы тәмамлангач, фронт командующиена Советлар Союзы маршалы дәрәжәсен бирделәр. Ә Советлар Союзы Герое Штельмах генерал булды. Рокоссовский үзенең яшьлек дустына Фронт Штабына күчәргә тәкъдим иткән. Ләкин Штельмах дивизиядән китмәде. Китмәвенә үзе дә шат иде. Рокоссовскийның маршал булуына фронт халкы мәзәк тә чыгарды һәм аны байтак көннәр, айлар буена бик тә тәмләп сөйләделәр.

Имеш, Рокоссовскийга маршал бирү турында Кремльдә сүз чыккан. Әмма Политуправление начальнигы Мехлис каршы икән. Иптәш Сталинга «доложить иткән»:

—Рокоссовский туп-туры ике вагон... билгесез профессиялы хатын-кызлар төяп йөртә. Кая барса да, шул вагоннарны калдырмый. Яхшы түгел бит инде, иптәш Сталин...

Ә Сталин моны ишетмәгән булып, колаклары яныннан уздырып жибәргән. Биш-алты минут чамасы узгач, Мехлис тагын шуны ук сөйли икән:

—Шулай-шулай, иптәш Сталин, Рокоссовский ике вагон яп-яшь чибәр кызлар йөртә икән үзе белән. Коммунистка ярый торган мораль түгел бит инде. Без нәрсә эшләргә тиешбез моны белгәч?

Иптәш Сталин Мехлиска карап алган да, елмаюын мыеклары астына яшереп, кабаланмый гына әйткән, имеш:

—Без, иптәш Мехлис, моңарга көнләшеп карарга тиешбез. Көнләшеп. Синең белән мин кызларны ике вагонлап йөртә алмыйбыз бит инде хәзер. Ә инде... Маршал Рокоссовский йөртә ала икән, йөртсен. Көнләшеп карыйк, иптәш Мехлис!

1945 елның гыйнвар азакларында Ленин, Кызыл Байрак, Суворов, Богдан Хмельницкий орденлы 232 нче Себер Гвардия дивизиясе (элекке 115 нче дивизия!) Чехословакияның Зволин исемле каласын алырга тиеш иде. Капитан Вильданов батальоны Зволинга беренче булып бәреп керде. Полкка Зволин исемен бирделәр. Шул каланы штурмлаган чакта капитан Вильданов контузия алды. Шартлау һавасы китереп сукканнан ун метрлар чамасы алга очкан. Шул коткарып калды да аны. Аягына баскан чагында шинеленең арты тоташ юк иде. Артыннан килгән ике ординарецы иксесе дә урталай өзелгән... Елдан артык бергәләшеп бик күп сугышлар үткән бик кыю егетләр иде иксесе дә. Зволинны алганнан соң тагын боерык

килде: шәһәр янындагы көнбатыштагы тауларга штурм башларга һәм якындагы икесен март башларыннан да калмыйча алырга!

Ул каршы тау дигәннәре Зволиннан ике чакрым чамасында урнашкан 400 метрлар чамасындагы калкулыклар иде. Итәкләре куе нарат, чыршы белән капланган. Түбәсе таз кешенеке кебек ялангач. Тауларны саклау өчен дошман көздән үк ныгытмалар төзеп куйган. Аларны кыш килү белән калын кар катламы басып киткән икән. Шунлыктан маскировкалары көчле һәм ул оборона ныгытмаларының нинди икәнен бер төрле ысул белән дә белерлек түгел. Һавадан самолетлар төшергән аэрофотосьемкалар бер төрле дә ачыклык китермәде. Җир өсте тоташ ап-ак кар иде фотоларда. Шулай да чех партизаннары белән элемтәгә кереп, дошманның оборона ныгытмалары турында азрак мәгълүматлар алдылар. Тик тауның сөзәгрәк, Зволинга якынрак урнашкан өлеше турында бер нәрсә дә белмиләр иде. Тау астында кечкенә бер чех авылы утырган. Исеме дә кызык кына—Збыжев. Капитан Вильданов батальоны шул авылда урнашты. Авыл мәктәбе директоры яшь капитанны зур хөрмәт күрсәтеп үзенә яшәргә чакырды.

Директорның йортында яшәү шартлары бик әйбәт иде. Ничәмә айлар буена мунча, эссе су күрмәгән тән инде сиземләү-тою сәләтен дә җуйган иде. Директорның өенә кермичә генә, Вильданов ишек артында чишенде дә, эссе су тутырылган ваннага кереп ятты. Ләззәтнең чиге юк иде! Каты мунчала белән ышкып тәнен берничә мәртәбә юды. Директор биргән җылы күлмәк-ыштанны киде. Кичен бик яхшы иттереп сыйлады кунак-капитанны мәктәп директоры. Хужа куйган шәраб шул хәтле тәмле һәм зур ләззәт бирә иде—аракыга, спиртка кагылмадылар да.

Ике төн немец ягына өчәр кешедән торган ике разведка җибәреп, дошманның алгы окоплар сызыгын билгели алдылар. Тау итәгендә, куе чыршылык эчендә ватылмаган кечкенә өч өй таптылар. Ул урман каравылчысының һәм көтүчеләрнең җәйләрен яши торган урыннары икән. Тәрәзә пыяласын алып, шуннан калайдан ясалган торба чыгарып, мич утырттылар. Батальон штабын шул йортларның берсенә күчерделәр. Телефон суздылар. Полк штабына батальон штабының яна урынын хәбәр итте дә Вильданов өстәл артында утырган җиреннән йоклап киткән. Шунда төш күрде.

Имеш, тау итәге буйлап, теге мина өзгәләгән ике ординарецы белән каядыр китеп бара икән. Һич көтмәгәндә, алда гына әллә мина, әллә граната булды—каты шартлау янгырады. Имеш, егылган да, кар эчендә, башы аста, каядыр шуып бара. Туктарга итеп карый—туктый алмый. Кычкырырга итеп авызын да ачып карый—тавышы чыкмый. Башы аста, һаман каядыр шуа, имеш. Азаплана торгач тукталды. Тик инде тора алмый. Тоташы белән кар эченә күмелгән килеш ята. Шулай да башын аз гына күтәрә биреп тау башы ягына карый алды икән. Үзе уйлый: «Ничек кенә алырга инде бу тауны? Ничекләр генә иттереп менәргә инде башына немецка күренмичә генә! «Ә тегеләрнең сөйләшкәннәре якында гына ишетелә икән: «Капут та капут!»—дип нәрсәдер сөйлиләр бер-берсенә...

Төшен күреп бетерә алмады, телефон шылтыраганга уянып китте. Дивизия командиры генерал Штельмах тавышы:

—Капитан Вильданов, исәнме?! Синең алда минем бер бурыч бар бит әле. Курск Дугасы өчен. Теге синнән ычкынган Герой дәрәҗәсе турында әйтүем. Шушы ике тауны атна-ун көн эчендә алсаң, сине Геройга бирергә булдык тагын бер мәртәбә. Бу юлы инде барып чыгар дип уйлыйм.

Зәйни шатланып елмайды: «Онытмаган Штельмах Курск Дугасын! Рәхмәт төшкере!»

—Тырышырбыз, иптәш генерал! Нык иттереп!

—Тырыш, Вильданов! Озакламый сугышлар бетә. Белемең җитәрлек—сина туры юл академияга. Син анда тырыш, ә мин монда тырышырмын.

—Рәхмәт, иптәш генерал!

—Тере кал!

Штельмах телефонны куйды. Ә Зәйнинең кәефе күтәрелеп китте: «Штельмах аны исеме белән белә һәм Курск Дугасын да онытмый!»

Ике госпитальдә яраларын дәвалаганнан соң да ул үзенең дивизиясенә әйләнеп кайта алды. Иркутск госпиталеннән чыккач аны каладагы «Кызыл казарма» дигән хәрби шәһәрчеккә җибәрделәр. Монда кайчандыр легендар Сергей Лазо прапорщиклыкка укыган. 1915 елда. Барган көнне үк өлкән лейтенант Зәйни Вильданов аннан фронтка «тайды». Ангара елгасы буенда урнашкан тимер юл вокзалына трамвай белән төште дә, Ерак Көнчыгыштан фронтка ашыккан хәрби эшелонга утырып та китте. Әле сугышны күрмәгән яшь лейтенантлар утны-суны кичкән, госпитальдән чыккан фронтовикны үз араларына зур теләк белән кабул иттеләр. Ә Зәйни хатлар буенча үз дивизиясенең кай тарафта сугышканын белә иде. Туп-туры үз полкына кайтып та керде. Анда аны күтәреп алдылар. Ә инде Новосибирск госпиталендәге чыгару комиссиясенә барып кергәч, турыдан-туры ярды:

—Мине үз дивизиямә кайтарыгыз. Мин башка дивизиягә бармаячакмын.

Генерал формасы кигән озын борынлы яһүд табиб күзлеген күтәрә биреп анарга карады да, мыегы астыннан елмайды:

—Нәрсә, өлкән лейтенант! Дивизияндә мәхәббәтең көтеп торамы?

—Юк! Үз дивизиямдә тере калу шансы югарырак!

Инде менә хәзер Чехословакиядагы Зволин каласы янындагы тауларны алырга кирәк. Батальон штабы начальнигына үзенең алгы сызыкка барып кайтырга уйлавын әйтте. Теге: «Төнгә каршы йөрмәс иден!»—диде.

—Окопта яткан солдатлар белән сөйләшергә кирәк.—Сүзне икенчегә борды:—Карале, Володя! Мин әле генә бер төш күрдем бит.

Төшен сөйләп бирде. Начштаб башын ия биреп, аны бүлдермичә генә тыңлап торды. Зәйни сөйләп бетергәч, аның «төшен юрады»:

—Төшең начар синең, Вильданов. Сине бүген йәисә үтерәләр, йәисә яралыйлар. Тыңла мине, йөрмә бүген окоплар ягына.

Зәйни кулын селтәп елмайды да ординарецларын ияртеп төн карангылыгына чыгып китте.

Тирән карга казылган окопларны, җылы землянкаларны йөреп чыкты. Төнгә каршы кабаланмый гына куәтләнә барган буран кузгалган иде. Окоптагылар белән сөйләште, немец турында сорашты. Инде кайту турында уйлый башлаган иде, олы яшьтәге бер солдат эндәште:

—Иптәш капитан! Миндә сезнең өчен бер яңалык бар.

—Әйтеп кара.

—Немец окоплары моннан 80-90 метр ераклыкта. Инде менә ике көн шуннан урыс маты ишетелә. Өч катлы иттереп, илләмә дә оста иттереп сүгенәләр инде. Немецны алай оста сүгенергә өйрәтү өчен ун ел укытырга кирәк. Мин үзем Ростовтан. Сугышка кадәрле грузчик булган кеше. Урыс матының тәмен яхшы беләм. Монда чын урыслар сүгенәләр. Матның иң асылы белән, урысча әйтсән—оборотный мат!

—Кемнәр булыр дип уйлыйсың?

Солдат:

—Уйладым мин. Болар теге сатлык власовчылар булырга тиешләр,—диде.

Капитан башын күтәреп буранга карап алды да, үзен озатып йөргән взвод командирына боерык бирде:

—Син мина ике кеше бир. Минем тагын ике ординарецым бар. Шул окоплар ягын барып әйләним әле. Үземнең тынлыйсым, ишетәсем килә.

Взвод командиры каршы төште:

—Иртәгә яхшы әзерлек үткәреп, «тел» алырбыз. Сезгә ярамый бүген.

Капитан көлде генә:

—Ярар, өйрәтмә инде син мине! Мин бит әле синең командирың да. Мин кушканны үтә.

Сакланып кына атлап биш кеше буран эченә кереп югалды. Бик ерак та китеп өлгермәделәр, алдан урысчалап боерык-сорау бирделәр:

—Стой! Кто идет?

Алдан атлаган Вильданов тавышын бик күтәрми генә җавап кайтарды:

—Свои!

Бик якын иде сораган тавыш. Зәйнинең тавышын ишетү белән 10-15 метрдан гына ике автомат ут ачты. Зәйнинең сул ягына берьюлы берничә таяк белән китереп суктылармыни—ул мәтәлеп кар эченә кереп китте. Бергә килгән сугышчыларның икесе җавап уты ачтылар, икесе капитанны килгән якка өстерәп, тау түбән ашыктылар...

Медсанбатта хирург тун һәм гимнастерка җиңнәрен кисkәләп ыргытты. Сул кул беләзектән алып, терсәктән югары тоташ чарпаланган иде. Хирург озак кына ит-сөяк боткасына әйләнгән кулны тикшерде. Тешләрен кысып, ыңгырашмаска тырышып яткан капитанга карамыйча карар кылды:

—Кисәбез кулыңны терсәктән.

Капитан дәшмичә генә азрак борылгандай итте дә, канга буялып беткән кобурасыннан «Вальтер»ын чыгарды.

—Кулымны кистермим.

Янында басып торган ординарецына боерык бирде:

—Ал автоматыңны кулыңа. Мине наркоз белән йоклатып кулны кисә башласалар, ат! Минем боерык шундый. Аңладыңмы?

—Так точно!

—Ярар!—диде хирург.—Кисмәм. Тик гангренадан үлүең ихтимал бит.

—Кулсыз яшәгәнче, үлгәнең артык. Кисмә. Ю спирт белән, тазарт. Түзәрмен.

Ике укол наркоз бирделәр. Тик капитанны наркоз алмады.

—Күпме эчкән идең?—дип сорады хирург.—Наркоз алмый сине!

—Йөз илле грамм спирт җибәргән идем. Шул барысы.

Стакан тутырып тагын спирт салдылар.

—Эч шуны. Өч йөз илле булсын. Кисмим кулыңны. Әйт ординарецыңа, чыгып торсын. Киссәм, операция беткәч, кереп атар...

Елмайды:

—Кулың булмаса дию ем...

Зәйни спиртны беткәнче эчте. Хирург тагын салды:

—Эч! Исер! Наркозсыз ясыйбыз сиңа операцияне. Эч!

Хирург кисмәде исерек капитанның кулын. Операцияне бик җентекләп ясады. Ярата иде гәүдәгә кечкенә хирург таза гәүдәле ирләрне. Көчле егетләр булганнары өчен...

Зволин тауларын, капитан Вильданов яраланганнан соң бер атна узгач, штурмлый башладылар. Өч көн—өч төн барган сугышлардан соң таулар алынды. Әсирлеккә эләккәннәрнең мундирларының сул җиңенә, терсәктән аз гына югарырак кечкенә итеп ясалып революциягә кадәр булган Россия байрагы тегелгән. Аңарга РОА дип өч хәреф язылган: Российская Освободительная Армия. Бу, монарчы бер фронтта да күрелмәгән сәер әсирләрдән сорау алгач, ачыкладылар: урыслар! Власов солдатлары икән! Үзләреннән кабер казытып барысын да аттылар...

Бер атна үтүгә капитан Вильданов госпитальдә ята иде инде. Җиңү көнен шул госпитальдә каршы алды.

* * *

Немец белән бу соңгы сугыш башланыр алдыннан яшәгәннәр, ди, авылда бер егет белән бер кыз. Егетнең исеме Ягъфәр, ә кызныкы Хәтимә булган. Егеткә унсигез яшь, ә кызга уналты гына тулып

килә икән. Хәтимә иртән уянып китеп, коңгырт күзләрен ачып җибәреп, якты дөньяга караса, кояш, таулар артыннан күтәрелеп килгән җиреннән туктап, каушап кала икән. «Нинди сихри нур бу? Минем нурларымнан да яктырак түгелме сон?» Кояш шулай тау артыннан акрын гына үрелеп карый икән дә, бер йортның тәрәзәләреннән нурлар агылганын күргәч, куанып, тагын да ныграк яктырып китә икән:

—Сөбханалла! Хәтимә сылу күзләрен ачкан икән!

Иртән торып Хәтимә көтү куарга чыкса, аның үтеп киткәнен карап калыр өчен заманында арсландай гайрәтле егетләр булган бабайлар капка төпләренә чыгып утыра икән. Хәтиманең җинел адымнар белән атлый-йөгерә үтеп киткәнен утырган җирләреннән генә булса да күреп калсалар, бабайларның аяк-куллары, бил-аркалары көнозын сызламас була икән. Менә шундый кыз икән Хәтимә.

Ә Ягъфәр атаклы башкорт Баймурат нәселеннән килгән Динислам тимерченен улы икән. Динисламның хатыны икәү, балалары күп булганнар. Тимерче хатыннары көндәш булып яшәмәгәннәр, ә ике якын дус, ахирәт булып, бергәләшеп тату дөнья көткәннәр. Балаларын да бүлешмичә, икесе дә имезгәннәр, бергәләп караганнар. Шунлыктан балалары көләч һәм тырыш булып үскәннәр. Ике инәйләрен дә бертигез яратып, хөрмәт иткәннәр. Ә гаилә башлыгы Динисламның хатыннарына гайрәте, балаларына назы, дөнья көтәргә, кешеләр белән аралашырга акылы җитәрлек булган. Малны да кул көче белән күп тапкан, гаиләсенә нужа-михнәтне күрсәтмәгән. Таң җилләре белән бергә уянып, аякларына торып баскан Динислам, авылда иң соңгы җан иясе булып йокларга яткан. Кечкенә елга ярына салынган тимерчелегендә чаң-чоң китереп тимер чүкегән, сабан-тырмалар, балта-пычаклар ясаган, комган-чиләкләр төпләгән. Күрше-тирә авылларның базарларында да тимерчелек иткән ул. Эшләгәне өчен хакны үзе сорап ала белмәгән—кем күпме бирсә, шуна риза булган. Тик саран кешегә икенче кат тимер сукмаган. Юмартлар өчен күнеле киң, ярдәмчел булган тимерченең.

Динислам тимерченең егермедән артык балалары арасында Ягъфәр улы шулардан бар яктан аерылып торган. Асыл, зирәк акыллы, сәләтле бала булган ул. Ун яшеннән сандал янына басып атасы белән бергә тимер чүки башлаган. Динислам тимерчелек эчендә учак янында тимер кыздырган арада улы Ягъфәр ике чүкеч белән сандалга сугып башкортның бию көен чыгара икән. Учак янында басып торган Динислам аякларының тыпыр-тыпыр биеп китүләрен үзе дә сизми кала.

—Һайт, шайтан малай! Нәмә кыланаһың һин сүкештәр менән, ә?

—Сандал сынлай бит, атай, бию көйенә!.. Мин түгел!—дип елмая икән малай.

Унике яше тулып килгәндә атасы Ягъфәрне татар авылы Эстәрлебашның атаклы ярминкәсенә алып барган. Ялан аяклы малай бер сәүдәгәрнең өсте ябык кибитка-арбадан тальян гармуннар сатканын карап тора торгач, әтисен дә, үзенең тимер чүкергә килгәнен дә оныткан. Гармуннар сатучы татар сәүдәгәр янында яна гына мыек чыгарып маташкан бер яшь кенә гармунчысы да бар икән. Егет төрле зурлыктагы тальян гармуннарның әле берсен алып уйната, әле икенчесен... Татар көйләрен өздерә генә икән!

Кояш офыкка авыша башлаган. Ә Ягъфәр, баскан урыныннан кузгалмыйча, гармунчы егетнең уйнаганын карап, тавыш-тынсыз гына онытылып тынлап тора да тора икән.

—Аксаң бармы, башкорт балаһы?—дигән сәүдәгәр башкортчалап.

—Аксам юк шул,—дигән малай.

—Уйнайһың киләме?

—Килә шул.

—Тотып караганың бармы һун тальян гармунды?

—Юк шул.

—Тот береһен. Уйнатып кара. Бәлки, барып та сыгар.

Бер гармунны алып Ягъфәргә сузган. Тик малай анысын алмаган.

—Һин минә әнә тегеһен бир!—дигән ул, гармунның кара-сары төскә матур иттереп бизәлгәненә күрсәтеп. Сәүдәгәр сораулы итеп гармунчыга караган. Тегесе көлгән генә:

—Ул сораганы гармуннын иң моңлысы инде. Бир әйдә, уйнап карасын! Гармунда уйнаган башкортны күргән юк иде әле монарчы. Шул кураен гыжлата бит инде алар тал төбенә ятып. Минем менә елдан артык инде гармунга тотынганга, яна түмен таба башладым уйнауның...

Ягъфәр тальян каешын жилкәсенә кия-кия әйткән егеткә:

—Һинен уйнауыннын барыбер атаһы-инәһе юк әле...

Сәүдәгәр кычкырып көлеп жибәргән:

—Син, башкорт, тәүдә уйнап күрсәт! Аннан сон һөйләшерсен! Тарт әйдә гармунны!

Ягъфәр бармаклары белән гармун телләре буйлап өстән аска, астан өскә кабаланмый гына үткән. Аннан сон, гармун телләрен сайлап баскалап, көйләр эзләгәндәй иткән, гармун күрүген тарткан.

—Йә-йә!—дигән сатучы түземсезләнеп—Әйттер берәр бию көен башкортнын! Хәзер төшеп басам!

Ягъфәр авыз чите белән генә елмайган да, тальян гармунны сузып уйнатып та жибәргән. Үзе гармун тавышына кушылып жырлый да икән әле:

Күршеләргә кунак килгән,
Инде ни хәл ит-тәй-йе-ем?..

Йөрәге дәртлеләрдән икән, түзмәгән, биергә төшеп тә киткән сатучы. Халык жыела башлаган. Ягъфәр үзе уйный, үзе жырлый, үзе биер өчен түгәрәк ясый икән:

Тукмак кой-йрык кара бәрән,
Һуй-йып кун-нак итә-тәй-йе-е-ем!

Биеп тыны кысыла башлаган сатучыны башкалар алмаштырган. Дәртләре кузгалып, биергә хатын-кыз да төшкән. Алар да кыза башлаганнар, берсеннән-берсе уздырып ярышалар икән. Көйне туктатмыйча гына, ике егет Ягъфәрне ике ягыннан күтәреп алып арба үрәчәсенә утыртып та куйганнар. Туктатма, утырып уйнат, янәсе...

Тальян гармуннын көмеш тавышы, Ягъфәр кулларында уйнап моң сибүе, ярминкәгә килгән татарны, башкортны, чуашны, мордва-мукшыны, хәтта мишәрне дә жәлеп итеп, үз янына жыйган. Ярминкәгә алыш-бирешкә дип килгән халык сату-алудан, алдау-алданудан, кәсеп итүдән туктап, тальян гармун уйнаган жиргә жыйналып, дөньясын оныткан...

Халыкны байтак биеткәч, Ягъфәр үзе уйнап, үзе жырлап татар, башкорт көйләрен башкаруга күчкән. Ярминкә анын жырлаганына, уйнаганына сокланып, тын калып тынлаган. Барысы да нужа-михнәтләрен онытып, гармун-жыр тынлыйлар икән...

Байтак кына вакыт узган. Ярминкәдәге шау-шуны да, гармунны да ишетмичә, кая югалды бу шайтан малай, дип эченнән генә зарлангалап, Динислам башкорт, кызган тимер чүкеп, бик ныклап эшли икән. Шул чакта монын янына бер танышы килгән:

—Әйдәле, Динислам! Синен малай гөрләтә анда бөтен ярминкәне! Тальянда уйный! Биемәгән, басмаган кеше юк анда! Шул хәтле дәртле иттереп әйттерә, мин сина әйтим, чыдап торыр әмәл юк! Әйдә инде тизрәк!

—Кит әле-е!—дигән тимерче.—Кулына тоткан нәмә түгел бит гармун! Ниндәй гармунсы булһын ти инде ул малай актыгыннан!?

—Әйдә инде-е! Баргач үзен күрерсен! Әйдә, диләр бит сина, ташла чүкеченне!

Тире алъяпкычын сандалга салып куйган, чүкечен шунда ук сөягән дә, киткән Динислам танышына ияреп. Барган. Баскан халык арасына,

тыңлый башлаган һәм... ата булган кеше сандалын да, чүкечен дә, кайда басып торганын да оныткан.

Байтак уйнагач, җырлагач, китәргә булган Ягъфәр. Тальянның каешын иненнән салып, гармунны сатучыга сузган:

—Рәхмәт, агай һинә! Тот был һандугасты! Тауышы бигрәктәр зә монлы икән!

Татар сатучы алмаган гармунны. Ягъфәргә әйткән:

—Сандугач үзе тырышып сайраса да, синең хәтлүк булдыра алмас, энем. Чын, моңлы башкорт баласы икәнсең! Сиңа булсын бу тальян! Калдыр үзеңдә. Йөрәгең тулы моң бит синең. Минекәй абзый үзе бирде бу тальянны миңа—бүләк итеп бирде, дип сөйләрсең. Мине искә алып уйнарсың. Ходай гомеркәйләреңне озын кылсын...

Ягъфәр белән Хәтимә Эстәрлебаш мәктәбендә укыган чакларында очрашканнар. Ягъфәр унынчы сыйныфта, ә Хәтимә сигезенчедә. Бер ел буена бергә укыганнар да әле. Менә шул елда башланган да инде аларның мәхәббәте. Тик менә...

Чәчкә атарга дип бөреләнгән мәхәббәтләре, чәчкә ата алмаган. Ягъфәр белән Хәтимәнең мәхәббәт чәчәге суык тигәннән түгел, ә сугыш уты ялкыныннан көйгән, көл-күмергә әйләнгән. Бу мәхәббәт Хәтимәгә мәңгелеккә истәлек-үкенеч булып калган. Ә вафат булганнарның хәтере булмый...

Ике яшь йөрәкнең мәхәббәте «Галиябану» пьесасын сәхнәгә куйган чакта башланган.

Башкортстандагы борынгы татар авылы Эстәрлебашның биш бригадалы «8 Март» исемле колхозының клуб мөдире булып, сәләтле, бик тә шаян, җор телле, затлы нәселдән килгән бер кеше эшләгән. Авыл аны бүген дә исенә ала, аны сөйли, сагына, юксына. Мәшһүр татар галимнәрен, ишан-муллаларын, хәлфәләрен, мәдрәсә мөдәрисләрен, сәүдәгәрләрен, җир биләүче алпавытларын, татар тарханнарын биргән ул нәсел. Чукындырудан качып, Казан тарафыннан Эстәрлебашка килеп төпләнгән, урыска баш бирмичә, корал тотып сугышкан атаклы Тукай бабай нәселеннән булган Гали Тукай. Ике тапкыр төрмәгә дә тыгып караганнар кеше башы ашар бәлшәуик-чекистлар Гали Тукайны. Тик Ходай аны үзенең мәрхәмәтеннән ташламаган, коткарган. Төрмәләрдән исән-имин чыга алган Гали Тукай. Чөнки Эстерлебаш халкы арасында аның турында начар итеп сөйләүче, өстеннән НКВД га шикаять язучы табылмаган.

Бердәнбер көнне шул Гали Тукай Эстәрлебаш авылының ун сыйныфлы татар мәктәбенә килгән. Татар теле укытучысы Абдулла Нагаевны эзләп тапкан.

—Икәүләшеп тотыныйк та, клубта «Галиябану»ны куйыйк. Әртистләр синнән, ә сәхнә миннән. Икәүләшеп режиссерлык итик.

Нагаев иркенләп көлгән дә әйткән Гали Тукайга:

—Кит инде, Гали энем! Җыен юк-бар уй синең башыңа килеп керә. Ә бит үзең атаклы Тукай бабай нәселеннән! Нинди «Галиябану» ди инде ул тагын?! Ярар инде Бәдриләрен, Галимәбануларын хатын-кыз күлмәге киеп икәү дә уйнарбыз ди инде. Ә Галиябану кем? Ә Хәлил? Исмәгыйль каян килеп чыгар?! Ничекләр иттереп табарбыз без аларны? Каян? Җавап бир!

—Шуңа килдем дә инде мин. Син генә таба белгәнгә. Әнә сезнең мәктәптә укып йөргән, оялып кына сәхнәгә чыгып җырлый башлаган Фәйзуллина Хәтимә дигән тулышып килгән кыз уйнар Галиябануны. Ә инде унынчы сыйныфта укып йөргән Байморатов Ягъфәр—коеп куйган Хәлил. Исмәгыйль иттереп тугыз-ун тирәсендә укыган иң үткер, үт күзле малайны куябыз. Менә дигән Исмәгыйль чыгачак андыйдан. Тик авыл халкы гына белсен Исмәгыйльне уйнаган егетнең үткер икәнен...

Нагаев азрак уйланып тора да әйтә:

—И-и, Гали-и! Шәп бит синең бу уең! Шә-әп! Исмәгыйль иттереп,

алай булгач Габделхәй Ибәтуллинны алырга була. Илләмә дә үткер инде...

—Сон, шулай булгач, тотындык!

—Барып чыгар дисенме?

—Без икәүләшеп тотынсакмы-ы?! Әйдә Эстәрлене бер жырлатыйк та, жылатыйк та. «Галиябану»ны куеп без авылны бер гөрләткән идек инде.

—Кайчан?

—Унтугызынчы елда. Син әле безнен авылга кученеп килмәгән иден. Кызылларга да куйдык, акларга да куйдык. Эстәрлебаш мәдрәсәсенен мөдәррисе Мөхәммәтшакир Тукаев бабакайнын төпчек кызы Хәлимә Галиябануны уйнады. Илләмә дә чибәр иде, үзе шәп жырлады...

Кызыллары да, аклары да гөрләшеп кул чаптылар. Бик тә шәп булды.

—Әллә син дә уйнадынмы?

—Уйнадым. Эстәрледә миннән башка уен буламыни инде? Шунда кагылды инде мина әртистлек жене. Күреп торасын бит, һаман акыл утырта алмыйча килде-китте йөрим. Үзем кебек әртист хатынымнан башка сава торган кәжәм дә юк. Минем өчен бу дөньяда тик сәхнә генә кирәк. Галиябанунын энесен уйнадым мин ул елны...

Ике асыл зат 1939 елнын ноябрь азакларында «Галиябану» пьесасын сәхнәләштерергә керешәләр.

* * *

Хәтимә читкә тайпыла.

—Мин оялам...

Ике кулы белән кызарып чыккан битен каплап, сәхнә читенә барып баса.

—Әртист кешегә сәхнәдә чакта оят дигән нәстә бетәргә, юкка чыгарга тиеш. Спектакль бара сәхнәдә...

—Юк, кирәкми. Уйнамыйм мин Галиябану булып...

—Тот ишекне, Ягъфәр! Галиябануыбыз чыгып йөгермәсен!

Инде нәрсә эшләргә? Бераз сүзсез басып торгач, Гали Тукай Ягъфәрне мәктәпкә жибәрә:

—Бар, йөгер мәктәпкә! Алып кил Нагаев белән хатынын монда. Йөгертеп! Хатынын белән бергә дип әйтте Гали Тукай, диген. Анладынмы?

—Әйе...

Күп тә үтми, хәлләре-тыннары бетеп Нагаев белән хатыны килеп керә.

—Нәрсә булды? Янасызмы әллә?

—Янабыз шул! Пьеса яна-а! Сезнен укучы кызыгыз кочаклашырга да, үбешергә дә теләми! Галиябану булып! Ояла, им-ме-еш! Надан, мәхәббәт мәсьәләсендә. На-а-ада-ан! Нәрсәләр укытасыздыр ул мәктәбегездә, белмим! Кочаклаша да белми бит! Үбешүне әйткән дә юк! Нәрсә укытасыз сон сез анда, ә?

Абдулла Нагаев Гали Тукайнын һәрчак шаяртып сөйләшкәнен анлап бетерми:

—Сон, нәрсә дип инде?! Ана теле укытам мин. Габдулла Тукайны. Укыту программасында кочаклашуга, үбешүгә өйрәтү каралмаган.

—Тукайны укытам дисен инде-е. Синенчә, Тукай кочаклашмаганмыни инде-е?!

—Ул кадәресен, Гали туган, мин белеп бетермим инде. Илләмә дә мәгәр Тукай, үзе буйдак булса да, мәхәббәт турында байтак язган...

—Сон, шулай булгач, синен укучы кызын нилектән надан ул яктан?

Авызлары ерыла, күзләре нурлана башлаган Хәлил белән Галиябануга Гали Тукай тиз генә карап ала да Нагаев белән анын хатынына борыла:

—Әйдә азрак өйрәтеп алыгыз әле укучыларыгызны... Эһһем, эһһем... э-э-э... кочаклашырга да, үбешергә дә. Бу эшне үзегез беләсезләр дип уй йөртәм мин.

Гали Тукай авызы колакларына житеп ерылган Нагаев хатынына:

—Галиябану буласың инде син... Гәүдәң дә килешеп тора... Галиябану булырга-а. Менә дигән.

Юан, билсез хатын гыркылдап көлә:

—Эй, шушы Галинең тел-ле-е! Өч бала тапкан хатында ниндиләр Галиябанулык калсын инде-е?..

—Ярар, ярар. Син иренә һәрчак Галиябану сыман инде! Беләбез аны гына. Әйдә, Абдулла абый, тот тальянны! Хәлил бул! Тәрәзәдән керәсең. Менә бу утыргыч синең өчен тәрәзә төбе, ди. Әйдә, жәһәт кенә итеп кер дә кочакла Галиябануыңны... хатыныңны инде. Ә сез, надан укучылар, карап торыгыз ничекләр иттереп кочаклашалар бу дөньяда бер-берсен яраткан жаннар һәм егет белән кыз ничек иттереп үбешәләр...

Кулын кулга сугып ике мәртәбә шапылдатып ала:

—Башладык изге эшне!... Мен-ннә шул-лла-ай, менә ничек кочаклашалар аны-ы...

«Галиябану» пьесасын Эстәрлебаш халкы дөньясын онытып, эшен калдырып карады. Колхоз клубы эче кешеләр белән шыгрым тулы. Басып торырга урын житми. Беренче рәттә алда идән тулы ыбыр-чыбыр, малай-шалай тезелешеп утырганнар. Тик, ни хикмәт, тавыш-тыннары юк. Чөнки ишек төбендә кергәннәргә билет ертып торучы Фәкыйрь Түшәге улы Галләметдин Мостафин аларга әйтеп-искәртеп куйган:

—Берегезнең генә тавышы чыксын, барыгызны да куып-сөреп чыгарам!

Шулай диеп куркытса да, барлык малайларны «бушка» керткән. Чөнки шулай эшләргә Гали Тукай үзе кушкан аңарга. Югыйсә малайларның берсен дә кертәсе түгел икән Түшәк!

Галиябану булып уйнаучы, чибәр, зифа буйлы, көмештәй тавышлы, житез хәрәкәтле, килешле-ыспай иттереп татарча киенгән яшь кенә татар кызы Хәтимәнең бирелеп, дөньясын онытып уйнавы, моңлы жырлары, сәхнәдә йөгереп-очып йөрүләре, сыктап-сыктап жылаулары залда утырган-басканнарның барысын да сихри дөньяга алып керде дә китте. Шуның өстенә Ягъфәр-Хәлилнең тальянда уйнавы, шуңа кушылып жырлавы, залда булган сихри көчне тагын да ныграк арттырды. Хәлил һәлак булганда Галиябану-Хәтимәнең өзгәләнүләре, жырлап-жылавы залны тоташы белән тетрәндерде.

Ике тәрәзәсе урам якка караган, башы салам белән ябылган сәхнәдәге кечкенә өй, жил капка, яшел талдан үрелгән матур читән—барысы да авыл урамыннан күчерелеп, бирегә менгереп утыртылган кебек.

Пәрдә ябылып, беренче тәнәфес игълан ителгәч, моңарчы тавыш-тын чыгармыйча «эспиктәкел караган» тамашачы телгә килә:

—Иллаһ-һым кәри-им!—ди тешләре төшкәннән сакауланган карчык тавышы.—Боларның Бәдриләре безнең авылның Югары Очтагы тач теге Абдулла Шөшле үзе икән! Нәрсә эшләп йөри икән инде бу Шөшле монда, дип торам утырган жиремнән. Эшләпәсе дә шуныкы бит әле...

—Оек-чабаталарын карале син аның! Сул ягындагы чабатасының мыекларына хәтле чыга башлаган...

—Читәне соң, читәне?! Ул читәнне Гали Тукай Түбән Очтагы Камәр карттан үрдергән. Әйтәм аны Камәр карт кукраеп иң алга барып утырган. Гали Тукай утырткандыр инде...

—Үзебезнең авылның Гапкадыйр бай малае тач шушы Исмәгыйль кебек иде инде. Урамнан узганда биргән сәламне дә алмый иде инде, хайван нәстә...

—Ай-һа-ай Исмәгыйльнең усаллыгы-ы...

—Чибәрләрнең дә чибәре икән, Галиябануларын әйтәм...

Тәнәфес бетүгә халык тына.

Исмәгыйль Хәлилне ата башлагач, бер хатын залдан жан ачысы белән ачыргаланып кычкырып жибәрде:

—Күрәләтә үтертәсез бит баланы! Нәстә карап утырасыз авызларыгызны ачып!

Зал шул мизгелдә үк үкереп, урыныннан купты. Әртистләр куркып уеннан туктап калдылар. Сәхнәгә Гали Тукай атылып килеп чыкты:

—Туганнар! Туктагы-ыз! Бозмагыз уенны! Спектакль бит ул! Уен бара бит!

Пьеса тәмамлангач та халык тиз генә чыгып китмәде. Бөтен зал аягүрә басып, әртистләргә рәхмәтләрен белдереп, көчле алкышларга күмделәр.

Ике ел үтүгә сугыш башланды...

* * *

Ягъфәр Байморатов туып үскән Йомагужа авылыннан урман-таулар аша, кыйбла тарафына карап сигез чакрым чамасы юл үтсән, Кайраклы исемле татар авылына барып чыгасың. Шул юл белән барган чакта урман эченнән бик зурдан булмаган бер аклан үтәсен. Акланга кергәндә юл сай гына чокыр аша уза. Аның төбендә челтер-челтер чишмә агып ята. Суы салкын, көмеш кебек саф. Тик кешеләр дә, хайваннар да ул чишмә суын бик сирәк, бик тә сусаган чакларында гына эчәләр. Тимер тәме килә чишмә суыннан.

Бер җәйдә шул урман акланында печән чапкан чагында Ягъфәр чалгысын кап урталай сындырган. Бәрмәгән-сукмаган, әмма тип-тигез җирдә үлән чапкан чакта чалгысы сынган да куйган. Ягъфәр төенчегендә калган ипи кисәген кулына алган да, сынык чалгысын күтәреп кайту юлына чыга башлаган. Аклан читенә җитеп, чишмә янына килгән. Арыган кеше шул чишмә суы белән битен, кулларын юса, анарга хәл кереп китә, көче кире кайта икән. Ягъфәр чишмә янына килеп җиткәч күргән: юлдан аз гына читтә, чишмә янында бер карт учак ягып, шуны кул күрүге белән өрдереп утыра икән.

—Әс-сәламегаләйкүм, бабай! Алла куәт бирсен!

—Вәгаләйкүм-сәлам, улым!—дигән бабай.—Куәт кирәргә кичәдән бирле бер тәгам ризык капканым юк бит әле минем.

—Минем бер кисәк ипием бар. Шуны бирим. Мә!

—И-и! Ипекәй булгач җитте инде,—дигән бабай.—Ризыкның башы ипи. Рәхмәт, балам!

Ипине бисмилласын әйтеп ашаган.

Бабайның уң колагында ялтыраган алтын алканы күреп Ягъфәр сораган:

—Син, бабай, әллә чегәнме?

Бабай елмайган да әйткән:

—Әйе, мөселман чегәне мин, улым. Синең әллә чалгың сындымы?

—Сынды шул, бабай! Тип-тигез җирдә! Бер сәбәпсез урталай сынды да чыкты!

—Ясаган чакта корычын дөрес чыныктырмаганнар аның. Кая, бир әле, карыйк. Уртасында киеренкелеге нык булган моның...

Үзе сөйләнә-сөйләнә суккалап чалгыны сабыннан чыгарган да, сыныкларын икесен дә утка тыккан.

—Элекке елларның берсендә, кирәге чыкса диеп, каен күмере яндырып, бер урынга күмеп киткән идем. Менә кирәге килеп чыкты бүген. Ялгыйбыз хәзер чалгыңны.

Ап-ак тигез тешләрен күрсәтеп Ягъфәргә елмайган:

—Әтиең Динислам исәндер бит, Ягъфәр улым?

—Исән. Син мине беләсеңмени?

—Беләм. Син нәкъ әтиеңнең яшь чагысың. Мин өйрәттем әтиеңне тимер эшенә.

—Әллә син чегән Матей бабаймы?

—Әйе. Чегән Матей булам мин.

—Алайса, әйдә безгә кунакка. Атайым һәрчак мактап искә ала сине.

Чегән сул колагындагы алтын алкасын селкетеп елтыратып куя да, монсу гына елмая:

—Ярамый шул миңа синең әтиеңә күренергә. Нигә ярамаганын үзе белә ул. Миннән күп итеп сәлам әйтерсең. Хәзер карап тор. Мин сине сынган чалгы ялгарга һәм корычы начар чалгыларны яхшы иттереп чыныктырырга өйрәтәм. Чегәннәр генә белгән сер ул. Сиңа күрсәтим инде. Исеңдә калдыр минем хәзер нәрсә эшләгәнне...

Учакта кызып ак төскә кергән ике чалгы кисәген бер-бер артлы алып, башы ярык тимергә камыр урагандай иттереп урый да, тимердән алып, учакка сала, тагын кыздыра чегән. Чалгы кисәкләре кызып, тагын ак төскә кергәч, аларны учактан алып, эченә яшь каен яфраклары тутырылган чиләккә тыга. Икесен дә каен яфраклары эчендә байтак әйләндергәч, янә учакта кыздыра. Аннан соң сандалга салып, чүкеп, турайта. Кулындагы чүкече зурдан түгел. Үзе туктамастан догалар укый.

—Белгән догаларыңның кайсысы да ярый. Тик доганың һәрберсен укып чыккач, «бисмилла»ны уку фарыздыр...

Чалгыны ямап, чүкеп, сабына утыртып Ягъфәргә тоттыра. Күзләренә карап акрын гына:

—Тагын ике елдан бик каты сугыш башланачак,—ди.—Бик күп кан коелып, бик күп кеше кырылачак. Андый сугышның моңарчы җир йөзендә булганы юк. Солдатка киткән чагыңда яраткан кызың сине кочаклап үпсә, сугыштан исән-имин кайтырсың. Үпмәсә... үзең тырышып кара исән кайтырга... Ходайның кодрәте киң... Хуш, Ягъфәр улым!..

Шул сүзләрне әйтүгә, акланда чегән дә, аның сандалы да юк була. Ягъфәр кулындагы ямалып сапланган чалгы белән аяк астындагы пыскып төтенләгән учак кына кала...

Аклandaгы үләнне чабып бетереп, кичен өйләренә кайткач, Ягъфәр әтисенә чегән Матей бабайның сәламен тапшыра. Ышанмый Динислам:

—Матей бабайның гүр иясе булганына унбиш-уналты еллар бардыр инде. Миннән ике яшькә олырак улы кереп, бездә кунып, әтисенең вафатын әйтеп киткән иде. Шуннан бирле ул да күренми. Юкны сөйлисең.

Ягъфәр ямалган чалгыны күрсәтте.

—Менә чалгыны кара. Матей бабай ялгап та, чүкеп тә бирде. Бу чалгы башкача чүкелмәсә дә үткер булачак, диде...

Динислам сакланып кына чалгыны кулына алды. Ямалган җирен тимерче бармаклары белән сәрмәштереп карады. Озак утырды ямалган чалгыны карап. Шуннан соң гына әйтте:

—Дөрес, Матей бабай эше бу. Аның гына куллары шулай оста итеп ямый белә. Бу дәрәҗәдә мин дә булдыра алмыйм. Матей бабай рухын күргәнсең син, улым...

* * *

Урман юлы белән, Кайраклы авылы ягыннан җәяүләп килеп урман чишмәсе янында бер әби тукталды. Челтер-челтер тавыш биреп аккан чишмәне тыңлап, күзләреннән аккан яшьләренә ирек биреп, озак басып торды. Аннан соң кабаланмый гына ияге астыннан бәйләнгән ап-ак яулыгын чиште. Аякларындагы җинел ак чүәкләрен, юка оекбашларын салды. Оекбашлары да ап-ак иде. Чүәкләрен дә, оекбашларын да аз гына читкәрәк үлән өстенә куйды. Ялан аяк калды. Сакланып кына үләннәрне аера-аера чишмә янына атлады. Барып житеп иелде дә, калтыраганрак тавыш белән, акрын гына чишмәне сәламләде:

—Әс-сәламегаләйкүм... Ягъфәремнең чишмәсе! Агасыңмы һаман?!—Бисмилласын укый-укый уң кулының учы белән чишмә суын алды да, тәмләп карады. Судан тимер тәме килә иде.

—Аллага шөкер! Бу көннәрне дә күрергә насыйп булды!

Чүәкләрен салган урынга кире кайтты да, үзе белән алып килгән ак төенне чиште. Әбинең төене дә, киеме дә, үзе дә—бар да ап-ак иде. Төеннән кечкенә жиз Бохара комганы чыгарды. Ак чинаяк чәшке алды. Чишмә чыгып яткан урыннан аз гына астарак үләннәрне сыйпый-сыйпый аерып керде дә, агып яткан судан, чәшкесе белән комганына чишмә суы тутырды. Шомырт агачлары күләгәсендә, аклан читендә, кояшка күренмичә генә тәһарәт алды. Ап-ак сөлгесе белән сөртенде, пакъләнде. Төенчегеннән пөхтәләп төрелгән, почмакларына яшел үлән яфраклары чигелгән ак намазлыгын алып, чишмә янында иплəп кенә, жыерчыкларын калдырмыйча җәйде. Үләннәр дә әбинең ниятенең изге икәнен белеп, аны тыңладылар, куллары тию белән ята бардылар. Әби төенчегеннән алып аякларына юка гына, өр яңа ап-ак жеп оекбашлар киде, яулыгын кире ябынды. Намазлыкка кереп басты.

—Иллаhи ният кылдым иртәнге намазымның ике рәкәгать сөннәтен үтәмәккә. Юнәлдем кыйбла тарафына...

Кабаланмый гына, жиренә житкереп, зур ихласлык белән әби намазын укыды. Урман акланын кояш жылытып өлгермәгән иде әле. Шунлыктан hава азрак салкынчарак иде. Чутылдап-чутылдап сайраган сандугачлар, әбинең тавыш биреп укыган иртәнге намазына кушылалар. Азлап-азлап тыйганны тыңламыйча, күзләреннән тәгәрәп чыккан күз яшьләре, кыйммәтле энже бөртекләре кебек кояшта ялтырап алалар да, әбинең кайчандыр чибәр булган йөзен каплаган жыерчыкларга кереп югалалар. Әби күңеле белән сыкрый, жылый, өзгәләнә иде.

—Барча галәмгә рәхмәт өчен жибәрелгән безнең пәйгамбәребез Мөхәммәт Мостафа галәйhиәссәламнең рух шәрифләренә...

—hәм дә, сөя башлап та, сөеп, назлап, гаилә корып, дөньяга аңардан балалар китерергә насыйп булмаган, «Галиябану» пьесасында Хәлил булып уйнаган, гармунчы, жырчы, тимерче, сугышта шәhит булып кайта алмаган Ягъфәр Динислам улы рух шәрифләренә ирештергәй идең...

—hәм дә «Галиябану» пьесасын сәхнәгә куючылар булган, шулай ук сугыш кырларында ятып калган Абдулла абый Нагаев белән Гали абый Тукай рухлары шәрифләренә ирештергәй идең...

—hәм дә Галиябануны үзенчә нык итеп ярата белгән Исмәгыйль ролен башкарган, шулай ук сугыштан кайта алмаган Габделхәй Ибәтулла рухлары шәрифләренә ирештергәй идең...

Әби кабаланмый гына гәүдәсен төзәткәләп, аякларын ябып куйды. Күлмәге кесәсеннән яшел төстәге тәсбихен чыгарды. Тәсбих төймәләрен тарта-тарта, иреннәрен кымшатып бик озак дога укыды. Акрын гына исеп-исеп киткәләгән аклан жиле әбинең ак яулыгы астыннан азрак күренеп торган ак чәчләрен сыйпый, әбине иркәли иде. Тәсбих тешләрен тартуын туктатып, әби акрын гына тавыш белән йөрәгенең иң ерак, иң сакланган жирләреннән чыккан моннарын, зарларын Ходаена сөйли башлады. Монарчы аларны чыгарганы, сөйләгәне юк иде әле.

—И раббым! Ягъфәр жанкисәккәем алдында гаебем дә, гөнаhларым да күптер hәм зурдандыр инде. Иртәгәсен армиягә китәр кичне кеше жибәртеп, өйдән чакыртып чыгарды. Азрак кына урамнардан йөреп килергә чакырды—бармадым. Кулларымнан тотарга итте—тоттырмадым. Кочакларга дип үрелде—кочаклатмадым. Оялдым егет белән урамнардан үтәргә дә, кулымнан тоттырырга да, кочаклатырга да. Яшь идем шул, бикләр дә кыргый идем, оялчан идем. Аннан бит безгә, мөселман-татар кызларына, сугышка хәтле тәртип иман белән бергә бирелде. Мөселман кызлары булып, инсафлы, тәртипле, иманлы булып үстек без. Бичаракаем яшь тулы күзләрен мөлдерәтеп карады үземә. Әллә нинди дәhшәтле, әчке бер тетрәнү белән әйтте:

—Мина чегән тимерче Матей бабайның жаны әйтте: «Ике елдан сугыш башланачак. Син солдатка киткәндә хушлашканда сөйгән кызың сине кочаклап үпсә, сугыш беткәч исән-сау кайтырсың авылыгызга,»—диде. «Син мине үпсәң, мин кайтырмын! Икәү бергә гаилә корып яшәрбез.

Балалар үстерербез. Чөнки син минем сөйгән кызым. Яратам мин сине, Хәтимәкәем!..»

—И, раббым! Оялдым, үпмәдем шул. Мин белмәдем бит сугышлар буласын! Ход-дай-ййы-ым! Бер дә үбешкәнем юк иде шул. Китте дә Ягъфәрем кырыгынчы елны ук, кайтмады. Ичмасам спектакль барышында да үбешмәдек бит. Йөземне күкрәгенә яшердем дә, бирмәдем иреннәремне. Мин аны үптерер өчен генә сөйли ул сүзләрне дип уйлаган идем шул, капка төбендә хушлашканда. Бик яшь идем шул, бик тә оялчан идем. Мин сәбәпчедер инде Ягъфәрнең сугыш кырларында ятып калуына-а...

Ел буена хатлар язды. Сугыш башлангач та кырык икенең язына хәтле хатлары килеп торды. Ленинград янындагы «Невский Пятачок» дигән иң куркыныч, иң мәхшәр жирдә сугышты ул. Өлкән лейтенант булган, күрсәткән батырлыклары өчен ике орден белән бүләкләнгән. «Көт мине, Галиябануым минем. Кайтырмын мин. Сәхнәдә син мине кочаклаган идең бит. Шул кочаклауны мин үбү итеп исәплим әле. Син мине көт, мин кайтырмын.»

Көттем. Сугышлар беткәч тә көттем. Өзелеп-өзелеп зур өметләр белән көттем. Кайтмады Ягъфәрем минем...

Әби намазлыгы өстендә сыктап, тавышсыз гына жылый иде. Акландагы сандугачлар да әбинең ничәмә-ничә еллар буе жыйналып килгән кайгыларын, уйларын анлагандай сайрауларыннан туктап тынлыйлар. Тик беренче мәхәббәтен эзләп чыккан бер яшь сандугач кызы гына, егет сандугачын чакырып чут-чут китереп, дәртләнеп-дәртләнеп сайрап куя. Туктый, тынлый, егет сандугачның сайравы ишетелмәгәч, тагын чутылдап сайрап алып китә, тагын тына, тагын тынлый. Тагын көтә, тагын чутылдый...

Әби, онытылып, ялгыз сандугач сайравын тынлый. Ялгыз күнеле өчен бик тә кирәк бу сайраган сандугач. Шушы акланда яшәгән сандугачлар, кеше балалары кебек, әллә кемнәр бәхетле булсын өчен сугышларга китеп башкайларын чит-ят жирләрдә салмаганнар шул. Сайрап яшиләр бүген дә, бала чыгаралар, аларны тигез яшәп үстерәләр. Нигә кешеләр дә сандугачлар түгел икән!?

Әби намазлыгы өстендә бик озак утырды. Акланнан һич кенә дә китәсе килми иде. Инде аяклары да ойый башлады. Тик ул урыныннан тормады. Жаны, тәне белән тойды: Ягъфәрнең жаны да шушы акланда! Бәлки, акландагы сандугачларнын берсендәдер әле?!

Кыйбла тарафыннан, Кайраклы авылы ягыннан ат пошкырган, арба шыгырдаган тавышлар ишетелде. Озакламый урман юлыннан атлы арба күренде. Әби кузгалмады, тавышлар килгән якка күтәрелеп карамады. Ул онытылып, үз уйларына, үз хисләренә бирелеп утыра иде...

Чишмәгә килеп житәрәк арбада утырган урта яшьләрдәге жыйнак кына гәүдәле ир атын туктатты да, арбадан төште. Дилбегә белән чыбыркысын йөк өстенә куйды. Йөге—он тутырылган унлап капчык өстендә 14-15 яшьләр чамасындагы, яна гына егетләр төсе керә башлаган чибәр генә бер үсмер утыра.

—Төш, улым!—диде юлчы.—Юынып алайык. Шишмә һыуы менән юынһаң аргандар бетеп китә. Әйткәнем бар бит инде ул турала...

Малай жиргә сикереп төште. Гәүдәсе жыйнак-житез иде. Шул мизгелдә алар икесе дә ап-ак чәчкәгә күмелгән шомырт агачы төбендә утырган ак әбине күреп алдылар.

—Исәнме, апай!?—диде юлчы.

—Исәнме, әбекәй?!—диде малай.

Әби шунда гына башын күтәреп юлчыларга карады. Малайны күргәч йөзе дертләп, агарып китте. Авырлык белән, акрын гына кузгалып ак намазлыгы өстенә торып басты. Атларга теләде—атлый алмады. Дәшәргә итте—сүзләре тиз генә чыкмадылар:

—Ягъ... Ягъфәр бит си-ин?!

Әби гәүдәсе белән өшегәндәй иттереп калтырап куйды. Малай

этисенә карады. Ул бернәрсә дә анламый иде. Әтисе ак әбигә азрак карап торды да, сак кына итеп сорады:

—Һин... апай... әллә Хәтимә енгәһенме?

Әби үзендә баш кагырлык кына көч таба алды.

—Мин, енгә, Таһир булам. Ягъфәр Байморатовтын бертуган кустыһы. Энесе. Атай бер, инәләр башка. Утыз тугызынчы елда туганмын. Ягъфәр агайымды ишетеп кенә, фотоларыннан карап кына беләмен...

Нәрсә әйтергә белмәгәндәй азрак уйланып торды да өстәде:

—Һугыштан кайтманы агайым. Ә атайыбыз узган ел гына вафат булды. Тукһан икелә инде...

Малайга борылды.

—Минем улым был малай. Исеме ысыннан да Ягъфәр. Атай кушты, агайымдын исеме «Невский Пятачок»та ятмаһын тиеп...

Баскан урнында таптанып куйды:

—Һине ишетеп кенә белә инек. Күрергә лә насыйп булды. Һине алып кайтыйык Йомагужага. Авылыбызга инде. Күреп, кунак булып китәрһен. Агаемнан ике яшькә олы Шәрифә исемле апайыбыз бар. Исән бөгөн дә. Ул күп белә Ягъфәр агайым хакында. Тальян да бар. Улым Ягъфәрдән уйнатырбыз. Бик матур уйнай ул. Йөрәгенә енелрәк булып китәр. Әйдә, енгә...

* * *

Ягъфәр чишмәсе әле дә челтерәп агып ята. Тик, Хәтимә әби чишмә янына килеп киткәннән сон суыннан тимер тәме түгел, күз яшьләре тәме килә. Сугышка киткән егетләрен көтеп-көтеп тә кавыша алмаган, сугыш вакытларында сөйгәннәрен югалткан кызларнын күз яше тәме чишмә суында..

Хәтимә апаны әле дә исән, диләр. Башкортстаннын Салават каласында яши икән. Ленин урамында, диләр. Шулайдыр, дөрестер, кеше белми сөйләмәс!

Эстәрлебаш авылынын колхоз клубында куелган шул «Галиябану» спектаклен мин дә караган идем. Ин алда, идәндә утырып. Исмәгыйль Хәлилне аткан чакта, тыела алмыйча, үксеп-үксеп елаган идем мин...

*Казан,*
*2001 ел*

---

## «Тәнкыйть кирәкле шәйдер...»

2000 елда әдәби тәнкыйтьне җанландыру нияте белән «Казан утлары» журналы тәнкыйть мәкаләләренә конкурс игълан иткән иде. Аңа үз вакытында йомгак ясалып, җинүчеләр билгеләнде. Узган ел да без бу традицияне дәвам иттек, журнал битләрендә әдәби хәрәкәтнең барышын дөрес яктырткан, актуаль мәсьәләләр күтәргән байтак язмалар басылып чыкты. Алар арасында **М. Госманов, Ф. Сафин, Р. Шәрәфиев, Д. Заһидуллина** хезмәтләре аерата уңышлы дип табылды. Бәйге шартлары буенча аларга журнал редакциясенең махсус бүләкләре тапшырылачак.

*Актив авторларыбызны чын күңелдән котлыйбыз, аларга яңа иҗади уңышлар телибез.*



## Илдар Юзеев

ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Җәйге таңда уяну

Бар тереклек арган-талган, яшәүдән туктаганмы?
Теге дөньяга киткәнме, әллә соң йоклаганмы?
Юк, бу—бары вакытлыча, беркадәр мәрткә китү,
Бер көн алга бару өчен бер төнгә артка китү.
Анда кемнәр ни кыладыр, табигать калган минсез.
Мин монда телсез һәм өнсез,—куркыныч һәм күңелсез.
Күктән күреп торучылар бу халәтне аңлатмас,
Уянгач та үзең уйла, сизен, йөрәк, аңлат, баш!
Бар гомерең йоклап узар, гамь белән уянмасаң,
Бу дөньяның фанилыгын җан белән тоялмасаң...
Нинди серле, нинди шатлык җәйге таңда уяну,
«Әле дә шөкер яшәештә мин бар!»—диеп уйлану.
Иң саф хисләр, изге эшләр шул җәйге таңда ата.
Күкрәгеңдә беркемгә дә әйтелмәс серләр ята.
Баштан сыйпап талгын гына рәхәт җил исеп куя,
Әнкәеңнең иркәләве исеңә төшеп куя.
Арттырмыйм да, киметмим дә, җир оҗмахы шушыдыр.
Ахыры юк, бу—гомернең сабый чагы, башыдыр.
«Хәерле иртә!» диләрме, асыл кошлар җыр суза,
Бакчадагы гөл-чәчәкләр: «Исәнме?»—дип, кул суза.
Зәңгәр томаннар аркылы Кояш нурларын коя,
Җир йөзенең көләчлеге бер җанга ничек сыя?!
Гомереңнең кыскалыгын искәртә бары гөлләр,
Беркайчан да килмәс кебек мәңгелек «минсез төннәр»...

---

Илдар ЮЗЕЕВ *(1933) - Татарстанның халык шагыйре, драматург; күпсанлы шигырь, пьеса китаплары авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Идел ярларыннан карап торам

Шәһри Казаныма карап торам,
Ераклардан балкый ак кала.
Күпме яу килгәнне кичергәнсең,—
Шуңа күрәдер син—сак кала.
Шатлыкларны хәсрәт алыштырган,
Булалмаган гел-гел шат кала.
Узган дәверләрнең фаҗигасе
Изге ташларында саклана.
Идел ярларыннан карап торам,
Җәйге таңда күңелем сафлана,
Йөрәк яраларын оныттырып,
Булсаң иде мәңге шат кала.

Шәһәр топольләре урамдагы
Кызлар кебек ярым шәрәләр.
Бу шәрәлек, ахры, туйдыргандыр,
Сөенешеп яфрак яралар.
Кызлар, кызлар, зинһар сакланыгыз,
Очрашырга вакыт: кич җиткән.
Яз шәрабе—яңгыр тамчылары
Аек топольне дә исерткән.
Язга таба чабып барган чакта
Тополь башын кисеп кем аткан?
Үлеп гашыйк булган яшь кыз сыман,
Шәрә тополь башын югалткан.

## Кая ашыгасың, дөнья?

Тормыш агымына иярергә
Тырышам да калам тукталып.
Кая барам? Кая ашыгам мин?
Уйга чумам ялгыз тын калып.
Карап торам ярны назлый-назлый
Талгын гына аккан дулкынга.
Бу тормышның көйсез агышлары
Илтмәс микән соңгы упкынга?
Тормыш агымына иярми дип,
Тәнкыйтьчеләр, әйдә, язсыннар.

Үз итәм мин чишмә сагышларын,
Заман агышыннан ятсынам.
Бу дөньяны куа-куабыз да
Тоталмыйча дөнья куябыз.
Төзәлмәслек хата-ялгышларны
Гомер азагында тоябыз.
Кая чабасың син, ашыгасың?
Юлың билгесез һәм ерактыр,
Дөнья, жаным, көйлә агышыңны,
Былбыл тавышларын тыңлап тор.

##Ниләр көйли Казансу?

*Явыз Иван гаскәрләре Казанны алу алдыннан Камай морза, дары мичкәләрен бушатып, су тутырта. Элекке Камай утары әле дә аның исемендә*

Гасырларда кала Изгелек һәм
Үз халкыңа кылган яман эш.
Кол Шәрифләр мәчет булып калка...
Дары мичкәләре һаман буш...
Үз кавеме, ятка әверелеп,

Явыз Иван белән туп аткан.
Үз-үзенә ышанычын татар,
Бәлки, шул чакларда югалткан?
Дары базларыннан сулар ага...
Ниләр көйли икән Казансу:
«Бүленүләр упкыннарга илтә,
Аерылулар бигрәк яман шул,
Һәлакәттән сабак алмасагыз,
Хәлләребез булыр һаман шул...»

## Кулъяулык хәтле болыт

Озатты мине еракка
Болытсыз көннәр яме,
Яшьлектә сөйгән ярым... һәм
Кулъяулык җилфердәве.
Узып барса күк йөзендә
Кулъяулык хәтле болыт,
Күренә миңа озатып калган
Ап-ак кулъяулык булып.
Без идек саф сөю белән
Зәңгәр күккә очынган...
Икебезне ике якка
Язмыш җиле очырган.
Яшьлегемдә җилфердәгән
Кулъяулык хәтле болыт
Иң караңгы көннәремдә
Яктыртты кояш булып.

Чәчләр агарды дип мактаналмыйм,
Ап-ак калалмады күңел дә.
Күп хыяллар, чынга ашалмыйча,
Югалдылар өмет күгемдә.
Сафлык калса әгәр бу җанымда—
Саклап калды аны җыр гына.
Гомеремнең соңгы тамчыларын
Көйгә салган чагым тын гына...

## Су буенда су эзлим...

Кулларымда ике чиләк:
Куш чиләк.
Чайкалалар, икесе дә
Буш чиләк.
Йөрим Идел буйларында,—
Сусадым.
Чүлдә йөргән дөяләргә
Охшадым.
Табигатем, мәрхәмәтле
Булсачы,
Су буенда сулар эзлим
Бер тамчы!

Яна тәнем, яна җаным,
Иреннәр...
Су юлын таба алмыйлар
Киленнәр.
Янгынчылар, ник йоклыйсыз,
Кайдасыз?
Ярдәм сорап кычкырсам да
Файдасыз.
Бирегезче бер тамчы су...
Әлсерим.
Су буенда саилчедәй
Су сорыйм.
Эзли-эзли таптым аны,
Ул—киткән,
Юлы гына калган бары—
Су—кипкән.
Хәлсезләнеп, кайнар җилдә
Чайкалам.
Буш чиләкне яңгыратып,
Чаң кагам:
Төшме, өнме? Өнме, төшме?
Ни соң бу?
Бу—һәлакәт өндә юктыр
Дисеңме?

## Әҗәл ... үлгән

*(Төш)*

Шатлан, бие, тантана ит!
Әҗәл үлгән! Күмелгән!
Мондый олы сөенечне
Моңа кадәр кем күргән?
Төшкә дә кермәс хыялың
Инде тормышка ашты:
Ниһаять, кыска гомерең
Мәңгелеккә тоташты!
Йөрим, имеш, җырлап-биеп,
Башны Күкләргә чөеп:
«Шул Әҗәлдән—Газраилдән
Котылдым инде!»—диеп.
Узам гасырлар буенча,
Еллар елга бәйләнде.
Яшәп аргач, сөенечем
Көенечкә әйләнде.
Инде тәмам картайганмын,
Хәлемне беркем белми.
Әҗәлне көтәм, чакырам,—
Ә ул килми дә килми.
Тәхетне дә, бәхетне дә
Явызлар басып алган.
Күпләр акылдан шашканнар,
Адәмнәр шашып калган.
Мин дә ялварам, кычкырам
Бәхетсез еллар аша:
«Китмә, китмә Җир йөзеннән,
Кил, Әҗәл, үлмә, яшә!
Яшә, әмма тормыш җиле
Иссен тәнне иркәләп.
Килми тор, гүзәл җаннарны
Алып китмә иртәрәк.
Синең алда бар да тигез:
Кол, җиһангир, патша да,
Җиңәлми яу да, акча да,
Үлмә, Әҗәл, кайтсана!
Салкын туфрак. Ташта язу:
«Монда Әҗәл күмелгән.»
Синнән башка бу дөньяга
Ни буласын кем белгән?
Кулда көрәк. Меңьяшәрләр
Теш кайрыйлар алдымда.
Чык, Әҗәлем, зинһар, безне
Мәңгелеккә калдырма!

*2001*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр

## ШАГЫЙРЬ, ӘДИП, МИЛЛӘТ ХАДИМЕ



*Айдар Хәлим (Борис Нәҗметдин улы Хәлимов) 1942 елның 1 гыйнварында Башкортстан АССРының Миякә районына кергән Бәләкәй Кәркәле авылында укытучы гаиләсендә туа. 1959 елны Миякә урта мәктәбен тәмамлый.*

*Иҗат белән мәктәптә укыган елларында ук шөгыльләнә башлый, беренче шигыре район газетасында 1958 елда басылып чыга. Октябрьский техник училищесында бораулаучы һөнәрен алганнан соң, калмык далаларында Каспий нефтеразведкасында эшли. 1961-1964 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1964-1968 елларда Казан университетының журналистика бүлегендә укый. Студентлык елларында ул яшь шагыйрь буларак таныла башлый. Җәмәгатьчелек игътибарын яулаган шигырьләре беренче тапкыр 1964 елда «Татарстан яшьләре» газетасында басыла. 1966 елда Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим сүз башы белән «Казан утлары» журналында дөнья күргән шигырьләр циклы әдәбиятка үзенчәлекле шагыйрь килүен раслый. Журналист дипломын алган яшь каләм иясе Түбән Кама төзелешләренә юнәлә. Ул анда тормыш сынаулары үтә һәм граждынлык чыныгуы ала. Нефтехимик комбинатта техник хәбәрдарлык буенча инженер, радиожурналист һәм балта остасы булып эшли. Андагы яшь әдипләр белән берлектә «Кама таңнары» әдәби берләшмәсен оештырыша, берничә ел аның белән җитәкчелек тә итә. Түбән Камада яшәгән чорда иҗади, иҗтимагый, шәхси каршылыкларга тап булу сәбәпле, 1971 елда ул Уфага китә. Башта «Совет Башкортстаны» газетасында иҗади хезмәткәр, соңрак—Урал-Себер магистраль нефть үткәргечләр идарәсендә өлкән инженер, Башкорт академия драма театрында баш режиссерның әдәби яктан ярдәмчесе булып эшли.*

*1974 елда аның башкорт телендә «Беренчеләр» исемле китабы дөнья күрә. 1976 елда Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудаш, шагыйрьләр Муса Гали, Әнгам Атнабаев тәкъдиме белән СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. 1983-85 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары Әдәби курсларда (драматургия буенча Виктор Розов семинары) укый. 1983-87 елларда Башкорт академия театрында аның «Җанчишмә», «Пәри туе» дигән спектакльләре сәхнәгә чыга.*

*1988 елда Мәскәүнең «Дружба народов» журналында аның СССР күләмендә зур резонанс тудырган «Язык мой—друг мой...» дигән зур мәкаләсе дөнья күрә. Башкортстан татарларын башкортлаштыруга багышланган бу мәкалә шул ук көннәрдә 30 мең тираж белән литва телендә аерым китап булып басыла. Ростов шәһәрендә урнашкан бөтенсоюз документаль фильмнар студиясе бу хезмәт буенча өч кисәктән торган «Как стать экстремистом» дигән фильм төшерә. Фильм 1990 елда Татарстан телевидениесе буенча да күрсәтелде.*

*1991 елда Вильнюсның «Мокслас» («Фән») нәшриятында А. Хәлимнең «Книга Печали» китабы дөнья күрә. Бу хезмәте өчен ул «Җирдә кешелеклелекне яклаучылар Конфедерациясе»нең Ак Лачын» ордены белән бүләкләнә (Амстердам, Голландия).*

*1991 елда Айдар Хәлим Чаллы язучылар оешмасы һәм Чаллы шәһәр советы тарафыннан яңа оештырылачак «Аргамак» журналына баш мөхәррир итеп чакырыла. 1991-1995 елларда ул бу журналның баш мөхәррире булып эшли.*

*А. Хәлимнең тормыш һәм иҗат юлын, яшәгән төбәкләргә бәйле рәвештә, берничә этапка бүлеп карарга була. Әле күптән түгел генә Казанда «Айдар Хәлим» дигән биобиблиографик күрсәткечтә хаклы рәвештә болай язылган: «Казанда шагыйрь буларак туса, Уфада шагыйрь һәм шәхес буларак чәчәк атса, Чаллыда ул публицистик һәм чәчмә әсәрләр остасы булып танылды».*

*1992 елдан Татар Халкы Милли Мәҗлесе депутаты буларак, ул 1997 нче елда Милли Мәҗлес рәисе булып сайлана һәм бу иҗтимагый постында 2001 нче елга кадәр эшли.*

*Публицистик китапларын ул өч—татар, башкорт һәм рус телләрендә бер үк дәрт һәм дәрман белән яза ала. Аның бу өлкәдәге хезмәтләре бүгенге татар публицистикасының казанышлары дип санала ала.*

*Бер үк вакытта Айдар Хәлим шигърияттә, аеруча татар прозасында иң актив эшләүчеләрнең берсе. Аның «Кыйбла», «Эңгер», «Авылдаш», «Казыктагы итальян», «Берлинга хат» кебек хикәяләре, «Өч аяклы ат» повесте, «Татар вакыты» дигән кыска романы (аларның күбесе иң әүвәл безнең журналда басылды) шул хакта сөйли.*

*Айдар Хәлим татар милли хәрәкәтенең, татар милли иҗтимагый фикеренең теоретик һәм гамәли лидерларының берсе. Аны һәм аның киң танылган «Книга Печали», «Этот непобедимый чеченец», «Убить империю!», «Гомеремнең ун көне», «Веселая книга», «Минем Түгәрәк Иманем» китаплары, «Татар Халкының Жир Шары халыкларына Меморандумы» дигән хезмәтен дөньяда яхшы беләләр.*

*Бүгенге көндә Айдар Хәлим Чаллы шәһәрендә яши һәм актив иҗат итә.*

***Бу айда шагыйрь, прозаик һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимгә 60 яшь тула. Редакция коллективы юбилярны котлый, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары тели.***

**Айдар Хәлим**

# БӨРКЕТЛЕ БАГАНАЛАР

КАЗАКЪ ДАЛАЛАРЫНДА

**1956** елның ноябре иде.

Күкчәтау казакъ драма театры бинасында беренче чирәм уңышын урып-җыю буенча җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы бара.

Бүләкләрне партия өлкә комитетының Беренче Секретаре Жалкын Жаксылыков, мөнбәр артыннан торып, үзе тапшыра.

Әле генә Сәдитләрнең «Мәмләкәт» совхозыннан Кривошапка дигән комбайнчы күкрәгенә Хезмәт Кызыл Байрагы орденын кададылар.

Сәдит әле шул вакыйгадан һушын җыя алмый утыра.

Менә тантаналы җыелышның рәисе чираттагы бүләкләнүченең исемен атады:

—Сәхнәгә беренче уңышны югалтусыз җыеп алу өчен барган социалистик ярышта җиңеп чыккан... һәм... һм... барлык өлкә буенча беренче урынны яулаган һәм... һм...—Алып баручы, кәгазен укый алмагандай, «һәм»не «һм-һм»га әвереллереп, телендә тәмләп, янадан төртелеп торды.—...хезмәт уңышлары өчен «Хөрмәт билгесе» ордены белән бүләкләнгән «Мәмләкәт» совхозы комбайнеры Сәдит Гәбдерәүф улы Гатиятуллин чакырыла!..

Монда, кичә генә компартия ихтыяры белән иксез-чиксез казакъ даласына җыйналган йөзләгән милләт балалары, ниндидер Сәдитнең ниндидер атасы Гәбдерәүф, атасының ниндидер бабасы Гатиятуллаларны түгел, Сәдитнең үзен дә белмәгән һәм белергә дә ашкынып бармаган,

аннан гайре, яхшы оештырылуыннан ук ясалмалык бөркелеп торган бу тантанадан шактый арый, талчыга төшкән зал гадәттәгечә иренеп кенә кул чабарга тотынды.

Арткы рәтләрнең берсендә утырган Сәдит, күрер күзгә егерме бишутыз яшьләр өстендәге ир, башкалар шикелле ут капкан сыман кыбырсымый, ашыкмыйча урыныннан күтәрелде һәм өстендәге соргылт пинжәген тәртипкә китерергә теләгәндәй, аннан-моннан тарткалап, сыйпап-сыйпаштыра салып, келәм буйлап президиумга таба юнәлде. Атламнары аның вак, әмма ышанычлы, бераз артка чөелгән йөзендә киләчәккә ышаныч, өмет һәм ихтыяр көче сизелеп тора иде. Аның «сәтсиәлистик ярыш йомгакларына» мотлак ашыкмавы Беренченең ачуын китереп куйды. Авыз суын корытып, күпме кешегә таратасы бар мондый бүләкләрне, ә ул, кара син аны, җәйләүдәге нәсел тәкәсе сыман, ничегрәк кенә текә басып килә ята!.. Ленин орденлы халык акыны, туксан тугыз яшьлек Җамбыл бабай Җабаев[1] та үзен болай иркен тотмаган мондый мәртәбәле залларда!..

Ул якынлашып килгән механизаторны карашы белән җиз иләктән или, нindидер, үзе генә белгән нурлар белән тикшерә, үтәли үтә иде. Беренченең йөз җепселләре кинәт тартышып куйды. Ул, таныгандай булып, үткер карашы белән янадан Гатиятуллинга кадалды. «Шул түгелме бу?— дип уйлап алды ул.—Бункеры өстенә бишек элеп, ашлык өемнәре белән басуны тутырган нугай[2] малае түгелме соң бу?»

Гүя аның алдыннан ялкынланып яна-яна агарган кояш үзе тәгәрәп килә иде. Бер карады—ул кайнардан пеште. Икенче карады—ул салкыннан өшеде. Аннан күтмәгәндә генә елмаеп куйды. «Нугай малае» әле һаман килеп житә алмый иде, әтнәке.

Аны тизрәк тартып китертергә теләгәндәй, Беренче үзе дә сизмәстән кул чаба башлады һәм алкышлаудан әле генә туктаган, бу пошмас бүләкләнүченең ниһаять сәхнәгә күтәрелүен көткән залны артыннан ияртеп алып китеп, янадан кул чаптырырга, дәррәүдән алкышлатырга тотынды. Менә ул килеп җитеп килә... Менә ул килеп тә җитте. Әйе, шул. Нәкъ үзе. Кыска, туп шикелле җыйнак буй-сын. Үзе ашыгып бармаса да, дәртедәрманы ташып торган, хәрәкәтчән тән-бәдән. Иген басуы кебек киң, якты маңгай. Кояшта янып, кызгылт кавын төсенә кергән йөз. Һәм... шуның капма-каршысы: житкән арыш сабагы сыман аксыл-сары чәчләр учмасы. «Бу кеше җәй буе баш киемен салмаган, күрәсең,—дип уйлап куйды Беренче.—Моның чәчләре быел җәйге кояш белән бөтенләй танышып та өлгермәгән...» Гомерендә меңләгән «социалистик ярыш» алдынгыларын күргән-белгән Беренченең бу кешене истә калдыруының, онытмавының үз сәбәбе бар шул. Ярар, анысы хакында, әгәр насыйп итсә, соңыннан искә алырлар. Хәзергә партия гозерен үтәгез, иптәш Җаксылыков.

Беренче үзе басып торган мөнбәр артыннан чыкты һәм Сәдит Гатиятуллинны кысып кочаклады, аннан, тәртип кушканча, орденны кечкенә каптан чыгарып, пинжәк якасына беркетә башлады. Бүләкләнү-чененң күзенә карап, ата-бабаларының нинди нәселдән булуын аныклау, зал каршында озаклап гәп куертып тору регламентта бөтенләй каралмаган каралуын. Әмма бу юлы Җаксылыков үзен регламент белән чикләп, бу бурычтан котыла алмады. Гатиятуллинга орденның таныклыгын һәм буш кабын тапшырып, кулын кысканда аларның карашлары очрашты. Комбайнчының жете зәңгәр күзләре нindидер боз биләү эчендә яна, ана нindидер бер куркыныч белән янап ялкынлана, бәгърен бораулый иде... «Зәңгәр күзле нугайлар, гадәттә, аксөяк нәселле, тирән тамырлы, кабилиятле нугайлар була торган иде,—дип уйлап алды ул.—Ә бу туескан[3] карашы белән мине ашап бара, әтнәке. Вагаймаганнармы?»

---

[1]Җамбыл Җабаев (1846—1945)—казакъ халык акыны, Сталин премиясе лауреаты (1941).
[2] Нугай—Урта Азия халыклар Идел буе татарларын үзара нугай диләр.
[3]Туескан *(казакъ)*—туган, энекәш.

Көткәне озак көттермәде.

Комбайнчы еларга житеп авызын чалшайтты, Жаксылыковның кулын үз кулының мамырлы ыргагы белән эләктереп кысып, пышылдады:

—Ниг—гә?! Пач-чам-му?!!!

«Вагайганнар икән». Секретарь бер нәрсәне аңламады һәм берүк вакытта күп нәрсәне аңлады да кебек. Иң мөһиме, ана бу «Ниг-гә? Пач-чам-му» дигән сүзләрне зал гына түгел, СССР компартиясенең беренче секретаре иптәш Хрущев үзе, Казакъстан компартиясенең беренче секретаре иптәш Брежнев үзе, Казакъстан Министрлар Советы рәисе Димәш әкә—Динмөхәммәд Әхмәд угылы Кунаев үзе, алар гынамы, Жир шарының барлык коммунистик һәм эшчеләр хәрәкәте житәкчелеге, дөньяның барлык прогрессив жәмәгатьчелеге ишеткән кебек тоелды.

Берничә секундка гына югалып калган Беренче үзен кулга алды:

—Тс-с!..

Комбайнчы жегет ана бертуган энесе сыман өзеп, яшьтән дымлы күзләре өздереп карый иде.

Жаксылыков үткер карашы белән тирә-ягын чумырып алды.

Аларга барлык кешеләр аңлаган-белгән һәм мотлак аңларга-белергә тиеш булган рәсми, милләт-ара дәүләт телендә сөйләшергә ярамый иде. Бу телдә аларны мөнбәрләр генә түгел, диварлар да тыңлыйлар иде шул. Аларга шул мизгелдә онытылып барган телләре ярдәмгә килде. Алар, беркем дә аңламасын дигәндәй, татар һәм казакъның уртак гомумтөркиендә икеөч кенә кәлимә сөйләшеп алды:

—Бавырым, ол сезбе?... Ә-ә-бү-га-лис!.. Бункердагы бисек... Кечкентәй бала... Кырык градус кояш ... Ол сезбе?

—Мин, иптәш секретарь!—диде тыны куырылган Сәдит.—Мин булмыйча!.. Кем булсын тагын?!..

—Өзелестә[1] яныма килче! Жду!..

Ялкыннарга чорналган Сәдит гүя үзе артыннан бар дөньяны да яндырып урынына төшеп утырды. Орден таныклыгын эчке күкрәк, аның кызыл катыргы кабын исә аскы кесәсенә салганнан соң, үз горурлыгын башкаларга сиздермичә генә, кулын сул як түшеннән шудырды. Орден урында иде. Металл салкыны аны өшетеп алгандай булды.

Сәдит әле үткән жәйдә генә булган, әмма көтелмәгәндә генә менә бу, ана хәзер бер караганда сөенеч, икенче караганда көенеч булып күренгән, инде теләсәң-теләмәсәң дә тарихка әйләнгән вакыйгалар өермәсенә чумды...

... Алар оештыра башлаган яңа «Мәмләкәт» совхозының жирләре чынлап та иксез-чиксез иде. Татарстанның Сарман якларында туып-үскән Сәдитнең бу кадәр киң һәм иркен яланнарны күргәне юк иде. Мондагы бер совхоз жирләре бөтен Сарман районы жирләренә тора. Әгәр үзеңжитәкчеләрең һәм синең бункердан иген ташучы шоферларың белән килешеп, басуны кишәрлекләп-бүлеп алмасаң, загонның бер башыннан икенче башына бер тәүлек эчендә дә барып житә алмассың кебек. Яратмый Сәдит мондый торгын монсулыкны. Нәкъ әнә шул казакъ акыны Жамбул Жабаев айтыс[2]лары кебек инде. Башы да. Азагы да юк. Нәрсә күренә, шуның хакында жырлыйсың да жырлыйсың. Жырлый-жырлый, барасың да барасың. Әмма да ләкин аның нәселе, канының килгән кешелек табигате, Сарман, Минзәлә тарафларындагыча, борылышларны, манзараларның янарып торуын ярата. Нишләп шулайдыр инде ул тагын?

...Совхозга быел кыш, дөресрәге, ыжгыр февраль суыкларында килеп урнаштылар әле алар. Яшь бала белән. Кеше ышанмаслык нәрсә инде бу. Имеш, язгы чәчү башлануга өлгерәләр. Бераз гына соңласалар да, харап булалар, югыйсә. Аны авыз тутырып «урнашу» дип тә булмый инде югыйсә. Бер сүз белән, Теләнче Тамак комсомолы биргән путевка буенча инде, ташка үлчим инде ул мондый «урнашу» дигән нәрсә. Әй, тора-бара барысы да булыр әле. Түзәргә кирәк. Германиядә танкист булып хезмәт иткән һәм

[1]Өзелес *(казакъ)*—тәнәфес.

[2]Айтыс *(казакъ)*—акыннар ярышы, әйтеш.

шулай итеп, көтмәгәндә, механизатор һөнәренә ия булган егеткә туган Теләнче Тамакларында трактор да, комбайн да бирмәделәр. Бер карасаң, үпкәләргә дә урыны юк инде. Анда инде, ходаем, күптән түгел генә өч авылны берләштереп эреләтелгән колхозда, ике трактор. Бер кәлүсний У—2 һәм НАТИ аламасы тагын. Бер комбайн. «Сталинец—4». Алары да иске, төртсәң, таралырга тора... Әмма шундый сирәк һөнәре булган ир-егетнең төрле эшләрдә, труттинле Нуреттин сыман, кәгазьдәге таяк хакына бушка йөрисе, алданасы килмәде. Җитмәсә, гаиләләре дә ишле. Җитмәсә, өйләнеп тә ташлады. Җитмәсә, балалары да булып куйды бит әле. Беренчеләре. Рәмзияләре. Казакъстан якларында чирәм җирләр турында шау-шу купкач, Сәдит ике дә уйлап тормады—нибары яше тулып маташкан кызы белән хатынын «култыгына кыстырды» да чыкты да тайды менә шушы тарафларга. Хуш, Теләнче Тамак! Син теләнеп яшәсәң дә, без теләнмәбез, Алла боерса!

Бөтен ил шашты бит ул көннәрдә. Урамнардагы барлык радиобаганалар «Чирәм җир! Чирәм җир!» дип бакырды. Һәр яшь йөрәкнең таза тешләренә шул көннәрдә чыккан атаклы җыр эленде. Аңлар-аңламас булса да, Сәдит белән Шәфыйка да җырлады ул җырны:

Едут новоселы
По земле целинной.
Песня молодая
Далеко звучит.
Ой ты, зима морозная,
Ой ты, земля целинная!
Скоро ли я увижу
Свою любимую в степном краю...

Әйе, Аллага шөкер. Җан сөйгәннәрен көтеп ятмады Сәдит далада, урыннарыннан кубарды да, үзе белән бергә өстерәде дә алып килде. Тормыш җинелдән булмаса да, теләнеп яшәмиләр. Килүләренә нибары сигез ай—өс-башларын энәсеннән җебенә кадәр бөтәйттеләр.Үзенә яп-яңа комбайн эләктерде. «Сталинец-6». Монда үз йөрешле комбайннар да күренгәли инде. Әгәр монда ошамый башласа, җитәкчеләр үзләренең «Яшәргә почмак та бирәбез» дигән вәгъдәләрендә тормасалар, ул совхозның бирәр үзйөрешле комбайнын чәлдерәчәк тә, Теләнче Тамакка таячак! Шәфыйкасын, Рәмзиясен, тапкан бар «җиһазын» төиячәк тә качачак! Фью-фью! Ул мондый чакларда сызгырып та җибәрә. Әйе, киләсе сезонда үз йөрешлегә күчәргә хыяллана әле ул. Бар, Теләнче Тамакта күреп кара син мондый яңа техниканы!..

Менә «Бирәсе килгән колына чыгарып куяр юлына» дигәндәй, көтмәгәндә генә бу орден кисәге дә килеп кунды әле аның җылы учына. Орден турында уйлаганда аның күзенә ачы яшь типченә. Шатлык катыш гарьлектән ул, әлбәттә.

Быел, әле оешып кына ятсалар да, «Мәмләкәт»ләрнең, кем әйтмешли, бүресе улады. Чирәм җирләрдән беренче уныш алынды һәм нинди генә уныш әле! Теләнче Тамакта елның елында иң зур уныш гектарына ун центнердан артмагандыр. Ә монда? Монда, егетләр, Җир Ана гүяки миллион еллар буе безне генә көтеп яткан. Әйе, җирдә миллион еллар буе тупланып килгән аш һәм татлы тоз чирәмнең беренче елында ук гектарыннан, ышанасызмы, кырыгар-иллешәр центнер уныш бирде. Күрелгән нәрсәме бу?! Киләсе елларда ничегрәк булыр, анысын Алла бабай гына белә, әмма быел игеннәр ишелепләр, котырыплар үсте. Совет Армиясенең ярты техникасы иген җыйнарга, ярты брезенты урылган игеннәрне явымнардан капларга китте. Куярга урын калмагач, кешеләрнең ишек аллары, ихаталарына, ат һәм сыер абзарларына, мәктәп, клуб иdәннәренә бушаталар иде. Мондый уныш Америкада да булмагандыр. Башак буйга бер карыш, ингә—имән бармак кебек юан, бөртек үзе төш кебек эре, саллы һәм эчтән яктыртылып якты иде. Кайчакта, эштән арып, бераз күзне, билне һәм тез буыннарын язылдырырга дип җиргә төшкән чакларда, Сәдит куанычын

кая куярга белмичә, берничә башакны әөрелтеп, учма итеп өзеп ала һәм кояшка күрсәтә—югарыда вакыты-вакыты белән кырык, ә бәлки вакыты белән илле дәрәҗәгә дә житеп кыздырган кояш нурларында башаклар шәмдәлләр кебек эчтән яктыра. Бер карасаң, алар Мәскәүнең киножурналларда, сурәтләрдә сурәтләнгән Кремль шәмдәлләрен хәтерләтә. Нигә, чынлап та шулай. Әйе, әйе, әгәренки дә шул башаклар булмаса, Ватанның гербы каян килә ди дә, теге Кремль шәмдәлләренең төссез һәм хәлсез пыяла кисәкләре ничек итеп илне эчтән яктырта, ана көч бирә алсын, ди? Икенче карасаң, анда гүяки түбәтәйле аксакал картлар һәм ак яулык бәйләгән мөслимә әбиләр тезләрен чәнчеп, китап укыйлар һәм мөнәжәт әйтәләр. Әйе, чынлап та шулай! Игътибар белән карый гына, аларны күрә генә белергә кирәк. Ул бер тапкыр мондый башакларны штурвалда торучы ярдәмчесенә дә күрсәтеп карады. Ярдәмчесе дигәч тә, әллә кем түгел инде ул. Үзенең хәләл хатыны. Шәфыйкасы, ягъни мәсәлән. Совхозда кеше житмәгәч, ул минем хатыным, әле күкрәктән аерылып та өлгермәгән баламбагалмам бар, фәлән-төгән дип тормады, баласы-ние белән үз экипажына алды да куйды. Штурвалчы булу өчен әллә ни белем кирәкми бит инде. Санга бар—исәпкә юк. Кем әйтмешли, коданың кардәшлеге, кәжәнең маллыгы, штурвалчының һөнәрлеге. Екипажда алар өчәү, мин сезгә әйтим. Сәдит, хатыны Шәфыйка һәм ике яшькә житеп барган кызлары Рәмзия. Өч танкист, ягъни мәсәлән. Ул кайчакта кәефе килеп жырлап та жибәрә: «Тыр-ри танкиста, тыр-ри вес-селых друг-га, ек-кипаж маш-шины бай-йа—вай!» Шулай «экипаж» түгел, армиядә өйрәнгәнчә, «екипаж» ди ул. Юк, күрми хатыны башакларда теге Кремль шәмдәлләрен. Мөслимин бабай белән әбиләрне ул гүпчим дә күрми инде. Вәт, надан!.. «Күр,—мин әйтәм.—Әгәр күрмисең икән, үзеңне салып та очырам, екипаждан да куып чыгарам!» Чак сугышып китмәделәр башактагы яктылыкны күрү мәсьәләсендә. Күрде, ниһаять тегесе. Хатын булгач, күрми кая барсын ул?!

Беренче секретарь Җаксылыков белән танышлыгы да аның нәкъ әнә шул «екипаж» аркасында булды да бит инде.

...Уракка төшүнең беренче көннәре генә иде әле. Мондагы загоннарның озынлыгы берничә чакрымга сузыла икән шул. Күзне талчыктыра, жанны арыта мондый бер төрле манзара. Барасың да барасың. Иге-чиге юк бу баруның. Аннан, эһ итәргә дә өлгермисең—бункер тула. Игенне кая куярга? Ташырга йөк машиналары житешми. Аны бит уч төбенә аударып булмый. Балтасы суга төшкән ир кебек, хет утырып ела. Юк, иң зур иген басулары алтмыш-житмеш гектардан артмаган Теләнче Тамакның егетләре монда, бер басуы гына мең-ун мең гектар мәйдан биләгән совхоз шартларында да утырып елар өчен тумаган. Алар ятып калганчы атып калыр өчен туганнар, мин сезгә әйтим.

Сәдит житәкчеләрдән беркем белән дә киңәшми-нитми торып, теге чакрымнарга сузылган загонны кишәрлеккә бүлеп ура башлады. Чөнки ул аларның моңа барыбер рөхсәт бирмәячәкләрен белә иде.

Ул шушы юл белән совхоз житәкчелегенә иген ташучы машиналарны файдалырак файдалану мөмкинлеген аңлатырга тели иде. Теленә көтмәгәндә «файдалырак файдалану» дигән сүз килгәч, кәефе килеп, елмаеп та куйды ул чакта. Әйе, машиналарны загонның бер башыннан икенче башына ягулык яндырып чаптыру кирәкми. Игенне жиргә бушаткан хәлдә бу аеруча уңайлы. Ә менә меңәрләгән гектарларны вак кишәрлекләргә ничегрәк итеп бүләргә соң? Сәдит кояшның кайнар рәшәсен күз зәңгәре белән үтәли үтеп, тирә-ягына караш ташлады һәм куанычыннан кычкырып жибәргәнен дә сизмәде:

—Яшибез, болай булгач!..

Ул комбайнында чайкала-чайкала үзе килгән юл дала юлы буйлап сузылган телефон баганаларын шәйләп алды. Бәй-бәй, моңа кадәр ул аларны ничек күрмәгән?! Әгәр дә... Әгәр дә аралары якынча йөзәр метрдан торган биш багана арасын бер кишәрлек итеп бүлсән?.. Ул баганаларны янадан күзеннән кичерде. Үз күзләренә үзе үк ышанмыйча, бер юлы ике күзенең дә кабакларын уыштырды: шунысы кызык, һәр багананың очы гүя киртләп

очлаган чук белән чукланган иде. Нәрсә булыр бу?! Казакъ элемтәчеләре һәр бағананы шулай киртләп утырта мәллә югыйсә?! Әгәр шулай икән, Теләнче Тамакка кайткач сөйли торган бер әкәмәт нәмәстәкәй бит бу! Татарстанда да шулайтып киртләсеннәр элемтә баганаларын!

Егет комбайныннан сикереп төшеп, баганаларга таба йөгерде.

Багана башында яшел күзләрен чекрәйтеп дала бөркете утыра иде...

Сәдитнең жаны өшеп, арка үзәге чемердәп куйды.

Куркуы юкка булган икән. Соңыннан бу бөркетләр Сәдитнең иң якын дусларына, җан сакчыларына, көн торышын алдан хәбәр итүче кошларга әйләнделәр.

Ул икенче, аннан өченче, аннан дүртенче баганага чапты. Арыды. Бөркетләрне өркетеп, аларның чынлыгын раслау өчен ул җирдән кечкенә таш кисәге эзләде. Иксез-чиксез далада ташның ишарәте дә юк иде. Ниһаять ул күзенә чалынган туфрак төеремен кулына эләктерде һәм бөркеткә атты.

Бөркет томшыклары белән җинелчә генә ыскылдау авазы чыгарып, багана очтыгында жилпенде һәм һавага күтәрелде.

Сәдит комбайнына таба юнәлде. Бераз баргач, артына борылып карады: бөркет үз баганасына кире кунган иде. Башка бөркетләр исә, берни булмагандай, шундый ук багана башларындагы чук сыман оеп калганнар. Соңыннан белүенчә, аларның чын исемнәре дәшти, ягъни дала бөркетләре икән. Дәшти бөркетләр туган баганаларын ташламыйлар да, бирмиләр дә икән...

Күп күрде Сәдит баганалардагы дәшти бөркетләрне. Ул аларның сыннарын гына түгел, жаннарын да күрде. Бөркетләрнең жанын, ир-ат жаннары кебек үк, карбыздай ярып, тиз генә карап булмый икән. Алар каты биктә икән. Әмма аларның жаннары изге икән. Ул бөркетләрдән ярдәмнән, теләктәшлектән башка бернәрсә дә күрмәде. Кайчакларда аларның Шәфыйкасы белән нәниләрен кишәрлек башында бөркетләр карамагына калдырып китәргә дә туры килгәләде. Комдай кызгылт дала төлкеләре, аксыл сары дала барыслары, чиядәй куе кызыл чиябүреләр—дала шакаллары аның шул ук далада йөзгән иген корабына якынлашкан очракларда дәшти бөркетләр һавалардан төшкән шәүләләре белән хәвефле өркетеп, ыскылдыйлар, хәбәр бирәләр. Кайвакыт томшыкларыннан дала еланнары сәленеп торган бу дәһшәтле кошлар Сәдитнең хәләл җефете һәм кечкентәй генә кызчыгыннан торган гаилә «екипажын» төрле күренгән һәм күренмәгән афәтләрдән саклап калалар иде...

Ул бөркетле биш багана калдырып, загоннан озынлыгы чама белән биш йөз метрдан ким булмаган кишәрлек бүлеп алып, ура башлады.

Озакламый кишәрлек башларында кечкенә ындыр табаклары хасыйл булды. Ниһаять басу тоташ бер ындыр табагына әйләнде. Игенне көн кызуында урып калуны изге бурычы итеп санаган Сәдит үзенең гадел эш итүен белә һәм шуңа күрә дә үзен тыныч һәм ышанычлы тота иде. Нигә, чынлап та шулай түгелмени: комбайнны аның кулына якты көндә иген янында елап утыру өчен түгел, ә ул игенне уру өчен биргәннәр. Йөк машиналарының житмәве өчен ул гаепле түгел бит. Комбайн биргәнсең икән, машинасын да бир. Нәрсә, көзге быжык, кара яңгырларны көтеп утырсынмы ул?! Шуңа күрә бит ул урак өсте «урак конвейеры» дип атала. Бер божрасы булмаса, чылбыр өзек булып чыга түгелме?

Кишәрлек башларында кирегә яңа борылыш ясаганда ул еш кына бөркетле баганаларга карап ала. Бөркетләр гүя урыннарыннан кузгалу, аерылуның нәрсә икәнен дә белмичә шул ук баганаларын саклыйлар. Гүяки алар оеп, баганалары белән бер бөтен сынга әйләнгәннәр. Шулай ук соңыннан аңлашылуынча, дәшти бөркетләр, ябалакларга охшап, көндезгә караганда күз бәйләнгән мизгел, иләс-миләс эңгер, тома караңгыда күбрәк күрәләр икән. Шуңа күрә, алар көндез даими очышта булырга бик яратмыйлар, күк тирәнлекләренә сирәк, ихтыяж булган очракларда гына күтәреләләр. Аларның күз бәллүрләрендә төнлә күрә торган нурлар бар, димәк? Бу фикер Сәдитне әллә нинди истәлекләргә алып кереп китте. Моннан өч ел элек танкистларның Магдебург полиго-нында аларга, яшь танкистларга, бер яшерен жайланма—яңа танкларга куелырга тиешле булган төнлә күрү приборларын күрсәткәннәр

иде. Т-54 дип аталачак бу танкларны алар төнлә йөртеп тә карады: тышта күзгә төртсән күренмәс карангы, ә тримплексларда исә бераз яшькелт нурга чумган яп-якты жир өсте, мин сезгә әйтим...

Дәшти бөркетләрдәге Туган Ил тойгысы анын жылыйсыларын китерде. Яшь тулган күз чокырларын ул челт-челт ачып-йомгалап алды.

Сагынган, бик сагынган иде үзенен Теләнче Тамагын яшь чирәмче.

Сәдитнен урактагы мондый башбаштаклыгын белеп алган житәкчелек тәмам котырды. Эссесе белән якты көнне бер юлы ак һәм кара мунчага әйләндергән кояш бер яклап кыздырса, урындагы түрәләр Сәдитне икенче яклап кыздырды. Башта анын янына директор урынбасары Чабатенко килеп, төрмә белән янап китте. Аннан директор Алмаченко үзе килде һәм урылган игеннен хакын түләтү белән куркытты.

—Ти у мене на карачках ползать будеш!—диде ул ана, күзләрен алартып. Аннан кояш ялкынында табак битеннән эреп аккан маен тастымал кадәр кулъяулыгы белән сыпырып алып, козгын сыман талый башлады.—Запамятуй, татарове, ти у мене кажну ридну пшиницю языком лызать будеш!.. Я тоби сказав, кажиця, татарове...

Рәнжетте, бик тә рәнжетте Сәдитне Алмаченконын бу сүзләре.

Күп тә үтми анын урып барган комбайнын куып житеп, каршысына ук бер төркем жинел автомобильләр килеп туктады. Кызган рәшә ялкыны аша кулын болгап, Алмаченко ана туктарга һәм моторны сүндерергә дигән ишарә ясады. Сәдит агрегатны шып туктатып сүндергәнче һәм жиргә сикереп төшкәнче анын комбайны тирәсен ул белмәгән һәм күрмәгән житәкчеләр сырып алды.

Араларыннан берсе—озын буйлы, алсу шома йөзле, бүгенгедәй кырык градуслы эсседә дә өстенә карасу зәнгәр төстәге, түшендә орденнар шакмагы ялтырап торган китель, галифе кигән, милләте белән казакъ икәнлеге чакрымнар аша кычкырып торган кеше ана кулын сузды:

—Исәнмесез. Өлкә комитеты секретаре Жаксылыков булам.

Сәдит үзенен исем-фамилиясен әйтте.

—Эшләр барамы сон?

—Ничек дим икән инде. Бара шунда. Дөрес оештырган хәлдә ун мәртәбә яхшырак бара алган булыр иде...

Беренче Алмаченкога карап алды.

—Дөрес оештыру дигәндә сез нәрсәне күздә тотасыз?

Сәдит барысын да үз каланчасыннан торып анлатып бирергә тырышты.

—Бу егет ничегрәк эшли сон?—дип сорау бирде Алмаченкога секретарь.—Яхшы эшлиме, әллә...

—Болай алганда, начар түгел. Тырыш. Әмма бик тә үз сүзле, кирегә беткән кеше...

—Ничек... кирегә беткән?

Алмаченко үз роленә кереп Сәдитне сүгәргә тотынды. Имеш, ул иген конвейеры закончалыклар бозып, барлык басуны тәртипсез ындыр табагына әйләндерде. Нәтижәдә, имеш, совхоз күрелмәгән зур югалтуларга юл куярга мәжбүр булачак...Тагын да шунысы...Бытыр-бытыр... Тагын да шунысы...—директор Беренченен колак төбендә бытырдавын дәвам итте.—Әйткәнне тынламый.—Тагын да бытыр-бытыр... Жаксылыковнын ирен читләре тартыша башлады. Ул Алмаченконы шып туктатты:

—Евгений Христофор малае, тукта. Әтеү әрләшеп китәрбез. Шунысын гына әйтәм: егетләрен районда искиткеч зур уныш үстергән. Урыны-урыны белән алтмыш центнерга житкән бүлекчәләр бар. Нәрсә, алар синен егетләрен түгел мени? Алар хәзер шул унышны тизрәк жыеп алу өчен көрәшмиме? Без аларга барлык шартларны тудырырга тиеш түгелбез мени? Әгәр син кеше кулына комбайн штурвалы тапшыргансын икән, анын игенне ташу өчен синен машинан булуы-булмавында ни эше бар? Нигә сез Өлкә Комитеты резервыннан өстәмә транспорт сорамыйсыз?—Ул Алмаченконын күзләренә текәлде.—Сезнен иген ташырга автомобильләр житми икән ләса! Ә минем бу хакта ишеткәнем дә юк. Ә сез, оят булса да әйтим... Ул жинелчә генә сүгенеп куйды.—Безгә әллә кайлардан килеп,

иген үстерергә өйрәткән бу уңган егеткә яла ягасыз! Әйтегез әле,совхозга бүгеннән ничә йөк машинасы кирәк?

—Йөз,—диде баягы өшкерүдән әле айнып та житмәгән Алмаченко, аны-моны уйлап тормыйча.

—Бәлки ике җүздер тагын? Какой умница нашелся. Бәлки урынбасарыгыз беләдер?

Жаксылыков тирәсендә кара шәүлә сыман кемсә пәйда булды. Аның фото кәгазе кебек соры чырае ничектер истә калырлык түгел иде.

Йөзе саргаеп каткан Алмаченко нәрсәдер мыгырданып маташты.

—Сезнең агрегатка шәхсән ничә автомобиль кирәк булыр иде?—дип сорады Сәдиттән Беренче.

Егетнең башына шаукым бәрде, шатлыгыннан кан басымы күтәрелде.

—Алты,—диде ул, комбайн белән ындыр табагы арасының шактый ерак булын исәпкә алып. Әлегә мине нибары ике ЗИЛ хезмәтләндерә. Аның да берсенең брезент япмасы юк. Игеннәре юлга коелып бара... Миңа алты ЗИЛ булса яхшы булган булыр иде..

—Җитешәчәксезме?

—Нигә житешмәскә?—Егет үзе дә сизмәстән шаркылдап көлеп җибәрде.—И-и-и, житешми диме, бирсеннәр генә!—Аннан ул Алмаченко ягына утлы караш ыргытты.—Без, татарлар, яуда да, хезмәттә дә беренчелекне бирмибез. Не чабата же я какуй, чтобы я и мой хатун у кава-ты как чабата на хбасту мотатсы...

Сәдитнең соңгы сүзләренә игътибар итүче дә, аңлаучы да булмады кебек. Аларны бары тик совхоз директоры—бирегә Брежневның шәхси чакыруы буенча Днепропетровскидан килгән Алмаченко гына бар кинаясе белән аңлый иде. Әйтелгән сүзләрне бары тик үзенең тупас алабарманлыгы аркасында гына илтифатсыз калдырган кебек тоелса да, ул аларны игътибарсыз калдырмаячак һәм бер килеп үчен алачак иде бу фиргавен токымы.

Нишләптер гел бәйләнеп кенә торды шул Сәдиткә бу Алмаченко дигән җитәкчеләре. Башта ул аның исемен ошатмады—Сәдитне Александрга әйләндереп маташты. Аннан фамилиясен, аннан әтисенең исемен кабул итмәде. «Без, татарлар, исемне әҗәткә алмыйбыз, үзебез аны башкаларга бүләк итәбез,—дип әйтергә мәҗбүр булды аңа бер тапкыр йодрыкларын төйнәгән Сәдит.—Менә сезгә дә фамилияне без бирдек. Сезнең Алмаченкогыз ул безнең «Алмачы әнкәй» дигән сүзебездән алынган, аңладыңмы? Урысча, яблучная мать, ызначит. Чабатенкогыз—чабатадан пүнәл, лапти, ызначит. Кахулчасын үзең беләсендер...—Аннан күзләрен кысты да, армиядә ишеткән бер мәзәгендәге татарның урыска әйткән сүзләре белән җөпләп куйды.—Не забудь, тбой тринадцатый прапрадед мене прикурить дулжын...

—Жазып куй һәм контрольгә ал,—диде янындагы Шәүләгә Жаксылыков.—Совхозга резервтан өстәмә егерме биш ЗИЛ кайтартырга, шуларның алтысын урып-җыю тәмамланганчы Гафиятуллин агрегатына беркетергә. Сынап карыйк, өлгәшер микән?—Беренче Сәдиткә таба борылды.—Туктагыз әле, миңа сезнең фамилиягез бик тә таныш күренә.—Гүя ул «таныш фамилияне» телендә тәмәйтеп карый иде.—Гафиятуллин... Гафиятуллин бит, шулай бит, Гафиятуллин? Сез Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллинның туганы, йә булмаса алыстан туесканы...э-э... берәр чыбык очы түгелме?

—Юк, без Гатиятуллиннардан булабыз,—дип төзәтте комбайнчы. Безнең аерма...—Ул берни булмагандай эчкерсезлек белән тагын да шаркылдап көлеп җибәрде.—Бер хәрефтә генә... Гафиятуллин—Гатиятуллин. Газинур абзый Гафиятуллин исә минем бик якын якташым була, мәрхүмкәй... Ул—Сугышлыдан, ә мин...

—Ә-ә-ә, менә эш нәрсәдә!—дип кычкырып җибәрде Жаксылыков.—Менә шул син әйткән бер хәреф бутаган да инде мине!..—Ул кулын Сәдитнен иңенә салды.Йөзенә бер мизгелгә уйчан шәүлә яткан секретарь күзен бер ноктадан күтәрмичә сүзен дәвам итте.—Без аның белән бер армиядә хезмәт иттек... 22-нче армия, Икенче Балтыйк буе фронты... Әмма таныш түгел идек. Кая ди анда? Армия кадәр армия бит ул!..—Ул авыз чите белән

көлемсерәп куйды.—Әйтергә генә жинел.йөз мен солдат.. Ә ул безнең армиянең беренче шундый бөек герое...—Жаксылыков соңгы сүзләрен үз тирәсендә басып торучылар өчен өстәп куйды шикелле.—Беләсездер инде, Газинур Гафиятуллин—дошман амбразурасын күкрәге белән каплаган татар каһарманы... Псков өлкәсенең Овсище авылын алганда... Озакламый бәлки безнең казакъ даласында якын карындашымыз Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин исемендәге совхоз да күтәрелер әле, шулай бит, туганнар?

Бу сүзләрдән соң Сәдитнең жаны күккә ашты. Әмма шундук жиргә төште—жирдә башаклардан иген, алтынланып өлгергән иген коела иде!..

Баш өстенә менеп кунаклаган дала кояшы чеметеп алып, өздереп кыздыра, жир йөзендәге аз гына симез нәрсәне дә аяусыз рәвештә өтә, эретә һәм юк итә. Аның гаебе белән шулай тукталып, вакытны—кадерле минутларны заяга очырганы өчен оялып, Сәдит урынында таптанды, аннан, башка кайберәүләр кебек, мондый чакларда хәйләләгән булып, кунакларга аерылышырга, эшкә башларга вакыт икәнлеген төшендерү өчен кат-кат сәгатенә караган булды. Тик аның кул беләзегендә әлегә сәгате юк иде. «Алла бирсә, баесам-нитсәм, камалы тун тектерәм»,—дигән кырыктартмачы үсмер кебек, ул сәгатьне, чынлап та баеган хәлендә, сатып алырга гына жыена иде. Кыскасы, вакыты кыскан Сәдитнең вакытны белү өчен үз вакыты юк иде...

Якында гына чыелдап йомран сызгырып жибәрде.

Сәдитнең йөрәге ярылгандай итте.

Ул күк гөмбәзендә, нәкъ үзенең баш түбәсеннән шәм сыман эреп аккан кояшка карый алмаган карашын жиргә төшерде.

Ләкин мондагылар ашыкмады, чөнки Беренчеләре бу юлы ни сәбәпледер ашыкмады. Сәдит ашыккан саен ашыкмады мәллә ул? Юк, армия дәрәжәсендәге политработник булып авыр сугышларны үткән казакъ Жаксылыков ашыкмавының сәбәбен башкаларга караганда яхшырак белә иде: яу алдыннан һәм яу барышында адәм баласына булган игътибар аны күккә күтәрә, дәрәжәләрне тормыш офыклары белән тигезли һәм адәм баласы биеклеккә эленгән байрак, күкрәгенә кунган шөһрәт, кочагына тулган мал-мөлкәт белән жиргә төшә. Дан мондый адәм баласына! Ул галифе кесәсеннән эре зәңгәр шакмаклы кульяулыгын чыгарып, инде ничәнче кат битендәге тирләрен сөртте.

—Бая сине бүлдердем бугай. Ә син өзенде кайсы авылдан айткан идең әле? Теге... Сугыслыдан алысмы ул?

—Теләнче Тамактан мин. Сарман ягыннан. Сугышлыга булса шул житмеш-сиксән чакрым булыр..

—Тукта, тукта... Сарман... Сарман...—Секретарь кояшның бу кайнар мичендә нишләргә белмәгән жолдасларының һушын алып, жырлап жибәрде:

Сарман буйларыннан үткән чакта
Тыңларсыңбы жырулар жырласам?
Күзләреңде тултырып карарсыңбы,
Зәңгәр таудан жаулык болгасам?..

Сәдит куанычыннан үкси иде. Ул үзенең мондый жебегәнлеген башкалар күрми микән дип оялгандай итте һәм керфек очларындагы яшь тамчыларын үтеп барышлый гына жиң очы белән жилпеде.

Алмаченко моны шәйләде. Ул үзе дә сизмәстән кулындагы чыбыгы белән хром итеген чәбәкләп алды.

Жаксылыков боларның икесен дә күрмәмешкә салышты. Болар аның жиңүе иде.

—Безнең 37-нче укчылар дивизиясенең яртысы татарлардан торды.—дип сөйләп китте ул.—Хәер, Россия армиясе гомер-гомергә яртысы белән татар армиясе бит инде ул... «Сарман» исә безне иң хәтәр хәлләрдән коткара торган авральный жыр... юк, тантаналы марш иде! Һич тә арттырмыйм, яудашларымның күп чакларда һөҗүмгә шушы жыру белән күтәрелгәнен хәтерлим...—Секретарь истәлекләреннән арынып, янадан Сәдиткә таба борылды.—Теләнче Тамак дисең. Ул урысчага ничек кайтарыла?

Сәдит анламый торды.

—Переводится?

Сәдит монысын да аңламады.

—Теләнсе Тамак. Орысча кандай?

—Не знай.—Сәдитнең бу хакта беркайчан да уйланганы юк иде. Урысчасы да чамалы булгач, ул беразга югалып калды.—Них-харуший сүз инде ул, егетләр.—Теләнче... Теләнче.. Ул нишший була микән инде? Нишший,—диде ул аннан ике дә уйламыйча.

—Немае, ни нищий,—дип тезеп китте Алмаченко.—Һолодный, буде!.. Липрошайка! Батрачни!

—Таптым! Таптым!—Сәдит, алтын күргәндәй сөенеп, урынында таптанды.—Ачлык! Гулыт, ызначит! Гулытный! «Тамак» дигәне... «Тамагы» инде аның «гурлы» була шикелле...

—Ни. Ни һорло,—ди малороссларга хас булганча, «г»ны «һ» белән каплап.—«Рит» я вам кажу!

—«Теләнче Тамак» ызначит Гулытный гурлы,—дип раслады Сәдит.

—«Һолодный рит»,—дип раслады Алмаченко.

—Хохол белән татар бәхәсе—басмадагы ике кире тәкә бәхәсе инде ул,—диде кемдер.

«Моңа биллаһи дә акыл кермәгән икән,—дип уйлап алды Сәдит.—Тагын акыл утыртырга туры килер, ахрысы.»

—Икесе дә дөрес,—дип төзәткән булды Җаксылыков.—Авылыгызда, нәселегездә кемнәр бар?

—Авылда сугыш янбалиты әтием, әнием, өч ир, ике кыз туганым бар. Тирә-якка атаклы балта осталары, бетончылар нәселеннән без. Галимҗан абзыкаебыз Березникида атаклы бетончы, Сәлимҗан абзыкаебыз Магниткада атаклы балта остасы...

—Акча белән ярдәм иткәлиләрме соң?

—Кая ди инде ул. Кайвакыт елына бер тапкыр посылка салгалыйлар. Анысына рәхмәт.

—Татарстанда тормыш авырмы?

—Күтәреп карасаң, авырдыр инде ул. Әлегә кайда җинел соң? Җинел булса, мин яшь ярымлык баламны, хатынымны ияртеп, шушы күз күрмәгән якларга чыгып олагыр идемме? Дөрес, халык ызан башында ачка үлеп ятмый ятуын, тырышкан була, түзә... Безнең авылның вербавай кызлары-егетләре бер пар эрзинкә, бер күлмәклек хакына Сахалиннан Мәскәүгә кадәр урман кисә һәм туриф чыгара. Һәм, мин сезгә әйтим, бик һәйбәт чыгаралар...—Сәдит тешләрен ыржайтып һәм шаркылдап көлә башлады.—Хәер, безнең халык Явыз Иван заманнарыннан алып лашманчы инде... Ха-ха-ха-ха-ха!..

—Ә син нигә...көләсең жылаудың орынында?

—Көләм, бәй. Көлеп кенә исән калам бит мин. Ә бу хакта көлмичә сөйләп буламы соң?

Нәкъ шул чакта каяндыр яшь бала елаган тавыш ишетелде.

Бу тавыш якында, бик якында, гүяки кемнеңдер кесәсеннән чыга иде.

Адәмнәр барысы да тирә-якка караштылар. Анда чиксез казакъ даласыннан, күктә эреп аккан кояштан башка бернәрсә дә юк иде.

Елаган тавыш кабатланды. Адәмнәр бер-берсенә караштылар. Беренче янындагы шәүлә карашы белән һәркемне тентеп чыкты. Араларында беркем дә еламый иде.

Кинәт Сәдитнең комбайны артыннан өстенә зәңгәрсу комбинезон, башына чөерелтеп шундый ук яулык бәйләгән хатынкай йөгереп килеп чыкты һәм ут капкандай ашыгып бункерга күтәрелә башлады.

—Кем бу?—дип сорады Беренче Сәдиттән.

—Хатыным.

—Тукалың?! Ул биредә нистәп йөр?

—Эшли. Минем белән.

—Кем болыптыр?

—Кем булсын,—диде Сәдит аптырап.—Пешекче түгел инде. Штурвалчы. Монда бүтән эш юк.

—Штурвалчы? Хатын-кыз. Штурвалчы?!

—Әйе. Һаман кушканча, мин аннан ир—ат ясыйм.—Ул көлемсерәде.—Үземнән хатын-кыз ясыйм, бала карыйм... Җаксылыков бу кинаяне төшенеп җитмәде.

—Болай ер тетрәтеп әле нистәп йөр?

—Нишләсен, баласы янына күтәрелә.

—Бала?! Кечкәнтәй? Кайда ол?

—Бункерда.

—Нистәп ол анда?

—Нишләсен, йоклый, бәй. Аның бишеге шунда.

—Бисек?!

Беренченен күзләре маңгайга сикерде. Аның кулыннан папкасы төшеп китте. Янында басып торган адәмнәрнен дә күзләре ике булган иде. Әмма алар барысы, күрәсен, үзләренен күзләре турында оныткан иде, алар шапылдап төшкән папканы камылдан күтәреп хуҗасына тапшыру өчен ташландылар.

Ул арада бала бар тавышына елый башлады. Далага ниндидер ямь, көрлек һәм дәрт өстәлде. Кояш эссесе сүрелгәндәй, җил искәндәй итте. Ана бункер өстенә иелде. Инде баланын анда, бары тик анда икәнлеге беркем өчен дә сер түгел иде. Беренченен терсәге белән Шәүләсенә төртүе булды, Шәүлә шундук акбарс тизлеге белән бункерга ыргылды. Шәүләнен бункерга күтәрелүе булды, нәкъ шул мизгелдә ана сабыенын елавын тагын да көчәйтә биреп, тагын да елата биреп, алтынсу рәшә уйнаган бункердан алтын бодай көлтәсен суыргандай суырып чыгарды, аннан бу кадерле көлтәсен күкрәгенә кысып, аңа нидер сөйләп маташты, аннан мотор ягына китеп чүгәләде һәм баласына имчәген каптырды.

Сабый тынып калды. Далада монсу булып китте. Гүя анда баланын ычмык-ычмык килеп имгән авазлары гына саркыла иде.

—Здесь—махонький!.. Монда бишек ба-а-ар!—Бункернын эчен караган Шәүлә бугазыннан җиз торба тавышлары чыгарып кычкырды.—Бишек ба-а-ар!..

—Төш аннан, баланы куркытырсын тагын!—дип җавап бирде ана Җаксылыков.—Тавышын кеше тавышы кебек булса тагын ...

Әмма бу хәбәр инде беркемне дә кызыксындырмый иде.

—Бисек...—Ни әйтергә дә белмәгән Беренче башта Сәдиткә карады.—Бисек элеп, батырлык эшләдем дисен инде... Лихо, ничего не скажешь.—Аннан ул Алмаченкога иелде һәм анын колак куышын кайнар тыны белән өттереп алды.—Сез мондый бардак өчен бюрода җавап бирәчәксез. Нәрсә, комбайнга бишек асып, уракка чыгарга Суматра джунглиләре түгелдер бит монда?! Советлар Союзыдыр, шәт?! Әгәр идеологик дошманнар комбайн бункерындагы бишекне фотога төшереп, берәр «Нью-Йорк таймс» та бер егерме миллион данәдә бастырып чыгарсалар?! Советлар чирәм унышын балаларнын саулыгы, күз яше белән яулыйлар дип бераз күпертеп тә җибәрсәләр, ә ?!

Җаксылыков комбайнга таба юнәлде. Йөзендәге аклы-күкле төсләрне сары камылга коеп, анын артыннан Алмаченко һәм башкалар да иярделәр.

Сәдит каккан казык сыман урынында калды.

Секретарь комбайнга күтәрелде һәм күләгәле булсын өчен өсте ясалма брезент белән капланган бункер өстенә иелде. Һәм елмаймыйча түзә алмады: эре, якты, чүпсез, кара солысыз, кем әйтмешли, чеп-чиста бодай белән тулып килгән бункернын эченә беркетелгән аркылы агачта, кырык дәрәҗәдәге кояш астындагы күләгәдә, карлыгач оясы кебек биектә һәм җил җиләсендә тияккә тоенләнеп, чиста, ак җаймәләр белән тулган бишек тирбәлә иде...

Бункер мәйданчыгынын аргы очында бераз чүгәли биреп бала имезгән тукалга караш ташларга да кыенсынып, ул җиргә сикереп төште. Беренче артыннан ашаган ат сыман гөп-гөп килеп башкалар да сикерделәр.

Беренченен күнеле тулган иде. Бугазына торган төенне тизрәк йотарга, дулкынлануын сиздермичә генә басарга теләп, ул бер сәбәпсез комбайнны әйләнеп чыкты. Анын артыннан кайсы хром итек, кайсы җиз калаклы

штиблетлары белән эре сабаклы, сөян төсенә кереп саргайган камылда чаштыртап, башкалар да комбайнны урап әйләнде.

Ул әле һаман казалган казык сыман урында басып торган Сәдит янына килде. Аңа ияреп, башкалар да килделәр.

—Ай-бай, бавырым, үзең дә булдырасың икән... Әбугалис син, мин сиңа әйтим! Әбугалисина! А-ви-цен-на!

—Кем була ул?—Сәдит күзләрен тожырайтып Беренчегә карады.

—Шуны да белмисеңме?—«Шуны да» дигән каһәр суккан сүзбәйләнешен ничек ычкындырганын сизми дә калган һәм мондый гакылсызлыгы өчен кешене рәнҗетә күрмим дип уйлап өлгергән Беренче авызын каплап куйды һәм мизгелне йомшарту өчен ашыгып-ашыгып сөйли, шомарта башлады.—Моннан мең ел элек яшәгән бөек табиб, тылсымчы гыйлем иясе... Безнең бөек төрки бабабыз Әбугалисина!.. Тутырып ук әйткән хәлдә, Габдел Гали Хәсәен ибне Габдуллаһ ибне Гали ибне Хәсән диләр аны. Күрәм, син дә аның кавеменнән икәнсең бит!.. Кана, бавырым, син бу бисегең белән безнең барымызды да савыктырдың бит әле...—Жаксылыков ләззәт белән көлде, инде яшереп тә тормыйча күзендәге яшен сыпырып алды. Аның артыннан башкалар да көлде.—Ә синең белемең нинди?

—Безнең якта әйтүләренчә, коридорлары белән дүрт класс...

—Һәйбәт бу. Бик һәйбәт. Чынбарлык шуны раслый, Рәсәйнең дүрт сыйныф белеме әлегә Казакъстанның урта белеменә тиң. Димәк, синең, бавырым, бездә урта белемле адәм булып исәпләнергә хокукың бар... Төпләнеп, тамырланып китсәгез, Күкчәтау авыл хужалыгы институтына керерсез. Үзем тәкъдим итәрмен. Инженер-механик булырсыз. Армия һөнәрегез нинди?

—Танкист.

—Шулай булгач...—Секретарь бер мизгелгә уйга калды.—Шулай да, әйт әле, Гатиятуллин, ничек итеп... Ничек мөмкин бу? Комбайндагы шнек шавы астында ничек итеп кечкәнтәйне йоклатырга мөмкин?... Куптәнме?

—Күптән түгел әле. Булса, бер атна чамасы булыр. Башта без кызыбыз белән яшел печәнгә дип кукруз чаптык. Кукруз чапкан чакта, беләсез, бункерга берни дә акмый, шау-гөр юк. Бодай урагына төшәр алдыннан сиртмәле бишеккә чүп-чар кермәсен өчен чыбылдык юнәттем дә, бәбине бишеккә салып, сынау үткәрдем. Ничауа, йоклый!.. Гөрелтегә игътибар итмәскә ул кукруз урагында өйрәнеп калды, ахрысы.—Сәдит майлы кул сырты белән танау астын себерде.—Аннан, иптәш секретарь, артык борчыла башласа, әнисенә дә ял кирәксә—әнә, минем куыш!—Сәдит камыл уртасында торып калган салам куышка күрсәтте. Анда мендәр-юрган, башка кирәк-ярак та бар... Икесен дә күтәрәм дә, илтәм дә салам!..

—Кечкәнтәй канча жаста?

—Ничә яшьтә дип... Бер яшь тә сигез ай.

—Һы. Үзегез дә тәвәккәл, үзегезгә охшап, сабыегыз да тәвәккәл икән.

—Йоклыймы?—диде Секретарь әле һаман ышанмыйча.—Ыжламыйдамы?

Сәдит багана башларындагы бөркетләргә карап алды. Алар урынында иде.

—Йоклый. Ыжламый да. Ярдәм дә итәләр.

—Кемнәр тагын? Моны бездән көлеп әйтәсезме?

—Бөркетләр,—диде Сәдит баганаларга таба ымлап.—Дала бөркетләре.

—Ә-ә-ә. Танышып өлгердегез мени инде? Бездә аларны дәшти бөркетләр дә диләр. Бик хуп, бик хуп. Димәк, сабый дала бөркетләре яслесендә тәрбияләнә... Тәвәккәл! Тәвәккәл!—диде кәефе килгән Беренче һәм аннан нәрсәнедер исенә төшеп, сорап куйды.—Ә сез нигә... исеме ничек әле... Рәмзияне яслегә бирмисез?

—Биргән идек тә, кире алдык та, бирегә алып килдек. Монда, басуда, бет тә, микроб та юк.

—Ни сәбәптән кире алдыгыз?

—Бетләде, бәй. Өченче көнендә үк. Андагы зимләнкедә бала түгел,

ат та бетләр. Монда бет чүпләп утырырга килмәдек бит без...

—Ишетәсезме, Алмаченко, яслегездәге бетләр унышын комбайн белән уралар.

—Тикшерербез, Жалкын Сарбаевич.

—Тикшерергә кирәк имәс. Бетләрне үлтерергә кирәк.

—Әйткәннәрегез үтәлер, Жалкын Сарбаевич.

—Бөҗәкләргә каршы тиешле санитария чаралары үткәргәннән соң, Гафиятуллинның кечкәнтәен яслегә урнаштырыгыз. Кирәк булса, тәүлек әйләнәсенә. Кирәк булса, атналыкка. Карагыз аны...

—Карарбыз, Жалкын Сарбаевич.

Бөҗәкләр турында барган мондый унайсыз сүздән соң авыр тынлык урнашты. Сәдит бу кунаклардан шактый туйган иде. Әшкә башларга теләген белдергәндәй итеп, ул комбайнына карап, урынында таптанып куйды.

Моны Секретарь дә тойды шикелле. Сүзне югары каефтә тәмамлау ниятендә ул, тәҗрибәле «партия мулласы», мондый чакта, «тырыш хезмәт хакына утка керергә әзер булган совет кешеләре даирәсендә» бирә торган сораунын иң үтемлесен бирергә уйлады:

—Ә син бит инде...—Жаксылыков Сәдиткә туган-тумачаларча күз кысты.

—Яратасың бит инде, әйеме? Ул да сине ярата, әйеме?

—Сез... нәрсә турында?—Аптыраган Сәдит сорауга сорау белән җавап бирде.—Әшнеме? Комбайнныммы?

—Юк... Кхе-кхе...—Секретарь бункерга иелеп баланы бишеккә салып маташкан Шәфыйкага ымлады.—Киленне әйтәм...

—Яратмый нишләсен, монысы булгач,—диде Сәдит үз кочагында бала тирбәткәндәй итеп.—Аннан, яратмаса, аптыраган юк, Жалкын Сарбаевич. Икенчесе бар...

—Ничек... икенчесе бар?—Жаксылыков дөрес ишеттемме, дигәндәй, колакларын уды.—Ничек... икенчесе бар?

—Мине хатын-кыз бик тә ярата,—дип сөйләп китте Сәдит берни булмагандай. Әллә ул дөресен сөйли, әллә бераз гына кыйлана—моны аеруы читен иде хәзер.—Мине эзләп авылдан икенчесе, Сәвиясе дә килеп житкән әле, мин сезгә әйтим... Әле совхозда, ындыр табагында эшли...

Беренче Секретарь, бу сүзләргә ышаныргамы-юкмы дигәндәй, бераз урынында чайкалып торды да кеткелдәп кенә көлеп куйды:

—Ну, кызык адәм дә сез!..

Ана кушылып Сәдит тә, башкалар да көлә башлады.

—Теләнче Тамактан ук килгәнме ул?

—Әйе. Теләнчедән үк. Яраткач, нишләсен? Алар икесе дә мине.. теге... үлеп яраттылар шул. Әмма мин Шәфыйкага насыйп булып куйганмын...—Ул тагын да кочагында бала тирбәткәндәй итте.—Ә минә Сәвия бәгырькәем... Алма гөлем...—Сәдитнең йөзе борчулы төс алып томанланды.—Безнең авылдан юл ике тарафка гына чыга шул—йә Уралга торф чыгарырга, урман кисәргә, йә—казакъ далаларына чирәм жирләр күтәрергә. Сәвия минә чирәм жирләрне сайлаган...

—Әфарин!—дип кычкырып жибәрде Жаксылыков.—Сезнең өчен килгән бит ул!.. Минә саф мәхәббәт нишләтә!.. Без ул Сәвия карын-дасымызга чирәм жирләрдә минә дигән кияү табармыз әле!—Аннан шапыл-датып Сәдитнең кулбашына сугып куйды.—Шулай бит, ә, Гатиятуллин?

—Шулаен шулай ла ул,—диде ни әйтергә белмәгән Сәдит урынында таптанып.—Шулай булырга тиеш лә ул...

...Сәдит белән Жаксылыковның минә шуннан соң очрашканнары юк иде.

Яхшы эшләде Сәдитләр. Жаксылыков бүлеп биргән ЗИЛ-лар килеп житүгә алар башта совхоз, аннан район буенча беренче урынга чыктылар. Кечкенә Рәмзияләрен атналыкка дип теге «жанвар»лардан тулаем арынды-рылган яслегә дә урнаштырып алгач, Сәдит белән Шәфыйканың гаилә «екипажы» инде бөтен өлкә буенча беренчелеккә күтәрелде. Алар турында язмаган гәзит, сөйләмәгән радиобагана, аларны сурәткә төшермәгән фоторепортер калмады.

«Урак өсте елга бер килә торган бөек мәшәкать, аны сызланмыйча үткәреп жибәрергә кирәк»,—дип исәпләгән Сәдит, кем әйтмешли, алны да, ялны да белми эшләде. Таңнардан таңнарга кадәр, күзләре кызарганчы урды ул беренче чирәм унышын. Таң йокысы тенкәләргә тиеп күзләрне буа башлаганда гына тәртеп ала иде ул башын жылы, сөт исләре килеп торган салам күбәсенә. Мондый чакларда багана башындагы дәшти бөркетләрнең томшыкларын кайрап ыскылдауларыннан уяныл китә иде ул. Әйе, бу бөркетләр каркылдамый да, гөрелдәми дә, бары тик даланы иркә генә сискәндереп, уятырга чамалап ыскылдыйлар. Мондый сәер һәм жанга газиз аһәңнәрне Сәдитнең беркайда да ишеткәне юк иде. Аның һәм аның кечкенә гаиләсенең тән сакчыларына әверелде бит бу дәшти бөркетләр. Рәмзия киң басуны яслегә алыштыргач һәм бу тарафларда күренмәс булгач, бөркетләр алмашлап комбайн өстендә әйләнә-тулгана башлады. Гүя дәшти бөркет халкы үз тавышы белән «Әннә, әттә!» дип даланы яңгыраткан татар кызчыгын юксынып, күк гөмбәзендә бөтереләә, аны эзли һәм яңадан баганалары башына барып кунаклый иде...

Кишәрлек башында зәңгәр сүстән ишелгән аркан булып төтен күтәрелә. Бу—Шәфыйка яккан учак. Учакта чәй һәм итле аш пешә. Озак та үтми, артларыннан даланың соргылт жиләне өстендә шундый ук сыек зәңгәр төтен киндерәләре калдырып, ашлык ташучы машиналар да килеп житә. Аларның әржәләренә ун бункерны бушатуга аш та өлгерә. Яшерми Сәдит, кәефен күтәрү, беләкләргә көч һәм дәрт өстәү ниятендә ул бер йөз грамм чамасы теге нәмәстәкәйне дә жибәреп ала. Шәфыйкасы йөзен чыта, Шәфыйканың йөзе сытылуы Сәдит өчен теге, нәстә диләр әле, закуска гына инде ул. Ул кәгеп кенә куя. Мондый авыр эштә ансыз була диме? Ансыз дөнья сансыз! Әлбәттә, ул моны беркайчан да башкаларга күрсәтеп эшләми, гәрчә кайчандыр фронтта, хәлиткеч һөжүм алдыннан, солдатикларга геройлык өстәп, йөзәр грамм «наркомовский»ларның махсус бирелгән булуын белсә дә. Үзләре «һорилка»дан чучка кебек күбенеп йөргән Алмаченко, Чабатенколар бу эшеңне сизеп алсамы? Аларның үзләренә ярый ул яравын, ә менә башкаларга, башка ирекле гыражданнарга... Ул чакта сәтсиәлистик ярыш тактасыннан очып төшкәнеңне көт тә тор, менә шул.

Аннан, аракы, тәмәке дигәнең табуы да жинел түгел әле монда. Бер карасаң, әллә нинди сирәк әйберләр дә булмаска тиешләр дә бит инде алар. Нишлисең, башта нәкъ әнә шул «юклык»ны тудыру, анан бу «юк»ларны «яшрен» юллардан табу белән бара бит инде безнең тормыш. Бер өйрәнгәч, шул «юк»лардан башка яшәүнең кызыгы да юк кебек. Бу "юк"лар торабара алдавыч льготаларга әйләнеп, адәм баласын капкынга каптыра. Мәскәүнең нинидидер Мытищи дигән жиреннән ашлык ташырга килеп чыккан шофер егет Володя гына ярдәм итте аңа хәмер мәсьәләсендә. Моннан бер илле чакрымда яткан нинидидер Сары Арка аилы янында чегәннәр табыры бар икән, имеш. Бу «әжәл даруларын» шул чегәннәр сата, имеш. Дөрес тә булган ул имеш-мимеш. Володя хәзер ике арага тузан төшереп тормый. Бара да алып кайта. Яшрен-батырын түгел, кайсы чакларда, ару-талудан күзләре бәйләнеп, барасы юллары элже-мелже килә, мотор тавышларыннан баш миләре изелә, савыла башлаган мизгелләрдә Сәдит урындыгы астыннан чүпрәккә төрелгән теге ак башлы зәңгәрсу шешәне тартып чыгара, биләвеннән баласын сүткән кебек иркә генә итеп аны чүпрәгеннән арындыра, пухылдатып ак сургычлы бөкесен чыгара, аннан ап-ак сыеклыкны чынлап та «әжәл даруы» микъдарында гына кечкенә зәңгәрсу савытка сала һәм савытны авызына каплаганнан соң, телләре белән анкавын бераз тәмәйтеп тора да, авызына бер нәрсә дә капмыйча, бу сыеклыкны ашказаны тарафларына зәңгәр күзләренең татлы челт-челте белән генә озатып жибәрә. Шушы «челт-челт»не дә «закуска» дип атый ул. Тагын шунысы да хак, артык мавыкмый Сәдит ул нәрсә белән. Тәүлегенә ике, бик матавыкланганда өч тапкыр бирә ул үзенә мондый мөмкинлекне. Илле-алтмыш грамм бодай аракысы аның шушы ук бодай унышын күтәреп арыган, талчыккан тәнендә, кан юлларында бер шифалы дару сыман эреп югалып, дәрт-дәрманны күтәрә...

Менә шулай Шәфыйкасының турыдан-туры штурвалчылык ярдәме, аның тәмле аш-суы, җан җылысы һәм, әгәр шулай әйтергә яраса, йөрәк мае, Сары Арка чигәннәреннән килгән бодай мәе ярдәме һәм дәшти бөркетләрнең илһамлы ыскылдаулары астында яулый алды Сәдит сәтсиәлистик ярыштагы беренче бу җиңүен. Менә бүген ул шул җиңүе өчен Беренче Секретарь Җаксылыков кулыннан менә шушы «Хөрмәт Билгесе» орденын алды. Сәдит орденны капшады. Ул урынында иде. Тимердән килгән гүр салкыны аны өшетеп куйды. Ул тешләрен шыгырдатты. Иркәй ике кулы белән тотып, түшендәге орденны эләктергеченнән ычкындырды, кире кабына салды һәм кесәсенә шудырды.

Егерме минуттан концерт булачаган әйтеп, тәнәфес игълан иттеләр.

Ачуын кая куярга белмәгән Сәдит шатлыкларын кая куярга белми кайнашкан, бер-берсен котлашкан, кулларындагы орден капларын, төргәкләрен юлпыч сыман селки-селки буфетка таба чабышкан бүләкләнүчеләрне ера-ера, залның президиум чыгачак очындагы ишеккә таба юнәлде. Җаксылыков аны табарга үзе кушса да, ишекне үзе бәреп керергә кыенсынды ул. Бераз көтәргә булды. Гадәттәгечә, башта аның температурасы, аннан кан басымы күтәрелә башлагандай итте. Ниһаять аякларына ап-ак фетр итек кигән, башындагы чәче шома итеп кырылып алынган, күрер күзгә колхоз рәисе, йә булмаса совхоз директоры кебегрәк бер адәмзат ишекне ачып, үтәргә дигәндә генә аңа сылана салып, Сәдит тә эчкә үтте дә куйды. Пелэшбаш артыннан эчтәге икенче бер зур гына залны аркылы чыгып, ул ишеге ачык бүлмә каршында туктап калды. Бүлмә алсу йөзле, канәгать чырайлы, тулы карынлы җитәкчеләр белән тулган иде. Сәдит кайнар карашы белән капшап, алар арасыннан Җаксылыков эзләде. Әнә ул! Әле генә дәүләтнең зур бүләген тапшырган комбайнчыны Беренче үзе дә шәйләп алды һәм кулы белән изәп, үзенә чакырды:

—Гатиятуллин! Бире кил!..

Әмма барлык дәһшәте белән агарынып калган Сәдит урыныннан кузгалмады. Гүя ниндидер көч аны басып торган җиренә кадаклаган иде. Җаксылыков аңа таба юнәлде һәм бөркеттәй кочагына колачлап алды:

—Чын күнелдән!.. Чын күнелдән котлыйм!.. Килеп урнашуыгызның беренче елында... и такой орден!.. «Хөрмәт билгесе»! Безнең өлкәдә бердәнбер мондый батыр бит сез!..

Сәдит бер сүз дә эндәшмәде.

Секундлар сәгатьләргә тиң иде.

Секретарь Сәдитне күздән кичерде. Ул куркыныч иде.

Секретарь аңардан нәрсәдер көтте.

—Пач-чам-му?!—Ниһаять Сәдит хәнҗәрдәй үткен күзләре белән Беренчегә кадалды.—Ниг-гә?!

Аның күзләре чынлап та куркыныч иде.

Монда ниндидер бер зур, котылгысыз сөйләшү барлыгын аңлап алган Җаксылыков, янәшәсендәге берәүгә башын какты да, кулын Сәдитнең иңеннән төшерми торып, аны күршедәге икенче бер бүлмәгә таба алып китте. Алар артыннан мунча яфрагы сыман аркага ябешеп, бүлмәгә теге дә керде. Сәдит аны таныды: ул урак өстендә очрашкан Шәүлә иде.

Алар икесе өстәл артында урын алды. Шәүлә өч-дүрт адымда баскан килеш катып калды.

—Нәрсә булды, Гатиятуллин? Сөйләгез.—Ул Шәүләгә ымлады.—Тартынмагыз, безнең кеше...

Бу кеше үзенең карадан-кара киеме белән бүлмәне тутырган иде.

Тәмам агарынган Сәдит орден кабын һәм таныклыгын кесәсеннән чыгарып, өстәлгә салды:

—Мина мондый... билгесе булып та хөрмәте булмаган бүләк кирәкми. Мин бик тә рәнҗедем, Җалкын Сарбаевич...

Шәүләнең маңгаена бөрчек-бөрчек тирләр шытып чыкты. Ул агарынып хуҗасына карады.

—Ничек... хөрмәте булмаган? Моны ничек аңларга?—Беренченең кандай кызарган йөзе буйлап ниндидер төеннәр йөгерде. Ул сүз таба алмагандай,

бер мизгелгә тынып калды. Аннан үзе дә сизмәстән өстәп куйды.—Бездә орденны сорап алмыйлар. Нәрсә бирсәләр, шуны алалар, гуй...

Менә сиңа мә! Иште ишәк чумарын! Ул, коммунистик идеянең тәҗрибәле көрәшчесе, ерак Татарстаннан яхшы тормыш һәм социаль гаделлек эзләп килгән гади бер комбайнчыга, шулай дип әйтергә тиеш идеме? Кызу урак өстендә бункерга бишек асып, чирәм игенен урган егетнең хакы шулай очсызмы ни?

Әмма дилбегә кулдан ычкындырылган иде. «Гади комбайнчы» исә бу дилбегәне шундук кулына алды:

—Ә менә бездә алай итмиләр... Бездә тиешлесен бирәләр...

Сәхнәдән әле генә таулар актарырлык күтәренке кәеф белән төшкән Беренченең гүя эчендә тегермән ташлары дөбердәп кузгалды. Ул кашларын җыерды. Сәдит беренче тапкыр аның тырпаеп торган чәчләренең шомырт кара, ә кашларының чал булуын абайлады.

—Нәрсә, бүләгебез кечкәнтәй мәллә?

—Эш бәләкәйлектә,йә булмаса зурлыкта түгел.

—Нәрсәдә соң? Тиешенчә бәһаләмәгәннәрме?

—Әйе. Нәкъ шулай.

—???

Сәдит пинҗәк кесәләреннән бер төргәк гәзит кисентеләрен чыгарып салды һәм алар өстеннән күзләрен йөгертеп алганнан соң, чак-чак ишетелерлек тавыш белән дәвам итте:

—Орден тапшырганда сез мине сәтсиәлистик ярышта җиңүче дип атадыгыз. Мин дөрестән дә җиңүче булганмын икән шул... Менә бу гәзиттә язуларынча, игенне мин Говоровка караганда...—Ул, тамагы төелеп, эндәшә алмыйча торды.—... ике мең центнерга, Зельцерга караганда... өч мең центнерга, Жумабаевтан исә...—Аның күз алдыннан дәшти бөркетләр кунган баганалар йөгереп үтте.—... дүрт мең ярым центнерга артыграк суктырып, беренче урынны яулаганмын ләбаса! Әмма... «булганмын» гына! Әмма җиңүчеләр итеп икенчеләрне раслагансыз икән... Ә безнең «Мәмләкәттән» бүген орден алган Кривошапка исерек килеш яна үзйөрешле комбайнны яндырган кеше... Аны утыртырга иде дә бит, әмма... Сез мине әләкче дип уйлый күрмәгез, болай, сүздән генә әйтәм.—Сәдит бер мизгелгә тынып калды.—Сәтсиәлистик ярышта җиңүен мин җиндем, ә менә сез бүген иң югары бүләкләр—Ленин орденын Говоровка, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнарын Кривошапка, Зельцер һәм Жумабаевка тапшырдыгыз, шулай бит? Миңа «Хөрмәт билгесе»,шулай бит?.. Ягъни мәсәлән, хөрмәтсез билге, хөрмәттән көлү билгесе... Мине дөрес аңласагыз иде... Мин сезнең янга орден дауларга дип килмәдем. Минем бары тик беләсем генә килгән иде: нишләп болай килеп чыкты икән ул, Җалкын Сарбаевич?

Секретарь кайнар тиргә батты. Аның һәрчак ярдәмчел, алып бирергә, илтеп куярга, хәбәр итәргә, сакларга, утыртырга, азат итәргә, пычратырга, агартырга әзер торган, әмма бу мизгелдә онытылган гына түгел, иң мөһиме—хуҗасына бернинди дә ярдәм итә алмаган ярдәмче Шәүләсе исә гүя бу һавада үтә күренмәлегә әверелеп эрегән иде. Җаксылыков үткән җәйнең бар тирә-юньне шәм итеп эреткән июль кояшы астында, даланың беренче чирәм уңышын җыйганда, көтмәгәндә генә, каяндыр Татарстаннан бәхет эзләргә килеп чыккан бер гидай комбайнчы белән танышуы өчен хәзер хәтта үкенә дә иде кебек... Мондагы, бу бүлмәдәге кояш теге чактагы дала кояшыннан күпкә эссерәк һәм рәхимсезрәк иде. Аны аңлау, йә булмаса аңларга тырышу бүгенге тантанадан алган ләззәтне җиргә салып таптау, алдагы якты идеаллардан баш тарту, җиңүләрнең бәясен юкка чыгаруга тиң иде...

—Иптәшләренә карата алай ук кансыз... алай ук рәхимсез булырга кирәк имәс иде, Сәдит... кем малае әле?

—Гәбдерәүф малае.

—Әйе, Сәдит Гәбдерәуфович. Алар да бит эшләгән, хезмәт кылган, тир түккән... Кешеләрне бердәй күрүемез кирәк...

Секретарь мондый җебегәнлеге өчен үзен ертып ыргытырга, чәйнәп

өзәргә әзер иде. Шушыларны сөйләп торырга тиеш идеме ул хәзер, аттасының б-б-баш б-б-бал-ласы!..

—Кеше буларак, без, әлбәттә, тигез,—дип эләктереп алды политграмотасын Магдебург танк полигоннарында нығытып өлгергән яшь механизатор.—Ләкин, абзыкаем мой харуший, кешеләрнен тигезлеге аларнын хезмәтен тигезләү дигән сүз түгел әле, шулай бит? Хезмәт тигез була да алмыйдыр ул. Шуңа күрә бит партиябез үзенең программасында «Һәркемнән—сәләтенчә, һәркемгә—хезмәтенә карап» диелгән. Дөр-рес бу!.. Ул бит «Һәркайсын тигезләгез» димәгән, шулай бит? Аннан, «сәт-сиәлистик» дигән сүз, минемчә, «гаделлек» дигәнне аңлатадыр кебек. «Сәтсиәлистик хезмәт ярышы» дигәне инде «гадел хезмәт ярышы» буладыр, шулай бит?

Әйе, «шулай бит», «шулай бит» дия-дия, комбайнчы иптәш Казакъстан коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты әгъзасы, аның күренекле әһелләренең берсе булган иптәшне диварга китереп терәгән һәм бу иптәшнең бу кадәр төгәл мантыйк, аек акыл, ышандырырлык, дәлилле итеп сөйли белгән комбайнчы иптәшен үзенә лекторлар төркеме җитәкчесе итеп эшкә аласы килә башлаган иде...

Әйе, комбайнчы иптәш Казакъстан коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты әгъзасы, аның иң күренекле әһелләренең берсе булган иптәшне бик тә куркыныч, кагылырга да ярамаган, рухи, әхлаки, идеологик бәхәснең чыга алмаслык баткагына алып кереп батырган, инде аның борын тишеге бу сазлыкның соргылт-сасы массасы эченнән беренче куыкларын чыгара башлаган иде...

Ул, котылырга теләгәндәй, урындыгына чат ябеште һәм Сәдитнең күзләренә карады. Алар нәкъ басудагыча садә зәңгәрлек белән ялкынланалар. Комбайнчының сүзләрендә ачу зәһәре булса да, шунысы сәер, күзләрендә бернинди ачу да, зәһәрлек тә юк, татарның бары тик теге, Җаксылыков үзе искә төшергән затлы нәселлелегенең асаба зәңгәрлеге генә бар. Бу аның күңелен нечкәртеп җибәрде. Нәрсә, ул күпне күргән, солдат белән ат тоягы эзендәге сазлык суын да, сасы аракысын да бергә чүмергән армия политработнигы түгел мәллә?! «Бәлки, бүләкләнү хөрмәтенә... чынлап та бер иллешәр грамм тяпнуть что ли?»—дип уйлап куйды Беренче.

Хуҗасы өчен бу җәзаның да җәзасына, бер комбайнчы кисәгеннән түбәнлекле, үкенечле, моңа кадәр күрелмәгән хөкемгә әйләнгән бу бәхәстән котылып, моннан ничек чыгып сызарга белмәгән Шәүлә идәндә катып калган шәүләсен кузгатып маташты. Әмма хуҗасы бу ишарәгә игътибар итмәде. Шәүлә бүлмәдәге кизүлеген дәвам итте.

—Мондый истәлекле көндә...мондый гадәти сорауларга җавап эзләп, вакланып маташасы да килми, Сәдит туесканым,—дип башлады сүзен Секретарь саклык белән алга барып.—Казакъ әйтмешли, ат аунаган җирдә төк калмый булмый, гуй. Аннан, без бит—солдатлар. Ир-егетләр, туесканым. Нәкъ менә шул ир-егетләрчә синең беренче җиңүең хакына берәр йотым кайнар хәляльне тотсак, барча үпкәләрне онытсак,ә? Аннан юлыбызны, партия кушканча, яңа җиңүләргә таба дәвам итсәк, ә? Яшь гаиләң хакына, гүзәл тукалың хакына, ә?—Секретарь элекке хәләтенә кайтып, батырайды һәм хәлиткеч хәрәкәт ясап, өстәлдә яткан орден кабын Сәдит алдына шудырды.—Кечкәнтәен... бункерда үскән бодай баласы хакына... Әйткәндәй, исәнме, исеме-аты кем әле аның?

—Эчмим,—дип алдалашты Сәдит.—Кызның исеме Рәмзия анысы.

—Һмм... Ярар алайса.—Секретарь унайсызланып куйды.

—Авызыма да алган нәрсәм түгел.—Сәдит шундый ук боерыкчан хәрәкәт белән орден кабын Беренченең алдына ук кучерде һәм чекерәеп янадан күзләренә текәлде.—Социализм «тигезлек» дигән нәрсә түгел мени?

—Тигезлек.—Сәдит таккан бәхәстән, ул алып кергән сазлыктан котылу мөмкин түгел иде. Секретарь тирән итеп сулыш алды һәм уфырды.—Мин синең белән килешәм. Тигезлек, туесканым.

—Мине, беренче урынны яулаганны, иң түбәнгә тәгәрәтү тигезлек буламыни?

—Э-э-э... Карагыз әле, безнең республикада ике иң зур халык бар—

казакълар һәм орыслар. Бүләкте беренше итеп орыска бирү безнең халкымызның көнел кинлегенә тап киләдер, гуй. Бездә милләтшелек имәс. Болар барысы да халыкларымыз дуслыгы бола ятыр, гуй.

—Ә мин, татар, шул дуслыкның кайсы тирәсендә инде?—дип сорап куйды Сәдит.

—Ярар инде, арттырма, туесканым,—дип каршы төште ана Җаксылыков һәм ягымлы итеп елмайды.—Ортасында, нәкъ аманат ортасында, гуй!.. Хөрмәт билгесе! Орыстан, казакътан кала, татар туесканымыз өченче болып орден алып ятадыр, гуй!..

—Кахулдан кала,—дип төзәтте Сәдит.

—Әйе, бу мисалда украиннардан кала.—Ярар инде, орден нисбә-теннән һәр халыкны мыскалга салып булмайды... Ул гадел дә булмас иде... «Хөрмәт билгесе»! Йә, әйт, бу бүләк кемнәрдә бар тагын? Татар карындасымызда! Мин, мәсәлән, моның белән бик тә горурланам!—Ул орден кабын янадан Сәдит алдына шудырды. Шәүлә, аякларын алыштырып, урынында таптанды.—Килгән елында ок мондаен һәдия алуың белән котлаемдыр, гуй...

Ул сикереп торды, Сәдитне кочты, сөякләрен он итәрдәй итеп шатырдатып кысты һәм кап эченнән орденны чыгарып, калтыранган куллары белән Сәдитнең түшенә янадан беркетә башлады:

—Без аны шулай итәбез, туесканым... Хөрмәт орденыннан баштаек... Аннан—Кызыл Байрак. Аннан Ленин бабамызның үзен үк чамаларсың, гуй..

Сәдит белән әллә нәрсә булды. Нәкъ шушы мизгелдә кемдер аның үзе белән дә кинәшми-нитми, ризалыгын сорамый торып, аның корыч их-тыярын сындырды, диярсең: ул хәзер үз-үзе белән дә идарә итә алмый, имеш. Гүя ул үз күкрәгенә үзе хужа да түгел. Гүя анда бишек. Гүя аның бишекле күкрәген кемдер арендага алган да, шунда җир сөрә, тырмый, чәчә, ура, анда тамырдай каты куллары белән туфрак йомшарткандай итеп, үзенә кирәк максатларда файдалана, тик Сәдитнең үзен генә кертми иде... Менә ул якасына нәрсәнедер каптырган, нәрсәнедер боргычлаган пинжәген Җаксылыковның кысла сыман капшаучы кулларыннан арындырасы, азат итәсе, аннан бер читкә этәреләсе килә, әмма ничек кенә тырышмасын, моның өчен анарда—әле генә көч-куәт чәчеп торган баһадир ир-егеттә—батырлык та, ихтыяр көче дә җитми. Хәтта багана башларында ыскылдап утырган дәшти бөркетләр дә ярдәм итми. Бу нинди хәл? Ул Җаксылыковның фиркави һәм дәүләти кочагында балавыз сыман эри һәм эрүен дәвам итә иде.

Сәдит кинәт кенә, тиле кеше сыман, шаркылдап көлә башлады.

Бу көлү исә Беренченең күнеленә аеруча хуш килде.

Ниһаять орден янадан Сәдит күкрәгенә менеп оялады.

—Менә ничек бөтәеп киттен, гуй!..—Беренче ана сокланып карап куйды.—Әтеү, алмыйм, имеш! Әтеү, онытма, бездә дә «бирмим, имеш» булуы мөмкин, гуй...

Ул тынычланды. Кемне нинди орденга билгеләү буенча хакимиятнең гадел эш иткән булуын раслау өчен меңләгән ялган дәлилләр китерә, әгәр бик тели икән, үзенә генә билгеле булган юллар, чаралар, чамалар, шомартулар, куркыту-өркетүләр аша ышандыра, инандыра алган, инандыра алмаган очракларда, үз сүзен барыбер сүз итеп, маңгае белән дивар жимергән Беренче бу юлы,—ә бәлки бу барлык тормышында, партиядә эшендә эшләү дәверендә беренче мәртәбә булгандыр—комбайнчы белән артык кызылланып, шомартынып, татлы телләнеп тормады, Сәдит туесканы биргән сораунын иң аска яшерелгән җавабын ачты да салды:

—Алмаченко теләмәде. Евгений Христофорович. Без аңа Ленин орденын да, Хезмәт Кызыл Байрагы орденын да тәкъдим иткән идек. Кирәк имәс, диде. Безнең совхозда әлегә лаеклылар юк, диде...

—Рәхмәт... рәхмәт,—дип пышылдады шалкан сыман агарынган Сәдит.—Мин җавабыгыздан канәгать... Миңа шул гына кирәк иде ... Миңа орден һич кенә дә кирәкми иде...

«Бу Алмаченко һаман акылга утырмаган»,—дип уйлап куйды ул тагын.

Әле күптән түгел генә Теләнче Тамагындагы оясыннан очып чыккан татар бөркете шунысын аңлады: бу шартларда орден—адәм баласының

хезмәте өчен алган горурлык билгесе—ул хосусый милек икән. Ул лаеклы булган бүләкләр арасындагы иң «түбәндәге»сен алу да аның өчен зур батырлык икән. Сәдитнең күңеле уйнап куйгандай итте. Ул читкә карады. Шул мизгелдән алып Сәдит өчен Тукайлардан килгән саф, чиста милли хиснең милеккә, шәхси хуҗалык сыман ниндидер бер матди, гасаби хиссият чыганагына әйләндерелгән булуы аңарда мәңгелеккә тар, тынчу милләтчелеккә карата мәңгелек җирәнгеч мөнәсәбәт тудырды.

Аның җавабыннан канәгать булучыдан үзе үк канәгать булган Беренче, кәефе килеп, елмайды, кәнәфиендә тоендәй чишелеп, бәдәнен яздырды һәм Сәдитнең колагына ишетелер-ишетелмәс итеп кенә пышылдады:

—Аннан, туесканым, һич тә аптырама: мондый тантаналар ниндидер микъдарда театр... концерт рәвешен алалар. Син алдагы зур тантаналарга репетиция генә үтәсең...Синең юлың—Социалистик Геройлыкка!..

Сәхнә ягыннан «Ой, ты, зима морозная»ны кумәкләп җырлый башладылар. Бу бүләкләнүчеләр хөрмәтенә концертының башлануы иде.

Беренче Шәүләсенә баш какты. Менә ярты сәгать инде күрсәтмә көтеп урынында кара баганага әйләнгән, йөзендә йөзе, телендә теле булмаган һәм кеше хәтерендә шәүләсеннән башка бер нәрсәсе белән дә хәтердә калмаган телсез аппарат чиновнигы, саздан аерылгандай, аякларын чак кузгатып һәм кергәнендәге сыман елышып кына, бүлмәдән чыкты. Бүлмә аның артыннан киңәеп, яктырып киткәндәй булды.

Әмма Шәүлә аларны бөтенләй ташлап китмәде—бүлмәдән чыгу белән икенче бер уңайлы урынны сайлап тагын да катып калды. Хәзер ул күзәтә дә, берүк вакытта концерт та тыңлый иде.

—Ә син кайгырма... Алмаченкога да кинә саклама. Җаманлыкта нан үстереп болмыйдыр, гуй.—Секретарь болай да бик тәртипле итеп ятып торган шомырт кара чәчләрен сыйпады.—Таррак адәм ол, әлбәттә. Бездә озак калалмас ол...

—Тар түгел. Татарны яратмауда татарның үзеннән дә ... татарырак кеше...

—Нишләтәсең, һәркемнең үз холкы. Аннан, житәкче халкы үзенчә чирли бит ул.. Аларны вакытында кашып торырга кирәк, шулай бит?—Беренче елмайгандай итте.—Кайгырма, барысы да рәтләнер. Исәнлек кенә кирәк. Тукалың, теге бункердагы бишектә үскән кызың ниһәлдә сон? Исән-аманнармы?

—Исәннәр, аллага шөкер. Әнисе йөгереп, кызы сикереп, әтиләре кикереп йөри. Малайга да нигез салдым. Бишкә кадәр туктамаска исәп.

—Менә монысы өчен...бездән сина һәм тукалына тагын бер орден. Ә теге... авылдан, синең арттан килгән кызкай... Исеме кем иде әле... Ну, синең икенче хатының...

Ниндидер чинашкан тавышлар чыгарып, сәхнә ягыннан җыр яңгырады.

Сәдит бу концертка кереп тә тормаячак. Мондый шома, монсыз җыр ишарәтләрен, шырды-бырдыны аның җене сөйми.

Беренче сәгатенә карап куйды.

Сәдит тә, җиңен ышырып, сәгатьсез беләгенә карап куйгандай итте. Аннан, нәрсәнедер исенә төшергәндәй итеп, сискәнде:

—Нишләп ул минем икенче хатыным булсын, ди?!—Сәдит, уянып киткәндәй, кап урталай ярылды.—Сез... чамалап! Бездә безләргә бер генә тапкыр яратырга кушылган, пәнниммәешь ты!..

—Гафу ит инде! Сине һич тә рәнҗетергә теләмәгән идем дә бит...

—Мактарга теләгән идегез мени?

—Һәрхәлдә, һич кенә дә кимсетермен дип уйламаган идем. Аннан, шартыннан чыгып, кулыннан килгән, булдыра алган ир-егеткә ул кадәр хөкемгә тарттырырлык җинаять тә түгелдер инде ул...

—Нич- ча- уа сиб-бә!—дип кычкырып җибәрде Сәдит.—Болай булгач, сезне зәррәгә генә Беренче Секретарь итмәгәннәрдер, абзый!.. Сездә, Казакъстан компартиясендә ничектер, ә менә бездә, Татарстан компартиясендә, көпә-көндез ике хатын белән яшәү мактала торган нәрсә түгел. Ул ике аягына ике ыштан киеп чабу белән бер, мин сезгә әйтим! Андый чакларда райкомга чакыралар да, түзәлмәсәң дә түзеп торырга кушалар...

—Син бит коммунист түгел...—дигән булды Җаксылыков Сәдитнең бары тик «Хөрмәт билгесе» орденына гына тәкъдир ителүенең бер сәбәбен сиздерергә тырышып.—Совхозыңа кайту белән партиягә кер. Син бит... һаман да коммунист түгел!..

—Булмаса ни! Анын каравы, мин—партия баласы!..—дип җавап бирде ана Сәдит.—Партиясезләрнең балалары да мәм-мәм сорый, мой харруший!

—Анысы хак. Минем ул кызкай хакында беләсем генә килгән иде. Совхозда калдымы ул? Китмәдеме? Кем булып эшли?

—Китмәде. Ындыр табагында үлчәүче булып эшли.

—Кияүгә чыкмагандыр бит?

—Чыкмады әле. Сезне көтә.

—Ну, кызык та инде син, Гатиятуллин!

—Шул кызык коткара инде мине... Югыйсә, элмәккә керергә кирәк...

—Нигә алай бик кискен әле?

—Ничек кискен булмаска, ди? Алдан да, арттан да мәхәббәт камалышындамын. Ә менә яшәргә, ике хатын белән түгел, берсе белән дә йокларга урын юк...

—Кит аннан! Нигә әйтмичә торасың? Әле кайда яшәп азапланасыз?

—Ат абзарында.

—Ат абзарында?! Булмас ла!

—Килеп карагыз, бәй. Ат карауčы алачыгында. Рәмзиянең бишеге хәзер шунда күчте.

—Һм. Хуҗалыкның ат караучысы юкмыни?

—Бар иде. Хатыны бу шартларга түзә алмыйча алып кайтып китте. Ат караучы булып әлегә мин эшләп торам. Әле кичә генә Шәфыйка белән ике колын кабул иттек...

—Кит аннан!..—Җаксылыков йодрыгыннан ут чыгарып, өстәлгә сукты һәм, ялкын капкандай, урыныннан күтәрелде.—Кайтуына совхоз сине фатирлы итәчәк, Гатиятуллин!.. Туесканым!.. Йә мин, йә бу Алмаченко!... Әйдә, концертты карап алайык, гуй...

Кәефләре җиңеләеп, фикерләре сукыраеп калган Сәдитнең бер йөз генә грамм булса да төшерәсе килеп китте.

Орденыннан баш тартып, Секретарь белән кайнар бәхәсләшкән Сәдит һәм инде менә орденын түшенә тактырган Сәдит гүя икесе ике кеше иде.

Алар бүлмәдән чыктылар һәм концерт залына юнәлделәр. Артларыннан дивар буйлап шуыша-шуыша теге Шәүлә дә озата барды. Татар моның, аның «Шахта» һәм «Сарман»нарын сагынган Сәдитнең бу колак тондыргыч, уйлавынча, моңсыз һәм җиде ят тамашага һич кенә дә керәсе килми иде. Ләкин ниндидер пошаманлы көч иркәйне шунда тарта, кальбенә каршы килеп булса да, керергә, мондый бергәлектән читтә калмаска боера иде...

Буфет каршында шактый кызып алып, кайсы кайда изрәгән, шаулашкан, сүз куерткан замандашларын ерып, ул гүя үз күкрәгенә бишек итеп орден таккан Сәдит, артыннан майлы комбинезон киеп ир-ат рәвешенә кергән штурвалчы Шәфыйкасын да ияртеп, һәлакәтенең, бөек тарихының азагына, аның гына түгел, үзеннән соң калачак балаларының, балаларының балаларының, барлык нәселенең, милләтенең яна бер мәҗүси сыйфатына таба үзе теләп атлагандай, Беренче Секретарь ачкан ишек аша залның шаушулы ят авазларда, хәмер исләрендә чайкалган томанлы караңгылыгына, туган җырулардан җинелчә, моңсыз «Ой, ты, зима морозная»лар аша якын киләчәкнең меңләгән шырды-бырды такмаклары патшалыгына кереп чумды.

Кайчан чыгар ул аннан?

Чыгар микән?

Чыккан хәлдә, аның үзен дә икенче бер бишеккә салып чыгармаслармы?

*2001, январь—февраль.*
*Чаллы.*

# Şigriət
# Шигърият



## Рашат Низами

### ИКЕ МӨҺАҖИР

**АЗАТЛЫК ТУРЫНДА МОНОЛОГЛАР**

#### 1. Сүзнең башы

*Мәгърифәт—азатлык юлында*
*беренче адым.*
Гаяз Исхакый.

*Ни кызганыч: туган туфрагымда*
*Бер тупыл да үстерә алмадым.*
Назыйм Хикмәт.

**Тормыш бит ул чуар калейдоскоп—**
**Кайда золым, кайда тамаша...**
**Яшәү серен күбрәк аңлар өчен**
**Без туганбыз җиргә ләбаса.**

**Син төрекме, үткен яһүдиме,**
**Әллә урыс, яки татармы,—**
**Күкрәк куеп без якларга тиеш**
**Үзебезнең газиз Ватанны:**

**Ана сөте белән язылгандыр**
**Табигатьнең шушы кануны.**
**Син саналсаң азамат ир булып,**
**Күрсәт, әйдә, дөрләп януны!**

**Күтәрелә кемдер Гареп яктан,**
**Күтәрелә кемдер Шәрыктан.**

---

Рашат НИЗАМИ *(1950)—шагыйрь, прозаик; «Йолдыз яңгыры», «Кызыл җәй» һ.б. шигырь китаплары, «Ут һәм җыр» исемле роман-хроника авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Туры Тукай сыман шәхесләргә
Егерменче гасыр зарыккан!

Патшалар һәм кара диктаторлар
Тарих чүплегенә очканда.
—Азатлык!—дип оран сала гавәм
Иманнары шулай кушканга.

Көрәш ләкин, көрәш җиңел түгел,
Язмышларны бүлә урталай.
Синең язмыш белән
«Шаярырга» мөмкин
Ататөрек[1] яки Николай[2].

Шәхесләрне корыч-калкан итеп
Әзерләгән Вакыт, чарлаган.
Көрәшләрнең кыл уртасын сайлап,
Һәммәсенә урын барлаган.

Һәр халыкның асыл егетләре
Дисбе-мәрҗән булып тезелгән.
Нишләтәсең,
Гел кирәкле чакта
Милли тәсбих безнең өзелгән!

Таркатырга ярыймы соң шулай
Мең гасырдан килгән дисбене?
...Ир-егетләр атны иярләгән,
Кулларында—язмыш тезгене.

## 2. Чистай зинданы. 1907 ел.

*Төрмә, әлбәттә, куркаграк кешеләрне куркытыр өчен, йомшаграк кешеләрне кылган эшләреннән тәүбә кылдыру өчен ясалган.*

Г. Исхакый.

Тоткын хәлен тоткын гына белә:
Ялгыз калу—хәтәр бер нәрсә.
Ярый ла бит шундый чакларында
Күршең сиңа
Дивар аша «сәлам» җибәрсә.

Шакып-шакып әллә ниләр сөйли
Күрше камерадан утырдашың.
Тик Исхакый өчен иң кыйммәте—
Кәгазь, каләм, һәм дә ялгыз башы.

Татар өчен җаны актарыла,
Уйный канда фикер хәрәкәте.
Җай чыктымы, их, язасы килә!
Бу—бердәнбер төрмә бәрәкәте.

Ул бит тоткын—кирәк санасалар,
Төн эчендә бәреп керәләр дә,
Бер сүз өчен аяк-таяк белән
Тотыналар сине типкәләргә.

Һай, бу кяфер, нәкъ кирәксез чакта
Ишек тибеп өскә ябырыла.

[1]Ататөрек—Төркиянең беренче Президенты итеп 1923 елда сайлана. 1938 елны үлә.
[2]Николай II (1868—1918)—Россиянең соңгы императоры.

Ялтыр очлы винтовкасы белән
Кул тыкмакчы милләт тамырына.

Алар өчен тик бердәнбер ләззәт—
Винтовка һәм пычак кулларында.
Без дә шулай корал тоттырыйкмы
Әллә инде татар улларына?..

Гаҗәеп хәл: төрмә сакчылары
Бар да ямьсез, бар да кызыл күзле.
Менә шушы ямьсез дөньялыкта
Югалтмаска кирәк үзебезне!

Кояшы да юньләп чыкмый аның,
Рәсәй өсләрендә—кара болыт.
Шәм яндырып, ладан бөркеп кенә
Таралырмы мондый караңгылык?

Патша китәр...
Совет килеп җитәр—
Большевиклар көрәш башлаячак.
«Халык дошманы» дип Тинчуринны,
Бурнашларны кыйнап ташлаячак...

Ә хәзергә—рәшәткәле тәрәз,
Лампа уты—тычкан уты сыман.
Халык күптән уянырга тиеш
Инкыйраздан, гафләт йокысыннан!

## 3. Истанбул төрмәсе. 1939 ел.

*(Назыйм Хикмәт монологы)*

*Йөрәгемнең ярасында,*
*Чал чәчләрем арасында—*
*Ватан, ватан...*
Н. Хикмәт.

Яратыйк Ватанның һәр гөлен,
Үләнен, туфрагын.
Ирektән татлырак, затлырак
Ни-нәрсә бар тагын?

Коммунист булганга гаепләп,
Ирektән, хакымнан сөрделәр.
Төрмәсе-зинданы күп күбен,
Тик Ватан бер генә!

Шулай да кадерле Ватаннан,
Әй, килә качасы.
Чит илдә татлыдыр шикелле
Азатлык һәм Ирек һавасы.

Язмышны, тәкъдирне сайладык,
Утларда без хәйран кайнадык.
Алланың бирелгән бүләге—
Хакыйкать кайда соң?

Төрмәләр шулпасын мул итеп
Эчерде замана.
Сындырды, бастырды ул безне
Гел утлы табага.

Рәсәйдә ачлык, дип ул чакта
Кемнәрдер сөйләнде.
Без исә курыкмый ашадык
Ямь-яшел үләнне.

Төрмәләр коймасы яз көне
Бай иде үләнгә.
Икмәкле, хикмәтле Рәсәйне
Бирмиктер үләргә!

Унөч ел төрмәдән-төрмәгә
Тоткында йөрдем мин.
СССР—алсу төс икәнен
Ишетеп белдем мин.

Исемем, җисемем тапталган
Болганчык бу илдә—
Шатлыклар, куаныч бар микән
Кояшка һәм җилгә?

Сәясәт өченгә, әнкәем,
Җәзалар күп килде.
Догадан догага көн саен
Кабатлыйм исмеңне.

Безнеңчә исемең чук матур,
Әнкәем Җәмилә!
Шулай дип эндәшсәм, күңелгә
Һәрвакыт яз килә.

Күңлемә кадерләп салдым мин
Ватанны һәм Сине.
Кәгазьгә, шигырьгә батканга
Кичерә күр мине...

Төшемдә еш кына мин күрәм
Ут-кызыл миләшне.
Булсаң да син кырыс һәм ачы,
Бир юньле киңәшне!

Тынычмы сәясәт мәйданы,
Кем йөри капкада?
Ни уйлый икән соң кешеләр
Мылтыктан атканда?

Фюрерның яшертен нияте
Беләбез, һай, яман,—
Тупларын җай гына бора ул
СССРга табан.

Шигърият, азатлык җиленә
Сусадым мин тәмам.
Мин фәкать җыр белән барырмын
СССРга табан.

Илемдә, һай, тынчу, һай борчу,
Күңелгә бигрәкләр кысандыр.
Мәскәүнең кып-кызыл миләше,
Син мине
Матурлык җиңәр дип ышандыр!

Тупыллар толымын сыйпарга
Вакытны берзаман табармын.

Ә күңел һаман да ашкына
Советка табан гел.

Зинданның бетонлы биленә
Йодрыклап сугармын.
Күңлемнең кошлары һаман да
Очалар югартын.

Кичерә күрче син, әнкәем,
Язмышлар тулгагын.
Улыңның бу фани дөньяда
Ник шагыйрь булганын...

## 4. Гаяз Исхакый монологы

Чит илләргә чыгып киткәч кенә
Мин милләтче дигән ат алдым.
Туган телне, илне кыскан өчен
Нишләтергә урыс Ватанын?

Туган илдән качып китмәдем мин,
Ирексездән бары сөрелдем.
Ауропаны үз күзләрем белән
Күргәч кенә рухым терелде.

Россиядә шундый тынчу иде,
Туры килде күбрәк туңарга.
Туфрагымны, әчәр суларымны
Ташлап киттем менә шуңарга.

Ир-егеткә мохтаҗ икән милләт—
Бер затка да, тагын мең затка.
Азатлыкка мәйдан эзләп, илне
Ташлап киттем озын-озакка.

Истанбулның өсләрендә болыт,
Казаннарга барып җитәрме...
Йоклап яткан татар улларына
Миннән сәлам нурын илтәрме?

Ишетегез, татар угланнары,—
Дәүләтчелек диеп чаң кагам.
Кан көрәшле Ватан азатлыгын
Сатып алып булмый акчага.

Бу дөньяны ничек төзәтәсе,
Кяфер явы—яман, куркыныч.
Ярый әле саклап калган безне
Туган телебез дигән ут-кылыч.

Һаман бер сүз: «единая...» диеп
Кабатлыйлар, гүя попугай.
Безнең өчен шушы сүзләрдән дә
Хәтәррәк нәрсә юк бугай.

Шовинистны күбрәк белгән саен
Кояш белән ныграк дуслашам.
Әйтер сүзләремне әйткәч кенә
Мин дөньялык белән хушлашам...

## 5. Идел белән Урал арасы

*Россия—халыклар төрмәсе.*
В. И. Ленин.

*Чукындырган чагында да*
*Чукынмадың, татар теле!*
Нажар Нәжми.

Кояш асларында
Җәйрәп ята
Идел белән Урал арасы.
Сибелешеп шунда дөнья куган
Кыпчак-болгар-татар баласы.

Бөтенесе бергә кайнашканнар—
Галим, итче, җайдак, узаман.
Бөек Кытай диварына хәтле
Барып җиткән алар берзаман.

Гөр-гөр килеп бердәм яшәгәннәр,
Дер-дер килеп дошман яшәгән.
Тарих битләреннән кан ага да,
Адәм күзләреннән яшь ага.

Чабаталы мужик, көнләшүдән,
«Ах» дигән дә, аннан «вах!» дигән.
Болгар дигән яугирләрнең чөнки
Читегенә хәтле сәхтиян.

Сәүдә юлларына карый-карый
Билен бөккән Шәрык, Көнбатыш.
Кызыл малың, кәрваннарың булса,
Ефәк Юлы дигән эзгә төш.

Күпме шәһәр, хансарайлар кулда—
Әчтерхан һәм Сембер, Самара...
Күрше илгә күз текәгән саен
Мәскәүләрнең йоны кабара.

Явыз Иван саранчадай килгән,
Казан ауган, Казан егылган.
«Кол булмагыз!»—
Илнең капкасына
Ятим җилләр килеп сугылган.

Кадаклар һәм дага ясаулардан
Тыеп торган патша фәрманы.
Атны дагалаудан мәхрүм булгач,
Калырмы соң татар дәрманы?

Корылтайлар эзләп, Европаны
Айкап йөри Гаяз Исхакый.
Илдән-илгә шулай куа аны
Туган тел һәм гадел сүз хакы.

Шуңа күрә чакыру ташлый Гаяз:
Кирәк милли автономия!
Төрмәләргә түгел, Азатлыкка
Күпме илләр әнә баш ия.

«Коммунизм» дигән кызыл афәт
Европаны алса бугазлап,
Бергә-бергә канда коеначак
Немец, француз, поляк, югослав.

Идел белән Урал арасы ла,
«Өф-өф» итеп кенә барасы.»
Чөкердәшеп шунда яшәсеннәр
Башкорт белән татар баласы.

Идел белән Урал арасы ла,
Гүя ике күзем карасы.
Бәйли-бәйли йөрәк яраларын,
Барасы да безгә барасы.

Вакытында әйтеп калу кирәк,
Күпме фикер үлә югыйсә.
Гаҗәпмени: «Идел-Урал» сүзен,
Байрак итеп,
Мәйданнарга халык түгелсә,
Фениксгай кабат терелсә...

## 6. Казан. Ирек мәйданында уйлану

*Империя капкасында—йозак...*
Рәшит Әхмәтҗан.

Исхакыйны Назыйм Хикмәт белән
Куеп карыйм кайчак янәшә.
Назыйм Хикмәт—сәяси бер корбан,
Ә Исхакый—
Тугры Тукайга тиң ләбаса!

Милләт өчен утка-суга кереп,
Күпме канаткан ул йөрәген.

Чорналышып, еллар һәм гасырлар
Көтеп торган аның кирәген.

Коммунист һәм антикоммунистлар
Алыш-биреш ясап караган.
Хәзер инде вакыт—икесен дә
Араларга актан, карадан.

Егерменче гасыр уртасында
Мин туганмын...
Менә шул чакта
Назыйм Хикмәт ачлык игълан иткән
Йөрәк утын ташлап учакка.

Язлар гына түгел, бу дөньяда
Кабатлана бик күп нәрсәләр:
Ачлык игълан итә күпме татар,
Нәрсә булыр—
Арттан мылтык белән бәрсәләр?

Туган телне мәңге саклар өчен,
Тотар өчен илне гөл итеп,—
Бер тамчы да артык сорамыйбыз,
Кирәк бары суверенитет!

Палаткадан кинәт калкып чыга
Трибун шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан.
Эстәрледән—Зәки Зәйнуллиннар,
Калганнары тагын кай яктан?

Бәйрәмова—шактый агарынган,
Рәшит исә шактый ябыккан.
Татар илен саклап калыр өчен
Алар ярдәм сорый халыктан...

Басып торам Ирек мәйданында.
Ах, йөрәкнең авыртулары!
Утызынчы август көннәредәй
Тыгызланып килә уйларым.

Ул чакларның кайнарлыгы истә:
«Дубинка»лар кисте һаваны.
Ак яулыклы әбиләре белән
Мәйдан тотты татар гавәме.

Кайтардыкмы илнең гасырлардан
Күчә килгән кодрәт-шәүкәтен?
Һаман әле камалышта яши,
Ут эчендә яши дәүләтем.

Җирләр уртак, язмыш уртак, диеп
Сөйләнмәгез, Ходай хакына.
Хәләл малларыбыз һаман әле
Рәсәйнең
Тишек кесәсенә агыла.

Шовинист та бер аңласа икән,
Акылы калган булса әз генә:
Империя упкан халыкларның
Күз яшьләре—милли хәзинә.

Без әйтәбез: дәүләтчелек диеп,
Алар әйтә—милләтчелек дип.

Бу Рәсәйнең милли сәясәте
Астан өскә кадәр черек бит.

Азатлыкның татлы икәнлеген
Аңлау кирәк инде, ниһаять.
Кешеләрне илдән, ирегеннән
Мәхрүм итү—иң зур җинаять.

Назыйм Хикмәт «коммунизм» диеп
Үзенчәрәк шулай саташкан.
Ул бит—шагыйрь! Ул шигырьгә түгел,
Сәясәткә кереп адашкан.

Тоткын чакларында сизгәндер ул
Босфор бугазының тарлыгын.
Белде микән Исхакыйлар өчен
Татар бугазының барлыгын?

Татар исән!
Кирәк түгел ләкин
Бу халыктан «бүки» ясарга,
Бугазына, моңлы җырларына
Күнитекләр белән басарга.

«Урыслашып» бетте самавырлар,
«Урыслашып» бетте каеннар.
Күкрәк тәрәп милли хисләремне
Яклар өчен минем ваем бар.

Байрак тотып һаман алдан бара,
Оран салып бара Исхакый.
Ирек дигән дәрья кочагында
Аның гомере—түгел кыска көй!

Бумеранг сыман Илгә кайтты,
Кире кайтты безгә әйләнеп.
Яңа гасыр—Ике меңенче ел
Булсын бездә шатлык бәйрәме.

Көл-туфракта, бик еракта калган
«Орхон-Енисейлар» язмасы.
Бүтән җырны бүген яңгырата
Әрсез магнитофон тасмасы.

Тел югалса—илең югалачак,
Ил югалса, телең үләчәк.
Яңабаштан исән калу өчен
Мәдәт бир син безгә, Киләчәк!

Их, сөйлисе һәм җырлыйсы иде
Бәйсез Татарстан турында.
Танк тавышларын күмә-күмә,
Өмет кайный әле җырымда.

Азатлыкка юллар ярган чакта,
Милли көрәш кыза барган чакта—
Мин нишләргә тиеш?
Син нишләргә тиеш?..

Безнең халык кол булмаска тиеш:
Безнең—миссия бу,
Бу—безнең эш!

*Гыйнвар—август, 2001 ел.*



# Солтан Шәмси

## НИЗАГЛЫ ЙОРТТА

### АЛТЫН УРДА ДӘҮЛӘТЕНЕН ТАРКАЛУ ЧОРЫННАН СӘХИФӘЛӘР

«Хак булса, без күпчелек фикере хөкем сөргән заманда яшибез һәм анын тавышы корольләр белән кенәзләр хакимиятен алыштырды дип уйланыла. Әмма тарихның азчылык арасындагы конфликтны тәшкил итүен дә онытмыйк, ягъни тарих ул—массалар белән идарә итүче юлбашчылар конфликтыннан гыйбарәт.»

Джон Бейнс,
XX йөз Чили философы.

*Укучыга тәкъдим ителә торган бу әсәр соңгы еллардагы эзләүләремнең нәтиҗәсе булып тора. Анда сүз мәшһүр татар дәүләте Алтын Урданың гаять гыйбрәтле бер дәвере—таркалу чоры турында бара. Гадәттә, галимнәр язган хезмәтләрдә тарих киң планда һәм әтрафлы тасвирлана, вакыйгалар тезмәсе, аларның үзара бәйләнеше, үсеп чыккан теге яки бу күренешнең сәбәпләре аңлатыла, икътисад белән сәүдәнең роле күрсәтелә, хәтта мәдәни тормышка да урын бирелгәли. Әмма бу хезмәтләрдә аларның барысы өчен дә уртак бер кимчелек—шәхесләргә игътибар җитмәү гел күзгә ташлана. Ә бит, төптәнрәк уйлап карасаң, вакыйгалар уртасында һәрвакыт шәхесләр тора, вазгыятьне алар тудыра, карарлар кабул итеп, тарихи барышны теге яки бу якка борып җибәрә.*

*Шул сәбәпле, әсәрдә төп игътибар тарихи шәхесләргә юнәлтелде, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең вакыйгалар агышына ничек тәэсир итүе тикшерелде, ягъни вакыйгаларның күзгә күренми торган ягын—эчке пружиналарын ачып салу максаты куелды. Шушы ягы белән әсәр башка тарихи китаплардан аерылып тора булса кирәк.*

*Бай тарихыбызны өйрәнгәндә, язучы буларак, мәсьәләнең бу ягына мин гел игътибар итә килдем, кызыклы хәлләрне үзем өчен теркәп тә куя торган булып киттем. Бу җәһәттән Алтын Урда тарихы вакыйгаларга аеруча бай. Шул рәвешле шәхеснең тарихтагы роле турында материал тупланды. Тора-бара тарихыбызның бер чорын шушы җәһәттән күзәтеп чыгу теләге туды—Алтын Урданың таркалу чоры ифрат дәрәҗәдә гыйбрәтле тоелды.*

Солтан ШӘМСИ *(1946)—прозаик, тәрҗемәче, тарихчы. «Көмеш чылбыр» (1984), «Җәяүле буран» (1988), «Ут хәйләсе» (1994), «Волжская Булгария в рассказах для детей» (1995), «Еллар эзе» (1996), «Әхмәд ибне Фазланның Итил елгасына сәяхәте» (1999), «Идел Болгарстаны» (2001) һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

*Хронологик яктан карганда, әсәр кечкенә бер дәверне эченә ала. Вакыйгалар мәшһүр Үзбәк ханның вафаты (1342) белән башлана да татар дастаны каһарманы Идегәй мирзаның үлеме (1420) белән тәмамлана. Әмма шушы 70—80 ел эчендә Алтын Урда дәүләте зур тетрәнүләр аша уза. Ара-тирә тукталып торса да, нигездә даими дәвам иткән ватандашлар сугышы, Куликово кыры вакыйгалары, Идел-Йортны кара күмергә әйләндергән Аксак Тимер яулары, шуларга өстәп ил өстенә афәт булып төшкән чума авыруы эпидемиясе, татар мәмләкәте идарәчеләренең үзара алып барган туктаусыз сугышлары гайрәтле һәм шанлы дәүләтне акрынлап зәгыйфьләндерә, эчтән җимерә, торган саен хәлсезләндерә бара һәм, ахыр чиктә, таркалып, вәйран булу куркынычы алдына куя. Шулай итеп, татар мәмләкәтенең тарих мәйданыннан төшеп калуында тышкы сәбәпләр белән эчке (шәхесләргә бәйле) сәбәпләрнең дә гаять зур роль уйнавы ачыклана. Үзбәк хан заманыннан соң дәүләт идарәчеләренең күпчелеге ил кайгысын кайгыртып яшәү, бөтен игътибарны шуңа юнәлтү югарылыгына күтәрелә алмаган. Шул сәбәпле илне идарә итүдә күп хаталар җибәрелгән һәм тора-бара татарны фаҗигале язмышка дучар иткән.*

*Әйткәнебезчә, бу күренеш Алтын Урданың таркалу чоры мисалында аеруча ачык күренә. Соңрак шул ук хәлне без Казан ханлыгы тарихында күзәтәбез. Шушы хәлләрне кабат күздән кичерү әле дә таркау яшәүче милләтебез, аның тарихы өчен һаман актуаль мәсьәлә булып кала бирә. Алтын Урда, гомумән, татар дәүләтләрендә барган эчке низаглар, туктаусыз барган тәхет даулары, олы бер максат-идея булдыра алмыйча яшәүләрнең нигезендә нинди сәбәп ята соң? Минемчә, татар дәүләтләрендә көч-гайрәт ташып торса да, шуңа юнәлеш бирүче рухият җитенкерәмәгән. Беренче чиратта, аның идарәче даирәләренә. Рухи көч белән йөгәнләнмәгән гайрәт, төрле тарафка ташлап, олы максатка омтылмыйча, үз-үзен харап иткән.*

*Әйе, халкыбыз тарихында гыйбрәт алырлык хәлләр күп. Тик ни өчен татар тарихтан һаман гыйбрәт ала белми? Тарих юлларыннан сәяхәт иткәндә авторны шундый сораулар гел борчып торды һәм аларга җавап табу теләге аны кулына каләм алырга мәҗбүр итте.*

Автор

## Бозылган васыять

Үзбәк хан заманында Алтын Урда үсешенең иң биек баскычына күтәрелә. Бу вакытта татар мәмләкәтенең даны бөтен дөньяга тарала, төрле илләрнең идарәчеләре Үзбәк хан белән бәйләнешкә керүне, булган мөнәсәбәтләрне тирәнәйтүне үзләре өчен дәрәҗә саныйлар. Бу дәвердә илдә иминлек, муллык хөкем сөрә, төзек һәм матур калаларда тормыш гөрләп тора, мәдәният чәчәк ата, сәүдә алга китә. Бөек ефәк юлының төньяк тармагы дәүләтнең башкаласы Сарай аша үтә, анда дөньяның төрле кыйтгаларыннан китерелгән тауарлар сатыла. Сарай каласына атаклы галимнәр, дин әһелләре, шәехләр, шагыйрьләр, һөнәрчеләр агыла. Башкала барысына да урын бирә, монда һәркем үзенә иш һәм шөгыль таба. Имин һәм бай тормышлы шушы калада һәркем үз бәхетен эзли. Үзбәк хан заманында мәмләкәттә эшләр шул кадәр көйле бара ки, хан үзе бары тик иң зур мәсьәләләрне хәл итүдә генә катнаша, ә инде керемнәр-чыгымнар, салымнар салу, жыю кебек нәрсәләр тулысынча диван, андагы карачылар, әмирләр хөкеменә тапшырылган була.

Көннәрдән бер көнне гөрләп яшәп яткан шушы данлы илдә кайгылы хәбәр тарала:

—Үзбәк хан хәзрәтләре вафат булган...

Бу хәбәр 1342 елның далалар кардан-боздан арынып, үләннәр баш калкытырга җыенган март ахырларында тарала.

Үзбәк ханның васыяте буенча тәхеттә аның өлкән улы Тинибәк калырга тиеш була. Әмма ул бу вакытта башкаладан еракта, атасы әмере белән Чагатай олысында яулар алып бара. Шуна күрә атасын җирләүдә дә, үзенең тәхеткә чыгу мәрасимен әзерләүдә дә катнаша алмый. Ул башкалада булмаудан файдаланып,

Үзбәк ханның хатыны Тыйтгали (урыс тарихына ул Тайдулла исеме белән кереп калган) тәхеткә Җанибәк исемле уртанчы угылны утырту хәстәренә керешә. Моның өчен ул әмирләр белән сүз берләшә, аларны Җанибәкне тәхеткә чыгарырга күндерә. Ә халыкка исә «Тинибәк әйләнеп кайтканчы тәхеттә Җанибәк утырып торачак» дип игълан итәләр.

Тәхеткә ия булгач, аннан баш тарту җинел түгелдер, күрәсен. Җанибәк анда тәхетне агасына кайтару өчен утырмый. Шулай Тинибәкне юк итү планы корыла һәм тормышка ашырыла башлый. Тәхет варисы Чагатай олысыннан (Урта Азиядән) яудан кайтканда, аны Җаек буендагы Сарайчык каласында бер төркем аксөякләр—әмирләр, бәкләр, мирзалар каршы ала. Алар Үзбәк хан васыяте буенча тиздән тәхеткә чыгачак Тинибәккә хөрмәт күрсәткән булып кыланалар, анын кулларын үбәләр һәм... шул вакытта хәнҗәр белән чәнчеп үтерәләр. «Олылаулары» шулай тәгәлләнә. Аннан сон, Сарай шәһәренә әйләнеп кайтып, булган эшне Җанибәк ханга җиткерәләр.

Исән калган төпчек углан Хызырбәкнен дә язмышы фаҗигале тәмамлана. Әлбәттә, энекәше исән чакта Җанибәк үзенен тыныч күнел белән тәхеттә утыра алмаячагын яхшы белә. Шуңа күрә аны юк итү юлларын эзли. Бәйләнергә сәбәп эзли торгач, Хызырбәкнен дә ниндидер гаебе табыла, бераздан ул да юк ителә.

Шулай итеп, мәшһүр Үзбәк ханның вафаты ике улының бер-бер артлы үтерелеп ташлавына сәбәп була. Алтын тәхеттә Җанибәк хан утырып кала. Кан коеп тартып алынган тәхет аңа бәхет китерерме? Иң мөһиме—Дәшти Кыпчак калаларына, авылларына, аларны урап алган киң далаларга тынычлык бирерме?

Ә Тыйтгали хатын? Ул нинди вөҗдан белән яшәде икән? Аны бик зирәк хатын булган диләр, югыйсә. Тарихта ул шулай тасвирлана, дәүләт эшләрендә бик маһир булуы әйтелә. Әмма күнелдә бер шик туа: тәхет варислары булган өчен үтерелгән Тинибәк белән Хызырбәк угланнар Тыйтгали хатынның үз балалары булган микән? Моңа ышанасы килми.

Билгеле булганча, Үзбәк ханның Тыйтгалидән кала тагын өч хатыны булган—Көпек, Бәйлүн, Әрдуҗа. Бәлки, әлеге көрәш шушы хатыннардан туган өч угылның берсен тәхеткә чыгару өчен баргандыр? Әлбәттә, инде бу көрәштә дәүләт эшләрендә иң оста, иң йогынтылы һәм тәҗрибәле, астыртын эш йөртә белүче Тыйтгали хатын җинеп чыккан һәм тәхеткә үз улы Җанибәкне утыртуга ирешкән.

Вакыйгаларнын асылында шушы нәрсә ятуы бик мөмкин хәл ич...

## Алтын Урдада чума афәте

Мәшһүр аталарның балалары бик сирәк очракта гына аталарына хас сәләтләргә ия була. Гадәттә, табигать андый аталарның балаларында «ял итә», диләр, ягъни андый аталарның балалары еш кына күзгә бәрелеп торган сәләтләре белән аерылып тормый икән. Күрәсен, Җанибәк хан да шундый очракка туры килә торгандыр. Анын ундурт ел дәвам иткән хакимияте бер дә дәүләтнең ярты дөньяга таралган данын-шөһрәтен үстерү, һичьюгы булган абруен саклау юнәлешендәге күркәм эш-гамәлләр белән тарих сәхифәләренә кереп калмаган.

Җанибәк хан тәхеткә утыру белән берничә җирдә татарларны кысып чыгару, аларга һөҗүм итү галәмәтләре күренә башлый. Үзбәк хан заманында башка да килмәслек хәл бит бу! Әйтик, 1343 елда (Үзбәк хан 1342 елда вафат) Азак (Азов) дингезе буендагы Тана каласында яшәүче Венеция сәүдәгәрләре ханның шушы шәһәрдәге калгаен (идарәчесен) үтереп ташлыйлар. Әлбәттә, Сарай хөкүмәте башбаштаклыкны бастыру, гаеплеләрне җәзага тарту өчен гаскәр җибәрә. Шәһәр алына, туйганчы талана. Венециялеләргә моннан соң калага керү, сәүдә итү тыела. Тик башбаштаклыклар моның белән генә бетми, Кәфә каласында да татарларга каршы кузгалыш, үтерешләр булып ала, Җанибәк хан бу очракта да җәнүизләрнен (Генуя сәүгәрләрен шулай атап йөрткәннәр) каладан чыгып китүен таләп итә, тегеләр баш тарткач, татар гаскәре каланы камап ала. Әмма кала капкалары бикләп куелганга, гаскәр керә алмый, аны камап алырга туры килә. Бәрелешләр сүлпән генә дәвам итә.

Бу хәлләр Кара дингез, Азак (Азов) буендагы калалардагы ныгытылган кальгаларда кәеф-сафа кылып, сәүдәдән зур табыш алып яшәгән Италия сәүдәгәрләренең көйгә салынган тормышын боза, аларның дингез сәүдәсеннән килгән табышлары кими. Өстенлекне саклап калу өчен алар берләшәләр, Рим папасы Клемент VI да аларга ярдәмгә килә. Ул татарларга каршы тәре явы оештырырга чакыра. Әмма моның әллә ни нәтиҗәсе булмый, чөнки татар гаскәре чит ил килмешәкләрен кысканнан-кыса.

Берничә елга сузылган тарткалашудан соң, Венециянең сенаты үз илчеләрен Җанибәк хан хозурына җибәрергә мәҗбүр була. 1347 елда Сарайдан ерак тормаган, ханнар резеденциясе саналган Гөлстан каласында солых төзелә. Үзбәк хан заманындагы тәртипләр торгызыла, ике як та бер-берсенең тауарларына 5 проценттан артык салым салмаска килешәләр.

Үзбәк ханнан соң дилбегә бушый төшүен сизеп алган көнбатыш күршеләр—Литва белән Польша да татар дәүләтенең чикләрендә башбаштаклыклар кыла башлыйлар. Польша короле Казимир элек Алтын Урда җирләренә кергән Галиция белән Волынны үзенә тартып ала. Шулай ук Литва кенәзе Ольгерд та көньяк-көнбатыш чикләрдәге берничә каланы кулга төшерә.

Билгеле, Җанибәк ханның мондый югалтулары игътибардан читтә калмый. Дәүләтнең көнчыгышында урнашкан Күк Урдада, мәсәлән, атасы Эрзен хан вафат булгач тәхеткә чыккан Мөбәрәк-Хуҗа дигән идарәче, Сарайдан аерылып мөстәкыйль яшәү өчен көрәш башлап җибәрә, ягъни үзәк хөкүмәткә буйсынмыйча идарә итмәкче була. Әмма чыганакларда «болгак» (болганыш) дип бәяләнгән бу эш барып чыкмый. Ул бары ярты ел тирәсе генә ирекле-мөстәкыйль яшәп кала, аннан тәхетеннән төшерелә һәм берничә ел кыргыз җирләрендә, Алтай тауларында каңгырап йөри дә юкка чыга. Тәхеткә Җанибәк хан әмере белән аның энекәше Чимтай углан утыртыла.

Шулай Җанибәк хан тәхеткә чыкканнан соң илнең төрле тарафларында төрле кузгалышлар, бәрелешләр, чик бозулар, җирләрне тартып алулар күренә башлый, ягъни Алтын Урда дәүләтендәге элекке тотрыклылык ара-тирә бозылгалап ала. Тик бәла ялгызы гына йөрми дигәндәй, 1346 елда татар дәүләте өстенә афәт килә—анда чума авыруы тарала. Бу коточкыч эпидемия, Кытайдан чыгып, анда 12 миллион кешене алып китеп, Ефәк юллары буенча Иделгә дә килеп җитә. Ул Хәзәр дингезе (Каспий), Дон елгасы, Кара дингез буйларында таралып, аннан Италия сәүдәгәрләренең кораблары белән Италиянең үзенә, Грециягә, Сириягә, Мисырга, Франциягә, Германиягә, Англиягә, хәтта 1349 елда Скандинавия илләренә кадәр барып җитә. Аннан Новгород белән Псков кебек урыс калаларында да тарала.

Алтын Урда дәүләте чума эпидемиясеннән коточкыч зыян күрә. Идел буе белән Кырымны кара үлем пәрдәсе каплап ала. Үргәнеч, Хаҗитархан, Сарай, Төньяк Кавказ, бөтен Идел буенда, урыс елъязмасы әйтмешли, «үлгәннәрне күмәргә исән-сау кеше калмый». Күрәсең, бу афәт Болгар, Казан тирәләрендә дә котырынгандыр, әмма мәгълүматлар сакланып калмаган.

Бу эпидемия Алтын Урда дәүләтенең иҗтимагый-сәяси тормышына, аның икътисадына, мәдәни көчләренә зур зыян сала. Аның тәэсире Җанибәк хан идарәсенең соңгы елларына кадәр үзен сиздереп килә. Әйткәнебезчә, Җанибәк хан, атасы Үзбәк ханның васыятен тупас рәвештә бозып, агасы Тинибәктән тәхетне тартып ала һәм анда ундүрт ел идарә итә.

## Фетнәче әмир

*«Әгәр сиңа хөкемдар булырга вакыт җитсә, атаңа хөкемдарлыкны тапшырырга вакыт килде».*

(Урыс елъязмасыннан.)

Алтын Урдада чума авыруы котырынган чакта ханның абруен күтәрә торган яулар оештыру турында хыялланырга да мөмкин булмый. Шулай да Җанибәк хан идарәсенең соңгы елларында тормыш бераз эзгә төшә башлаган булса кирәк. 1357 елда Җанибәк ханның, 300 мең гаскәр туплап,

Әзәрбайжанны яуларга баруы шул хакта сөйли кебек. Яуның тышкы сәбәбе бер вакыйга белән бәйле. (Берәр ил, әгәр дә күршесенә һөҗүм итәргә жыенса, һәрвакыт сылтау-сәбәп таба бит ул.) Эш шунда ки, Әзәрбайжанда 1335 елда Абу-Сәет хан үлгәннән соң, байтак еллар аның тәхете өчен көрәшләр бара. Шул көрәшләрдә Мәлик-Әшраф исемле кансыз бер адәм жинеп чыга һәм золымзолмәт белән халыкны бик жәберли башлый. Бу хәлгә түземе төкәнгән халык Жанибәк хан янына, явыз идарәчедән яклауны сорап, шикаять-зар белән бер атаклы шәхесне—Мөхетдин әл-Бәрдагыйны жибәрә. Шәех Сарай каласына килә, халык зарын ханга төкми-чәчми сөйләп бирә һәм аның шушы үтенече Әзәрбайжанга яу белән баруының тышкы сәбәбе була. Эчке сәбәбе, гадәттәгечә, күрше дәүләтне үзенә буйсындыру, аның байлыгына хужа булудан гыйбарәт.

Яу бик уңышлы башлана, татар гаскәре Тимер Капу (Тимер Капка, Дербент каласын төркиләр шулай дип йөрткән) белән Ширванны ала, ил эченә үтеп керә. Аксөякләр рәхимсез хаким Мәлик-Әшрафка ярдәм итмиләр, киресенчә, Алтын Урда явы ярдәме белән аннан тизрәк котылу ягын карыйлар. Бу шартларда Мәлик-Әшраф Жанибәк ханга каршы сугышыр өчен зур гаскәр туплый алмый һәм беренче бәрелештә үк тар-мар ителә, үзе әсирлеккә төшә. Ә бераздан, халык үтенеченә колак салып, Жанибәк хан аны үлем жәзасына хөкем итә.

Яулап алынган илдә идарә итү өчен Жанибәк ханның улы Бирдебәк углан билгеләнә. Шуның белән яулар тәмамлана. Алтын Урда гаскәре бик күп малмөлкәт белән кире Идел буена әйләнеп кайта. Яудан соң Жанибәк ханның да ил-көн арасында абруе үсеп китә. Әмма уңышлы яу тантаналары узып, бераз тынычланып калдык дигәндә генә, Жанибәк ханның кәефе начарая башлый, аннан ул бөтенләй урынга ята.

Табигый, ханның авырып китүе турындагы хәбәр тиз арада Ширван каласында калдырылган Бирдебәк угланга да килеп житә. Ханның атаклы әмире Туглы бәй, Бирдебәк угланга яшерен хат жибәреп, ана тиз арада Сарайга кайтырга, иң мөһиме—кеше-фәләнгә белдермичә яшерен генә кайтып төшәргә куша. Атасы Жанибәк хан белән ул-бу була калса, аны тәхеткә утыртырга вәгъдә итә. Укучы: «Ни өчен Бирдебәк углан яшерен рәвештә кайтып төшәргә тиеш булган?»— дигән сорау бирергә мөмкин. Эш шунда ки, Әзәрбайжан тәхетенә утыртып калдырылган Бирдебәк угланның атасының рөхсәтеннән башка тәхетне ташлап, Сарайга кайтырга хакы булмаган. Тәхетне ташлап китү—хан сүзеннән чыгу, зур жинаять саналган. Шуңа күрә Бирдебәк углан бу эшне яшертен генә эшләргә тиеш булган.

Әлбәттә, әмир Туглы бәйдән шундый өметләндергеч хат килеп төшү Бирдебәк угланның хыялларын үстереп жибәрә, ул идарәне әмир Сарай-Тимергә тапшыра да Тимер Капу аша Сарайга юнәлә. Күпмедер вакыттан соң, ул төн карасында юлдашы белән башкалага кайтып төшә, әмир Туглы бәй өендә урнаша.

Әмма иртәгесен көтелмәгән хәл була. Саулыгы көннән-көн начарая барып, менә үлә, менә үлә дип, якыннарын кайгыга салып яткан Жанибәк хан ул иртәне үзен яхшы хис итә, хәтта торып утыра, дәүләт эшләре белән кызыксына башлый. Диван утырышында (хәзерге Министрлар Кабинеты кебегрәк бер орган) катнашырга теләк белдерә. Шул вакыт сарай әһелләреннән берәү Бирдебәк угланның башкалага кайтып төшүен белеп ала һәм моны Жанибәк ханга житкерә. Хәбәр ханны зур борчуга сала, аның күңелендә шик уяна. Ул янына хатыны Тугай-Туглыны чакырып ала да хәбәрне ана да чишә, шиген белдерә, ачыкларга куша.

Ә Тугай-Туглы хатын улы Бирдебәкнең башкалага кайтып төшүен белеп торса да, ханга хәбәрнең имеш-мимеш кенә булуын, дөрес түгеллеген исбатларга тырыша. Жанибәк хан исә мәсьәләне тәмам ачыклап бетерү өчен үзенә әмир Туглы бәйне чакырта, аның белән серне уртаклаша (әгәр дә кемгә чишүен белгән булса!). Шулай итеп, фетнәчеләр жинаять өстендә тотыла язып калалар, аларга зур куркыныч яный.

Мәсьәләне ачыклап бетерү сылтавы белән әмир Туглы бәй хан янынннан чыгып китә. Күп тә үтми бернича фетнәче-тарафдары белән кире хан янына килеп керә дә аны чәнчеп үтерә. Бу хәл 1357 елның 22 маенда була.

Шулай итеп, Жанибәк ханның якын киңәшчесе саналган әмир Туглы

бәйнең фетнә оештыруы нәтиҗәсендә тәхеткә аның улы Бирдебәк углан чыга. Тарих кабатлана, вакыйгалар агышы, бумеранг кебек әйләнеп кайтып, Җанибәк ханның үзенә китереп суга. Ул да бит, туганнарын үтереп, тәхет иясе булган иде. Бу очракта язмыш ана үзе кылганны кайтарып кына бирә. Кешегә кое казыма, үзең төшәрсең, ди татар мәкале. Ата васыятен бозып тәхеткә чыгудан башланган гөнаһлы эшләр дәүләт тарихында әле күп фаҗигаларга китерәчәк.

## Рәхимсез хан

Тәхеткә чыкканнан соң, Бирдебәк хан беренче көннән үк хакимиятен саклау чаралары күрә башлый. Бу эшне дә ул шул ук Туглы бәйгә таянып оештыра. Әле атасы Җанибәк хан үтерелеп, келәмдә кан да кибәргә өлгерми, ул үз хозурына сарай әһелләрен, диван әгъзаларын чакыртып ала да, аны танымаган, буйсынырга теләмәгәннәрен үтерергә боера. Аннан соң әмир Туглы бәйне чакырып ала да: «Син Мөксан карачыны үтергән кебек, мин дә үз ыруымнан кайберәүләрне теге дөньяга озатырга җыенам»,—ди. Әлбәттә, әмир Туглы бәй моны хуплый. Шулай итеп хан хозурына аның якын туганнарын чакырып алалар. Һәм барысын берьюлы үтереп ташлыйлар. Ир затларыннан булган унике кеше юк ителә. Дәүәнисе Тыйгали (Үзбәк хан хатыны) бер сигез айлык нарасыен кулына тотып алып килә дә ханнан баланы ярлыкавын, исән калдыруын үтенә. Бирдебәк хан хәтта аны да кызганмый—баланы карчыкның кулыннан тартып алып, идәнгә бәрә. Шулай берәм-берәм дә, төркемләп тә яңа ханның тәхеткә утырырга хакы булган туганнары үтерелеп бетерелә. Әлбәттә, корбаннар Үзбәк хан нәселе белән генә чикләнмәгәндер.

Әлбәттә инде, бу вакыйгаларда катнашкан, куштанлык күрсәткән әмирләр, бәкләр ханның якын кешеләренә әверелә. Әйтик, монархы Алтын Урда дәүләтендә дүрт кенә олыс әмире булса, Бирдебәк хан тәхеткә утыргач, аларның саны алтыга җитә. Бу исә дәүләттә территориаль бүленеш ягыннан ике олыс арткан дигән сүз. Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев күрсәткәнчә, әмирләрдән Маглы бәй, мәсәлән, үзенең элеккеге бәкләрбәк (бәкләр бәге) дәрәҗәсен саклап калган, шулай ук Хисаметдин Мәхмүт тә элеккечә вәзир урынын саклаган. Әмма күп тә үтми ханны тәхеткә чыгаруда зур тырышлык күрсәткән Туглы бәй хөкүмәттә иң йогынтылы кешегә әверелә.

Гаугалы йорттан бәрәкәт китәр дигәндәй, үтерешләр белән шөгыльләнгән ханның ил белән идарә итәргә әллә ни вакыты калмаган булса кирәк. Сарайда барган хәлләрне ишетеп һәм үзәк хөкүмәтнең игътибары бөтенләй башка нәрсәләрдә икәнне күреп, Әзәрбайҗанда калдырылган гаскәр дә чит җирдә ятуга караганда, Идел-Йортка әйләнеп кайтуны кулайрак күргән булса кирәк. Андагы җирле әмирләр, үзара сүз берләшеп, татар гаскәренә каршы көрәш башлау белән, шуны сылтау итеп, гаскәр ике айдан Идел буена кайтып төшә. Шулай яулап алынган Әзәрбайҗан кулдан ычкына.

Дилбегәнең бушый төшүен сизеп, Кырымда кабат Венеция сәүдәгәрләре күтәрелә, алар элекке хокукларын дауларга керешә. Тарткалашу бер елга сузыла һәм 1358 елда Сарай белән алар арасында яңа килешү төзелә. Бу килешү буенча аларның вәкаләтләре арта, Бирдебәк хан файдасына җыела торган тауар салымнары 5 проценттан 3 процентка калдырыла.

Урыс руханилары да тик ятмый, алар да вәзгыятьтән файдаланып калырга тырыша. Йөри торгач, үз дигәннәренә ирешәләр, ясак түләүдән азат ителәләр, урыс чиркәвенә хөкем эшләрен карауда мөстәкыйльлек бирелә. Бер сүз белән әйткәндә, Бирдебәк хан көннәрендә Алтын Урда дәүләте акрынлап элекке данын-шөһрәтен, күп казанышларын кулдан ычкындыра башлый. Күрәсең, атасын үтереп тәхеткә чыккан бу ханның бар кайгысы туган-тумачасын кыру, үз хакимиятен саклап калырга тырышу булгандыр. Әмма рәхимсезлек, кансызлык юлы каршылыклар китереп чыгара, дошманнарын арттыра. Хакимиятендә шушы юлны сайлаган Бирдебәк хан барыбер тәхетен саклап кала алмый. Чираттагы фетнә корбанына әверелә һәм 1359 елда үзе дә үтерелеп ташлана. Бары ике ел гына тәхеттә утырып

кала. Ана гаепсезгә кыелган җаннарның каргышы төшкәндер, күрәсең.

Алтын Урда тарихында Бирдебәк ханның үтерелүе зур буа ерылып киткән сыманрак вакыйга була. Шуннан соң дәүләттә егерме елга сузылган ватандашлар сугышы башланып китә. Шушы егерме ел эчендә тәхеттә егерме биш хан алмашына, илдә тәртип бетә, татар дәүләте таркалу куркынычы алдында торып кала.

## Болгак

Әйткәнебезчә, Җанибәк хан улы Бирдебәк хан 1359 елда үтерелгәннән соң, Алтын Урда дәүләте тарихында зур ызгышлар, тәхет бүлешүләр дәвере башланып китә. Әлеге низагларны читтәнрәк күзәтеп торган урыс елъязмачылары, бу тамашага гаҗәпләнеп, аны «великая замятня», ягъни «бөек болгак» дип атаганнар, гәрчә урыс тарихында да андый низаглар аз булмаган.

Бу дәвер нәкъ 20 ел дәвам итә һәм бары тик 1379 елда Сарай тәхетенә Туктамыш хан чыгу белән генә дәүләттә күпмедер тынычлык урнаша. Бераз артка чигенеп булса да, без әлеге аяныч хәлләрнең башланып киткән чорына—Бирдебәк хан үтерелгән көннәргә әйләнеп кайтыйк.

Әлбәттә, Бирдебәк ханнан бушап калган бөек тәхет күпләрне кызыктыра һәм анда омтылучылар арасында ыгы-зыгы, үзара үтерешләр башланып китә. Беренчеләрдән булып, Сарай тәхетенә чыккан Көлнә хан анда бары тик 6 ай да 5 көн генә утырып тора. Аның урынына Нәүрүз хан чыга. Күп тә үтми Сарай әмирләре Нәүрүз хан белән аның улы Тимерне, кызган шәптән Үзбәк ханның тол калган хатыны Тайдулла (Тыйтгали) белән өлкән әмир Маглы бәйне, шуна өстәп тагын берничә олы түрәне дә теге дөньяга озаталар. Тәхетне Хозыр ханга тапшыралар.

Нәүрүз ханның болгатай-фетнәчеләр тарафыннан төшерелүен аңлавы кыен түгел. Шул ук 1359 елда Хозыр хан да улы Тимерхуҗа тырышлыгы белән тәхеттән коры кала һәм якты дөньядан китеп бара. Тик Тимерхуҗа хан да, атасыннан котылып, тәхеттә озак утырып тора алмый—бу вакыйгаларга мәрхүм Бирдебәк хан кияве Мамай морза килеп катнаша. Хан кияве-гурген аталып йөргәнгә, аның дус-ишe дә, ышаныр кешеләре дә күп, абруе да көчле булган, күрәсең. Хан кияве дәрәҗәле, асыл затлардан саналган. Шуңа күрә ул да болганчык заманда үз бәхетен сынап карамакчы була. Дөрес, нәселе Чыңгыз хан ыруыннан килмәгәнгә, ул тәхеткә чыга алмый, ләкин көчен-куәтен, таяныр кешеләрен барында ни өчен тәхеткә үзенә кулай, сүзеннән чыкмастай берәр чыңгызыйны утыртмаска.

Һәм Мамай мирза шулай эшли дә. Тарафдарларын оештырып, ул Сарай тәхетеннән Тимерхуҗа ханны алып ташлый, аның урынына «үз» ханы Габдулланы куя. Шулай итеп, Бирдебәк хан үлгәннән соң үткән бер-ике ел эчендә генә дә Сарай тәхетендә ничә хан алышынырга өлгерә. Тарихчыларның язуынча, Мамай мирза Габдулла ханны Сарай тәхетенә 1360 елда утырткан.

Бәлки шушының нәтиҗәсендә тәхет тирәсендәге ыгы-зыгы, талаш-үтерешләр тукталып калгандыр?! Юк шул, алай түгел, Габдулла ханга да озак хөкем сөрергә туры килми, аның да тәхеткә чыгарга теләүче көндәшләре тиз табыла. Сарай әмирләре Мамай мирза белән Габдулла ханга каршы да фетнә оештыралар. Һәм күп тә үтми аларны да башкалардан куып җибәрәләр. (Ярый әле башлары исән кала! Юкса, урыслар 2 елдан соң булган Куликово сугышында кемне җиндек дип мактанырлар иде икән.)

Әлбәттә инде, әмирләр бу юлы да тәхеткә үзләренә кулайрак Котлык Тимер атлы берәүне чыгаралар. Тик Котлык Тимер хан тәхетен дә җылытып өлгерә алмый кала—аны явызлыгы белән аты чыккан Килдебәк хан бәреп төшерә. Аның турында замандашлары: «Бу адәм әмирләрнең нәселен корытуны үзенең төп максаты итеп куйды. Аерым-аерым үз янына чакыртып алып, аларны бер-берсенә каршы котырта һәм шулай үзара үтертә иде»,—дип язып калдырганнар.

Үзенең үтә дә рәхимсез, кансыз сәясәте аркасында Килдебәк хан тәхетен бераз ныгытуга ирешә—Сарай олысын кинәйтә, Азак шәһәрен ала, Идел буендагы мордва җирләрен дә үз биләмәләренә куша. Тик Алтын Урдада кузгалып киткән гауга көчәйгәннән-көчәя генә бара. Бераздан Килдебәк ханның да башына җиталәр.

Ул үзенең өлкән әмире тарафыннан үтерелә. Үзара килешенеп тәхеткә яңа кешене куялар, ләкин анысы да өч көннән гүр иясе була.

Хәер, шушының белән житеп торыр... Сарайдагы низагларны жентекләп сөйли башласак, бик озынга китәр, вакытны да күп алыр иде. Иң яхшысы, без Алтын Урда дәүләтендә башланган бу башбаштаклыкның нинди үзгәрешләр китереп чыгаруын барлап чыгыйк.

Башсыз илдә бәрәкәт булмас, ди халык. Татарның бу мәкале Алтын Урданың шушы дәверендә барлыкка килгән диярсең. Чыннан да, Сарайдагы аяныч хәлләрне күреп, гел алышынып торган ханнарның уйлары дәүләт эшләрендә түгел икәнне аңлый башлаган гайрәтле олыс бәкләре, әмирләр, мирзалар, угланнар башкала ханнары кул астыннан чыгу, мөстәкыйль-үзбашка яшәү, олысында тулысынча үзең хужа булу турында хыяллана башлыйлар. Кайберләре хыялланып кына калмый—аерылып ук чыга, ирекле олыс-вилаять рәвешендә яшәргә тотына.

Әйдәгез, Алтын Урда картасына күз салыйк та аны барлап чыгыйк.

Себер кинлекләрендә бу вакытта хәрәкәт сизелми. Дәүләтнең мәркәзе Сарайдан бик ерак булганга, алар сәяси тормышта катнаша алмыйлар. Ә менә көньяктагы Күк Урдада исә тормыш кайнап тора. Билгеле булганча, ул заманда Арал диңгезе белән Жидесу арасында урнашкан киңлекләр Күк Урда дип атап йөртелгән. Бу төбәк әле Чимтай хан заманында ук Алтын Урдадан аерылып чыга. Дөресрәге, Чимтай хан үзенең соңгы елларында инде Сарай хакимнәре белән хисаплашудан туктый. Ә тәхеткә аның улы Ырыс хан чыккач (1369), Күк Урда бөтенләй ирекле дәүләт рәвешендә яши башлый.

Арал диңгезенең көньягында, аның ярларына килеп сыенырга жыенгандай, Хәрәзем олысы урнашкан. Монгол яулары чорында бу жирләр бик зур зыян күрә, калалар, кышлаклар жимерелә, көлгә әйләнә, төбәкнең сугару системасы юк ителә. Су булмагач, халкы да төрле тарафка тарала. Тик без сүз алып барган XIV йөз урталарында бу төбәк кабат жанлана, зур янарыш кичерә, халкы да арта. Ерак Кытай чикләреннән сузылган Бөек ефәк юлы Хәрәзем олысының үзәге Үргәнеч каласы аша уза. Һәм бу төбәк тормышында гаять зур роль уйный.

XIY йөзнең 30 нчы елларында бу жирләр аша узган бөек ислам сәяхәтчесе Ибне Батутта Хәрәзем олысы турында түбәндәге сүзләрне язып калдырган: «Бу иң зур, тоткан урыны буенча әһәмиятле һәм гажәеп матур төркиләр шәһәре. Аның атаклы базарлары гөрләп тора, урамнары киң, биналарын санап, гүзәл урыннары карап бетерерлек түгел. Ул халыкның күплегеннән, тормышның кайнап торуыннан диңгез кебек тирбәлә һәм дулкынлана».

Без сүз алып барган XIY йөзнең 60 нчы елларында да Хәрәзем әле шушы хәлдә булган. Аның Алтын Урдадан аерылып чыгуы Сарайда тәхет даулары башланып киткән чорга туры килә. Хәрәземдә коңгырат ыруы вәкилләре хакимияте урнаша. Тарихчы Шәрәфетдин Йезди сүзләренә караганда, Хәрәземдә тәхеткә чыккан Суфилар династиясе Алтын Урда әмире Нангудайның улы Ак Суфидан башланып киткән. Әмир Нангудай үзе мәшһүр Үзбәк ханның кияве булган. Аның улы Ак Суфи да хан кызына өйләнә, шулай итеп хан нәселе белән туганлаша, зур дәрәжәгә ирешә. Тарихчы М. Г. Сәфәргалиев фикеренчә, хан кияве Ак Суфи, Алтын Урдада болганышлар башланудан файдаланып, Хәрәземны Сарай ханнары кулыннан тартып ала, үз хакимиятен урнаштыра. Тик чыңгызый булмавы аркасында, үзенә хан титулын алмый, акча суктырганда да тәңкәләргә үз исемен куйдырмый, аның урынына: «Лә иллаһә иллаллаһ Мөхәммәдәр рәсулуллаһ» дип кенә яздыра.

Бераз ныгып алгач, Хәрәзем хакимнәре күршеләр хисабына олысны киңәйтә дә башлыйлар. Шул рәвешле Кят, Хива калалары яулап алына. Бу хәл Сәмәрканд әмире Аксак Тимерне нык борчый, ул Хәрәземгә берничә тапкыр яу да оештырып карый, тик уңышка ирешә алмый—Суфилар үз биләмәләрен дошманнан нык саклыйлар.

Хәрәземнән Бөек ефәк юлы буенча төньяк-көнбатышка таба сәфәргә чыгып китсәк, кәрван юлы безне Жаек даласына, Каспийның төньягында урнашкан үзе жылы, яшәү өчен унайлы кинлекләргә, андагы Сарайчык, Хажитархан (Әстерхан) кебек калаларга китерәчәк.

Сарайда башланып киткән «бөек болгану» бу төбәкне дә үз чоңгылына

бөтереп ала, андагы олы һәм кече идарәчеләр ирексездән сәяси тормышка кушылып китәргә мәҗбүр булалар. Мәсәлән, Бирдебәк ханның яу әмире Хаҗи Чиркәс, хан үтерелгәннән соң, үз җаенны үзен карамасан, кеше сине кайгыртмас, дигән мәкальгә тугры калып булса кирәк, Хаҗитархан каласын яулап ала да аны Алтын Урдадан аера, кәрван сәүдәсе белән баеган бу калада мөстәкыйль хаким сыйфатында яши башлый. Ә соңрак, Идел тамагындагы Хаҗитархан белән генә чикләнмичә, ул биләмәләрен шактый киңәйтүгә ирешә.

Бу вакыт Җаекның түбән агымындагы уңайлы җирләр дә Сарай ханнары кулыннан китә. Анда урнашкан Сарайчык каласына Бирдебәк ханның яу әмире Али бәк исемле берәү хуҗа була. Күп заманнар кәрван сәүдәсе үзәгендә торган бу кала Көнчыгыш белән Көнбатышны тоташтырган. Аннан Алтын Урда башкаласы Сарайга туры юл сузылган (300 чакрым). Ул Бөек ефәк юлы аша Хәрәзем олысы, Үргәнеч каласы белән тыгыз элемтәдә торган.

Коры далалар, ярым чүлләр аша узган юлда мосафирларны 25-30 чакрым саен ял итү өчен уңайлы кәрван-сарайлар, салкын сулы тирән коелар кәткән. Бу юл—Көнчыгыш белән Көнбатышны тоташтыручы төп юл саналган. Сарайчык белән Үргәнеч арасында бүгенге көннәрдә дә 15 кәрван-сарай калдыкларын күрергә мөмкин икән.

Үргәнечтән чыккан кәрван Җаек елгасы ярында утырган Сарайчыкка килеп җиткәннән соң ике тарафка сузылган юлның берсен сайларга тиеш булган. Төньяк-көнбатышка таба борылганы кәрваннарны Сарай шәһәренә китергән, ә көньяк-көнбатыш тарафка киткәне Хаҗитарханга алып барган. Аннан инде ышанычлы, имин яшел дала аша Төньяк Кавказдагы Мажар каласына барып җитү кыен булмаган. Мажар—Алтын Урда дәүләтенең әһәмиятле шәһәрләреннән саналган. Ул да нигездә транзит сәүдәсе хисабына яшәгән. Бу каладан Дон елгасы тамагында урнашкан Азакка туры юл сузылган. Диңгез ярында торганга XIY йөздә Азак каласы да Алтын Урда икътисадында зур роль уйный, Генуя сәүдәгәрләре (җәнүизләр) аркасында биредә диңгез сәүдәсе бик нык алга китә. Үзбәк хан заманында бу далалар аша узган Ибне Батутта юлларның имин булуын, сәяхәтчеләр, сәүдә әһелләре туктап ял итсен өчен анда суфилар, дәрвишләр яши торган такияләрнең еш очравы турында яза.

Азактан кояш батышына таба чыгып киткән мосафирны юл Кара диңгез буе далалары аша Кырымга алып килгән. Кырым ул вакытта Алтын Урданың бер олысы. Бер-берсеннән бик нык аерылып торган ике географик зонага бүленгәнгә, аның дала өлешендә күчмәләр яшәгән, ә диңгезгә якын таулы көньяк районнарда авыллар, борынгы калалар гөрләгән, гаваньнарда йөзләгән кораблар чайкалган. Диңгез буена тезелешкән Кәфә, Феодоро, Судак, Чембало кебек калаларда җәнүизләрнең диңгез сәүдәсе чәчәк аткан. Алар Кырым ярлары белән генә чикләнмичә, бераздан Азак диңгезе бассейнын да үз кулларына алалар, киң сәүдә эше җәелдереп җибәрәләр.

Әлбәттә, Сарай ханнарының үзара кырылыш-әкәмәт оештырып ятуларыннан җәнүизләр дә файдаланып калырга тырыша, алар бу төбәктә үз йогынтыларын тагын да киңрәк җәелдерү ягыннан яңа адымнар ясыйлар. Мәсәлән, Бирдебәк хан исән чакта Азак каласының бер генә кварталы Венеция сәүдәгәрләре кулында булса, 1367 елда бу кала инде тулысынча алар хөкемендә яши. Шул ук елларда җәнүизләр Кырым ярындагы Судак (Солдея) гаванын һәм 18 авылны буйсындыралар.

Сарайда барган тәхет даулары, дәүләттә тәртип бетү, ил кайгысы белән яшәүче шәхеснең тәхеттә булмавы шундый аяныч хәлләр башлануга китерә. Дәүләтнең өлкәләре арасында элемтәләрнең зәгыйфьләнүе, гомумән Сарайда яшәүнең хәтәр бер нәрсәгә әверелүе бик күп мирзаларны, бәкләрне, әмирләрне тынычрак җирләргә китеп торырга мәҗбүр итә. Һәм арадан иң тәвәккәл һәм гаярьләре үз җаен үзе карарга керешә. 1361 елда Алтын Урда бәге Булат Тимернең Болгар каласын басып алуы, шушы гаять зур өлкәдә үз хакимиятен урнаштыруы, Сарайга баш бирмичә яши башлавы нәкъ шул хакта сөйлидер, күрәсең.

Тарихчылар күрсәтүенчә, Алтын Урда әмире Нугай улы Булат Тимер ханнар нәселеннән булмаган, шуңа күрә үз тәңкәләрен мәрхүм Җанибәк хан исеменнән суктырган. Хәер, Булат Тимер Болгар олысында ныгып тамыр җибәрә алмый кала. Килеп урнашуының бишенче елында (1366) урыс елга юлбасарлары (урыс-улаклар,

ягъни ушкуйниклар) Болгар шәһәрен бик нык талап китәләр. 1370 елда урыс кенәзе Дмитрий Суздальский үзенең энесен һәм улын Болгарга яу белән җибәрә. Ул чакта Болгар каласында Булат Тимер түгел, Хәсән (Асан) исемле әмир хөкем сөргән була. Димәк, Булат Тимер 1366 елгы урыс-улак һөҗүме вакытында әллә үлгән, әллә качып киткән дип әйтергә мөмкин. Тагын дүрт елдан (1374) Нижний Новгород урыслары, 90 көймәгә утырып, кабат Зөя, Кама һәм Идел буендагы калаларны талап йөриләр. Билгеле инде, Болгар шәһәрен дә әйләнеп узмыйлар.

Гомумән, Болгарга каршы экспансия моның белән генә чикләнми. 1376 елда урысның великий кенәзе Дмитрий Иванович һәм инде телгә алынган Дмитрий Суздальскийлар Болгар олысына, Казанга зур яу белән киләләр, каты сугыш була. Тик болгарларның ул кадәр зур гаскәргә каршы торырга көчләре җитми. Ахыр чиктә 5000 сум акча түләргә мәҗбүр булалар.

Шушы болганчык чорда Иделнең уң ярындагы мордва җирләрендә дә мөстәкыйль бәк пәйда була. М. Г. Сәфәргалиев фикеренчә, аның исеме Сигез бәй булган. Эш шунда ки, Мамай мирза белән Габдулла хан 1361 елда Сарайдан куып җибәрелгәч, алар башта Азак каласын кулга төшерәләр. Билгеле, андагы җирле хаким Сигез бәйгә качып китәргә туры килә. Сигез бәй төньяк тарафка китеп югала һәм мордва җирләреннән аккан Пьяна елгасы буена килеп урнаша, шунда кальга төзи, аны урлар, тирән чокырлар белән әйләндереп ала. Тик ул тынгысыз заманда тынычрак урын эзләүче бер Сигез бәй генә булмый. Әмирләр, бәкләр, мирзалар, угланнар күп, ә Сарайдан аерып алып, мөстәкыйль олыс төзәрдәй төбәкләр санаулы гына. Шуңа күрә бәкләр, морзалар арасында бер-берсеннән майлы калҗаны тартып алырга омтылу күренешләре еш очрый.

Сигез бәйгә дә яна җирдә тыныч кына яшәргә ирек бирмиләр. Шул ук 1361 елда аның җирләрен Тагай бәк яулап ала, Сигез бәйне әллә куып җибәрәләр, әллә үтерәләр—билгесез. Тагай исә мордва-мукшы җирләрендәге Наручат каласында урнаша, тора-бара биләмәләрен шактый киңәйтә.

Тузар илдә җәнҗал бетмәс, ди халык. Бирдебәк хан үтерелгәннән соң (1359) башланып киткән шушы даулар, низаглар ике-өч ел эчендә дәүләтне таркалу куркынычы алдында калдыра. Бүгенге Мәскәү сәясәтчеләре теле белән әйтсәк, Алтын Урдада «суверенитетлар парады» башланып китә. Һәр өлкә, олыс, төбәк шушы башбаштаклыклар чорында иркенрәк яшәргә омтыла. Дәүләтнен төрле олыслары арасында элемтәләр йомшый, сәүдә эшләре сүлпәнәя, юл йөрүләр хәтәргә әйләнә. Житмәсә, нәкъ шушы вакыйгалар алдыннан гына Алтын Урданың күп өлкәләрендә, бигрәк тә Идел буенда чума авыруы тарала, аннан бик күп халык кырыла. Бу афәт Идел-Йортның икътисадына зур зыян китерә. Әмма татар дәүләтен хәлсезләндерүче мондый күренешләр ничек кенә өстенлек алырга тырышмасын, кыенлыкларны җиңәргә, тагын бер күтәрелеш кичереп, күрше мәмләкәтләргә үзенең көчен күрсәтергә Алтын Урданың әле гайрәте җитәрлек була. Бу күтәрелеш Туптамыш хан, Идегәй-морза исемнәренә бәйле һәм алар заманына туры килә.

## Ырыс хан кыйссасы

Ырыс ханның атасы Чимтай хан Күк Урдада хөкем сөргәндә, аның олысы (Күк Урда) Алтын Урдадан аерыла һәм мөстәкыйль рәвештә яши башлый. Атасы үлгәннән соң Ырыс хан үзе тәхеткә чыга. Бу хәл 1369 елда була.

Бу ханның исемен урыс тарихчылары үз хезмәтләрендә гел «Урус хан» дип язалар һәм заманыбыз укучылары еш кына: «Нигә бу ханны «Урыс-хан» дип атап йөрттеләр икән?»—дип гаҗәпсенеп уйлап куялар. Ханның исеме, алда күрсәтелгәнчә, Ырыс булган. Ырыс—борынгы төрки телдә «бәхет» дигәнне аңлаткан.

Замандашлары аның турында мондый сүзләр язып калдырганнар: «Ул холкы-фигыле белән гаять көйсез, ләкин бик гайрәтле хан иде. Атасының вафатыннан соң ул тәхеткә чыкты. Әле атасы Чимтай хан исән чакта ук, ул аны Ак Урда (Алтын Урда) олысын яулап алырга күп үгетләде. Тик Чимтай хан аның сүзенә колак салмады. Ә инде атасы үлеп, үзе тәхеткә чыккач, беренче корылтайда ук, хан үзенең яраннарына, түрәләргә һәм сарай әһелләренә ниятләрен ачып

салды. Барысы да аны хупладылар, ниятләрен тизрәк тормышка ашырырга өнди башладылар. Тәхеткә чыгу унаеннан ул берничә көн дәвамында зур туйлар, мәҗлесләр үткәрде, һәркемгә кыйммәтле бүләкләр өләште. Шуның соңында зур гаскәр белән Сарай тәхетен яуларга кузгалды».

Ул заман өчен «Сарай тәхетен яулау» һәрвакыт Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрен кулга төшерү, шулай бөек ханнар тәхетенә чыгуны аңлаткан. Җучи олысының берәр тарафында көчле хан мәйданга чыгып, дала халкын үз тирәсенә туплый һәм ныгый башлаган саен аның хыялы Идел буендагы Сарай шәһәренә төбәлгән. Ул бөтен көчен-тырышлыгын куеп, андагы төп тәхеткә ия булырга тырышкан. Чөнки Сарай тәхетенә чыгу—ханнар өчен иң зур дәрәҗә, дан-шөһрәт казану саналган.

Ырыс ханның да Күк Урда тәхетенә чыкканнан соң нәфесле күзләрен Идел буена төбәве, Сарай тәхетенә утырырга омтылуы ул заман өчен бик табигый күренеш. Бераз алга сикереп булса да әйтик—тырыша торгач, Ырыс хан, чыннан да, теләгенә ирешә, Сарай ханы була. Ләкин аның хыялы бераз вакыт узгач кына тормышка аша. Иң әүвәл ана атасыннан калган Күк Урдада тәмам ныгып житәргә, көч тупларга, тәхеткә өмет иткән көндәшләрен бастырырга туры килә.

Тарихчылар күрсәтүенчә, ул Сарай тәхетенә бары тик 1377 елда гына ия булган. Димәк, Идел буена килгәнче аның 7-8 ел гомере Күк Урдада узган. Ә бит тормыш кайнап торган далада 7-8 ел гомер аз вакыт түгел. Бу арада олыста нинди хәлләр-вакыйгалар булып узды икән? Тарихта бу хакта хәбәрләр калганмы?

Күк Урдада хөкем сөрә башлаган көннәрдә үк, Ырыс ханга үзенең каты куллы хаким булуын күрсәтергә җай чыга. Аның биләмәләренә яна гына кергән Мангышлакта бу вакытта Туйхуҗа исемле әмир хөкем сөргән. Бу зат Ырыс хан җыйган беренче корылтайга килүдән баш тарта. Ул заман кануннары буенча, бу эш яңа ханны танымау, аңа буйсынмауны аңлаткан. Ырыс хан исә баш бирмәскә маташкан Мангышлак хакиме Туйхуҗага каршы гаскәрен җибәрә дә сүзен сүз итмәгән өчен тегенең башын чаптыра.

Әлбәттә, монда гаҗәпләнерлек нәрсә юк, дала тормышы өчен гап-гади вакыйга бу. Ләкин шунысы игътибарга лаек—башы чабылган Туйхуҗа киләчәктә Алтын Урда тарихында зур урын алачак Туктамыш ханның атасы була. Хәер, бу хакта без әле Туктамыш хан заманына килеп җиткәч сөйләрбез. Әлегә исә Туктамыш яшь, шуңа күрә аңа җил-давыл тими кала.

Тәхеткә чыгуының беренче елларында Ырыс хан үз биләмәләрен киңәйтү буенча да кайбер омтылышлар ясап карый. Әйтик, аның Хаҗи Чиркәс кулындагы Хаҗитархан (Әстерхан) каласына яу белән баруы билгеле. Каланы бераз камап торганнан соң, Хаҗитархан әмире аны куып җибәрә. Тынгысыз хан шулай ук Сарай шәһәренә дә һөҗүм итеп карый. Бу юлы да уңышсызлыкка юлыга.

Җыйнап кына әйткәндә, Күк Урдада инде тәмам ныгып өлгергән Ырыс ханга дөнья һаман тар тоела, аның бөтен хыялы Җучи олысының иң гүзәл шәһәре Сарайны үзенеке итү, Чыңгыз балаларыннан калган тәхеткә күтәрелү була.

Әйе, Сарай тәхете бөектән бөек, тик бөек җирдә утырып торулары да җиңел түгел, ә инде егылып төшә-нитә калсаң, сөякләреңне дә җыеп ала алмаслар. Шуны белә микән Ырыс хан?!

Әмма кеше дигән зат берәр хыялга бирелсә, аны-моны уйлап тормастан, ахырынача бара. Ырыс хан да 1377 елда теләгенә ирешә—Сарай тәхетенә чыга. Шул көннән Иделдән көнчыгышка таба җәелгән бөтен Җучи олысы җирләре Ырыс хан кулына күчә. Хәер, ялгыз утрау сыман, хан биләмәләренә кермәгән бер төбәк шулай да калган икән, ул—Хәрәзем олысы. Анда бу вакытта Суфилар династиясе хөкем сөрә.

Ырыс хан бу мәшәкатьләрнең игелеген барыбер күрә алмый, ул Сарай тәхетендә бары бер ел гына утырып кала, ягъни 1378 елда үтерелә. Атасы Чимтай хан зирәк карт булган, күрәсең. Ул Сарай тәхетенә кызыкмый, улының үгетләүләренә колак салмыйча дөньядан тыныч кына үз үлеме белән китеп бара.

Аждаһа симерсә, күлгә сыймас, ди халык. Хак әйтә. Бу сүзләр Ырыс хан язмышына да туры килә шикелле.

## Туктамыш мәйданга чыга

«Идегәй» дастанында Туктамыш хан Идегәйнең атасы Котлыкыя бине:

Һай син татар, һай татар,
Мангыттан азган чал татар!—

дип мыскыллый. Бу сүзләр белән ул үзенең Чыңгыз хан нәселенең ерак варисы булуын, ә Котлыкыя бинең төркиләшкән мангыт ыруыннан («татардан») чыгуына төрттерә. Ә икенче бер җирдә:

Аргы атасы Чыңгыз хан,
Бирге атасы Туйхуҗа,
Аннан туган Туктамыш—
Ул Туктамыш мин булам,—

дип мактана.

Туктамышның атасы Туйхуҗаның Мангышлак олысында хөкем сөрүен Ырыс хан турында сөйләгәндә әйтеп үткән идек. Бу вакытта Алтын Урдада тәхет өчен бик зур ызгышлар, талашлар, сугышлар бара. Шул сәбәпле дәүләттә тәртип, канун тәмам бетә. Шуннан файдаланып, Ырыс хан Идел буен, ягъни Алтын Урданы да үз биләмәләренә кушарга, Сарай тәхетенә чыгарга омтыла. Тик моны тормышка ашыруда көчәеп киткән Сәмәркәнд әмире Аксак Тимер аңа гел киртәләр тудыра, төрлечә комачаулык итә. Шуның өстенә Мангышлакта хөкем сөрүче Туйхуҗа да Ырыс ханның сүзенә колак салмый, аңа ярдәм кулын сузмый. Юкса, алар Аксак Тимерне ике яктан китереп кыса алган булырлар иде.

Ахыр чиктә Ырыс хан барыбер Туйхуҗадан үч ала—аның башын кистерә. Аның улы Туктамыш яшьлеге аркасында гына исән кала. Әмма ул Ырыс хан кул астында яшәүнең үзе өчен нинди куркыныч икәнен күрә, бер-ике тапкыр хан урдасыннан качып китеп тә карый. Ләкин аны тотып алалар. Бу эшләре өчен дә Ырыс хан аны гафу итә. Шулай да Туктамыш Ырыс хан хозурында калмау ягын карый, ниһаять, Сәмәркандтагы Аксак Тимергә качып китә.

Сәмәркәнд әмире аңа зур хөрмәт күрсәтә, хәтта егетне бик якын итүен, яратуын белдереп, аны үзенең «улы» дип атый. Ул заманнарда берәр хаким кемне дә булса «улым» дип атаса, бу инде аны үз канаты астына алуын, ярдәменнән ташламаячагын аңлаткан.

Чыннан да, Аксак Тимер яшь Туктамышка зур ярдәмнәр күрсәтә. Күп тә үтми ул егеткә Сырдәрья буендагы Сәүран өлкәсен, андагы Отрар, Сыгнак кебек калаларны бүләк итә, егетне Сәүранда хан итеп күтәртә. (Төрки халыкларның бөек акыл иясе, суфи шагыйрь Әхмәт Ясәви нәкъ шушы төбәктә туган.)

Тарихчы Шәрәфетдин Йәзди язганча, Аксак Тимер кабул ителгән гадәт буенча Туктамыш белән аның якыннарына шул кадәр күп байлыклар, алтын-көмеш, асылташлар, халатлар, кием-салым, кыйммәтле бил каешлары, кораллар, тукымалар, атлар, дөяләр, чатырлар, күтәрмә-палаткалар, барабаннар, байрак-туглар, күп гаскәр, хезмәтчеләр һәм башка төрле дан-шөһрәт һәм хакимият кирәк-яраклары бүләк итә ки, аларны тел белән сөйләп, каләм белән язып бетерерлек түгел икән.

Кеше ярдәмендә хан булып күтәрелү бер хәл, ә менә шул урынга лаеклы булып калу башка нәрсә, һәм күп тә үтми тәхеткә күтәрелгән Туктамышка авыр сынаулар үтәргә туры килә.

Ул үзенә бирелгән Сәүран олысында озак утырып тора алмый. Туктамышның Сәүран хакиме итеп билгеләнүен ишетеп алган Ырыс хан аңа каршы гаскәр җибәрә. Табигый, яшь Туктамыш бу сугышта тар-мар ителә. Һәм химаячысы Аксак Тимер хозурына Сәмәркандка әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Җинелеп кайтуына карамастан, Аксак Тимер анардан йөз чөерми, киресенчә, яшь угланны юата, аңа тагын күп байлыклар, гаскәр, хезмәтчеләр бирә һәм кире Сәүран олысына озата.

Бу хәл Аксак Тимернең кан дошманы Ырыс ханның җен ачуларын чыгара. Ул өлкән улы Тактакыяны яу белән кабат Туктамыш өстенә җибәрә. Тарихчылар Тактакыя гаскәре Туктамышныкыннан 4 тапкырга ишлерәк булган, дип язалар.

Моны аңлап була. Ырыс ханда гаскәр, чыннан да, аз булмаган. Дошманы Аксак Тимер кулында уенчык рәвешендә йөргән Туктамышның башына житәр өчен ул көчне кызганып тормагандыр.

Билгеле, бу очракта да Туктамышка Сәуран олысыннан качып китәргә туры килә. Ул аз гына үлемнән кала. Качкан чакта Сырдәрья ярына житкәч, тиз генә киемнәрен салып ташлап, каршы ярга йөзеп чыгарга дип суга керә, шул вакыт куа килүчеләр аны күреп ала да җәядән атарга керешә. Укларның берсе аның инбашына килеп кадала, тик Туктамышның ярга кадәр йөзеп чыгарга көче житә. Ул яралы хәлдә камыш арасына кереп яшеренә. Бераздан аны Аксак Тимердә хезмәт иткән Идегәй Барлас углан[1] табып ала һәм коткарып кала. Бу хәл 1376 елда була.

Бу жинелүдән соң да Аксак Тимер Туктамышка кул селтәми, аны кадерләп үз янында асрый. Күрәсең, ул ханзадәне киләчәктәге эшләрендә файдалану өчен әзерләгәндер. Юкса, ничә тапкыр жинелгән кеше өчен ул чаклы байлыгын, гаскәрен әрәм итәр идемени?

Бераздан вакыйгалар кабат кызып китә. Ырыс хан Туктамышны куып жибәрү белән генә чикләнми, Аксак Тимергә илчеләрен озатканда шундый сүзләр тапшырырга куша:

—Туктамыш минем улгым Котлы Буганы үтерде. Ул хәзерге көндә синда килеп сыенды, тик син аны миңа бирергә тиешсең. Әгәр дә Туктамышны бирмәсәң, орыш урынын билгелә,—дип, Аксак Тимергә катгый таләп тә куя.

Моңа каршы Аксак Тимер:

—Әйе, хәзерге көндә Туктамыш миндә яши, тик мин аны сиңа бирмим. Орышырга дигәндә—мин һәрвакыт әзер,—дип жавап бирә.

Болар сугышка 1377 елның кышында бик гайрәтләнеп тотынсалар да, һаваларның кинәт бозылып китүе икесенен дә дәртен суыта. Кышын далада жепшек кар яву, аның артыннан кинәт суыклар башлану һәрвакыт зур фажигага китерә. Кышкы далада терлек-туар азыкны тибенү юлы белән таба, ягъни тояклары белән карны казып, туклыклы коры үлән ашый. Ә инде жепшек кар явып, кинәт суыклар китереп сукса, жир өсте боз белән каплана һәм... ач калган терлекләр меңәрләп, ун меңәрләп кырыла. Моны «жот» дип атыйлар, дала халкы өчен «жот килү» чума эпидемиясе белән бер. Бай, дәүләтле ырулар бер атна эчендә шыр ялангач калырга мөмкин һәм иң аянычы—монда бернинди чара да ярдәм итә алмый. Далада жәен үлән чабып, берәү дә печән әзерләмәгән. Ул кадәр күп терлек өчен печән әзерләү мөмкин да булмаган.

Яу башланып китеп, Аксак Тимернең зур гаскәре Отрар шәһәренә юнәлә һәм Сәуран янындагы бер жирдә тукталып кала. Ырыс хан да дошманыннан ерак тормый. Әйткәнебезчә, нәкъ шул чакта һавалар бозылып китә, жир өсте боз белән каплана. Илгә жот килә, афәт килә.

Билгеле, ач атлар белән яуны дәвам иттерү мөмкин булмый, шуңа күрә сугыш өч айга тукталып тора. Дөрес, вак-төяк бәрелешләр булгалый, ләкин алар боз берни дә бирми. Күрәсең, ике як та яз житеп, кояш карый башлауны көткәндер.

Көннәрдән бер көнне Аксак Тимергә, Ырыс хан үзе гаскәреннән китеп барды, үз урынына Кара Кисек бәкне калдырды дигән хәбәр китерәләр. Ул моннан ничек тә файдаланып калырга тели һәм көтмәгәндә гаскәрен дошман өстенә ташлый. Кара Кисек бәк дошманның кысрыклавына түзә алмыйча качып китәргә мәжбүр була. Шулай итеп, Аксак Тимер аның гаскәрен ахырынача тар-мар итәргә өлгерми кала. Тарихчылар язганча, Аксак Тимер үзе дә бу яуларда 10-15 мең атын, байтак яугирләрен югалткан. Ул дошманын ярты-йорты гына таркатып, Сәмәркандка әйләнеп кайта.

Ләкин сүз Туктамыш турында иде бит әле. Бу яуның ахыры аның өчен бик уңышлы тәмамлана. Сәмәркандка юнәлгән Аксак Тимер ике атнадан гаскәрен кире борып алып килә дә Сәуран тирәсендәге Жәйран Камыш дип аталган жирдә тынычланып ял итеп яткан Ырыс ханга көтмәгәндә һөжүм итә. Хан үзе качып өлгерә, барлык байлык Аксак Тимер кулына төшә. Шулай, химаячысы

[1] "Идегәй» дастаны каһарманы Идегәй Мангыт, ягъни Идегәй мирза түгел, башка кеше.— *Автор.*

ярдәме белән Туктамыш икенче тапкыр хан итеп күтәрелә, кабат Сәуран олысының хакиме итеп билгеләнә. Яулар шуның белән тәмамлана.

Сыр-Дәрья буенда кабат тәхеткә чыккан Туктамыш Ырыс хан белән көрәшне дәвам иттергән булса кирәк. Без алдагы хикәядә Ырыс ханның 1377 елда Сарай тәхетенә чыгуын, анда бер ел хөкем сөргәннән соң үтерелүен әйтеп үткән идек. Сарай тәхете өчен бертуктаусыз көрәш барган бу болгавыр дәвердә шулай булмыйча мөмкин түгел. Ырыс ханнан соң тәхеткә улы Тактакыя чыга. Ләкин аның да гомере бик кыска була—ул ике ай гына тәхеттә утырып кала.

Аннан соң тәхеткә Ырыс ханның икенче улы Тимермәлик чыга. Беренче эше итеп ул Ырыс хан нәселенең кан дошманы, Аксак Тимер йомышын йомышлап йөрүче хыянәтче Туктамыштан үч алырга, аның башына житәргә жыена. Моның өчен Сәурандагы Туктамыш биләмәләренә яу белән килә.

Ырыс ханнан Аксак Тимергә качып киткәннән соң Туктамышның ничә тапкыр сугышып та, бер мәртәбә дә жиңә алмавын без инде күрдек. Бу аның хәрби сәләте чамалы булуын ап-ачык күрсәтә. Моңарчы ул бер тапкыр да сүзен сүз итә, холкын күрсәтә алмады. Бары тик Аксак Тимер ярдәме аркасында гына кеше рәтендә йөрде. Тимермәлик тәхеткә чыккач та шул хәл кабатлана. Ул яу белән Сәуранга килеп, Туктамышны туздырып ташлый. Теге очраклы гына үлемнән котылып кала һәм кабат Аксак Тимер бусагасына килеп егыла.

Дөрес, тарихчылар Ырыс хан улы Тимермәлик турында да әлләни зур фикердә түгелләр. Туктамышны куып жибәргәннән соң ул, күрәсең, төп эш башкарылганга санап, тынычланып калгандыр. Чөнки дәүләт эшләренә бөтенләй илтифат итми башлый. Бу исә аның шактый чикләнгән, зур омтылышлар белән яши белми торган шәхес булуын күрсәтә.

Балык башыннан чери дигәндәй, ханнан күреп аның түрәләре, сарай әһелләре дә типтерә, вакытларын күбрәк ауда, мәжлесләрдә, жарияләр янында уздыра башлыйлар. Ә Тимермәлик үзе бөтенләй түбән тәгәри. Шул заманның тарихчысы аның турында: «Нинди генә ашыгыч һәм мөһим дәүләт эшләре булмасын, көнен төш житкәнчегә чаклы йоклап үткәрә. Аны уятырга берәүнең дә кыюлыгы житми, шуңа күрә кешеләрнең аннан тәмам гайрәтләре чикте, барысы да дәүләткә Туктамыш хужа булуын тели»,—дип язып калдырган.

Аксак Тимер Күк Урдадагы хәлләрне шымчылары аша белеп торган булса кирәк. Шуңа күрә форсаттан файдаланып калырга тели һәм 1379 елның кышында Тимермәликкә каршы яу жибәрә. Билгеле, Туктамыш та яуда катнаша.

Аксак Тимер үзенең гаскәр башлыкларына:

—Туктамышны тәхеткә утыртып кайтыгыз,—дип боера.

Сыгнактан әллә ни ерак булмаган Каратал дигән бер жирдә типтереп яткан Тимермәликне Аксак Тимер баһадирлары тиз айныта. Ханның хәле мөшкел икәнне күреп, әмирләре аны ташлап китә. Ә инде ханның гайрәтле әмире, аның төп таянычы булган Казан баһадир Тимермәликтән аерылып киткәч, халык гомумән Туктамыш ягына авыша. Хәтта аның якын туганнары да икеләнә башлый.

Шул рәвешле Тимермәлик хан бик авыр хәлдә кала. Тик ул үз хәлен дөрес анламаган, күрәсең. Бу аның сугышны дәвам иттерергә азаплануыннан да ап-ачык күренә. Бер туганы аны ниятеннән баш тартырга үгетләп тә карый, Тимермәлик исә, Туктамышка сатылгансың дип, аның башын чаптыра.

—Яудан баш тарту хакында сүз кузгаткан һәрбер адәм үлем жәзасына хөкем ителәчәк!—дип жикеренә хан.

Ләкин куркытып-өркетеп кенә хәлне жиңеләйтеп булмаячагын һәркем күреп тора. Бу вакыт аның кул астындагы күпчелек халык, чыннан да, Туктамыш ягына чыккан була.

Күнеле үсеп киткән Туктамыш үзенә тапшырылган гаскәр белән Карабака суы буенда Тимермәликкә һөжүм итә, каты сугыштан соң өстен чыга. Шунда Тимермәлик үзе һәм аның өлкән әмире Балтычак (Балтачык?) әсир төшәләр. Тимермәлик хан шундук үтерелә, ә дәүләт эшләрен яхшы белгән тәжрибәле әмир Балтычакны Туктамыш үз ягына чыгарга үгетли. Тегесе ханына тугры калачагын белдереп, Туктамышны үзенең ханы дип танудан баш тарта. Бу аның язмышын хәл итә—өлкән әмир Балтычак юк ителә.

Бу фажига турында алда әле сүз булыр, чөнки ул киләчәктәге вакыйгаларда

үзен бик нык сиздерәчәк. Әлегә исә Тимермәлик ханның өлкән әмире Балтычакның татар дастаны каһарманы Идегәй мирзаның атасы булуын гына искәртеп үтәбез («Идегәй» дастанында аның исеме Котлыкыя). Тарихи чыганаклар күрсәткәнчә, бу яу вакытында Идегәй инде, Күк Урда ханнарыннан качып китеп, Аксак Тимер янында хезмәт иткән. Бәлки әле Туктамыш белән бер үк гаскәрдә Тимермәликкә каршы сугышкандыр да. Димәк, ата белән ул капма-каршы лагерьда орышканнар.

Шулай итеп, Туктамыш, бернигә карамыйча, Идегәйнең атасы Балтычак картның башын чаптырды. Туктамыш турында Идегәй нәрсә уйлады икән? Атасының үлемен ул ничек кабул иткән? Туктамышның бу катылыгын кичерә алганмы? Соңрак калкып чыгып, Алтын Урда тарихында Идегәй мирза белән Туктамыш ханның 20 елга сузылган аяусыз көрәше фәкать шушы көнне башланып китмәгән дип кем әйтә ала? Дөрес, бу көнне ана оеткы гына салына. Әмма ул үзен әле сиздерәчәк, сиздерәчәк...

Карабака суы буендагы җиңү Туктамышның дәрәҗәсен күтәреп җибәрә. Аксак Тимер дә мона сөенә—аның оясында күпме заман канат яра алмыйча интеккән лачын, ниһаять, үзе оча башлады түгелме соң? Бу җиңүне ничек тә билгеләп үтәргә теләгән Аксак Тимер караңгы зинданнарда яткан тоткыннарны ирекkә чыгара. Үзе, яулап алынган Сыгнак каласына өстәп, Хәрәземне дә бүләк итә. Бу изгелекләрнең киләчәктә үзенә нинди яманлыклар булып әйләнеп кайтасын белсә, Аксак Тимер боларның берсен дә эшләмәс иде, әлбәттә. Ләкин киләчәктәниләр буласы бер Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле, ә кеше дигәнең берәүгә артык ышанып китеп, еш кына алданып та куя шул. Хәер, вакыйгаларны ашыктырмыйк, барысы да үз тәртибе белән бара бирсен.

Туктамыш хан 1379—1380 елларның кышын Күк Урдада үткәрә, ә инде яз җитү белән, зур гаскәр туплап, Идел буена, Алтын Урданың үзәк олысларын яуларга кузгала. Бу юлы да химаячысы Аксак Тимер көченә таянып һәм аның фатихасын алып чыгып китә. Ләкин шушы төштә безгә сүзне өзеп торырга туры килер, чөнки моннан соң булачак вакыйгалар бөтенләй башка дәвергә карыйлар. Шулай да бу урында кечкенә генә нәтиҗә ясау кирәк булыр.

Шундый зур түземлекләр күрсәтеп һәм күп байлыклар исраф итеп, Аксак Тимернең иленнән качкан Туктамышны теге аякка басканчы үз канаты астында асравын бер нәрсә белән генә аңлатып була: Аксак Тимер яшь һәм күндәм чыңгызый Туктамышны киләчәктәге ниятләре белән бәйләгән, шуларны тормышка ашыручы төп фигура итеп файдаланырга уйлаган. Ни күренеп торган сәләте, ни төпле акылы-фигыле булмаган Туктамыш гомере буе аның сүзеннән чыкмас, гел аның кушканы буенча йөрер дип уйлаган булса кирәк Сәмәрканд әмире. Шуның өстенә тамырларында чыңгызыйлар каны типкән бу шаһзадәнең тәхеткә чыгарга да хакы бар. Аны теләсәң кайда хан итеп күтәреп була. Берәү дә мона каршы килә алмаячак. Ә Тимернең күзе кызган җирләр әле күп. Һәм шуларның иң татлысы, иң гүзәле—Дәште Кыпчакның мул үләнле киң далалары, анда йөргән меңләгән елкы, куй көтүләре һәм гүзәл калалары. Андагы иксез-чиксез байлык. Менә кайда ул мал-мөлкәт, менә кайда дөнья рәхәте!

Бу яшел далаларга, мул сулы Идел ярларына тезелешеп киткән Болгар, Укәк, Сарай Бату, Сарай Бәркә, Хаҗитархан кебек бай шәһәрләргә ия булсаң, Мажар, Азак кебек калалардан ясак килеп торса, җәннәт синең кулыңда икәнне бел дә тор! Ә бит барысын да уйлап эшләгәндә, болар коры хыял гына булып калмаска да мөмкин. Һәм аларны тормышка ашыру өчен Туктамыш иң кулай зат. Ул аның сүзеннән чыкмас. Шул кадәр изгелекләр күрсәтеп тә, ничек чыксын икән? Юк, чыкмас! Аксак Тимер шулай уйлый, планнар кора, ә тарих бөтенләй икенче юлдан китә...

## Гыйсъянчы мирза—Мамай

Бу шәхес Алтын Урда дәүләте тарихында тирән эз калдыра. Бирдебәк хан үтерелгәч (1359) башланып киткән тәхет дауларында актив катнаша. Ул үзенең вафатына кадәр (1380) егерме ел дәвамында

илнең сәяси тормышында мәйдан тота, сәясәткә юнәлеш бирүче төп фигураларның берсе була. Кыскасы, Мамай мирзаның тормыш юлы, аның эшчәнлеге Алтын Урда тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән, аны шушы тарихтан аерып карау бөтенләй мөмкин дә түгел.

Мамай мирза үзе ханнар нәселеннән булмаса да, гаять көчле, һәркайда сүзе үтә торган абруйлы затлардан саналган. Тумыштан килгән ихтыяр көче, гайярьлек, тәвәккәллек, кешеләр белән идарә итә белү кебек сыйфатларга Бирдебәк ханның кияве булу да өстәлгәч, аның дәрәжәсе тагын да үсеп киткән булса кирәк. Урыс тарихчылары аның хакында, түбәнсетергә тырышып, «темник Мамай» дип кенә язалар. «Темник»—татарча «төмән башы» дигәнне аңлата, ягъни 10 мең сугышчы белән идарә итүче гаскәр башы. Мамай мирзаның рәсми титулы-дәрәҗәсе чыннан да төмән башы булгандыр, күрәсең. Тик Алтын Урда тарихына ясаган йогынтысы-роле ягыннан караганда, аның «төмән башы» гына булуы белән килешүе кыен. Чөнки тарихи вакыйгаларга бик нык тәэсир итеп килгән, еш кына аларны теләгән якка борып җибәрә дә алган, үзенә кулай кешене тәхеткә хан итеп куйган шәхеснең гади төмән башы гына булмавы көн кебек ачык.

Мамай мирзаның биләмәләренә Кырым белән Кара диңгез буе, Азак-Дон далалары кергән. Бу хәл үзе үк аның Кырым белән хәзерге Украина далаларында хуҗа булып яшәвен күрсәтә. Димәк, аның тоткан урыны олыс бәге дәрәҗәсенә туры килгән. Бәлки Бирдебәк хан гайрәтле киявенә шушы олыс-җирләр белән идарә итүне тапшыргандыр. Мамай мирза исә, үз чиратында, ханга күп хезмәтләр күрсәткән, хәбәр килеп төшү белән гаскәрен җыеп, аның байрагы астына баскан, биләмәләрендә ханга тиешле салымнарны җыюны оештырган һ. б.

Мамай мирза нигездә үз олысында иркенлектә яшәсә дә, хан кияве буларак, дәүләтнең башкаласы Сарай шәһәренә дә еш килә, анда озаклап кунак була. Шулай ул Сарай әһелләре, түрәләр, дәүләт эшлеклеләре арасында бик күп дус-ишләр, табындашлар, тарафдарлар булдыра һәм бу файдалы танышлыклар вакыты житкәч ана бик тә ярап куялар, сәяси эшчәнлегендә таяныч булалар.

Бирдебәк хан үтерелгәнче (1359) Мамай мирзаның сәяси вакыйгаларга катнашуы тарихи чыганакларда күренми. Күрәсең, бу дәвергә ул хан кияве сыйфатында беркая да кысылмыйча тыныч кына яшәгән булса кирәк. Хәер, тәхеткә чыкканнан соң күп туганнарын үтерткән явыз Бердебәк хан заманында андый мөмкинлек булмаган да. Каршы сүз әйтү баш бәясе торган. Ә инде Бирдебәк хан фетнәчеләр тарафыннан юк ителгәч, буа кинәт ерылып китә.

Башта Сарай тәхетенә Үзбәк ханның оныгы, Иренбәкнең улы Көлпә чыга. Тик ул ярты ел гына хөкем сөреп кала. Аның артыннан тәхеткә Нәүрүз хан утыра. Ләкин Нәүрүз хан заманы да озак дәвам итми. Ул үз эшчәнлегендә дәүләтнең Идел буе һәм аннан көнбатышта урнашкан олысларына таяна. Димәк, бу вакытта көнчыгышта урнашкан олыслар дәүләт эшләрендә үз сүзен әйтә дә, актив роль дә уйный алмаган. Бу исә андагы олыс бәкләрен, идарәчеләрне Нәүрүз ханга каршы куя. Сарайның үзендә дә ханга каршы торган әмирләр аз булмый һәм алар, мөстәкыйль яшәп яткан Күк Урда ханы Чимтайга кешеләрен җибәреп, аның Сарай тәхетенә чыгуын сорыйлар. Тик Чимтай хан башын андый хәтәр эшкә тыкмый, бу низаглардан читтә калу ягын карый. Шулай да мөмкинлекне бөтенләй кулдан ычкындырмас өчен ул Сарай тәхетенә үзенең туганы Хызырны тәкъдим итә. Күрәсең, Сарай әмирләре бу кандидатураны да ярашлы дип тапканнар, чөнки тиздән Нәүрүз хан бәреп төшерелә дә тәхеткә Сасы Буга улы Хызыр хан чыга.

Хызыр ханның тәхеткә чыгуы дәүләт башкаласы Сарайда көнчыгыш олысларга йөз тоткан партиянең вакытлыча өстенлек алуы турында сөйли. Әлбәттә, мондый чакта яна хан үз «командасы» белән килгән, аны күтәргән кешеләр алдында ул үзен бурычлы итеп тойган, аларга зур бүләкләр, җылы урыннар өләшергә тиеш булган. Бу инде җинелгән партия вәкилләрен таркату, урыннарыннан алу, эзәрлекләү, ә иң хәтәрләрен гомумән юк итү юлы белән башкарылган. Нәкъ шул сәбәпле Хызыр хан идарәсенең беренче

көннәрендә үк мәрхүм Үзбәк ханның үтә дә абруйлы, зур йогынтыга ия тол хатыны Тайдулла (Риза Фәхретдин аның исемен Тыйтгали дип атый), Нәүрүз ханның улы Тимер һәм төшерелгән хан тарафдарларыннан бик күп бәкләр, мирзалар, угланнар юк ителә. Шуна да карамастан, Хызыр хан белән хакимияткә килгән Күк Урда партиясе Сарайда ныгып өлгерә алмый. Күп тә үтми Хызыр ханны да тәхеттән алып ташлыйлар.

Уйлап карасаң, сәбәбе бик гади—монархы Күк Урда вәкилләренең беркайчан да Сарай тәхетенә чыкканнары булмый. Бу исә аларның Сарай шәһәрендә, кинрәк алганда Идел буенда, Кыпчак даласында таянырдай көчле тарафдарлары санаулы булганлыгын күрсәтә. Ә Сарай әмирләренең, Нәүрүз ханга үч итеп, тәхеткә Хызыр угланны чакыруын башкалада барган ызгыш-талаш, идарәче даирәләрнең бер капризы дип карарга кирәктер. Бераздан Хызыр ханның да улы Тимерхуҗа тарафыннан үтерелүе фәкать шул хакта сөйли кебек. Бу вакытта башкаладагы төркем-партияләрнең һәркайсы тәхеткә үз ханын куярга омтыла.

Хәер, сүз Мамай мирза турында иде бит әле. Ул Алтын Урданың сәясәт мәйданына менә шундый шартларда килеп чыга. Илдә тәхет бүлешү башланып киткәч, хан кияве дә читтә торып өлешсез калырга теләмәгән, күрәсең. Ул хәтта, чаманы онытып җибәреп, 1360 елда Азак шәһәрендә үз исеменнән «Мамай солтан әл-гадел» дигән сүзләр төшкән көмеш тәнкәләр дә суктыра. Дөрес, аның тормышында бу бердәнбер очрак була, андый хатаны ул бүтән беркайчан да кабатламый. Киләчәктә тәнкәләр бары тик үзе куйган хан исеменнән генә суктырыла.

Чыганаклар күрсәткәнчә, Хызыр хан үтерелеп, тәхеткә аның улы Тимерхуҗа чыккач, Мамай мирза аны төшерүдә актив катнаша, бәлки әле моны оештыручылардан төп кеше дә булгандыр. Шулай итеп, хыянәтче угыл тәхеттә атна-ун көн генә утырып кала (1361). Аның урынын Хызыр ханның икенче улы Урдамәлик ала (кайбер чыганаклар бу ханның исемен Урдашәех дип тә атыйлар).

Игътибар итик, Хызыр хан үзе, аның уллары Тимерхуҗа белән Урдамәликләр—барысы да Күк Урда вәкилләре, ягъни Сарай тәхете өчен ят кешеләр. Сарайда, гомумән, Идел буенда аларның дошманнары күп булган, шул сәбәпле аларның гомере дә тиз киселә. Бу җәһәттән Күк Урда ханы Чимтайны искә төшерик—аның зирәклегенә сокланып куясың. Әмирләр аны дәүләтнең төп тәхете торган Сарайга күпме генә чакырып карамасыннар, үгетләмәсеннәр—ул гел биек тәхеттән баш тартып килә, анда кардәше Хызырны тәкъдим итә. Әлләни биек булмаса да, ул үзе утырган Сыгнак тәхетен, Сыр-Дәрья буйларын якынрак күрә һәм шуның аркасында башын саклап кала. Өстәвенә әле тәхет варисларыннан да бер-бер артлы арына тора.

Сарайда Урдамәлик хан хөкем сөргәндә Мамай мирза төп тәхеткә үз кешеңне утыртырга кирәк, дигән ныклы фикергә килә, гаскәр туплап Идел буена юнәлә. Иң элек ул Азак каласын ала, анда Габдулла исемле берәүне хан итеп күтәртә. Урдамәлик хан белән Мамай мирза Идел белән Дон арасындагы далада бәрелешкәннәр булса кирәк. Урдамәлик җиңелә, шуннан соң Мамай мирза Сарайдагы тәхеткә Габдулла ханны утырта һәм аның исеменнән идарә итә башлый. Тик андый болгавыр заманда Мамай мирза белән Габдулла ханга да Сарайда озаклап яшәргә туры килми. Ибне Халдун сүзләренә караганда, бу вакытта әмирләрнең берсе Габдулла ханга каршы фетнә оештыра. Фетнәчеләр уңышка ирешкәч, Габдулла хан белән Мамай мирзага Сарайны ташлап китәргә туры килә (1361). Шулай итеп, тәхеткә Котлык Тимер дигән берәү калка.

Шул ук көннәрдә мәрхүм Җанибәк хан балаларыннан булган Килдебәк тә Мамай мирзага каршы хәрәкәт башлаган була. Әлбәттә, Мамай мирзаның тәхет даулаучы берничә хан балаларына каршы торырга көче житми—ахыр чиктә Сарай тәхетенә Килдебәк чыга (1361). Чыганакларда аның үтә дә кансыз, рәхимсез адәм булуы әйтелә. Ул әмирләрне, дәүләтнең дәрәҗәле кешеләрен бер-берсенә каршы котырту юлы белән бик күпләрнең башына җитә. Әлбәттә, мондый сәясәт өске катлам вәкилләрендә нәфрәттән башка

бүтән нәрсә уята алмаган, чөнки күпләрнең гомере кыл өстендә торган. Сарай әһелләре явыз ханны алып ташларга мәҗбүр булалар. Шулай итеп, Килдебәк хан да тәхеткә чыккан елында ук дөньядан китеп бара.

Тарихчылар Алтын Урда дәүләте тарихының 1361 елдан соңгы берничә елын иң буталчык һәм ачыкланып бетмәгән дәвере дип саныйлар. Чыннан да, бу вакытта Кыпчак даласында барган вакыйгаларны тәгәл генә күз алдына китерүе җиңел эш түгел, тарихи чыганакларда да алар сирәк теркәлгән. Безнең игътибар үзәгендә Мамай мирзаның эшчәнлеге, катлаулы язмышы булганга, бу чорда аның кайда булганын, нишләп йөргәнен ачыкларга тырышып карыйк әле.

Мамай мирза әле яңа гына Габдулла хан белән Сарайны ташлап китсә дә, ул дәүләтнең мәркәзенә әйләнеп кайтып, төп тәхеткә янә үз ханын утырту уеннан һич тә ваз кичми. Тарихи фактлар һәм вакыйгалар барышы нәкъ шуны күрсәтә. Гайрәтле татар мирзасы Сарай өчен көрәшүен дәвам иттерә. Бу көрәштә ул үз артында торган Кырымга һәм Кара диңгез буе, Азак-Дон далаларына таяна.

Килдебәк ханнан соң әмирләр Морат (кайбер чыганакларда Мөрит) дигән берәүне хан итеп күтәрәләр. Тик аны Сарай шәһәре һәм аның тирә-юнендәге беркадәре җирләр генә таный. Мамай мирза бу вакытта Иделнең уңъяк ярында урнаша. Ул Иделдән дала эченә ерак китмәгәндер, чөнки аңа Морат хан белән көрәш алып бару өчен Сарайдагы хәлләрне белешеп торырга, астыртын эш йөртергә, унай чак туры килсә, кинәт һөҗүм оештырырга кирәк булган. Ә көчне, гаскәрне ул, әйткәнебезчә, артында җәелеп яткан Кыпчак даласыннан һәм Кырым ярларындагы шәһәрләрдән алган. Анда Италиянең Генуя шәһәреннән чыккан бай сәүдәгәрләр бик күп була. Мамай мирза үз эшчәнлегендә аларга да таяна, гаскәргә түләр өчен акчаны алардан ала.

Дөресен әйткәндә, бу вакытта дәүләт башкаласы Сарай шәһәре дә, диңгездәге утрау кебек, ялгызы утырып кала. Башкалада ханнарның туктаусыз алышынып торуы аркасында илдә тәртип тәмам бетә һәм зур дәүләтнең олыслары, Сарайдан аерылып, башка чыккан гаилә сыман, мөстәкыйль яши башлыйлар. Шулай итеп, Иделнең урта агымында Болгар белән Наручат, аскы агымында Хаҗитархан (Әстерхан), Җаек (Урал) елгасы буенда Сарайчык, көньякта Хәрәзем олыслары мөстәкыйль тормыш алып бара. Сыр-Дәрья буендагы хакимнәрнең дә Сарай ханнарына инде күптән исе китми. Дөнья тәмам болганып, таркалу көчәеп барган бер чорда Мамай мирза Иделдән көнбатышка таба сузылган Кыпчак даласының тулы хокуклы хуҗасына әверелә.

1360 елда Сарай өчен башланып киткән аяусыз көрәш 1362 елда да дәвам итә. Көрәш барышында өстенлек әле бер партиягә, әле икенчесенә күчә. Урыс елъязмасында бу хакта шундый сүзләр теркәлеп калган: «Ул чакта Идел буе патшалыгында ике падишаһ бар иде—Мамай урдасы хакиме Абдул (Габдулла хан), ә икенче хаким—Амурат (Морат хан) белән Сарай кенәзләре. Бу ике патша һәм бер-берсенә каршы торучы ике урда һәрвакыт дошманлык сакладылар һәм үзара сугышып тордылар»,—диелә анда. Шунысы кызык: көрәш барышында һәр як үз лагерына өстәмә көчләрне җәлеп итәргә омтыла. Бу очракта сүз урыс кенәзлекләре хакында бара. Габдулла хан исеменнән Мамай мирза да, Сарайда утырган Морат хан да урыс кенәзләренә ярлыклар бирәләр, аларны үз якларына тартырга, көрәштә үз аркадашы-союзнигы итәргә тырышалар. Хәтта бер үк кенәзлеккә ике тарафтан бер үк кешене берьюлы кенәз итеп билгеләү очраклары да булгалый. Бу хәлгә татарның бөек мәгърифәтчесе, тарихчы Ризаэтдин Фәхретдин дә үзенең «Алтын Урда ханнары» исемле хезмәтендә игътибар итә. Дөрес, ул моңа илдә тәртип бетүнең бер мисалы итеп кенә карый.

1363 елда Морат хан да өлкән әмире Ильяс тарафыннан төшерелә. Аннан соң Сарайда бер-бер артлы Булатхуҗа (1364), аның улы Газизшаех ханнар (1364—1367) хөкем сөрә. Газизшаехтән соң Сарай тәхетенә кабат Габдулла ханның чыгуы безгә чыганакларда чагылмый калган күп вакыйгаларның

эчке механизмын аңларга ярдәм итә. Димәк, бу вакытта Мамай мирза да кул кушырып утырмаган, тарафдарларын үз тирәсенә туплый алган һәм, нәтиҗәдә, Сарай тәхетенә кабат Габдулла ханны утыртуга ирешкән. Ләкин бер болганса су да тынмый дигәндәй, еш үзгәреп торган вәзгыятъ аркасында тагын бел елдан (1368) Габдулла хан кабат тәхеттән коры кала. Бу инде Мамай мирза тарафдарларының җинелүен, башка партиянен өстен чыгуын күрсәтә.

Чыннан да, бу юлы Сарай шәһәре Хаҗи Чиркәс хан кулына төшә. Чыганаклардан аның монарчы Хаҗитархан хакиме булуы билгеле. Күренә ки, бу вакытта үзен Бату, Үзбәк ханнардан калган асыл тәхеткә лаеклы санаучылар житәрлек булган. Әйтергә кирәк. Хаҗи Чиркәс белән беррәттән Хәсән дигән берәү дә Мамай мирзага каршы көрәш башлый. Бу бәрелешләрдә Хәсән җинеп чыга да тәхеткә утыра. Әйткәнебезчә, бу вакыйгаларны тарихчылар 1368 ел белән билгели.

Бу очракта Хәсән хан турында киңрәк итеп сөйләү үзен аклар, дип уйлыйм. Эш шунда ки, бу затның эшчәнлеге турыдан-туры Казан ханлыгы тарихы белән бәйле. Күптән түгел әдәбиятчы һәм тарихчы М. Әхмәтҗанов борынгы шәҗәрәләр, сугылган тәңкәләрне өйрәнү нәтиҗәсендә 1368 елда Сарай тәхетенә чыккан Хәсән ханның Казан ханлыгына «нигез салучы» Олуг Мөхәммәт ханның атасы булуын ачыклады. Урыс елъязмалары бу затны «болгар кенәзе» дип кенә искә алалар. Чыннан да, тагын бер елдан (1369) Хәсән хан фетнәчеләр оясына әверелгән Сарай шәһәреннән качып китә дә, Болгар олысының мөстәкыйльлеген торгызып, шунда идарә итә башлый. Бу факт күп нәрсә хакында сөйли. Димәк, әле Олуг Мөхәммәт хан Казан ханлыгына «нигез салганчы» ук (1438 елда) Алтын Урда татарлары Болгар олысында идарә иткәннәр. Олуг Мөхәммәт ханның үзенә килгәндә, ул да башта 17 ел дәвамында Сарай ханы була, хәлләр катлаулану аркасында гына аннан китә һәм соңгы 8 ел гомерен Казан тәхетендә үткәрә. Моннан без Казан ханлыгын дәүләт буларак яңа баскычка күтәрүчеләр Алтын Урда татарлары икәнен күрәбез. Шул сәбәпле, Казан ханлыгын Алтын Урда дәүләтеннән аерып карау һич тә мөмкин түгел. Бу ике дәүләт арасында туганлык җепләре, дәвамлылык гаять нык булган. Казан ханлыгына «нигез салучы» Олуг Мөхәммәд хан соңрак бары тик атасы Хәсән хан тәхетенә генә чыккан (1438).

1368 елда икенче тапкыр Сарайны ташлап чыкканнан соң Мамай мирза белән Габдулла хан арасыннан кара мәче йөгереп узган булса кирәк. Бәлки Габдулла хан үзе үк көчле мирзаның «кесә ханы» булып йөрүдән туйгандыр, мөстәкыйль яшисе килеп, аның белән араны өзгәндер. Юллары аерылышуның сәбәбе шулай ук Мамай мирзаның үзеннән чыгуы да бик мөмкин. Үзен сәясәткә багышлаган зат килеп туган вәзгыятьне исәпкә алмыйча булдыра алмый. Еш кына үз җырының «бугазына басарга» мәҗбүр була. Соңгы еллардагы уңышсызлыклары аркасында аның Габдулла ханнан гайрәте чигүе дә бар. Һәрхәлдә, алар арасында бу вакытта ниндидер каршылык килеп чыкканга охшый, чөнки 1369—1370 елларда Мамай мирза үз урдасында, Мәмәт солтан дигән берәүне хан итеп күтәртә (Мөхәммәт Бүләк хан).

М. Әхмәтҗанов фикеренчә, 1368 елдан соң Габдулла хан үтерешсуешлардан, фетнәләрдән, тәхет дауларыннан ераграк торган Җаек (Урал), Сакмар елгалары тирәсенә барып урнашкан булырга тиеш. Чөнки татар шәҗәрәләреннән аның Кырымнан соң (Мамай мирза урдасы шул төбәктә була) Сакмар буйларында яшәве күренә икән. Мамай мирза үзе дә шушы хәлләрдән соң Кырымга әйләнеп кайта, Мөхәммәт Бүләк хан исеменнән идарә итә башлый. Әлбәттә инде, тәңкәләр дә Мөхәммәт Бүләк хан исеменнән сугыла. Бу вакытта Мамай мирзаның Урда каласында яшәве билгеле. Урда дигән кала борын-борыннан ханнар урдасы урнашкан җирдә үсеп чыкканга охшый. Шулай тора-бара «урда» сүзе кала исеменә күчкән булса кирәк.

Әлбәттә, Мамай мирза Сарайны ташлап киткәч тә анда ыгы-зыгы

тукталмаган. Ханнар бер-берсен алыштыра торганнар, тәхет өчен туктаусыз көрәш барган.

Мамай мирза—Габдулла хан берлегенең икенче кат Сарайдан куылуы белән Мамай мирза тормышында зур бер дәвер тәгәлләнә кебек. Аның моңа кадәрге тормышын ике өлешкә бүлеп карарга мөмкиндер. Беренчесенә—яшьлек еллары, егет чагы, Бирдебәк хан кызына өйләнеп, горур хан кияве булып яшәве, аннан түмән башы, ханның өлкән әмире сыйфатында төрле гайрәтлекләр күрсәтүе керсә, икенче өлеше, Бирдебәк хан үтерелеп (1359), илдә зур башбаштаклыклар, тәхет даулары башланган вакытка туры килә. Зур ихтыяр көченә ия, инициативалы, тәвәккәл, батыр йөрәкле Мамай мирза бу елларда татарның, ятып калганчы атып кал, дигән мәкаленә тугрылык саклагандай, өлешсез калмас өчен иң әүвәл, Кырымнан килеп Азак каласын кулына төшерә, аннан соң катлаулы көрәш стихиясенә кереп чума һәм, тырыша торгач, үзе белән килгән Габдулла ханны ике тапкыр Сарайның алтын тәхетенә утыртуга ирешә. Икенче төрле итеп әйткәндә, Мамай мирза бу елларда тормышта үз урынын эзли, шуның өчен аяусыз көрәш алып бара. Сер түгел, гайярь табигатьле, дан-шөһрәт сөючән мирза үз урынын фәкать дәүләт башкаласы Сарайда, илнең мөнбәрендә генә күрә. Аның гомерен җентекләп барлый башлагач, бу затның күңелендә гомерлек фаҗига ятканын бик ачык аңлыйсың. Күкрәк читлегендә горур ханнар йөрәге тибә торып та тәхеткә утырырга хакың булмау—бу фаҗига түгелмени?! Бу шәхес тормышта үзен күпләрдән өстен тойган, кешеләр белән идарә итү мәктәбен бик әйбәт үзләштергән. Тик һәр заманның аерым шәхес җимерә алмый торган катгый кануннары була—шуңа күрә дә йөрәгендә җиде арслан гайрәте талпынган Мамай мирзага гомере буе үз янында уенчык ханнар тотарга, аларны тәхеткә куеп-төшереп мәшәкатьләнергә, алар белән киңәшкән төс чыгарып яшәргә туры килә.

Әлбәттә, Сарай хакиме булу—аның күңеленә кереп урнашкан алтын хыял, бер идеал булган. Ул бәхетен бары тик шул сыйфатта гына күз алдына китерә алган. Чыннан да, тормыш аны тәхеткә бик якын куя, хан кияве сыйфатында туй-мәҗлесләрдә ул ханга бик якын утыра. Ә инде йөрәгендә бетмәс-төкәнмәс көч-дәрт сизгән затның яшертен генә биек тәхет турында хыяллануы—гаеп эшмени! Ләкин Мамай мирза яхшы белгән—бу мәңге тормышка ашмаслык хыял гына. Шуңа күрә ул бөтен гомерен шушы хыялга мөмкин кадәр якын килү өчен сарыф итә, бу юлда күп көч түгә. Тәхеткә утыра алмаса да, анда үзе теләгән ханнарны куя, шуннан канәгатьләнү таба.

Әлбәттә, Сарайдан икенче кат куылу аның өчен гади вакыйга булмаган, күңелендә тирән яра-эз калдыргандыр. Җинелгәндә, уңышсызлыкка дучар булганда якын дусларың, аркадашларың да еш кына синнән йөз чөерә башлый, тырнак астыннан кер эзләп, төрле гаеп тага. Бу очракта да Мамай мирзага ниятләрен аның белән бәйләнгән кайберәүләрнең үзенә карата суынуын тоярга туры килгәндер. Шуның аркасында сәяси вәзгыятьнең дә үзгәреп китүе бик ихтимал. Моны Мамай мирза белән Габдулла ханның арасы өзелүе дә раслый кебек.

Шуннан соң Мамай мирза Сарай өчен алып барган мәшәкатьле даулардан соң үз олысы Кырымга кайтып төшә, шуның белән аның тормышында бер әһәмиятле дәвер тәмамланган сыман була.

*Дәвамы алдагы саннарда*



## Рәмис Аймәт

### КАЯ БАКМА—ҖӘЙРӘП ЯТА ИРЕК...

**Мин әле тумаган**

Мин әле тумаган, мин әле
Үрелеп бакмаган дөньяга.
Мин әле Мәңгелек иренендә
Бөрегә төйнәлгән бер Дога.

Мин әле тумаган, әмма мин—
Карында кайнаган бер Дәвам.
Кайдадыр җил булып исәм дә,
Кайдадыр кар булып мин явам.

Мин әле тумаган, ишетәмсез
Җанымда галәмнең гүләвен?
...Дулкыннар ияртеп киткәндер,
Тибрәтеп минем ак биләвем.

Мин әле тумаган, ә инде,
Ә инде... арылган яшәп тә.
Ничә кат туамдыр? Язмышым
Күгендә гел тимер рәшәткә.

Бу дөнья—гарасат мәйданы.
Әллә соң яшәү дә—бер җәза?!
...Мин әле тумаган, ә инде
Күкләрдә укыйлар җеназа.

*1998*

---

Рәмис АЙМӘТ *(1968) —«Шомырт салкыннары» (2001) исемле китап авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

## Ирек

Узып бара чегән арбалары,
Серле таңның саф тынлыгын сөзеп.
Җирне түгел, әйтерсең лә җанны
Ярып уза тәгәрмәчләр эзе.

Тәгәрмәчләр булып әйләнә дә,
Кайтып төшә уйлар үз эзенә.
Кайта уйлар...
Мин дә кайта-кайта
Меңләп сорау бирәм үз-үземә.

Уза... уза... чегән арбалары,
Кая бакма—җәйрәп ята Ирек!!!
Ул Ирекне, таңгы тузганактай,
Җилләр генә таратал мас өреп.

Минем Ирек?!.
Ерак офык кебек,
Барган саен чигенә бара һаман.
Ирек-кошым, ватып читлекләрен,
Иңнәремә килеп кунар сыман.

...Нинди төстә икән минем Ирек?
Шанлы үткән, йөрәк, исеңдәме?!
Шәһре Казанымда гөрләп аккан
Бабамнарның каны төсендәме
Минем ирек?
Инде ничә гасыр
Татлы бер сүз булып тибри телдә.
Ирек исен алып килми хәтта
Көнләштереп искән иркә җил дә.

...Тукта...

Нинди җыру суздың чегән кызы?—
Өнсез калды кинәт кырыс чынлык.
Сискәнепләр уяндымы анда
Әле беркем орынмаган тынлык?

Уяндымы хәлсез куллар кебек,
Офыккача сузылып киткән юллар?..
Чыңрый-чыңрый арба эзләренә
Тулып кала саркып таңгы сулар.

Әле җанда таңгы сулар сыман,
Челтери-челтери якты өмет ага.
Бир иркенлек, Тәңрем, хыялларга—
Кабул, диләр, таңда кылган дога.

Җанда—тетрәү!
Нинди давыл кыйный
Бертуктаусыз күңелем кыяларын?

...Катып калдым.
Арба эзе буйлап
Йөгерә бары ярсу хыялларым.

Килеп чыктым мәллә көтмәгәндә
Язмышларның соңгы өзегенә?
Йөрәгемдә гөлләр туе дисәм,
Йөрәгемдә...
богау эзе генә.

...Тынма әле! Җырла чегән кызы!—
Сихри тараф синең алларыңда.
Ирек сорап зеңләп тартылганмы
Гитараңның бәйсез кыллары да?

Күкләр—аяз. Нидер көтә күңел.
Моң-зарлардан, бермәл, җан арына.
Чегән кызы! Күкләремә бак та,
Юрап китче Ирек татарыма.

...Уза... уза... чегән арбалары...
(Таңны уятып тагын кем йөресен).
Кәрван-кәрван узган арбаларның
Булсам иде мин дә, эх, бересе...

*2000*

## Җитәр

Җитәр! Җитәр!!
Шомлы дулкын булып,
төште пәрдә—
Җанда ярчыгы.
Сюжет—ялган.
Уен—фальш.
Минме
режиссерның тере курчагы?

Җитәр!
Пәрдә!!
Сүндерегез утны!!!—
тынды суфлер төче су коеп.
Кайда дублер?

Бутафорлар кебек,
нигә шулай калдыгыз оеп?

Уен—драма?
Дивардагы мылтык
Бер атарга тиеш?
Үземне
мишень итеп әләм,
Уенның ич
Finita La Comedia—резюме...

Кызыл күзле үлем бага һаман,
Әлмәк ишеп шәрә уемнан,
Җитәр! Җитәр!!
Мин масканы салам
һәм мәңгегә чыгам уеннан.

Мин масканы салам...
Аh, сагындым,
Кайтыйм инде, җитәр, үземә.
Минме соң бу?
Аптыраушта калды,
Танымыйча тора күзге дә.

Минме соң бу?..
Әй, сез! Ник дәшмисез?
Кемнәр Шомбай монда, кем Яго?
Дон Кихот кем?
Финал.
Геройларның
Кем карасы монда, кем агы?

Акылыннан шашып, туктый алмый
Әй әйләнә сәхнә, ни уйлап?
Сезнең күчәр сәхнә тирәсендә,
Мин әйләнәм, әйе, җир буйлап.

Мин әйләнәм...
Сәхнә арты ачык,
Ил каршында—безнең кемлекләр.
Һава җитми сезгә, канат җитми,
Хыял өчен очар киңлекләр...

*1997*

## Тәрәзә

*Ачыгыз тәрәзәләрне*
*Тәрәзәгез булса!..*

М. Әгъләм

Тәрәзләр бар, ләкин ачылмыйлар;
Рәшәткәле безнең тәрәзәләр.
Кадакланган алар (озаккамы?!)
Ачылмаслык итеп.
Күрәзәләр
Безне бүтән алдый алмас инде.
Үтте инде җаннан андый агым.

Уйлап куйдым әле мин, нигәдер,
Тәрәзләрнең карындыклы чагын.

Һәрбер уем күңел учагыма
Өсти генә бара көчле ялкын.
Сүрән карындыклар аша да бит
Еракларга карый алган халкым.
Дөрли-дөрли, озын төннәр буе,
Йөрәгемдә күпме учак ягам?!
Рәшәткәле тәрәзәләр аша
Рәшәткәле рәшәләргә багам.

Багам рәшәткәле дөньялыкка,
Читлектәге ерткыч җанвар сымак.
Күпме була адәм җаннарында
Бертуктаусыз тәҗрибәләр сынап?!

...Өсләремә рәшәткәләр ава,
Якты хыялларны кыя-кыя.
Ябыла бара күңел тәрәзләре,
Европага тәрәз уя-уя...

*2001*

## Вакыт!

Күтәр, әйдә, күтәр җилкәннәрне,—
Сукты сәгать! Кузгалырга! Юлга!
Гизеп чыгалмаслык котсыз дәръя,
Уйга баткан Билгесезлек алда.

Чолгап алган җанны Бертөслелек,—
Беркайда да нигә һичбер ямь юк?
Киерелгән җилкән—соңгы өмет.
Әллә оҗмах алда, әллә тәмуг?

Ни булса да, без китәргә тиеш!
Кузгалырга тиеш бүгеннән үк!
Вакыт—алтын. Арыныл китеп булмый
Үткәннәрнең авыр йөгеннән ник?

Кузгалырга! Әйдә, барыйк әле,
Өметсезлек томаннарын сөзеп.
Үксез Үткән белән (соң түгелдер!)
Мәңгелеккә арабызны өзеп.

Тизрәк!.. Тизрәк!.. Алгысыта нидер.
Соңарырбыз кебек. Менә... менә...
Сыңар маймыч кына булса да, хет
Эләгер бит хыял ятьмәсенә.

Нидер ымсындырып, су өстендә—
(Җилләр язып киткән безнең уймы?)—
Кояштанмы?.. Әллә безгә насыйп
Алтын балыкныңмы нуры уйный?..

*2001*

## Бер истәлек

Нигә мине һаман газаплыйдыр
Еракта калган бер Истәлек?
Күксел томан аша калка да ул
Бертуктаусыз төшә искә ник?
Яфрак-яфрак очкан хатирәләр
Тора гына җанга өстәлеп.

Искә төшә... Инде онытылды дип,
Уйлыйсың да, кабат яңара.
Җилләр җан иңдергән учак кебек,
Тотына ул кабат янарга.
Тотына ул узган яшьлегемнең
Садә минутларын санарга.

Дәфтәр битен ачсам, ул Истәлек
Килеп чыга кипкән гөл булып.
Сулган сөю булып очып төшә,
Тузгып оча сагыш-көл булып.
Көтмәгәндә кинәт Бүгенгемнән
Үткәнемә төшәм убылып.

Үткән—үткән! Ятьмә кебек җанны
Күпме генә аны теткәлә...
Ул карашлар... һаман үзәк өзеп,
Еллар аша миңа текәлә.
Җилеп узган елларгамы хәзер,
Язмышкамы әллә үпкәлә?

Тынгы бирми һаман ул истәлек,
Тынгы бирми бер дә—кич, иртә...
Ярты төндә кабызып утларымны
Күңел тәрәзәмне ул чиртә.
Хатирәләр ага ташкын булып,
Ташкыннарга бармы соң киртә?

Шыбыр-шыбыр яңгыр елавы да
Алып кайта аны Үткәннән.
Яфрак шавы, җилләр сулавы да—
Барысы да, бар да ул көннән.
Ул көннәргә китеп югалсам да,
Мин мәңгегә, юк, юк үкенмәм.

«Кайтарыгыз Үткәннәрне!» диеп,
Берәүдән дә инде үтенмәм.

...Үкенмәм!...

*Геленжик, 2001*

## Төгәллек һәм кыскалык

*Нурулла Гарифның кыска хикәяләре мине менә нинди хәлләр турында уйландырды.*

*Бик борынгы заманнан ук һәр халыкта кыска-кечкенә күләмле әсәрләр күп иҗат ителгән. Уйлана торгач, хәтта, әдәби иҗат шул миниатюралардан башланмадымы икән, дигән фикергә дә килеп куясың. Шигърияттә бер куплетлы җырлар, чәчмә жанрда җыйнак риваять-истәлекләр һәм мәзәкләр, халык алдында уйнау өчен театраль миниатюралар әдәбиятның чишмә башы булган кебек. Һәм һәр халыкта әдәбиятның бу төре заманалар узуында шомарган-чарланган.*



*Без бу очракта проза жанрына гына күз салыйк.*

*Егерменче гасыр башында Габдулла Тукай кыска хикәяләрен иҗат итә, Дәрдмәнд «Вак хикәяләр»ен яза. Аларга чаклы һәм алардан соң да халык иҗаты әсәрләре—кыска әкиятләр, мәзәкләр—күп җыентыкларда басылып чыга.*

*Бик еракка чигенмичә, рус әдәбиятыннан Лев Толстойның, Михаил Пришвинның шундый әсәрләре шактый булуын искәртик. Узып кына киткән егерменче гасырның җитмешенче елларында бу төрдә Василий Субботин («Подорожники»), Владимир Солоухин («Камешки на ладони»), Леонид Гурунц («Ясаман—обидчивое дерево») актив иҗат иттеләр. Шул елларда Советлар Союзының башка халыклары язучыларының да үз әдәбиятларында мондый төр хикәяләрне алгарак чыгарырга тырышулары күзәтелде.*

*Безнең татар әдәбиятында Фаил Шәфигуллинның әйбәт кыска хикәяләре (аеруча юмористик) истә калды. Галимҗан Гыйльманның «Тозлы яңгыр» исемле китабының зур өлешенә шундый әсәрләре тупланган, әдип аларны «Парчалар, нәсерләр» дип билгели. Рабит Батулланың мәгълүм шәхесләр турындагы юморескалары вакытлы матбугатта еш басыла. Туфан Миңнуллинның «Кызыл тышлы дәфтәрдән» исемле бай җыелмасында кыска хикәяләр ишле. (Мәгълүмат итеп кенә әйтим, мин дә әле җитмешенче елларда ук вак хикәяләрдән торган шактый күләмле «Арыш көлтәсе» исемле җыентык туплаган идем. Тик ул, «көлтә бавы» кысып бәйләнмәгәнгәдер, укучыга тулысынча барып җитә алмады, әлеге хикәяләрнең шактые вакытлы матбугатта да басылмады, кайберләре башка әсәрләр кысасына сыйды.)*

*Нурулла Гарифның кыска хикәяләрен тәкъдим итү сүзендә бу төргә өстән-өстән генә күзәтү ясауның максаты андый әсәрләрнең һичшиксез язылырга тиешлегенә игътибарны юнәлтү иде. Аларда заман төсмерләрен, үткәннең һәм киләчәкнең бизәкләрен-чуарлыкларын тасвирлау җайлары-алымнары күп, алар, формалары белән үк, язучының вакыйгага-хәлгә мөнәсәбәтен төгәл-кыска белдерүен, тормыш күренешләрен дөрес бәяләвен, нәфислекне дөп-дөрес чагылдыруын таләп итәләр. Аннары. Мондый төр әсәрләр язу бигрәк тә яшь иҗатчыларның осталыкларын күтәрүгә булышыр иде.*

*Соңгы вакытта Нурулла Гариф әйбәт кенә хикәяләрен бастырды. Аның түбәндәге кыска хикәяләре (югарыда «мәзәк, юмореска, миниатюра, хикәят, парча» кебек терминнар да кулланылды, тик кайсысы дөресрәк?) әдәбият таләпләренә, аның да вак төре таләпләренә җавап бирәләр, дигән фикердә мин.*

**Мәгъсум ХУҖИН**

# Нурулла Гариф

## КЫСКА ХИКӘЯЛӘР

### Байлар ничек яши?

Уйланып кайтып киләм. Янәшәдәге олы юлда машиналар ташкыны. Һәркемнең үз юлы, үз кайгысы. Машиналарның берсе өздереп тавыш биргәч, борылып карарга мәҗбүрмен. Әйе, мине узып киткән машиналарның берсеннән шоферы чыгып кул изи. Таныш күренмәгәч, игътибар бирмим, юлымны дәвам итәм. Мондый күз күрмәгән чит ил машинасын йөртүче туганым да, танышым да юк минем. Тик котылырга насыйп булмаган икән. Машинаның ишеге шапылдап ябыла да, артка чигеп кабат минем белән тигезләшә. Бу юлы исемемне атап, абый, дип дәшәләр.

Яшьләр тиз үзгәрә шул. Күрше авыл егете Фәрит икән. Абыйсы белән бергә укыган, сүзләребез туры килеп, заманында дуслашкан да идек. Гомере генә озын булмады шул. Мәрхүм инде. Энесе үземне абыйсыдай якын күреп, кунакка кыстый. Сүзебез машинада дәвам итә. Тормышта кемгә ничек җай килә бит. Вакытында заманасының кая барганын тоеп, баеп калган Фәрит. Хәзер шул байлыгы үзе акча эшли.

Халык гайбәтенә кереп, гөмбәләр кебек үсеп чыккан зур коттеджларны күп күрсәм дә, моңынчы берсенең дә эченә кереп, адашып йөргәнем юк иде. Менә көтмәгәндә Ходай насыйп итте. Җитмәсә кунак булып. Яши белә безнең байлар! Җыен ангыра, әрәм тамак түрә булды, дип юкка сүгәбез, җәмәгать. Мондый лабиринтларны уйлап табарга да баш кирәк.

Һәркемнең күңелендә бер шайтан утыра, ди. Танышым йортын күрсәтеп, үз күңелен үзе күреп йөри. Сүз дә юк, сокланырлык. Йокы, ял, аш бүлмәләре. Сөйләү файдасыз, күрү кирәк. Арада иң гаҗәпләндергәне, танышымның ял бүлмәсенә терәп төзелгән төрмә-карцеры булды. Метр ярымга ике метр зурлыкта эшләнгән ул. Тимер рәшәткәле пыяласыз тәрәзәнең каршында ук агач сәндерә. Сыкранып ачылган оптик күзле тимер ишек. Шыксыз бүлмәнең эчендә күңелне өшетерлек салкын җил уйный. Оста яшерелгән магнитофон тавышыннан үзеңне тулаем төрмәдә утырган кебек хис итәсең. Алла сакласын, башка әллә нинди уйлар килә монда. Танышым да еш кына уйланып, әлегә ярый чын төрмәдә утырмыйм, дип шатланып чыга икән моннан. Безгә бит мондый җиргә эләгү озак түгел, шуңа тормышның түмән белеп яшәп ятабыз, ди.

Коттедж күрсәм, Фәритнең карцеры искә төшә. Биектәнрәк егылган саен тән катырак җәрәхәтләнә шул. Бу очрактан соң артык байлыктан бәйсез җан тынычлыгыма сөенеп яшәвем әле.

### Балалы байлар

Хатыны өченчегә бәби алып кайтырга тиешле танышым, беренче көннәреннән үк борчылып йөрде. Сәбәбе дә җитди, хатыны үзе дә авырып йөри шул. Җәфаланмас иде дә, алдагылары икесе дә кыз булды. Ә кайсы ирнең, җитмәсә әле авыл җирендә, эштән арып кайтса да тупылдатып малаен сөясе килмәсен. Авылда ир бала булу сәясәт белән дә бәйле бит әле ул. Эшләүнең, йорт-җирне нигытуның да тәме башкача булыр иде. Дөньяга килеп, Ходай биргән шатлыклардан кемнең баш тартасы килсен. Ир бала, дигәндә «үлә» иде инде.

Ходай «бала табучы белән йорт төзүчегә бер җиңеллек бирермен» дигән ди бит. Тәвәккәл таш яра шул. Өйләренә кабат бала исе, шатлык индереп, тәки

малай алып кайтты бит хатыны. Кызларын күрсәгез иде сез. Ире турында әйтеп тә торасы юк инде. Хезмәт ялын алганнан соң, ай буена урамда күренмәде ул.

Бу шатлык безнең эчкә дә сыймады. Шул турыда эштәге башка бер танышыма сөйләгән идем. Аптырады да, аннары әһәмият бирмичә генә, беренче балаларымы, дип сорады. Юк, мин әйтәм, өченчесе. Сүзсез калды танышым, ышанмады. Нәрсә, әллә икесе дә акчалы эштә эшлиләрме, дип сорап куйды. Үзем дә шул сораудан соң гына аның башта югалып калуының сәбәбен аңыштым. Күпсенеп аптыравы икән. Юк, дим кабат. Акчалы эштә түгел, ире әйбәт аның, хатыны шуңа курыкмыйча бала таба.

Уемда башка фикер. Акчалылар бала ташымый да ташымый инде хәзер. Татарның киләчәгенә өмет бирүчеләр күңеле бай булганнарда гына шул.

## Матдиләшәбез

Җиде-сигез еллар элек булган вакыйга бу. Бер танышыбыз әтисенең ычкыныбырак китүе, акча заманы булса да, җыен кирәкмәс төзү материаллары җыеп ятуы турында сөйләгән иде. Алган пенсиясен дә, өйгә китергән эш яисә читкә чыгып эшләгән акчаларын да кирпеч, такта, кадак ише әйберләр белән ала икән.

—Келәт, мунча, сарай түбәләре генә түгел, идән ассары, веранда, ул гынамы, хәтта кунак өенең караватасслары да тулды инде. Өй дә зур, яхшы әле. Аңа түгел, минем гомергә дә җитә. Абыйның да тормышы әйбәт, үзенә үзенеке җитәрлек. Сеңелләр дә кияүдә, аларның да тормышлары кешенекеннән ким түгел. Картаеп беткәч инде нинди уйлар кереп оялады икән башына, ди танышыбыз.

Кеше очрашмыйча тормый бит ул. Кабат очрашкач, танышыма әлеге вакыйганы исенә төшердем. Ә ул елмаеп кына:

—Минем әтидә дәүләт ирләрендә булмаган акыллар бар икән,—ди.

Үзенең колхозда эшләп өч еллык акчасын ала алмавын, ә әтисенең шул арада иске өйләренә терәп таштан зур, түрәләрнекеннән дә ким булмаган коттедж салып куюы турында сөйләде.

—Бу хәлләрдән соң үзем генә бик гарьләндем—ди. Колхоздан да чыккан. Хәзер әтисенең һөнәрен өйрәнеп өендә генә эшли икән. Эшне өйгә китерәләр, акчасын да эшләгәнче үк түләп куялар. Эшенә дә күңеле кайчан ята, шунда чыгып эшли икән.—Җан рәхәте икән, малай, үзеңне бәйсез һәм кешегә кирәкле сизү. Күпме гомер заяга узган,—ди. Рәхәтләнеп мактанды. Барысы да яхшы икән егетнең. Дөрес, тик элеккедән үзгә иде ул, хисләре азрак, киләчәк планнары да күпкә матдиләшкән иде...

## Җае чыккан җайсызлык

Элегерәк безнең якның бер яхшылыгы, мактанырлыгы бар иде. Юлда кеше калдырмадылар. Шофер халкы да тәрбияле, авыллардагы халыкның да бердәм чагы. Берара милиция халкы күбәеп, штрафлардан соң калган хезмәт хакы яшәргә җитми башлагач кына утыртмый башладылар. Шофер халкы унайсызланып, йә янга карап, йә башын аска иеп китә торган булды. Хәер, дөнья булгач, төрлечә була инде. Милициясе дә шул халыктан чыккан кеше иде. Өстән кушкач, ни эшләсен, якын туганына да штраф салудан тартынмады.

КамАЗ юлы чатында машина көтеп, таптанып торам. Үзем генә булсам, уйлана-уйлана күптән кайтып җиткән дә булыр идем, янда кечкенә малай бар шул. Кешесе дә күп. Җыела торалар, утырып китә торалар. Чират юк. Яшь бала-чага беләнме син, олы кешеме—аны уйлаучы юк. Әллә нигә бер кайтучы булгач, бәлкем, сан да юктыр. Барына да кул селтәдем дә киттем малайны сөйрәп. Көннәрнең озын чагы, ике-өч сәгатьтән кайтып җителер әле. Әмма ун-унбиш адым да китеп өлгермәдем, арттан куып җитеп бер машина туктады. Борылып та карамаган идем югыйсә. Безнең авылны узып йөрүче бер танышым икән. Болай булгач, капка төбендә үк төшеп калырга насыйп иткән икән Ходай. Сөйләшеп киттек. Юлда олы кешеләр дә, бала-чагалысы да очрый. Машинада ике-өч кешелек буш урын булса да, туктарга уйламый танышым. Юлда калганнар өчен борчылып барам. Әле үзем дә күпме вакыт элек кенә шулар хәлатендә идем.

Шофер нигә борчылганымны аңлагандай сүз башлый.

—Төрттереп әйтүем түгел, энекәш, яратмыйм мин булдыра алмаган халыкны. Азрак башы, сәламәтлеге булган кешегә машина алу чүп кенә хәзер. Җаен гына белергә кирәк. Хәзер кул көче дә кирәкми, бар байлык аунап ята.

Сатулашмадым. Бәлкем, шулайдыр. Тик һәркем дә совхозның ягулык-майлау складында эшли алмый шул. Хәер, ана бу турыда әйтсән дә, барыбер үпкәләмәячәк. Үзенең юлда калган кешеләр өлешенә керүен дә аңламаячак. Хөкүмәтнең халыкны талап яшәве белән дә ризалашмаячак. Аның фәлсәфәсе бер—күпме таласаң да, хөкүмәт бөлми ул.

Шул уйлар белән кайтып җиттек. Рәхмәтемне әйтеп машинадан төшеп калганнан соң, нигәдер җәяү кайтканнан да җайсызрак тоелды.

## Кемнәр булып бетәрбез...

КамАЗ юлы тукталышында, кызы белән оныгын озатырга дип, бер әби басып тора. Әби белән кызы үзара татарча сөйләшсәләр дә, оныгы, әбисенең сүзен бүлә-бүлә, нидер сорый:

—Аби, абиясни, аби, дим, абиясни.

Ниһаять, әбисе, сүзеннән бүленеп, такыр урысчасы белән:

—Ышту нады, дучинкә,—дип сорарга мәҗбүр булды. Күрше татар авылында яшәүче әби белән оныгының сүзләренең мәгънәсе аңлашылып бетмәде.

Әбиләре озатканнан соң, әнисе белән автобуска утырып киткән бу бала өчен борчылып калдым. Без, татарлар, мишәр, крәшен, болгар ишеләрдән башка да, милләтче, манкорт һәм «интерлар»га бүленеп беткән.

Ә бу сабыйдан тагын кем чыгар?..

## Биләүсез бишек җыры

Юллар йөрелми тормый. Очраклы кешеләр белән дә танышасың. Күңелләр тибеше бер ешлыкка туры килсә, дуслашып та китәсең, яшьләр аермасы да сизелми. Шундый танышым белән Татарстан авылларының берсендә йөрибез. Ул миңа каршыбыздагы үз авылының тарихын сөйли. Авыл зур, төзек. Авылның элекке чорын ул сөйләгәнчә күзаллавы да кыен. Өйләрендә тырыш хезмәтчеләрнең яшәве сизелеп тора. Аптырарлыгы юк, үзебезнең татар авылы инде. Бара торгач, юлыбыз авыл читендәге җирдә ялгызы тырпаеп торган ярым җимерек йортка килеп терәлә. Танышым авылның тискәре якларын яшереп торуны кирәк тапмаган. Күңелен борчыган сәбәбе дә бар икән. Язмышы турында гыйбрәтле хәл сөйли. Әлеге өйдән типсә тимер өзәрлек биш егет чыккан. Бәхетләре дә булмаган түгел үзләренең. Картлар әйтмешли, күбесе Татарстаныбызның олы шәһәрләрендә зур урыннарда утыралар икән. Үзләренчә дәүләт өчен олы эшләр дә башкарган алар. Бары туган йортларына гына игътибар итәргә вакытлары житмәгән. Аптырамадым. Шаккатырлык берни дә юк. Мондый эреле-ваклы очраклар бүген дә авыл саен берничә.

Шулай да кызыксынып якынрак киләм. Ярым җимерек өй түбәсенең эчке ягында эленгән бала бишеге күренә. Җил, кайсы яктан исүенә дә карамастан, үз баласын карагандай, назлап тибрәтә икән аны.

—Төннәр буе шыгырдап чыккан тимер тибрәтмәнең сыкрануы бала тавышы чыгарып, авылның әллә кайсы урамнарына чаклы ишетелә,—дип сөйләвен дәвам итә танышым.

Әйе, гыйбрәт алырлык хәл шул. Әмма барыбер бишектә тибрәлеп, кеше булган егетләрдән көлүем түгел бу. Бәгырьләрне телеп үземнеке искә төшә. Башкалар да уйлансын. Гомернең иң гөнаһсыз чорларын үткәргән безнең бишекләр кай җирләрдә тибрәлеп, нинди утын әрдәнәләре арасында ягылыр чиратын көтә икән...

## Кемгә—нәрсә

Казан ягыннан килүче йөк машинасы кабинасында, өченче кеше булып, авылга кайтып барам. Юлыбыз КамАЗ юлы аша уза. Миннән алда утырган олы яшьтәге абый үзеннән күпкә яшьрәк шофер белән уртак тел тапкан да инде.

Соңрак миңа аларның туганнар булуы да аңлашылды. Сөйләшкән сүзләрендә—авыл язмышы. Бәрәңге сату, утын-печән әзерләү һәм башкасы. Хисаплары да бар. Үзләренчә. Сөйләшкән сүзләре уйларымны бүлеп колагыма керә.

Минем өчен кызыгы шунда—олырагы, бар эшнең, малның бәясен бер капчык он бәясе белән үлчәп, элекке вакытта шул чаклы азык белән күпме кешене ачлыктан коткарып булыр иде, ди. Икенчесе, яшьрәге абыйсы санаганнарның барысын да шул акчага күпме шешә аракы алып буласына кайтарып калдыра. Ике капчык бәрәңге, бер капчык он яисә дүрт литр аракы бәясенә төшә. Ә менә бер машина утын бәясе өч йөз сум, ягъни ун шешә аракылык икән.

Кемгә—нәрсә, кәҗәгә—кәбестә, дигәндәй, мин дә уйландым аларның сөйләшкән сүзләреннән соң. Мәктәптә эшләгәнлектән, татарча өйрәнүче балаларның өчесенә бер китап белән укып җәфалануларын беләм. Шуның аркасында әти-әниләре, күрше-тирәләре күпме азаплана. Туган телебезгә булган карашны да исәпкә алырга кирәк бит әле. Шуңа күрә чагыштыруым да үземчә, исәп-хисапларым да авыл агайларыныкыннан югарырак минем.

Сувар фирмасы юкка чыгарган йөз миллион доллар, төрек Дигереның кесәсенә кереп эрегән егерме биш миллион доллар, ат, машина чаптырып, шар куып җилгә очкан миллиардларча сумнар... Бу акчага бер балага гына түгел, Татарстанда яшәүче һәр кешегә меңнәрчә китап чыгарып була. Ул чакта яшьләрнең дә язмышлары үзгәрәк, тормыштагы исәп-хисаплары башкачарак булыр иде.

Кеше акчасын санавым түгел, хөкүмәтнең кесәмнән урлаганнарын барлау әле...

## Теләк

Бер танышымның кызы быел тугызынчы класста. Әтисе белән якыннан аралашкач, кызы да үз итеп, күңелен борчыган уйларын бүлешеп йөри. Шулай бер көнне килде дә, татарча исәнләшеп:

—Татарчагамы әллә урысчага өйрәнү җиңелме?—дип сорады.

Сәяси мәсьәлә бу. Соравына төплерәк җавап эзләү өчен вакыт оту кирәк, шунлыктан:

—Нигә андый сорау кызыксындырды әле кинәт кенә?—дим.

—Миңа татарча өйрәнергә кирәк, азрак аңласам да, яхшы белү өчен мөмкинчелек юк. Әни урыс милләтеннән булгач, өйдә барысы да урысчага кайтып кала. Әтинең татарчага күчүен, салып кайтып, әнигә җикеренгәндә генә ишетәбез,—ди кызый.

Татарчага яхшылап өйрәнергә теләвенең сәбәбе белән кызыксынуымны дәвам итәм. Кызый кызара-кызара аңлата. Ниһаять, мин дә аңышам. Әнисе үзе тукып тора икән. Эштәге иптәш хатыны кызының яхшы эшкә урнаша алмавының сәбәбе, татар телен белмәүгә кайтып калган. Һәр ата-ана үз баласының яхшы, акчалы эштә эшләвен тели бит. Агачта шул чикләвек! Тел белү кирәклеген бары сөйләнүгә генә кайтарып калдыруга караганда, бер дәлилле эш күрсәтү күпкә нәтиҗәлерәк.

## Тырма

Гыйбрәтле хәлләр адым саен, күңелеңә салып, ялгышлардан гына саклан. Әти-әнисе чуашлар иде кызның. Балалар, чуаш, дип котырткач, бәләкәй чакта гел «мин урыс кызы» дип елый торган булган. Инде үсеп житкәч тә әти-әнисенең өйләрендә дә, урамда да үзара һаман чыштын-пыштын рәхәтләнеп үз телләрендә аралашып йөрүенә карамастан, кызлары «рус милләте» дип язылган паспорт ала. Аннары әтисенең туган ягы Канашка кайтып, педтехникумга гариза яза. Тик, яхшы укыса да, конкурстан үтә алмый. Сәбәбе—чуашларга да милли кадрлар күп кирәк икән. Хәзер инде гыйбрәт итеп сөйләп, олылар көлә. Кыз үз гомерендә бер тырмага икенче тапкыр басты.

## Гөнаһлы уй

Кирмән каршындагы Казансуда коенабыз. Шунда бер исерек килеп, ярым татарча, ярым урысча, похмельдән үләм, бер-ике сум гына булса да бирегез, дип

елап, соранып йөрде. Танышларыбыз Татарстанга чиктәш төбәкләрдән килгән археологлар иде. Бу хәлгә чаклы берсенә—Самарадан килгән Вадимга, үзе кызыксынып сорашкач, Казан һәм татар халкы турында горурланып сөйләгән идем. Шуны искә алып булса кирәк, Вадим чеметеп алырга теләп:

—Монысы да Казан бизәге, сезнең халыкның бер гүзәл сыйфатымы?—дип ачы көлде.

Бар дөньясына ачуым килсә дә, тыныч кына:

—Шатлана аласың, болары Мәскәү сәясәтенә яхшы бәя, урыс аракысын эчеп, юкка чыкканнар токымыннан,—дидем.

Вадим тиз җавап тапты. Башка авыз ачып сүз әйтерлекне калдырмыйча:

—Горурлыгы булганнар читләргә иярми,—диде.

Гөнаһлы уйларга батып, теге якташымны бәреп үтерердәй булдым...

## Үзгәреш

Яшь чакта кем көндәлек язмый да шигырьләр белән җенләнми инде. Очраган бар канатлы сүзләрне дә күчереп барасың. Алда бар дөнья синеке. Шул канатлы сүзләр арасында бер күнелгә ятмаганын да хәтерлим. Анда—«Утыз яшьтән соң кешенең дөньяга, кешеләргә карата булган ышанычы югала. Югалмаса, син—көчле кеше»,—дип әйтелгән иде. Кайсы бөек тилесе әйткән булгандыр, анысын хәзер хәтерләмим инде. Дөресрәге, язып куймадым, ышанмадым мин аның сүзләренә.

Еллар үткәч, уйланам менә. Еш кына кешеләргә, җәмгыятькә ышаныч югала. Яшьләре дә безнең кебек түгел. Бу елларда минем дә дөньясына карап, кешелеклек, тигезлек, игелек, туганлык, мәрхәмәт кебек төшенчәләргә, хыялый буш сүзләр санап, ышаныч югалды. Югалыр да шул. Үзем дә кырыкка якынлашам бит. Бары шунысы сөендерә—көчле кеше булмасам да, бөек тилелектән дә азат мин.

## Ярдәм итәсем килә

Кечкенә чагымда туган абыйга ияреп урманга мендем. Утын әзерләшергә. Хәер, утын әзерләүне дә ял урынына күрер иде ул. Үзе белән пешерергә бәрәңгесен, кыздырырга итен алыр. Кырык төрле үлән салып чәен кайнатыр иде. Шулай утын әзерләшеп, чабып йөргәндә, әллә каян гына сарык көтүе килеп чыкты. Мин учак, ризыклар янында бөтерелгән сарыкларны куа башладым. Күп тә үтмәде, бер олырак яшьтәге апа килеп чыкты да:

—Төнлә туган, ник куасың ул сарыкларны?!—дип мине әрли башлады.

Мине тетрәндергәне, хәзергәчә истә калганы апаның тонык, төссез күзләре иде. Шул чакта туган абый да килеп житте. Апаның соңгы сүзләрен ишетеп калган икән.

—Таһирә, син бит үзең ничә иргә барып төнлә түгел, көндез дә бала тапмадың. Нигә кеше баласын алай диеп гөнаһсызга рәнҗетәсең?—диде.

Юк, каты бәрелмәде ул. Апаның үзен жәлләп, күнеленнән әйтте. Таһирә апа каршы дәшмәде, оялып кына китеп барды.

Хәзер телевизордан картлар йортындагы ялгыз әбиләрнең монсу карашларын күргән саен, Таһирә апа искә төшә. Язмышы ничек булды, картлык көнендә таянычы, ярдәм итүчеләре бармы икән? Күзләренә шатлык иңдереп, аңа ярдәм итәсем килә.

## Горурлык

Горурлык, дигән нәрсә кешедә дә, хайванда да бардыр ул. Дөрес, бәлкем, микъдары төрлечәдер. Һәрхәлдә мин шулай уйлыйм. Табын янында бер абый, кулын юмыйча ашарга утырган улын битәрләп:

—Эчәргә биргән суга кәҗә алдында бармагыңны тыгып алсаң, кәҗә булып кәҗә дә ул суны эчми,—дип горурлыгына тигән иде.

Минем бер туганым унҗиде яшькәчә бер авыз татарча сүз ишетми яшәп, Пермь өлкәсеннән бөтенләйгә Казанга килеп төште. Укырга керде.

—Минем янымда татарча гына сөйләшегез,—дип безне әрли-әрли, ватажимерә булса да сөйләшергә өйрәнде.

Аның татарлыгы хәзер дә безнең ишеләрнең унысына житәрлек, тормышы да кешечә. Без еш кына әби-бабайлар тәрбиясе турында сөйләшергә яратабыз. Ә тирә-ягыбызда шундый «тәрбия алган» күпме тәрбиясез йөри! Урыс жирлегендә яшәгән бу туганыма каян килгән соң мондый тәрбия?! Кайда, баш миенең кайсы почмагына яшерелгән ул?

## Авторитет

Әфган, Тажикстан шаукымы авыл жиренә ук килеп житәр, дип кем уйлаган. Армиядәге егетләрнең берсе—Закир алып кайткан аны. Баштарак ай буе суга манчылган ипидән башканы ашказаны кабул итмәгән, дип сөйлиләр аның турында. Сонрак әлеге гадәтеннән бизсә дә, йокыдан кычкырып уянып, пычакка ябыша торганы калган. Сөйләшкәндә урыс анасын искә алыр, күренгәндә кулында еш кына татар тустаганы булыр, диләр.

Ул кайткан көннән авыл егетләренә генә түгел, ә тирә-яктагыларына да көн бетә. Барысы да, тау арасына урнашкан кечкенә авылны, үз кызларыгыз үзегезгә булсын, дигәндәй әйләнеп уза башлый. Каз урлап, «тюремщик» атамасы алган Жаппарга да көн бетә. Әле моңынчы авылда мин кем дип күкрәк киереп, кеше куркытып йөрүче ул була. Закир аны кайткан көненең икенчесендә үк, кыек караганы өчен, тиз генә кеше күзенә күренмәслек итә. Кыскасы, кайтуына ике-өч айлап кына вакыт узса да, Закир турында сөйләнгән мажаралар таң калырлык, кеше ышанмаслык иде.

Авылына кунакка кайтып, күршесе турындагы әлеге гайбәтләрне ишеткәч, аптырашта калган бер очракны сөйләгән танышым.

—Кайчан гына үсеп житеп, армиягә дә барып өлгерә соң болар? Әле кичә генә маңкасын агызып, абый, абый, дип арттан чабып йөрер иде. Үзебез хезмәт иткән армиянең һәр көне роман язарлык булып истә калган. Шулай тиз узамы икәнни соң бу гомер дигәннәре?—ди.

Әмма аңа озак аптырап йөрергә туры килми. Кайтып ике-өч көн узгач, Закир белән бергә сыер көтүенә чыга. Дөрестән дә, Закирның кичтән кәефе яхшы булган ахыры. Иртән ул түмгәк саен баш төртеп йокымсырап йөри. Көн тулы көченә кергәч, кеше исәбенә кереп сөйләшерлек хәл ала.

Әйе, беренче карашка танымаслык, элекке «Кирмүш» малае Закир булмый ул. Сөйләгән сүзе «мат», мәгънәсе фәләнне, фәләнгә, фәлән чаклы. Сыерларны сүгеп туйгач, шундыйрак жөмлә төзелеше белән танышыма үзенең кичә башыннан кичергән мажараларын аңлата башлый. Жай белән берара тыңлаганнан соң:

—Беләсеңме нәрсә, Закир, сине генә түгел, мин әле синең әтиеннең дә армиядән кайтканын хәтерлим—дип, ул аңа үз хикәясен сөйли.

—Мине тыңлый-тыңлый күршемнең кыяфәте үзгәрде, күзләре зурайды, авызы ачылды. Соңрак аяк буыннары бушап, яныма чүкте. Мавыктыргыч итеп, озак сөйләгәнмен, күрәмсең. Берара аңышып китсәк, көтү таралган. Закир мине урынымнан да кузгалтмады. Абый, утыр, утыр, дип, тиз генә көтүне жыеп куйды. Аннары кабат килеп, абый, әйдә, капкалап алыйк әле, дип, бар булган ризыгын алдыма тезде,—ди.

Шул хәлдән соң алыштырып куялармыни Закирны. Көне буе яшь бала кебек чабып йөри ул аның артыннан. Танышым аңа әби-бабалары турында, авыл, татар тарихын сөйли. Акыл өйрәтмичә генә, үзе аңлаганча яшәү фәлсәфәсен аңлата. Сорауларына жавап бирә.

Бүтән бер дә әллә нинди күренми аңа Закир. Шуннан бирле үзе дә кеше гайбәтен тыңламый, ишетсә дә, ышанмый.

## Мәгънәле казык

Хәзерге шәһәр балалары читән казыгының нәрсә икәнен дә белмиләр инде. Хәер, авылда туып үсмәгәч, гажәп түгел анысы. Үзебез дә белмәс идек, кечкенәдән читән казыкларына эләктереп, ыштан балакларын ертып үсмәсәк. Һавадагы тимер казык йолдызына борынгы бабаларыбыз атларын бәйли торган булганнар, дип тә сөйләгәннәр иде тарих дәресендә. Дөньяның тоткасы да тимер казык белән бәйле икән.

Элегрәк авыл жиренең бар тотанагы да шул казыкта булган, дип уйлыйм

мин. Казыкны очлауның да үз хәйләсе бар. Шулай да казык белән бәйләп әйтәсе килгән сүземнең мәгънәсе башкада.

Кечкенә чагымда әти белән су буенда читән тотабыз. Әти казык урынына чи тал агачларын очлап әзерли. Үзе:

—Бар әле, башкаларның читәннәре ничек эшләнгән, карап кил,—ди.

Ә мин әйләнеп килдем дә аларның бар казыклары да имәннән икәнен искәрттем. Әти шунда елмаеп:

—Имән нык агач инде ул, шулай да, улым, коры агачка караганда тере агачның гомере озынрак була,—диде.

Дөрестән дә, бар хикмәт тамырларда икән. Шул ук елның җәендә әтинең барлык казыклары да тамыр җибәреп үсеп киттеләр.

Бүгенге көндә су буендагы элекке читән урыны белән күршебезнең имән казыклары юкка чыккан инде. Ә әтинең каккан казыклары урынында ел саен орлыкларын тирә-якка очырып, тал агачыннан торган урманчык үсә.

Әтинең мина биргән дәресен аңладым. Тик менә уйлап торам әле, малайга казыкны да, аңа бәйле тормыш тамырларын да яшәешебезгә бәйләп ничек аңлатасы?..

## Ялгыз кабер

Авылыбызга кайту юлындагы урман почмагында, юлдан ике-өч метр гына эчтәрәк урнашкан бер ялгыз кабер бар. Авылдашларның күбесе белми инде аны. Үземә дә кечкенә чакта бабам күрсәткән иде. Ул чактагы чокыр сыман уелган урын, бүгенге көндә беленмәс тә булыр. Урман юлыннан узган саен, әлеге кабер кылт итеп исемә төшеп, уйландырмыйча калмый. Кемнәр тапкан, кемнәр баккан бит аны. Кызыксынып сорашмыйча да калдым шул.

Әлеге уйлар КамАЗ юлы буйлап Казан чүплеге тирәсеннән узганда да еш искә төшә. Чөнки юл йөрүләремнең берсендә очраклы танышым аңа төртеп күрсәтеп:

—Казанның иң зур, билгесезләр каберлеге шушы була инде,—дип кеше ышанмаслык хәлләр сөйләгән иде.

Имеш, ул чүплектә йөзләгән кеше чүп-чар белән бергә түгелгән. Бомжларны, хәбәрсез югалганнарны да әллә каян эзләп йөрисе юк икән...

Урман янындагы ялгыз кабер өстендә агач шаулый. Ә бу «каберлек»тә, бөтен Казан шакшысын изеп, заман техникасы кайный. Кайда ятуы тынычрактыр әле? Аларга барыбер дә бит, үзебез—исәннәр өчен борчылуым.

## Килмешәкләр язмышы...

Яңа урынга күчеп килгәч, проблемалар чүп түгү урыныннан башланды. Унике квартиралы, ике катлы йорт белән янәшә шуның биеклегенә җитәрлек чүп тавы өелеп тора иде. Үзебезгә бу йомышны беренче вакытта төннәрен үтәргә туры килде. Укытучы башың белән оятын кая куярсың? Шулай да соңрак ияләшелде. Көпә-көндез өй янына чүп түгүнең бер нәрсәсе дә юк икән.

Бу әле ияләшүләрнең башы гына булган. Монда үзем белән булган тагын бер кызыклы хәл дә ярдәм итте. Квартираны үзебезчә тәртипкә китереп йөргәндә, идарәгә барып такта яздырып алырга исәп иттем. Әмма минем бу үтенеч анда эшләүчеләрне зур гаҗәпкә калдырды. Соңыннан билгеле булганча, бистәдә егерме ел инде беркем дә такта яздырып алмаган икән. Ә аның бәясе язылган китап та тузанга капланып, кулга тотарлык хәлдә түгел иде. Хезмәттәшләре янында югалып калуыннан ни эшләргә белмичә торган бухгалтер апа, җаен табып, мине коридорга дәшеп алды. Аннары үзебезчә:

—Энем, зинһар башымны катырып йөрмә, пилорамга барып сүз катсаң, сиңа тактаның нинди кирәк, күпме кирәк—барын да үзләре китереп бирерләр. Теләсәң, кирәк әйберенне ясап та куярлар. Бер-ике яртыга тау күчерәләр монда. Ул кәгазьне тутырганым да юк, җаен да белмим, безне унайсыз хәлдә калдырып, кеше көлдереп йөрмә,—дип җинелчә генә әрләп чыгарып җибәрде.

Үземне гаепле кешедәй тоеп пилорамга юл тоттым.

Дөрестән дә, агач эшкәртү цехына барып йомышымны әйткәч, барысы да хәрәкәткә килде. Такталарны шомарттылар, өйгә үк китереп бирделәр.

Иялəшелде. Соңрак аңладым, мин тора башлаган жирдə элек-электəн гомер итүчелəрнең саны берничə генə булып, калганнары бары да минем кебек килгəн жыен килмешəк икəн. Аерма бары шунда, кем алданрак, кем соңрак килеп урнашкан. Ə жыелган жирдə халык чуар, аларның килеш-килбəте, үзлəрен тотышлары да төрлечə. Җəмгыятьнең үз кануннары монда. Бар нəрсə дə сатыла һəм сатып алына. Һəркемнең үз тəгълимате.

Аларның бары тик бəйрəм итүлəре генə бер төрле—урысча иде.

## Тегермəн

Кунакка кайткан саен энемне яныма утыртам да авылның бар булган яналыкларын сорашып чыгам. Гайбəтлəрен, имеш-мимешлəрен дə тынлыйм. Бездəн сүз чыкмас, алай да барын да белеп тору барыбер кызык бит. Бу юлы да шулай булды. Əмма игътибар итəрлеккə санамыйча, энем, авылның иске тегермəнен сүтеп, утынлыкка алып китүлəрен əйтмичə калдырган икəн.

Соңгы вакытта бигрəк тə сокланып карап йөри идем мин аңа. Тарихын да сорашып белешкəн идем. Утызынчы елларда төзелгəн бу тегермəн авылда шул заманны саклаган бердəнбер бина иде. Биеклеге ике катлы булып, бурау ысулы да хəзерге заман йортларыннан үзгə. Əйтерсең лə борынгы кирмəн стеналары. Дөресрəге, авылымның ачык һавадагы бер музей экспонаты иде ул.

Күнелдə кечкенə чактагы хатирəлəр янара. Əнилəр ашамлык пешерерлек оннары булмауга зарлана. Ə күрше авылдан кибеткə кайткан ипи авыл халкының яртысына да житми. Əле анысына да чиратны көтү вакытыннан алып, аны без бала-чагага көне буе сакларга кирəк. Ул елларда кибетлəрдə он сатылмый. Колхоз тегермəнендə дə тарттырырга рөхсəт юк. Шунлыктан, тегермəнче Имай бабайны бəхиллəтеп, булдыра алганы кеше-кара күрмəгəндə төнлə урлап тарталар иде. Без, тамагы ач бала-чаганың да иң еш уйный, буталып йөри торган урыны шул тегермəн тирəсе булды. Аһ ул тегермəн тирəсендəге он исенең тəме! Эчкə кереп, тегермəн ташының шыгырдаганын карап, азрак онга буялып чыгу да жан рəхəте. Ə инде ап-ак онга буялган тегермəнче бабай үз итеп күз дə кысып жибəрсə, күнеллəр күккə аша...

Егерменче гасырның соңгы елы. Бар дөньясы газ ягa. Анда Татарстан, татар халкының өлеше булса да, шактый күплəр əле газсыз утыра. Авыл укытучысына, утыны булмаганлыктан, тегермəнне сүтеп ягырга рөхсəт биргəннəр. Заманында бар авылны ашатып, ачлыктан саклап калган тегермəн бүгенге көндə юк инде. Кешегə акыл кертə-кертə картлык килə. Акыл кергəн саен дөньясының яме бетə...

Күнелемдə бүген аның тагын бер кисəге кителде.

## Түрəлəрне олылап

Күрше урыс авылы Шомбытның тарих төпкелендə татар катламнары ята. Шунлыктан атамасы да тирə-як татар авыллары телендə төрлечə йөртелə. Аларның берсе—Бурансау. Бу атама Шомбыт авылы урысларының язмышын билгелəгəн, аларны жыеп, берлəштереп торучы спирт заводы хужасы Воронцов исеменнəн үзгəртелгəн. Петербургта яшəп, шуннан идарə иткəн дворяннар нəселеннəн ул.

Хужаларын олылый белгəн урыс халкы. Хəзергə чаклы олы кешелəр Воронцов килгəн заманнарны хəтерли, уздырылган чараларны сагынып искə ала. Хатирəлəре каршы алудан ук башлана. Кем дə кем хужасын тезлəнеп барып беренче каршы ала, хужаның кулын үбеп:

—Хуш килəсен, хужам!—дип əйтергə хокукы була.

Сүз дə юк, биш тиенлек хəтле алтын тəңкə дə тигəн. Шундыйларның берсе, тезлəрендə дүрт чакрым юл үтеп, соныннан өч ай аягына баса алмаган, дип сөйлилəр. Воронцов, елга бер тапкыр килеп, завод эшлəрен барлап китə торган булган. Ул килгəн хөрмəткə заводның капкасы төбенə мичкəсе белəн спирт тəгəрəтеп чыгарганнар. Мичкə өстендə—тустаган. Эчүгə килгəндə, кем күпме булдыра ала, үзең белəн генə алып китмə. Бу чара, чама хисен белмəүче урыс халкыннан ел саен кимендə өч-дүрт мəет сораган. Гаеплене эзлəү юк, беркемне дə ирексезлəмилəр.

Бу хатирəлəр мина еш кына архивта документлар белəн эшлəгəндə искə

төшә. Анда сакланып калган гаризаларның барысы да:—«Прошу Вас...»—дип олы хәрефтән башлана. Түрәләрен олылап ыштансыз калган урыс халкы. Бүгенге халәте дә шуна бәйле.

## Язмышыңда ялгышсаң...

Казан урамын аркылыга чыгып киләм. Чыгасы якта мина карап бер кыз елмая. Ир йөрәге сиксәндә дә сикерә бит ул. Мин дә яшь чагыма кайтып эресәм дә, мина түгелдер, артымнан берәр яшь кеше киләдер, дип уйлыйм. Дөрес, әллә мин әле яшь кызларны каратмаслыкмы, дигән уйлар да башка кереп чыккалый. Машинага тапталу куркынычы да юкка чыгып, як-якка карау да онытылды. Кем икән бу бәхетле кеше, дип артыма борылып карыйм, ә анда... беркем дә юк. Гажәпсенеп кабат алдыма борылып карыйм, ә кызый инде мина кулларын болгый. Бәлкем, бу төштер, кулларым белән тәнемнән чеметерлек урын эзлим. Ләкин соң инде, чибәркәем кочакларга дип кулларын җәеп каршымда басып тора. Яхшылабырак карасам, туганымнан туган апамның кызы икән. Мине ерактан танып үзенә җәлеп итүе.

Менә шулай ул, туганыннның хәлен белешмәсән. Кызы инде үсеп житеп танымаслык та булган. Язмышында ялгышып ияреп кайтсаң... аңлатырлык сүз дә тапмассың.

## Бабасын исенә төшер

Ул елларда кечкенә авылларда сабан туйларын бетереп, колхоз-совхоз үзәкләрендә генә бәйрәм уздыру модага кереп бара иде. Яшьләр мона ризасызлык күрсәтәләр. Үзләре сабан туе үткәрү өчен яулык-сөлге җыеп, акчаларына сарык та сатып алалар. Әлеге уңышларны күреп бабайлар да йомырка җыеп, табын корып, үзләренә караган барлык эшләрне башкаралар. Тик бу эшләр читтән килеп эшләүче совхоз директорына гына бер дә ошамый. Районнан килгән фәрманны үтәргә кирәк бит. Башта дәшмичәрәк йөри дә, үз дигәнчә булмавын аңлагач: «Ну, фәлән кем малайлары, әйткәнне аңламаган өчен үкенерсез әле!»—дип янап китә.

Бу янауны ишеткән авыл картларының артык исләре китми. Аларның:

—Икенче юлы бәйләнә калса, бабасын исенә төшерегез сез ана, бабасында булган акылы да юк икән,—дигән сүзләрен яшьләргә житкерә-ләр.

Тик бабасына бәйле нинди дер вакыйганы күпме генә сорашсалар да сөйләмәгәннәр. Гайбәтен сөйләп гөнаһысына керәсе килмәгәннәрме, башка бер сәбәптәнме, белмәссең. Ләкин сонрак яшьләр, бу вакыйга белән кызыксынып, анын тарихын барыбер ачыклаганнар.

Анын бабасы гомер буе авыр тормышта булып, көтү көтеп, картлык көнендә кинәт кенә баеп киткән. Бу турыда да имеш-мимешләр күп, әмма эш анда түгел. Баеп, ике-өч хатын өстенә ялчылар тотса да, чыбыркысын чыгарып ыргытмый ул, киресенчә, түбәсенең иң күренә торган җиренә элеп куя. Ә инде холыксызланып киткәндә, ара-тирә узынып, хатыннарын әрләп, ялчыларын җәберләгәннән соң, түбәгә менгәндә, гомер буе сөйрәп йөргән чыбыркысына караган. Шуннан соң ул үзенә үзе:

—Ашыкма әле, син бит заманында хәерче бер көтүче генә идең,—дип өй түбәсеннән бөтенләй йомшарып төшә, соныннан хатыннарына да яхшы мөгамәләдә булып, ялчыларына да бүләкләр тарата икән.

Совхоз директоры элек үзе дә трактор артында утырып йөргән сукачы малай булган. Соныннан, тормышның жаена төшенеп, шул ук тракторчылар эшләгән совхозга баш була. Әмма вакыты-вакыты белән чамасын югалтып тузынгаласа да, бабасы кебек булмаган. Шунлыктан ана кирәкмәгәнгә узынган саен, авыл кешеләре еш кына бабасын искәртеп торганнар икән. Ә үзе аңламаган кешегә акыл бирүнең файдасы тигәндерме-юкмы, анысын әйтә алмыйм.

Бүгенге көндә анын заманы узган инде, пенсиягә чыккач, үзен дә онытканнар. Ә менә бабасын, әле хәзергәчә яхшылык белән искә алалар, ди.

## Җансыз Җәләй

Бу исемне ишеткәч, кайбер авыл картлары бүген дә тетрәнеп куялар. Заманында авыл советы рәисе булып, «Мин—Алла!» дип йөргән зат ул. Анын

карангы күләгәсе авыл өйләренең күбесенә авырлыклар китергән. Теге заманнарда нахак бәла ягылып, Себер киткәннәрне дә аның белән бәйлиләр. Заманы, дөрестән дә, аның ишеләрнең җаена килгән чагы. Совет властен атасының ярым җимерек өендә каршылый ул. Хәерчеләрнең (кешесенә карап) авторитеты зур була ул вакытта.

Сонрак, без үскәндә дә бу бер метр буйлы бөкерәеп беткән картны күрүгә малайларның «Җәләй килә!» дип кычкырып качканнары истә. Бу курку әби-бабайлардан күчкән. Булган икән шул заманалары! Кешеләр аның түш кесәсеннән чыгып торган кәгазь кисәге белән шәмәхә каранда-шыннан күбрәк курыкканнар. Аның шул кәгазьгә ни язуына карап, налогы күп түләнеп, башынның да себер китү ихтималы булган.

Шулай да алтмышынчы елларда бер тапкыр кикриген шиңдерәләр Җәләйнең. Җизнәсенең әшәкелеге белән бәйле оятына түзә алмаган хатынының энесе эшли аны. Кибеттә бер стаканны каплап, бар батырлыгын җыя да, тегенең түшендәге значогын йолкып ташлап, сазга изә. Ләкин түшендәге кәгазь белән каләме исән калганлыктан, бу хәлнең бәһасе ике ел утырып кайткан төрмә белән бәяләнә. Аның каравы ул әле бүген дә халык телендә батыр булып искә алына.

Бүген инде заманалар башка: Җәләй дә юк, аның өе дә, өенең нигезе дә юк. Әле авылга кайткач, кызыксынып сорашкан идем—нәселе дә калмаган икән...

## Менә шундый тарих

Авылның мәчет манарасын кискәндә, Гыйлаҗетдин абый үзенең энесе белән бергә Чистай ягында эштә була.

Аларның анда эшләп йөрүләренең бер мәгънәсе бар. Чөнки аңа чаклы авылда бер үзенчәлекле хәл булып ала. Нәҗми бабайның Мукшы авылы үзәненнән бер юлы ике аты югала. Кеше хакы белән яшәмәгәнлектән, атларын урлаулары турында исенә дә китерми ул. Әмма атлар юк та юк. Тагын берничә көн узып та атлар табылмагач, Нәҗми бабай авылга сөрән сала. Дөрес, ул елларда атлар еш югалганлыктан, авыл халкы моңа артык гаҗәпләнми. Әмма кич белән атларның табылуына өметен югалткан Нәҗми бабай янына авылдашы Гыйлаҗ керә. Ул үзенең бу атларны ялгыш башкалары белән бутап Чистай ягына сатып җибәрүен дә, инде акчаларны тотып бетерүләрен дә белгертә. Икенче көнне сатып җибәргән атларны күпме генә эзләсәләр дә, таба алмыйлар. Атның бәясен акчалата түләү килешүе белән энесен алып, Гыйлаҗ абый эш эзләргә чыгып китә.

Мәчетләренең манарасын җимерү хәбәре тиз килеп ирешә аларга, шул тынгылык бирми. Борчулы узган төннән соң, икенче көнне ук, вакытлыча эшләрен ташлап, авылларына кайтып китәләр.

Беренче эш итеп өйләренә дә кайтып тормастан, мәчет манарасының исән калган өлешенә кадаклап куйган кызыл флагны тибеп төшерәләр. Аннан соң Гыйлаҗ абый бөтен авылга ишетелерлек итеп азан әйтә. Атнага якын азансыз яшәгән авыл халкы шунда ук мәчеткә агыла. Авыл халкының хәер-догасын алалар алар бу көндә. Күңеле тулган Нәҗми бабай да кич белән өйләренә менеп, атларны урлау вакыйгасын кичерә. Акча алудан да баш тарта.

Әмма авыл халкының барысын да әлеге вакыйга бер төрле шатлан-дырмаган, күрәмсең. Иртә таңнан районнан килгән кораллы кешеләр алып киткәннән соң, бары ике елдан гына кабат авылына кайтып егылырга насыйп була Гыйлаҗетдин абыйга.

Авылдашлардан ишеткән бу вакыйганы еш сөйлим мин Гыйлаҗ бабайның оныкларына. Туачакларына да язып калдырам менә. Горурлан-сыннар бабалары белән, изге эш җирдә ятмасын.

## Урыс Хәбир

Армиядән күбәү кайтканнар алар ул елда. Барысы да бергә уйнап, кызлар артыннан чабып үскән егетләр булган. Киткәндә бер-берсен озата-озата сирәгәеп, ике елдан соң кочаклаша-кочаклаша күбәешкәннәр. Киткәнче бер калыпта булсалар да, кайтканчы гомер агышы белән армия таләпләре үзгәрткән аларны. Кемгә ирләр тавышы инеп, кемгәдер тәмәке исе дә сеңеп өлгергән.

Дөрес, күршедәге кечкенә малайлар да аерган әле аларны. Әллә кем абыйның алты гына медале бар, ә минем абыйныкы сигез иде, дип

мактанышканнар. Дөрестән дә, ул заманнарда армиядән нәрсә кирәк, күпме кирәк—барында тагып кайтырга мөмкин булган.

Аермалар тагын ниләрдә булгандыр, әмма берсенең искитәрлек булып авылны озак шаулатканын аерым сөйлиләр. Эш шунда ки, армиядән кайткан иптәшләренең соңгысы ике ел эчендә үз телен «оныткан». Хәер, ишләре моңа баштарак игътибар да итмәгән. Үзләренә дә ике ел эчендә урыс сөйләмен аңларлык итеп сеңдергәнлектән, әһәмият тә бирмәгәннәр. Шунлыктан авыл урамын әйләнгәндә дә елмаешып кына йөргәннәр. Ә инде һушларны алып, күңелләрен тетрәткәне кич белән аларга кунакка кергәч башланган.

Иптәш егетләрен жыеп кереп:

—Мамы, давай гони все что есть, братья пришли,—дип әнисенә ташлана.

Болай да улы кайткан сөенечтән ни эшләргә белмәгән анага яңалыкны кабул итүе кыен булган, күрәмсең. Күңелләрне эретерлек тавыш белән:

—Улым, картлык көннәремдә авыл кешесе алдында көлкегә калдырма инде, сөйләш үзебезчә генә, әнә, иптәшләрең кебек,—дип ялынган.

Әмма Хәбирнең артка чигергә батырлыгы житми.

—Чава-чава там ана бармочет?—дип иптәшләренә борылып, үз киресен сукалый.

Бу көтелмәгән күренештән яшьтәшләре кая кереп качарга урын тапмый. Жир дә ярылмады шунда, диләр.

Әлеге күренештән соң утырунын да рәте-чираты булмаган. Яшьләр торагында яшәгән чакта бу хәлне сөйләгән бүлмәдәшем:

—Хәбирләрдән чыккач, мин клубка да барып тормастан өйгә юнәлдем,—ди.

Шул көнне егетләр Хәбирне клубта яхшылап тотып кыйнаганнар. Икенче көнне инде ул чип-чиста татарча сөйләшә, ә урыслыгы аның бары исеменә генә тагылып калган. Авыл теленә бер керсән, гомерлеккә инде. Бу вакыйгага егерме еллап вакыт узса да, халык телендә һаман да «Урыс Хәбир» икән әле ул.

## Тарихи табылдык

Археологлар белән Мамадыш якларының тарихи урыннарын барлап йөргәндә, тап булдым мин ана. Техника кирәк булганлыктан, совхоз директоры янына иртән нарядка барырга туры килде. Урыс авылы булгач, ничек кенә жаена туры килергә белмичә баш ваттым, аңлармы ул синең тарихыңны? Кабул итү бүлмәсенә кереп, анда юан-юан урысларны күргәч, шикләрем тагын да артты. Шулай да чират фәлән көтеп тормастан, алга атладым. Үземчә директор дип язылган бүлмәгә кергән сыман идем, әмма кергәч тә башта, ялгыштым бугай, дигән уй туды. Чөнки түрдә тагын да юанрак урысларны калтыратып кечкенә генә бер кара өрәк сыманрак жан иясе утыра иде. Берара югалып торганнан соң, үземнең кем икәнлегемне һәм ни эшләп йөргәнемне генә аңлата башлаган идем, теге өрәк дигәнем яңгыравышлы татар телендә:

—Көчәнмә, энекәш, әйдә, үзебезчә генә сөйләш,—димәсенме?..

—Берәр нәрсә кирәк булса, туры үземә кил—дип озата чыгып, кантор төбеннән кирәкле техникасына утыртып та жибәрде ул мине.

Монысына гына аптырамадым ла мин: тәмле телле, яхшы күңелле ярдәмчел кешеләрне начальство арасында да күргән бар ла анысы!

Юлда барганда танышкан тракторчы Сашкага беренче сүз итеп үземне аптырашка калдырган соравымны бирмичә булдыра алмадым.

—Как,—мин әйтәм,—чип-чиста урыс авылында берләнбер директор гына татар. Нәрсә, үзегездә берәр акыллырак кеше таба алмадыгызмы әллә?—Ты что?—ди бу як-ягына каранып.—Безнекеләр күп утырдылар инде анда, барысын таркатып, эчеп бетергәч, үзебез кудык. Уйлаштык, киңәштек тә специально чакырып китердек. Татарлар эшләтә дә, ашата да. Дөресрәге, үзләренә дә өлеш чыгара, кешене дә онытмый. Аракы белән дә дус түгел алар. Нам другого не надо,—ди бу.

Аңлый алмыйм. Алтын Урда чорыннан ук калган нинди тарихи феномен бу? Тарихи табылдыклар, гасырлар кичеп, янәшәбездә генә яши бирә икән ләбаса. Ә без тагын аны жир астыннан эзләп йөрибез.

## Нигез

Авылдагы йортыбыз нигезе ике йорт арасына салынган. Беренчесен аның «кулаклар» дип үзебезнең бабайлардан тартып алган булсалар, икенчесен хуҗасы үзе сатып, күрше авылга күчеп китkән. Шунлыктан әти мина, бабаң еш кына, бу Хәлил абыең ничек туган нигезенә менеп тә карамыйча түзә ала икән, дип сөйли иде, ди. Соңгы вакытта әти үзе дә бабайдан кимен куймый, кайткан саен шул хәлне искә төшереп тора. Сизеп торам, өздереп әйтмәсә дә, минем чит җирләрдә йөрүемә риза түгел бугай.

Дөрес, без дә китми идек ул туган авылдан. Бабайлар язмышы безгә төшмәде, көчләп сөрмәделәр анысы. Тик шулай да ике яр арасында калдырдылар безне. Гомер буе бабайлар тарткан авыр йөкне тартасы яисә авылдан китеп, укып, дөньяны таныйсы. Нәрсә, без башкалардан кимме әллә? Әнә бит дөньясы да безне, урта гасырларда калдырып, үзе ни эшләп ята икән.

Табышлар югалтуларсыз булмас, ахры. Минем турыда да авылдашлар:

—Туган нигезен бетерде бу, кайтып та карамый,—дип сөйләмәсләрме?

Малай бар барын да, тик аның да кендеге җиргә берекмәгән, туып үскән кече ватаны да башка. Шунлыктан бу турыда сүз кузгатсам, ни өчен үзең калмадың соң, дип әйтүеннән куркам. Хәзер безгә дә космополитлар кебек «Туган җирем минем—җир шары» дип җырларга калырмы?

## Килмешәкләр урамы

Авылга кайтканда еш узыла бу бер яклы урамнан. Баш-башыннан узганчыга чаклы башны анда төзелгән йортлардан читкә юнәлтүе авыр. Бу караш аларның берсеннән-берсе төзек һәм матур булганга туа. Кешеләрнең мул тормышта яшәүләре күңелне сөендерә.

Күптән түгел генә бу урамның шул авыл халкы телендә «Килмешәк-ләр урамы» дип аталуын белдем. Баксаң, алар барысы да күчеп килүчеләр икән.

Килмешәкләр... Бу сүзнең мәгънәсен тулысынча һаман да аңлый алмыйм. Алардан көлү, дисәң, язмышлары инде. Кимсетү, дисәң, алар болай да бай. Юк, бу сүз бары тик буталмас өчен, авыл халкының гасырлар буе яшәп җыйган үзенчәлекләрен югалтмас өчен тырышканлыктан гына кушылган. Үпкәләмик аларга, барысын да бар булганча кабул итик. Бу дөньяда үзебез дә килмешәкләр, дөресрәге, вакытлыча гына килеп китүчеләр бит...

## Өметле качаклар

Соңгы елларда күп кайттылар алар. Төрле җирдән һәм төрлечә, машиналар белән выжылдаучылары да, өстендә ни булган шуның белән кайтучылары да булды милләттәшләрнең. Халык та төрлечә каршы алды. Берәүләренең бар сөйләнгәннәре «понаехали» булса, икенчеләре аңлап, дөресрәге, сөенеп тә каршы алды аларны. Мин исә бөтенләй башка яктан ачыш ясадым. Чөнки алар үзләрен чит итеп тә тоймадылар, мескен итеп тә күрсәтмәделәр. Кайттылар да җиң сызганып эшкә дә тотындылар. Ник берсе җебеп төшсен.

Ясаган ачышым тарихи яктан булды. Чөнки читләрдән кайтучылар күбесенчә утызынчы елларда туган җирләреннән китәргә мәҗбүр булган баш бирмәүчеләрнең ул-оныклары иде. Болар затлы нәселдән, шунлыктан мөмкинчелек чыгуга ук өзелгән тамырларын янарталар. Боларда өмет бар, файдалары да булыр әле...

## Дөнья тигезли

Күрше генә яшәгәнлектән, Ходай хакы гына да булмыйча, якын туганнар да иде алар. Ләкин бу туганлыклары да, якын күршеләре дә ике йорт арасында шаулап үсеп торган каен агачларына бәрелеп юкка чыга торды. Чөнки әлеге агачлар күршеләрнең берсен җил-давылдан, урам тузаныннан саклап торса, икенчесен көздән үк ишегалдын кар белән тутырган бураннары, кояш төшмәгәнлектән ярты җәйгә житкән пычрагы белән җәфалады. Яхшылык белән дә аңлаша алмадылар алар, бер-берсенә эшләгән этлекләренең дә файдасы тимәде. Дөрес, авыл халкына хас булмаган судка йөрүгә үк барып җитмәделәр, тик тормышлары төрмәдәгедән ким булмаган чаклары аз түгел иде. Ни эшлисең, бер ягы кояшны күчереп куя алмаганлыктан зарланды, икенчесе, әтисе утырткан

каеннарны балта-пычкыдан уздыра алмыйча, гөнаһысыннан курыкты.

Әлеге каршылыкларга игътибар бирмичә, гомер агышы үз юлын дәвам итте. Бүгенге көндә яртылаш бушап калган авылның әлеге ике йортында да хуҗасызлык хөкем сөрә. Яшьләр шәһәргә китеп, ата-аналары арасында булган низагка игътибар бирмәделәр, ә оныклары бу турыда бөтенләй дә белми булыр. Күршеләрнең араларын бозган агачлар да елдан-ел корып баралар. Хуҗалар үзләре дә исән түгел инде.

Хәзер зираттагы каберләрендә үскән агачларның кайсы кайсына күләгә төшереп җәфалыйдыр, төгәл генә әйтә алмыйм. Тик мона охшаш язмышлар безнең тормышта аз булмады. Ходай сакласын, гайбәтләрен дә сатуым түгел, гыйбрәт итеп кенә сөйләвем. Хәер, без инде ул бик гыйбрәт ала белүчеләр...

## Әнисезләр хыялы

Эштән кайтам да, бер рәхәтләнеп, кочарга килгән балаларымны сөям. Аларны яратканда гел әнием исемә төшә. Үсеп, инде егет була башлагач та:

—И, үз улым шул!—дип аркамнан сөеп ярата иде.

Ә минем бар курыкканым, күрше малайлары гына күрмәсә ярар иде, дип борчылу булды. Урамга чыккач, күзенне дә ачырмаслар. Шунлыктан:

—Әни алай каты кычкырып сөймә инде, күрше малайлары ишетә бит,—дип әйтә идем.

Бүгенге көндә әнием юк инде. Югалту авырлыгы да бары тик искә төшкәндә генә күнелне телгәли. Дөньясын бар булган килеш кабул иткәч, җиңелрәк. Әмма күнелдән һәрчак китмәгәне, үкендереп торганы да бар. Дөньялар яхшырып, үзебез дә эшләп, мөмкинчелегебез булган чакта юк шул әни. Иң авыры—әнигә яхшылык эшләп булмады кебек. Менә хәзер кунакка алып килеп, түр башына менгереп утырт та түләп бетерә алмаслык бурычның бер өлешен генә биреп куй иден...

Бу без, әнисезләрнең хыялы. Кызык, ә әниләләр ничек уйлый икән?..

## Аладан туган колалар

Күпләр кебек гади генә бер авыл егете иде Сәмигулла абый. Әмма беркатлылыгы аның үз тормышына гомер буена житәрлек тәэсир итте дә инде.

Әтисенә атлар карашып үссә дә, районнан килгән план буенча тракторчылыкка укып кайтырга туры килде аңа. Инде укып кайтып, яхшы гына эшли башлагач, колхоз рәисе чыгарып атты аны эшеннән. Имеш, ул тракторда килеш, юлдан каршыга килүче атлыга юл биргәндә, кырыйдагы кар көртенә кереп баткан. Колхоз җыелышында бар авылдашлары арасында хурлап, трактор түгел ат та жиктермим мин сина, дип куды. Монысы бер сәбәп кенә икән, дөресрәге, үз туганының малаена трактор кирәк була.

Тик шул хәлдән соң авылдан ук чыгып киткән Сәмигулла абый тракторның янына да бүтән барып карамады. Гомер буе ат өстендә килеш күрше авыл колхозының көтүен көтте.

Ә менә бер-берсенә терәлеп үскән өч малае да машинага утырдылар. Әтиләре белән булган хәл тәэсир иткәндерме, белмим, тик боларыннан атлыга гына түгел, җәяүлегә дә игътибар юк. Озын юлдагы олы кешеме, бала-чагамы, аны белү юк, выжылдыйлар да узып китәләр янынннан.

Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Менә уйлап торам әле, Сәмигулла абыйның малайларын нинди ачы заман жилләре үз яныннан читкәрәк илтеп ташлады икән?

## Казан күмәче

Кайда булса да кадерсез яткан ипи сыныгын күрсәм, әнием сөйләгәннәр искә төшә.

Әле сугыш беткән генә ел. Әни белән күршедә яшәүче олырак яшьтәге бер апа, Казанга баргач, авылдашлары янына хәл белергә керәләр. Тәмле сүзләр белән каршы алса да, әни хуҗа хатынның йөзендә борчылу сизә. Күрше бүлмәгә чыккач, бу хәлгә аңлатма тиз табыла. Хуҗа хатынның чәй эчәргә өйдә бер кабым ризыгы да юк икән. Әмма әни белән килгән олырак апаның авылда

беренче сүз йөртүче булуына күбрәк борчыла ул. Авылга кайткач: «Әллә кем кызы Казанда хәл белергә кергәч, чәй дә куеп эчертә алмады»,—дип сөйләп йөреп, әти-әнине борчуга салыр инде, ди. Шуннан соң күрше бүлмәдә алар әни белән бер план коралар...

Тагын азрак утырып авыл хәлләрен сөйләшкәч:

—Әсмабикә апай, юлга чыгыйк, кайтырга соңга калырбыз,—дип әни жәелеп утырган авылдашын кузгата.

Хужа хатын:

—Юк-юк, гомер эченә бер килгән кунакларны болай гына жибәрәмме соң, төнгә каршы да юлга чыкмагыз, кунып китәрсез, кая Казан кумәчләре белән майларымны турый торыйм әле,—дип аш бүлмәсенә юнәлә.

Әмма әни юлдашын, ай-вайына да карамыйча, жилтерәтеп алып чыгып китә.

Казаннан ике көн уфалла тартып кайталар алар. Әни:

—Әсмабикә апаң шул вакытта, Гамилә, нишләп чәй эчертмәден, үлеп тамагым ачкан иде минем, дип кабатлый-кабатлый гомер буена житәрлек итеп бәгыремә үтте,—дигән иде.

Әниләрнең тормыш тәжрибәсен өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле. Без ипибәрәңгедән өзелер-өзелмәс кенә булсак та, кунак килсә, әнинең өстәле сыйнигъмәтләрдән сыгылып торыр иде. Гомер эченә бер килгән кунак алдында оятка калмаска аларны тормыш үзе өйрәткән. Безгә дә кунаклар килә, вакытына карап, оятка да калабыз. Юклыктан түгел. Иртәгәсе көн турында уйламыйча яшәргә өйрәнгәнлектән.

Әниләрнең Казанда яшәүче авылдашлары Хәлимә әби бүген дә исән әле. Очрашкан саен:

—Улым, әниеңне хәер догадан калдырмыйм, эшләгән яхшылыгын да гомерем буена онытасым юк,—дип әлеге очракны хәзер дә искәртә.

## Елаткан шатлыгым

Табигать үзенең үзгәрмәс кануннары белән яши бирә. Без, кешеләр генә, аңа үз белдегебез белән үзгәртмәләр кертергә тырышып яши бирәбез. Ә вакыт дигәнең барыбер барын да үз урынына янадан куячак.

Мин бу турыда, кем әйтмешли, гомеремнең икенче яртысына чыккач кына уйлана башладым. Ә уйлар дөньясында гизәргә яшь арасы юк икән. Соңгы вакытта алты яшьлек улым әллә нинди фәлсәфи сораулар биреп йөдәтә.

Бу сорауларга жавап эзли-эзли кояшны, йолдызларны урап, бар жиһанны гизеп, соңында Мәккә жиренә төшәргә туры килде миңа. Кыйблага карап намаз укуның мәгънәсенә дә тукталдык без. Бар жавапларым арасында улыма иң тәэсир иткәне жиргә төшеп каралган кәгъбә ташы булды. Гөнаһлы жир йөзенә хаклык ингәч кенә кәгъбә ташының агарасын белеп аптырады ул.

—Тагын ташны ничек агартырга була?—дип кат-кат сорап та жавап ала алмагач кына башка дәшмәде.

Әлеге сөйләшүгә өч көн вакыт узгач, улым, яныма килеп:

—Әти, мин, үскәч, мулла булсам, ул таш агармасмы икән?—дип кабат миңа сорау бирде.

Бу сораудан минем күзләрем яшьләнде. Балаң күнелендә изге орлыклар шытып чыкканга ничек сөенмисең ди! Хәзер ничек кенә шиндермичә үстерәсе инде бала күнелендәге шушы өметне—барлык уй-хыялларым шуңа бәйле.

## Акча гаебе

Танышларыма өч айлык хезмәт хакларын көтмәгәндә берьюлы биреп куйдылар. Тагын кайчан жае килә әле, дип, берсенең хатыны бу акчага күптәннән хыялланып йөргән стенкасын сатып алды. Хатынының елмаюлы йөзен күреп, ире дә эчүен ташлады. Электән дә яхшырак тора башладылар. Әйтерсең лә барысы да шул стенкага гына терәлеп торган.

Икенчесе исә, хатынының ай-ваена да карамыйча, шул акчасына иске Т-150 тракторы сатып алды. Ул да түгел, аны йөрерлек хәлгә житкерерлек итү өчен сыерын да суеп сатырга мәжбүр булды.

Тракторы сафка баскач, кенне тенгә ялгаса ялгады, әмма кез буе йорт тезүчеләргә урманнан агач сөйрәтеп, тракторына кергән бәядән биш тапкыр артык акча эшләде. Ләкин бары да шома гына бармады шул. Аныңчы, тормышы бозылып, хатыны киткән иде.

Танышымның икенчесе өчен борчылып торам әле. Сүз дә юк, акчалы йортка хатын-кыз килми тормас анысы. Тик барысы да элеккечә үк ялганып бетәрме?

## Яман шеш

Шомбыт спирт заводы 1741 елда-тирә ягында яшәүче татарларны диненнән аеру максатыннан төзелә. Әмма революциягә чаклы мөселман татарларына бернинди йогынты да ясый алмый. Киресенчә Шомбыт авылында яшәүче урыс халкы гына чебен урынына кырыла.

—Зур бәйрәмнәрдән соң айный алмыйча үлүчеләр саны кайбер елларда өч-дүрт кешегә житә иде,—дип сөйлиләр алар үзләре.

Совет чорында да, көн-төн эшләп, салган зыяны ялгыз маржаларның кочагында эреп урыс булган берничә ир-аттан артмаган. Шулай да гасырлар буена бу афәткә бирелмәгән татар халкы соңгы ун-унбиш елда әллә нишләде. Су урынына аккан спирт белән булашып, холкы үзгәрде. Дөрес, берәүләре акылларын югалтмыйча спирт саткан акчаларына бай тормыш корса, икенчеләренең булганы да жимерелеп, үзләре дә инде салкын гүрдә ята. Кызганыч ки, соңгылары күбрәк. Ә аларның ялгыз калган хатыннары белән ятим балаларын кем санаган?

Тәндәге шеш бер тишелмичә калмый шул. Татар жирендәге бу яман шешкә киләчәктә бер дәва табылырмы?

## Замана таянычы

Әби белән бабайның унбер баласы булган. Олы кызларының туган елы тарихка «ачлык елы» исеме белән кереп калган. 1921 ел. Әти-әниләрдән үзебезнекеләр дүрт-биш тирәсе булып, безнең заманныкылар ике-өчтән артмады. Әле анысы да яраган икән, тик соңрак яшьләр икенче балага исәп иткәндә, тирә-яктан, нигә кирәге бар аларның, хәерчеләр арттырып, дигән сүзләр еш яңгырый иде. Дөрестән дә, ачынып, кая китә бу татар, диярсең.

Шулай да соңгы елларда авылларда бала-чага ишәя башлады. Кырык яшьтәгеләр дә яшьрәкләрдән ким түгел. Әллә иманга килеп, әбиләр әйтмешли, бульнис юлының гөнаһысыннан курка башлаганнармы, дигән идем, юк, сере башкада икән. Күрше әбием, боларның күбесе «чек» балалары, ди. Хәзер бит авылда «коммунизм». Бушка эшлиләр. Ә эшсез калган өч балалыларга аена эшләп ел буена да күрә алмаган чаклы чек бирелә.

Элек балаларны, картлык көнемдә өмет-таяныч булыр, дип үстерсәләр, хәзерге имчәк балалары—бүгенге көн таянычы... Сүз дә юк, насыйбы белән бирсен Ходай. Күңелемә әбием еш кабатлаган сүзләр инә: «Менә шундый заман житәр, Аллаһ дигел бәдәвам».

## Язмышлар охшашлыгы

Үзләренә кирәк чакта уйнадылар, йомшарса—өрделәр, тыгызланса—бушаттылар, ләкин сүтелеп-тишкәләнеп беткәч, текмәделәр, чыгардылар да ыргыттылар аны. Татар язмышы түгелме бу? Әлегә юк. Тик без дә шул футбол тубы хәлендә түгел идекме? Үзебез дә ничек сикертсәләр, шулай сикереп, кайда типсәләр, шунда очып, аздан гына футбол тубы язмышына төшмичә калдык. Әйе, бу репортаж әлегә чүплек башында язылмый. Әмма тагын да хәлсезләнеп бетсәк, безне тиздән тарих чүплегенә чыгарып ыргытачаклар.

## Татар байлыгы

Безнең халыкта: «Сабыр төбе—сары алтын»,—диләр. Бу—татар халкының гасырлар буе жыелып килгән байлыгы. Әмма биш гасыр буена жыелып килгән сабыр төбендәге тутыгып беткән сары алтын белән ни эшләргә инде? Үткәннәрдәге коллык жепләреннән арынырга да житмәде (әллә инде комачаулады) ул безгә.

Бүгенге көндә дә безгә: «Өметсезлеккә бирелмәгез: сабыр, сабыр, сабыр

итегез»,—дип тукып торалар. Ә менә бу сүзләр: «Сарык, сарык, сарык сез»,— дигән кебек ишетелә. Халык исеменнән әйтүчеләр: «Халык әйтсә—хак әйтә»,— дисәләр дә, сарыкның хаклыгы түрәләргә иткә киткән кебек, безнен сабыр итү дә кемгәдер файда китерә сыман. Әйе, сабыр итүнең дә унай яклары булган кебек, һәр ялтыраган да алтын түгел шул.

## Кеше җырын җырлап

1937 ел шаукымы кулак дип саналган бабамның әтисе белән энесен, тамырлары белән куптарып, ерак Себергә илтеп ташлаган. Үзе исә бу афәттән котылып кала. Сәбәбе эш урынында житәкчелек иткән яһүдкә бәйле. Үзе өчен куркыныч булса да, бабайны һәм сонрак әтисен дә, кирәкле кәгазьләр табып, үз авылларында калдыра. Киресенчә булганда, унбер балалы бу гаиләнең язмышы ничек бетәр иде икән? Үзебез дә бу дөньяга килер идекме? Белмәссең.

Бүгенге көндә бөтен Рәсәй буйлап яһүдләрне сүгү бәйгесе бара. Вакыт-вакыт үз татарларыбыз да күренә бу хәрәкәттә. Минем исә татар кебек заманында илсез-җирсез калган бу милләткә соклануым белән рәхмәтемнән башка карашым юк. Шуна күрә, урыс чанасына утырып, алар җырын җырлап йөрисем юк әле. Киресенчә, яһүдләрдән үрнәк алып, милләтебезне дә шуларга охшатасы иде. Ара-тирә кемнедер төп башына утырталар икән, анысы да безнең файдага, икенче юлы акыллырак булырбыз. Шул чагында, бәлкем, алар кебек югалган дәүләтебезне дә, бер-беребезгә ярдәмчеллегебезне дә, ышанычыбызны да кайтара алырбыз.

## «Дуслык»

Иртәдән кичкә чаклы машинасында чабып йөргән танышларымның берсе, эштән китеп, өч айлап эшсез йөрде. Шул вакытта гына аның белән аралашып, азрак дуслашып та алдык.

Чөнки машинасыннан чыккач, янына килүчеләр дә югалды. Бу сәерлекне күреп, берничә тапкыр:

—Сәлим, кая синең дусларың?—дип тә шаярткаладым.

—Алар минем белән түгел, машинам белән дус иделәр,—дип җавап кайтара иде ул.

Инде менә, эзләнә торгач, тир-яктагы кибетләргә товар озатучы булып эшкә урнашкан. Хәзер үзен теләсә нинди машиналарга утыртып йөртәләр.

Көн саен бер генә булса да кермичә калмаган «дустым» югалды. Хәлләр ничек, дип сорап үзем керер идем, башына, мона нинди товар кирәк икән, дигән уй килүеннән куркам. Ә нәрсә, дөньясын шаккатырып кабат хәл белергә керсә, мин дә, әллә кабат эшеннән чыктымы икән бу, дип уйламас идемме?

## Озак көттермәс

Күршедә яшәүче урыс карты көн саен таягына таянган килеш подъезд төбендә утыра. Кергән-киткәннең кая баруын белү—аның эше. Минем дә кабат Казанга ашыгуымны белгәч:

—Эх, елки-палки!—дип сөйләнеп калды.

Яшь чагында ул үзе дә гел аяк өстендә булган икән, хәзер генә ухылдамыйча адымын да атлый алмый.

Таякка таянган картлык озак көттермәс, аякта булганда, чабып калыйк. Вакытны куып житә алмасак та, үкенечтә калмас.

## *Һәр төбәктә—безнең каләмдәшләр*

*«Нинди гаҗәеп бер шәһәр бу!»—дип сокланганнар борынгыдан ук, Казаныбыз турында уйлап: «эресе дә, вагы да—һәммәсе дә шагыйрь, һәммәсе шигырь яза...» Бү—бүген дә шулай, мөгаен. Икътисадый хәл дә, социаль вәзгыять тә, гүяки, шигырьләр язылуына, яңа шагыйрьләр килүенә уңай тәэсир итә: иң авыр,хәтәр мәлләрдә шигырь белән уйлыйбыз, шигырь белән киңәшеп, сөйләшәбез, көрәшәбез түгелме икән? Шуңа да мәйданга төрле-төрле шигырь бәйләмнәре, яңа исемнәр, китаплар чыгуы гаҗәпләндерми кебек. Бу—халкыбыз яши торган барлык төбәкләрдә дә шулай: Кырымда да, Ерак Көнчыгышта да, Себердә дә, чит илләрдә дә (Австралиядә яшәп, иҗат итүчеләребез дә бар!). Журналыбыз редакциясенә дә шигырьләр белән хатлар агыла тора. Һәм, гаҗәп түгелдер, игътибарга лаеклары да байтак. «Юк, сүнмәс тә, сүрелмәс тә икән бу шигъри дәрт-омтылыш! Бу—ахры безнең бер милли сыйфат», дип, моң чишмәләребез саекмаслыгына инанасың, сөенәсең... Төрле язмышлар, төрле юллар белән килгән алар шигърьгә. Әйтик, Фоат ага Мортазин—күптәнге авторыбыз—Ялтага Буа якларыннан киткән. Фронтовик, укытучы, педагогия фәннәре кандидаты. Ару-талу белмәс җәмәгать эшлеклесе, сиксән яшендә дә яшьләрчә җитез, хәрәкәтчән ир-егет... Күптән түгел аның Казанда «Ялта бүләге» исемле китабы да дөнья күрде...*

*Ирек Сабиров—шулай ук Татарстаннан, Казан арты—Мәмдәлдән. Ул да—укытучылар нәселеннән. Чиләбе ягында яши, урысча басылган китаплары бар. Әмма каны, җаны милли моң, изге сөт белән сугарылганга, татарчага, туган телгә кайткан, фикерле, уйлы шагыйрь... Күптән түгел Татарстан Язучылар берлегенә дә тәкъдим ителде.*

*Фирдания Гыйлфан—Балык Бистәсе районы Мәшләк авылында туып үскән. Хәзер Казанда яши. Авыру булуына карамастан, язмышларны җиңү турында көчле рух, ышаныч белән шигырьләр яза. Аның да «Гомер юлы» исемле беренче китабы басылып чыккан—шигырьләрен сайлап, редакцияләп, басмага якташы—шагыйрь Әхмәт Гадел әзерләгән, безгә дә ул китерде...*

*Өч шагыйрь, өч төбәктән... Төрле почерк-стиль, тел-сурәт чаралары, шигъри фикерләү, кузаллау белән аерыла алар. Әмма барсында да туган телгә, халкыбызга чиксез мәхәббәт, аның яшәешенә ышаныч һәм дога, өмет сүзләре бар. Укучыларыбыз да аларны нәкъ шулай аңлап кабул итәрләр дип уйлыйбыз.*

# Фоат Мортазин

### ЯЛТАДАН ХАТЛАР

### Терелде үткәннәр

Кыраулы иртәдә карадым бакчага,
Мәкләрем ни хәлдә икән дип,
Йолдызлы таңнарда, үтәли җилләрдә
Ак кырау сукмады микән дип.

Ах, иркә мәкләрем боз күлмәк кигәннәр!
Бозланган керфекләр, бәбәкләр!
Бер төндә бөтенләй каралып янганнар
Ал нурлар сирпегән чәчәкләр.

Түтәлнең очына бастым да тыңладым.
Әй, мәкләр елады, әй, мәкләр зарланды!
«И, кырыс табигать! Ник һәлак итәсең
Син яшьләй гөнаһсыз җаннарны?

Тик яңа ачылды безнең саф бөреләр,
Үпмәде иренне күбәләк.
Кунмады безелдәп керфеккә бал корты,
Килмәде сабыйлар чүгәләп...»

Нечкәрде күңелем. Терелде үткәннәр
Һәм эче яралы дус-егет—
Кулымда җан бирде ул авыр сугышта
Вакытсыз, зарланып, мәк кебек.

## Поездда

Мин поездда барам, ә син калдың
Ярларында зәңгәр диңгезнең.
Әмма минем белән барасың гел
Татлы хыялымда син минем.

Зеңгелдәвен тыңлап көпчәкләрнең,
Талгансыман җиңел йокыга,
Керфек какмый күзәтәсең кебек
Һәр адымым минем син монда.

Төнлә белән бермәл йокы катыш
Эзләдем мин хәтта кулларың.
Әллә ничә: «Хәдичә!» дип, дәштем,
Чуалдылар тәмам уйларым.

Купе һаман йокы бүлмәм кебек...
Кыштыр-кыштыр кемдер йөргән күк.
—Вагон салкын, өстең ачма берүк,
Зур малаем минем!—дигән күк...

## Болыт булсам

Аяклары туңа каеннарның,
Бигрәк шәрә инде яшь таллар.
Болыт булсам, кышкы салкын төндә
Мул яудырыр идем мин карлар.

Иреннәре кипкән ал гөлләрнең,
Су! Су! диеп, илерә басулар.
Болыт булсам, «Ал, җиркәем!», диеп,
Түгәр идем Җиргә саф сулар.

Бер алан бар үзе генә белгән
Тәүге сөюемнең ялкынын.
Болыт булсам, һәр җәй шул аланга
Очып төшәр идем, алтыным!

## Исмәгыйль Гаспринский

*Бу шигырь Симферопольдәге безнең татар милли Культура Үзәге рәисе Ильмир Гасыйх улы Тимергалиев үтенече буенча язылды һәм 1998 елның 6 июнендә И. Гаспринскийга һәйкәл ачылуга багышланган митингта укылды.*

Ханнар, каннар, дан һәм зарлар уртак,
Язмыш безне бердәй «яратты».
Без бит бер ананың ике улы,
Бер үк кошның ике канаты.

Кырым-Казан тагын кавыштылар
Казан кызы Зөһрә аркылы.

Тиздән Гаспралы Исмәгыйль бәк
Якты йолдыз булып балкыды.

Мәгърифәтче халык йөрәгенә
Сузды гыйлемнәрнең ак нурын.
Сызып бирде Ислам дөньясына
Бәхет, сәгадәтнең чын юлын.

Мәрҗаниләр, Исмәгыйль бәк, Тукай...
Ни генә күрмәгән бу башлар!
Үрмәле гөл кебек үрелеп барды
Безнең кырыс уртак язмышлар.

Парижларда яшәп, дөнья гизеп,
Әкияти илләр күзәтеп
Гыйбрәт алды, тик уенда булды
Бакчасарай. Кырым. Ак мәчет.

Олпат шәхес. Әдип. Зур журналист.
Мөгаллим һәм халык трибуны!
Сине бүген зурлап күккә чөя
Милләтеңнең барлык буыны!

## Бөек хакыйкатьне эзләп

Гомер буе биек тау башына
Менгәннән соң белдем ахырда:
Тау түбәсе һаман ерагайды,
Җиталмадем барыбер асылга.

Ә бит түбә кул сузымда гына,
Бик якында иде югыйсә.
Авыр булды миңа: бик еш тайдым,
Упкыннарга төштем мин ничә!

Валун, кыя, үткен сөңгеләрдә
Асылынып тордым мин-фәкыйрь.
Җәнлек тоягыннан сулар эчтем,
Кыл өстендә булдым күп тапкыр.

Янап торды барлык кыйгалардан
Җәнлек-киек, шакал өере.
Әмма һаман югарыга дәште
Чишелмәгән серләр төене!

Кеше кайдан килгән? Кая китә?
Мәңгелекме—безне ни көтә?
Янәшәдә йөргән ачы үлем
Ник шул чаклы җанны өркетә?

Бу биек тау—чын хакыйкать иде.
Тау менүем шуның хакына.
Җан канатып, күтәрекләр алып,
Мөритләрчә түзеп барасына.

Әмма барыбер бик аз белә алдым—
Надан китәм Алла каршына.
Бөек хакыйкатьтән валчык кына,
Бөртек кенә газиз башымда...

*Ялта*

# Ирек Сабиров

## Сез һәм мин

Елау диган гадәт үтте инде,
Кипте инде корып яшьләрем.
Мин дөньяның бәхетен көтеп түгел,
Хәсрәтенә чыдап яшәдем.

Ә сез, бәхет көтеп яшәгәннәр,
Булмаганны көтеп ардыгыз.
Түземсезлек утларында көеп,
Саргаешып китеп бардыгыз.

Сезне җирдә әүвәл сабырсызлык,
Соңра өметсезлек биздерде...
Ә мин исә яшим бәхет итеп
Йөрәк сызламаган мизгелне.

## Табигать

Бу дөньяның фани казанына
Бар нәрсәне парлап салганнар:
Һәр ялганда хак сүз тамчысы бар,
Һәр чынлыкта әзрәк ялган бар.
Һәр нәрсәне чама белән бирә,
Табигать ул—кырыс диктатор:
Даның артып, чиксез үсеп китсәң,
Мәтәләчәгеңне көт тә тор...

## Гомер кыска...

Сату-алу, исәп-хисап,
Дан, хакимлек, мал-милек...
Син яшисең, бу дөньяга
Мәңгегә килгән кебек.
«Яшәү мәгънәсе шул»,—диеп
Юатасың үзеңне.
Әмма, дускай, киңрәк итеп
Ачып кара күзеңне:
Гомер кыска, дөнья фани,
Егыла гөлләр, сулып.
Тормыш узар, тәннәр тузар,
Мөлкәт очар көл булып.
Фәлән елдан онытылыр
Эшең, даның, кадерең.
Фәлән елдан тигезләнеп,
Юкка чыгар каберең.
Минем исә—мәхәббәт һәм
Сафлык—җаным кәгъбәсе:
Шунда гына тормыш яме,
Шунда гына мәгънәсе.

## Гөнаһсыз хатынга

Хыянәтчел булды сөйгән ярың,
Ә син серләреңне чишмәдең.
Тапталудан өзгәләнде җаның,
Тик яшәүчән икән хисләрең:
Мәхәббәтең—җәйге үлән синең.
Чалгы узган эзгә, әй, кара:
Янә үсеп чыга чапкан саен,
Таптасаң да, кабат яңара...

## Ике аваз

Истә генә калды кояшлы яз,
Һаваларда—кошлар кыйгачы.
...Без аерым чакта—ике ялгыз аваз.
Бергә чакта—моңлы көй башы.

## Лотфулла Фәттахов. «Сабан туе».

Альбомнарда актарынган чакта
Ирексездән саркый яшьләрем,
Күргән саен рәссам Фәттаховның
«Сабан туе» дигән әсәрен.
Күргән кебек булам: сөлге җыю,
Василәнең кара толымы,
Мәмдәл белән Юртыш арасында
Җәйрәп яткан Сыза болыны.
Шул болынга кереп китәр булып
Хәйран калып карап утырам:
Йә көрәшәм мышнап, йә чабышып,
Җитез аргамакта җилне узам...
...Ул заманда, гармуннардан агып,
Дәртләндерә иде саф моңнар;
Ул заманда ирләр аек иде,
Елмаючан иде хатыннар...

## Ә үзебез...

Агымнарга каршы йөзә
Вөҗданлылар һәм кадыйрлар.
Без сокланып кул чабабыз:
Баһадирлар! Баһадирлар!
Алар өчен горурланып,
Кинәнәбез, кинәнәбез,
Ә үзебез агымнарга
Иярәбез, иярәбез...

*Чиләбе өлкәсе.*

# Фирдания Гыйлфан

## Туган йортка сәяхәт

Күңелемнән туган йортка кайттым,
Капкасыннан кердем, ишегеннән...
Күз алдыма сабый чагым кайтты,
«Әннә» димен сыман бишегемнән.

Сырхау бәндә дөнья рәхәтенең
Күбесеннән мәхрүм булганга,
Сөйләмендә һәрчак рәнҗешле сүз,
Умырзая сыман сулганга...

Өй түрендә үскән чияләрне
Кулым белән сыйпыйм, иркәлим.
Ә нигә соң һичкем сәлам бирми?
Кем соң әле монда, кем, йә, мин?!

Карашлары кырыс булсалар да,
Әткәемне сөйдем, яраттым.
Авыр миңа, газиз әнкәемне,
Мин бит сөеклемне югалттым.

Сукмак буйлап бакчаларны күзлим,
Бәрәңгеләр, яшел суганнар...
Бу дөньяда без бит кунак кына,
Аң булыгыз, кардәш, туганнар!

Хыялымда нигез ташын үптем,
Туган йортны буйлап урадым...
Күңелемдә булган уй-хисләрне
Изгелеккә генә юрадым.

## Тукай җаны

«Кызым, синдә Тукай җаны»,—диләр,
Әллә инде чынлап шулаймы?
Мәшләгемнең тирә-ягы урман—
Әллә шүрәлеле Кырлаймы?

Пар атларга утырып йөрмәсәм дә,
Шигырь язып җанны юатам.
Суын эчеп, саф һавасын сулап,
Кайгы-сагышымны таратам.

Тукай абый бик тә яшьләй үлгән,
Бәлки, җаны күккә иңгәндер.
Җаны, исән калып, күккә иңеп,
Минем тууымны көткәндер.

Әгәр миндә Тукай җаны икән,
Әкиятләр сезгә сөйләрмен.
Туган телне күңелемдә саклап,
Матур итеп җырлар көйләрмен.

## Сабырлык

Минем дә бит җаным корыч түгел,
Тик бер мыскал калды сабырлык.
Җиңәм диеп алга бер ыргылам,
Баксам—тагын килә авырлык.

Авырлыклар алар бик күп төрле,
Бизмән сына кайчак, үлчәсәк.
Язмыш шулай сыный бәндәләрен,
Җиңеләсең, әгәр үртәлсәң.

Үртәләм дә, янә торып басам,—
Сүксен язмыш, суксын яңакка...
Язмыш белән кискен очрашулар
Инде калды алар еракта.

Язмыш белән дуслашырга телим,
Сабырлыкның соңгы мыскалы.
Язмыш бары үзе хәл итәчәк:
Безнең гомер озынмы? Кыскамы?

## Төшләр хакында

Мин берәүгә шулай сорау бирдем,
Нигә димен төшләр күрәбез?
...Баш миендә уйлар тоткарлана,
Шул уйларныммы төш диябез?

Үлгән җаннар нигә төшкә керә?
—Җаннар, үлми, күккә иңәләр.
Бар галәмне, үткән, киләчәкне
Читтән торып ачык күрәләр.

Фәрештәләр нигә төшкә керә?
Юлыкмагыз диеп ялгышка.
Киләчәкне алдан күрә торып,
Каршы килмәгез дип язмышка.

Мин төшемдә ак күгәрчен күрдем,
Бу төшемне ничек юрарга?
Киләчәгең бәхетледер,—диде,
Бәхет эзләп чык син юлларга.

*Казан*

## Марат Закир

# ЙОМШАК АГАЧНЫ КОРТ БАСА

Китап укымый торган заман килде... Хәзер инде үсмер—яшь-җилкенчәк парта астыннан гына, тез өстенә куеп, дәрес вакытында «матур» китап укымый. Алар төнлә караган порнофильмнар турында авыз суларын түгеп фикер алыша. Хәтта югары даирәләрдә кәнәфи биләп утыручы кайбер түрәләренә кадәр: «Мин китап укымыйм» дип, мәгънәсез горурлыгын дөньяга чәчә.

Китапны дошман күргән хакимнәр элек тә булган анысы. Гомәр хәлиф, әнә, Александрия китапханәсенә ут төрттергән, Аурупаның урта гасыр инквизиторлары, берничә гасырдан соң исә гитлерлар, сталиннар «кәфер» китапларны учакларда яндырганнар. Хәер, утта янган китапның яңадан «терелү» мөмкинлеге әле бар: аның берданбер исән калган нөсхәсен кабат бастырырга, хәтта мең вә мең данәләргә дә җиткерергә була!

Китапның төп дошманы—битарафлык. Бүгенгедәй болгавыр чорда әдип әсәр язуга сарыф итәсе көч-дәрманын китап бастыруга бетерә. Дөньяга чыккан китабыңны исә кабер тынлыгы каршылый. Китап, бахыр, яңа туган сабый баладай, авыз тутырып аваз салырга да өлгерми, аны тынлык-битарафлык мендәре белән томалыйлар...

Инглиз әдибе Сомерсет Моэм болай дигән: «Киләчәк буын шулкадәрле дә битараф, үз-үзе белән генә мәшгуль булачак ки, әгәр дә үткән чорның әдәби продукциясеннән «авыз итәргә» теләсә, ул, әлбәттә, шул чорның фәкать уңыш казанган әсәрләренә генә тукталачак.»

Әмма үз чоры әдәбиятының «йөзек кашы» булып та, үзе хакында бер сүз дә ишетмәгән әсәрне «уңыш казанган» дип әйтү мөмкинме соң?

Өстәлемдә—1999 елны Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән ике проза китабы. «Ил». Авторы—Ркаил Зәйдулла. «Бохара мачысы». Авторы—Нияз Акмал.

Бу әдипләр прозага шигырьдән килделәр. Бәхәссез талантлы, үз укучысын тапкан шагыйрьләр булып килделәр. Димәк, боларның чәчмә әсәрләрен шагыйрь прозасы буларак та күздән кичерү фарыз. Гюго да, Пушкин да, Лермонтов та проза әсәрләре иҗат иткәннәр. Әле ниндиләрен! Бу җәһәттән караганда, безнекеләр ничегрәк? Үз йөзләре, стильләре бармы? Куәләре ни кимәлдә?

«Үз йөзләре» дигәннән... Студент чагында без карават башына басып шигырь укый торган идек. Беребез фәлән-фәләннең шигырен укып чыга да, сорап куя: «Бу—кемнеке?» Шигырь иясен дөрес әйткәндә Хәсән Туфан белән Мөдәррис Әгъләм атала, Роберт Әхмәтҗан белән Рәшит Әхмәтҗанның исеме буталса да, шигырьләре һич кенә дә буталмый торган иде.

Бүген мин замандашларыбыз Ркаил Зәйдулла белән Нияз Акмалның әлеге китапларыннан берәр әсәрен сайлап алып, шулар хакындагы фикерләремне сезгә дә җиткерергә уйлыйм. Ркаилнең «Сөембикә» хикәясе бик кыска—китап бите белән 7-8 биттән артмый. Икенче авторның «Кол» кыйссасы исә шактый ук күләмле әсәр.

Заманында Фатих Хөсни: «Хикәя нигезенә салынган вакыйга гадәтилектән чак-чак кына күтәрелебрәк, чыгыбрак торырга тиеш»—дигән

фикер әйткән иде. «Сөембикә» хикәясендә дә бу «чак-чак кына күтәрелебрәк тору» сизелә.

Хикәя «КамАЗ» машинасын йөртүче шофер егет исеменнән сөйләнә.

«Менә ун еллар инде безнең авылда әрмәннәр шабашкада эшли. Аларның кайсысы килә, кайсысы китә, ә бригадирлары—Рафик дигәннәре—тәмам безнең авыл кешесе булып беткән иде. Әрмәннәр үзләре салган таш йортта торалар, ә бу Рафик исә Гәүһәр дигән тол хатынга йортка кереп, шунда яши иде. Ул теттереп татарча сөйләшә, безнең авыл кешесеннән аерып та алып булмый, дияр идең, үзен бик кибар тота, хәтта түрәләр кебек, муенына галстук асып йөри иде. Башта алар әйбәт кенә эшләделәр, хәзер әллә колхозның акчасы бетте, әллә төзисе әйбер калмады, әрмәннәр инде вак-төяк эшләрдә генә йөриләр, яртысы район үзәгендә персидәтелгә катижмы, матижмы диләр, өч катлы йорт салып ята иде. Шулай да өйләренә кайтырга ашыкмыйлар, нигә ашыксыннар, безнекеләр айлар буе акча алмаганда, болар Ходай бирмеш һәр ай азагында бухгалтер бүлмәсе тирәсендә чуала, елтыраган күзләренә караганда, юкка гына чуалмыйлар да иде төсле. Телевизордан да радиодан, алар илендә сугыш бара, дип лаф оралар, ә монда, кая башны тыкма, әрмән дә азәри, белмим, үзләрендә кемнәр генә сугыша торгандыр, әллә картлар белән бала-чага буза куптарып ята инде?»

Шулай, көннәрдән беркөнне, әрмән егете Арсенның көтүче Йосыф кызы Сөембикәгә күзе төшә. Әмма кызның моңа исе дә китми. Әрмәннәр исә бик тә үҗәт, бердәм халык, колхоз рәисен яучы иттереп, көтүче йортына киләләр.

«Өстәлгә ярты менеп утырган, тәлинкәләргә затлы кунаклардан калган шашлык калдыкларын куйганнар. Ул шашлыкның тәмлелеген көтүче Йосыф ярты ел сөйләп авыз суын корытты.

—Синең йортың бик тузган икән, беркөнне карап үттем,—дип, бераз салып алгач, персидәтел сүз башлаган.—Колхозга биш фин йорты кайтты. Берсен сиңа бирим мәллә? Яшә карчыгың, бала-чагаларың белән рәхәтләнеп яңа өйдә.

Иренен җыеп алырга азапланган Йосыфның «ә» дип тә, «җә» дип тә әйтерлек рәте калмаган, тик башын чайкап утыра икән, бичара.

—Тик шунысы бар, Йосыф абзый,—дигән персидәтел,—менә Арсен синең кызга үлеп гашыйк булган икән ич. Пәрәме Мәҗнүн инде, ашаганы аш, йокысы йокы түгел, тире дә сөяккә калган. Ә безнең колхозга андый кешедән ни файда?—ул гырылдап көлеп җибәргән.—Син аңа кызыңны бир, ә без сиңа туй бүләге итеп йорт бирербез.

Тагын берне салып куйгач, Йосыфның бөршәйгән кулы персидәтелнең дәү учына кереп югалган.

—Егет син!—дип мактаган аны персидәтел,—текущий моментны аңлыйсың.

Шулай иттереп, ихтыярсыз көтүче агай бердәнбер кызын фин йорты бәрабәренә сатып җибәрә... Хикәядән озын өзекләр китерүем юкка түгел. Авторның үзенчәлекле, беренче карашка гади дә тоелган, «мин» аша алып барылган вакыйгалар тасвирламасында никадәрле сарказм, ирония ята ләбаса! Персидәтелнең бер сүзе җитә! Бер ярты аракы эчү дә, фин йортына кызыгу да (тора-бара ул йортны авылдашлары барыбер ташып бетерә, бәрәкәте булмый) сәбәп түгел бит монда. Гади авыл кешесенең колхоз рәисенә «хуҗа» итеп каравы, коллык психологиясенең җелегенә төшүе сәбәп монда. Бөкрене кабер генә төзәтә шул... Ярый, көтүче Йосыф—үз гомерендә Хрущев «крепостное» булып та җан асраган бәндә, тоталитар совет-татар авылы колбиләүчеләренең дә камытын өстерәгән, бетәшкән, мескенгә әверелгән зат.

Ә менә авыл яшьләре ни карый? Алар үзләренчә юана:

«Безнең кызлар бит ул джунглидан орангутанг килеп чыкса, аңа да ябышырга әзер торалар, тик маймыл татарга гына охшаган булмасын».

Яшьләр дигәннән... Соңгы елларда Казанда FM каналындагы радиолар ачылды. Һәммәсендә дә яшьләр эшли. Шул радиоларның берсендә һәркөнне төш турында эфирга чыга торган бер тапшыру бар. «Саумы, хуҗам!» дип атала ул. Төрле оешмаларда хезмәт итүчеләр шефларын-башлыкларын котлап җыр тапшыруны сорыйлар. Валлаһидыр, ялагайлыкның, коллык психологиясенең югары ноктасы! Саумы, хуҗам?! Мөгаен, бу шаукым боларга ата-баба каны аша күчеп килә торгандыр. Чыраең чалыш икән, көзгегә үпкәләмә... Ирексездән, шагыйрьнең түбәндәге шигъри юллары искә төшә:

Безнең илдә, ахры, җил дә, су да бүтән—
Офыгында көннәр, төннәр бутала.
Йолдызларга карап кемдер чукынганда,
Сарылабыз янә алабутага.

Хәер, хикәяне дәвам итик:

«Арсен Сөембикәне иленә алып китте. Алар кузгалганда мин нигәдер кантур каршында утыра идем. Аның яшьле карашы минем йөзне кисеп үтте, күпергән иреннәре нидер әйтергә теләп кыймылдап алды. Мин, бу чарасызлыкны күрмәскә теләп, башны түбән идем. Соңыннан Сөембикәне тәкәбберлектә гаепләгән кыз-хатыннар аны шулай чит илгә алып китүләре турында бәет тә чыгардылар. Безнең халык нигәдер бәхетсезләрне, кимсетелгәннәрне ярата, өзелеп, чын күңелдән шуларны кызгана».

Менә кайда ул татар Моңының, бәет-мөнәҗәтләрнең килеп чыгу тарихы. Моң тудыру шартлары! Бу хакта «КУ»ның былтыргы 9 санында «Моң хикмәте» язмасында да тәфсилле генә тасвирланды.

...Берничә елдан шофер егет әрмән иленә татар ашлыгы илтергә бара. Көтүче Йосыф та кызы Сөембикәгә «мәктүп сырлый».

Ниһаять, егет авылдашы белән күрешә.

«Кара күлмәктән, башына да кара яулык бөркәнгән хатынны башта танымыйча тордым.

—Сөембикә!

Аның йөзе дә кучкылланып киткән, борыны да озынаеп калган шикелле. Әйе, әйе, Шалпы авылының Сөембикәсе әрмән хатыннарына охшый башлаган иде...»

Сөембикәнең ике улы да бар икән. Берсе—Тигран, берсе—Вазген исемле...

Әсәрнең шушы турына җиткәч, йөрәк чеметеп куйды. Ирексездән: «Соң, беткән идемени сиңа, Сөембикә, үз авылыңда татар егете? Үстер инде менә хәзер балаларыңны чит кавемгә, чит токымга!»—дип уйлап куйдым. Гаяз Исхакыйның урыс коллыгында интеккән Зөләйхасы искә төште. Йөрәк икеләтә чеметеп куйды. Үзгәрми икән лә бу татар дөньясы, гасыр узса да—үзгәрми яхшы якка... Һаман—кирегә генә. Үзбәккә—үзбәк, яһүдкә—яһүд, кыргызга—кыргыз, татарга—урыс табып бирә торган милләттән шул без. Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә татар булганга горурланабыз, ә менә әдип үзе горурлана микән соң?

Хикәя болай тәмамлана: «Икенче көнне без илгә кузгалдык. Муфтадан аякны алганда, нидер чиик итеп куйды. Инде минем тәмам өйдәшкә әйләнеп беткән теге тычкан ялгыш табаным астына килеп кергән икән. Менә бит ул—меңнәрчә чакрымны исән-сау үт тә, аз гына саксызлык аркасында дустыңның табаны астында сытылып үл. Мин машинаны туктаттым да, терсәгем белән рульгә таянып, йодрыкларымны күземә батырдым. Тик озак утырырга туры килмәде, арттагылар зәһәр итеп кычкырта башладылар. Мин ишекне ачып, канлы тычкан гәүдәсен тузанлы әрмән туфрагына этеп төшердем.

«КамАЗ» ухылдап алга кузгалды. Берәм-берәм тау тезмәләре артта калды, алда мине үксез илем көтә иде.» Менә шул.

Әрмән туфрагында үлеп калган татар тычканы... Бу бит татар кызының бәхетсез язмышы ләбаса! Автор юкка гына каһарманына Сөембикә исемен бирмәгән. Ул шул рәвешле моннан күп гасырлар элгәре Сөембикә-ханбикәбезнең урыс коллыгына җибәрелүенә ишарәләгән, бүгенге Сөембикә белән аны янәшә куйган. «Алда мине үксез илем көтә иде»—ди. Мескен, ятим ил ягъни. Бу ил инде Сөембикәне генә түгел, сине дә, мине дә якларга-сакларга сәләтсез, бетәшкән-үксез ил. Кыска, кырыс, тыгыз, тәгәл-үтергеч нәтиҗә. Шәп финал!

Әдәби ел йомгакларының берсендә хөрмәтле тәнкыйтьчебез Рифат ага Сверигин: «Ил» китабы—аерым, тәфсилле өйрәнүне сорый торган җыентык»—дигән иде. Күргәнегезчә, 7-8 битлек «Сөембикә» хикәясе генә дә никадәрле фикер-тәэсорат тудырды! Әйе, адәм баласы ирекле булырга да, ирексез калырга да хокуклы. Әмма үзен генә түгел, кызын да яклый алмаган бичара Йосыфлар татар илендә, һай, бихисап әле. Үзең нинди—илең шундый. Шагыйрь Равил Фәйзуллинның мондый шигыре бар:

Суыр көн дә коллыгыңны!
Җаныңнан чыгар чөйләп!

Ирегең, тоеп суласаң,
исемең—Кеше, димәк.

Хөрлектән башлана Кеше.
Коллыгы аның—ләхет.
Куркып тереклек иткәнче,
хөр үлә белү бәхет.

Төрекмән башы Сәпәрморат Ниязов әле күптән түгел генә бик тә мәгънәле бер фәрманга кул куйган. Төрекмән кызлары-егетләре чит ил кешесенә кияүгә чыга-өйләнә калса, чит ил кешесе дәүләткә 50 мең доллар күләмендә акча түләргә тиеш. Милләтне катнаш никах афәтеннән саклап калуның, менталитетны югалтмауның, генофондны бөтәйтүнең менә дигән чарасы түгелме соң бу, җәмәгать!

Хәер, нәтиҗә чыгаруларны азаккарак калдырып, Нияз Акмалның «Кол» кыйссасына күчик әле.

«Бу әсәрнең нигезендә чынбарлыкта булган хәл ята. Аның төп герое—минем бик якын бер танышым. Ике ай буе кайда югалып торуы хакында ул теләмичә генә сөйләде. Күрәсең, башыннан кичкән хәлләрне искә алуы коточкыч авыр иде аңа. Мин дустымның нинди бәлагә тарыганын бүтәннәргә дә бәян итәргә уйладым»—Автор үзенең әсәренә әнә шундый кереш сүз куя да, башлап җибәрә: «Мине инде эзли башлаганнар.»

Әсәрнең төп каһарманы Сөббух Каштанов колхоз рәисенең һәм дә үзенең йомышчылары белән калага килә, кунакханәгә урнаша. Ресторанда ашап-эчеп утырганда бер кыз белән таныша. Бу танышуның азагы бик күңелсез тәмамлана: кунакханәгә кайткач, кызый Сөббухка йокы даруы эчереп, аның бар булмыш малын-акчасын урлап кача. Бер тиенсез калган ир Кавказ ягы кешеләренә ялланып, шабашкага китә. Гарри белән Соломон атлы бу бәндәләр әнә шулай «шабашниклар» туплыйлар икән дә, аларны алдап-йолдап коллыкка төшерәләр, ягъни үзләренә бушка эшләтәләр. Әсәр әнә шул хакта. Заманча, әле моңарчы татар әдәбиятында яктыртылмаган тема.

Нияз Акмал җитди прозага «Күгәрчен сөте» повесте белән килде, укучыны вакыйгалар өермәсенә бөтереп алып кирә белә торган автор икәнлеген күрсәтте. Үтемле, ышандыргыч, нечкә, кайчагында бераз Хәсән Сарьянны да хәтерләтеп ала торган тел агымы, тасвирлаулар хас аңа.

«Кол»дагы Сөббухка килсәк, автор монда беркатлырак, әмма үзен хәйләкәргә санаучы, ихтыярын югалтмаган авыл кешесенең холык-фигылен, психологиясен оста тотып алган.

...Ахыр чиктә Сөббух коллыктан котыла:

«...Бераз ял итеп алгач, ничектер аңышып киттем: башта мин шактый озак йөгердем, бер авып, бер түнеп, куакларга тырнала-тырнала, озак чаптым... Мин бу мәхшәрдән котылырга, һичшиксез котылырга тиеш идем. Мин кол түгел, мин кол булырга тиеш түгел идем!

Кол?! Теге вакытта, кәрт уйнарга чакырган кичтә, Хуҗага да шулай дип әйткән идем. Ул көлде генә:

—Ялгышасың син, Сапог!—диде.—Без—барыбыз да коллар. Син—минем колым, мин—башка берәүнеке, ә кемдер—Алла колы... Бары тик коллыкның үзеңә тиешлесен сайлап ала белергә генә кирәк, аңладыңмы?.. Менә син, Сапог, үзеңне анда авылыңда чакта кол дип исәпләми идеңме? Син анда шундый ук кол идең. Кемдер сине эшләтә, синең исәпкә яшәми идеме? Менә хәзер мин сине эшләтәм, сине ашатам. Тагын ни кирәк?

Боларын ул исергәч әйтте.

Мин шуышам, үрмәлим, йөгерәм. Үзем Хуҗаның сүзләрен искә төшерәм. Ни өчен аның сүзләре яңгырый минем колагымда? Ник кирәк бу мәлдә миңа аның бу сүзләре? Аңламыйм. Юк, аңлыйм, беләм, шушы сүзләр мине алга үрмәләтә, алга таба куа. Шушы сүзләр минем тәндә үч һәм көч тудыра!»

Менә ул—шагыйрь прозасы! Хис тә, фикер дә—үз урынында. Үтемле, тәэсирле!

Күргәнегезчә, мин ике авторның да тел-сурәтләү чараларын, аерым детальләрен күзәтүне максат итеп куймадым. Бүгенге заманның берәр студенты, карават башына басып, авторын әйтмичә генә боларның берәр әсәрен укыса, кем язганын укымышлы иптәшләре дөрес тәгаенләр мөгаен. Чөнки бу

әдипләрнең һичкемнекенә охшамаган үз теле, үз стиле бар.

Ркаил Зәйдулла да, Нияз Акмал да әдәбиятка мәктәп партасыннан ук килеп, Олуг Татар Әдәбияты мәйданында каләм чарлаган, шәхес булып формалашкан әдипләр. Болар инде әдәбият белән язмышларын уртак иткән затлар. Янә шунысы куанычлы: икесе дә «кыскалыкта—осталык» принцибыннан чыгып эш итәләр. Шагыйрь прозасы шулай булырга тиеш тә. Чөнки шигырь кыскалыкка-тыгызлыкка, образлы фикергә, телнең тәмен-аһәңен тоярга өйрәтә ләбаса.

Безнең халыкта: «Йомшак агачны корт баса»—дигән бик тә гыйбрәтле бер гыйбарә бар. Сер түгел ки, бөтен Татарстан буенча бүген читтән килгән әрмәннәр мәктәбен-мәчетен төзи, фермасын, йортын сала. Үзебезнең татар исә эш юклыктан, акчасызлыктан интегә, «озын акча» артыннан читкә чыгып китәргә мәҗбүр. Гаррилар, Соломоннар, Рафиклар, һәм шуларга хәерхаһ персидәтел-түрәләр генә гаеплеме соң моңа? Шулай шул, йомшак агачны корт баса икән шул... Олуг әдибебез Миргазиян ага Юныс «Соңгы сулыш» әсәрендә *(«КУ» 1997, 8-10)* болай дип яза:

«Японнарның колониаль илгә әйләнми калуларының сәбәпләре күп булса кирәк. Алар бит җир йөзендә иң милләтче, чиктән тыш милләтче халык. Японнар арасында башка халык вәкилләре яши алмый. Монда яшисең килсә, рәхим ит, японлаш. Японлашасың килми икән—дүрт ягың кыйбла.

—Урыс та шундый түгелмени?

—Юк, түгел. Алар безгә, татарларга карата гына шулай аяусыз. Әрмәннәрне генә ал. (...) Башка халыкларны тулысынча урыс белән болгатып сыеклап бетергән чакта Әрмәнстанда бары тик ике генә процент урыс керә алган. (...) Әрмәннәр искиткеч пассионар халык. Алар әле безнең Татарстаныбызга да ябырылачаклар. Акча исенә искиткеч сизгер аларның борыннары.»

Авторлары раславынча, «Сөембикә»дә, «Кол»да—булган вакыйгаларга нигезләнеп язылган әсәрләр. Мәгълүм ки, авыруга диагноз куймыйча, аны дәвалап булмый. Минемчә, бу әсәрләр—диагноз. Коллык психологиясен чагылдырган әсәрләр элгәреге олуг каләм ияләребездә дә бар. Әмма бу язмада мин әле яшь ягыннан да чагыштырмача әлләни өлкән булмаган замандаш әдипләребезнең әсәрләренә тукталуны кирәк таптым. Чөнки бүгенге заман турында, бүгенге татарның хәл-халәте, кай тарафка юл тотуы хакында шушы заман казанында кайнаучы әдип кенә яза ала.

Франц Кафканың «Әверелеш» исемле хикәясе бар. Аның төп каһарманы Грегор Замза төшендә үзен бөҗәк итеп күрә. Бөҗәк исә дөньяны үзенчә—бөҗәкләрчә кабул итә... Ярый, Кафканың каһарманы өчен бу әверелеш төш кенә булып чыга.

«Әгәр милләтне йоклаган дисәк, дөнья көпчәгенең бу кадәр дөбердәп әйләнүенә вә башка милләтләрнең әллә нинди каты вә йөрәк яргыч тавышлануларына уянырга кирәк иде»—ди Тукай. Бу фикерне бөек әдип моннан бер гасыр чамасы элек әйткән. Шушы дәвер эчендә ни дә булса үзгәрдеме соң? Яңа меңъеллыкны ваклый башлаган безнең көннәрдә дөнья көпчәге Тукай әйткәндәгедән мең вә мең мәртәбәләр катырак дөбердәп әйләнә түгелме соң?! Татарың бөҗәк төше күреп яткан бер мәлдә кайсыбер милләтләр инде әнә дөньяга хуҗа булырга маташа.

# ТРАДИЦИЯДӘН ТАЙПЫЛЫП...

Совет чорында инкыйлаб солдатлары—кызыл гаскәриләр—тик уңай яктан гына, хәтта романтик биеклеккә үк күтәреп сурәтләнделәр. Рәхимсез керәш-бәрелешләрдә кан койган, шәһит киткән затларны бүтәнчә тасвирлау ничектер гаделсезлек булыр, күңелләрдә ныклап утырып калган күркәм образның типиклыгына күләгә төшерер кебегрәк күренә иде. Аннары кызыл гаскәри турында башкача уйлау хәвефсез дә түгел иде.

Ләкин бәндәләрнең бөтенесе дә бер генә калыптан сугылмаган бит. Дөнья күргән ил агаларына төрлесен очратырга туры килгән. Бар әйбәтләре, бар холыксызлары. Чынлап уйлаганда, тегеләре дә, болары да әдәбиятта үзләренә урын даулыйлар. Хәят турында китап аркылы гына фикер йөртмичә, тормышның үзенә текәлеп караган әдип андыйларга да игътибар юнәлтмичә калмый. Менә мисал итеп Ә. Еникинең «Корьәнхафиз» хикәясен, Г. Бәшировның «Сарут» повестен күрсәтергә була. Ә. Еники әсәре 1964 елда, Г. Бәшировныкы 1981 елда, ягъни тоталитар режим дәверендә язылган. Һәр икесе дә гражданнар сугышы чорын бәян итәләр, кызыл гаскәри образын яктырталар. Ләкин алар без күрергә күнеккән гаскәриләргә бер дә охшамаганнар, холык-гамәлләре, кыяфәтләре белән алардан шактый ерак торалар. Әллә шуннлыктан, әлеге әсәрләр тәнкыйть дикъкатеннән читтәрәк кала килделәр, гәрчә әдәби яшәештә күзгә чалынырлык булсалар да, аларга аерым игътибар юнәлдерелмәде, болар тирәсендә әллә ни бәхәс тә кузгалмады. Ошбу әсәрләр тикшерү, шәрехләү өчен җайсызрак та күренделәр, ахрысы.

Һәр ике әсәрнең авторлары да персонажларының болай төшеп калганнардан булмавына басым ясыйлар. «Корьәнхафиз»нең баш герое Хафиз хәлфә, мәсәлән, килеш-килбәте белән гаять күркәм, көяз-сылу: «Озын кара казаки кигән, нечкә билле, киң күкрәкле, уртадан калкурак нык, какча гәүдәле, бәрхеттәй кара сакал әйләндереп алган ап-ак чырайлы, юешләнебрәк торган кызыл иренле, ефәктәй йомшак кара мыеклы һәм аз гына сары йөгергән елтыр кара күзле бик чибәр бер кеше иде ул». *(Ә. Еники. Юлчы.—Казан: Тат. кит. нәшр., 1978.)*

Өстәвенә бу әфәнде Корьәнне яттан бик матур итеп, көчле мисыр мәкаме белән укый: «Әгузебилләһи... дип аз гына сакауландырып, тавышын аз гына калтырата төшеп башлап җибәрүгә, мәҗлес халкы тәмам оеп, мәрткә киткәндәй тынып кала, ә ишек артына җыелган хатын-кызлар, авызларын яулык чите белән каплап, тәмам эреп, яшьләрен агыза-агыза аны тыңлыйлар». Мәхәлләдә, Дәүләкәндә аның шөһрәте, дәрәҗәсе үсеп китә, агай-эне аның зур гыйлем иясе булуына, зирәклегенә соклана. Хәтта күп кенә сәүдәгәр кызларының да ул, хыялларына кереп, күңелләрен кытыклый һәм төн йокыларын качыра башлый.

Әмма хәлфә менә шушындый бер генә төс белән тасвирланырдай адәм түгел. Ә. Еники аны кискен контраст фонда чагылдыра. Бу кешенең мәдрәсәгә беренче керүендә үк шәкертләрнең эченә, салкын бизгәк шикелле, өшеткеч бер курку йөгерә. Аның кем икәнен ачык сиздерер өчен автор әсәргә гаҗәп үзенчәлекле бер деталь китереп кертә. Әлеге хәлфә кечкенә шәкертләр каршына өч талдан үрелгән озын чыбык белән килеп баса һәм юк кына гаеп өчен, сизмәгәндә, бер сүз әйтмичә, җитмәсә әле көлемсери биреп, шул чыбык-камчы белән балага китереп суга, аларны янаклый, базга төшереп ябa. Аның җәзаларыннан соң бәгъзе шәкертләрнең колагы ага торган булып кала. Корьәнхафиз бөтен мәдрәсәнең котын алган ерткыч зөбаныйга әверелә. Әсәрне хикәяләүче шәкерт аны өч урында сүләнгә (сәләүсенгә—рыська) тиңли.

Шул ук вакытта хәлфә үзенең хакимлек масштабын арттыру, хокукларын

кинәйтү турында да хыяллана. Анынча, мона ирешүнең иң ышанычлы юлы—Искәндәр ахунның жиләктәй сылу кызы Гайшәгә өйләнеп жибәрү һәм, ахун кияве сыйфатында, бай мәхәлләдә имам булып калу. Моның өчен ул хәзрәткә ничек тә якынаерга, үзен итагатьле итеп күрсәтергә, имамның жылы карашын яулап алырга тырыша.

Ләкин ахун хәзрәт колагына хәлфәнең кырын эшләре турында ишетелгән була инде. Ул аңа болай ди:

«—Алайса, ишек төбенә китеп, минем сүземне тыңлагыз: килмешәк-мишәр өчен минем үстергән кызым да, әзерләп куйган мөнбәрем дә юк.» Мондый жавап көяз-усал хәлфә өчен бөтенләй көтелмәгәнчә була.

«Сарут» повестеның баш герое Мифтах Шәмгуновны да Г. Бәширов күркәм кыяфәтле, гайрәтле егет дип тәкъдим итә. Ә. Еники хикәясенә хәлфә әзер характер белән килеп кергән иде. Әдип аның үткәне турында бер сүз дә әйтми. Беренче заттан, «мин» исеменнән хикәяләгәндә, читтән килгән кеше турында сүз барганда, бу мөмкин дә түгел. Аның бөтен барлыгы әсәрдәге вакыйгалар барышында, укучы күз алдында ачыла. Мифтах Шәмгуновта яман холык формалашуын исә Г. Бәширов тәрбия шартлары белән аңлата, моның байтак мисалларын китерә. Әсәрдән беленүенчә, Мифтах рәхимсез үги ана типкесендә үсә: «ул кечкенәдән үк явызлыкның зәһәре белән агуланып, аның «түмен татып», шуннан рәхәт табып үсте».

Гражданнар сугышы чорында бу егет ихтыярый булып кызыл армиягә языла да аннан качып кайта, гаскәри киемнәрен сатып эчә, бомба ыргытып авыл советы йортын шартлата, бөтен халыкны кан калтыратып тора. Трибунал аны атарга дип хөкем чыгара. Мифтах атарга алып барган жирдән качып китә.

Бу әсәрнең сюжеты гыйбрәтле характерларны ача баруга корылган. Ике әсәрдә дә әлеге персонажларның үчлекле булулары, ярсып-ярсып үч алырга йөрүләре бәян ителә. Гражданнар сугышы вакытында, авыл, шәһәрләр әле бер якта, әле икенче якта калган чакта, Ә. Еники герое Хафиз хәлфә Искәндәр ахун йортына бәреп керә: «Шпорлы итекләрдән, кызыл галифедан, ак папахадан, папаханың бөтен буена кыеклап кызыл тасма тоткан; аркылы-торкылы каеш шлеяләр кигән, бер янтыгында—кылыч, икенче янтыгында—наган». Шундый шартларда да бу егет кыяфәтне китерә белә. Ул, наган белән куркытып, Гайшәне таптыра, үзенә бирүне таләп итә.

Г. Бәшировның «Сарут»ындагы Мифтах, жаен туры китереп, товар поездына утыра, сактагы кызыл гаскәрине имгәтеп, киемнәрен, документын ала. Ләкин аның эш хәрәкәтләре гадәти мантыйк буенча бармый. Тормыш логикасы буенча йөрсә, ул бу жирләрдән мөмкин кадәр арырак китү, жан саклау, тынычрак урында яраларын дәвалау ягын карар иде. Мифтах исә үзенең дуамал холкы логикасы буенча китә. Анда үч алу тойгысы шулкадәр көчле ки, ул башка бөтен хисләрне, акылны каплап китә, аның сукыр ачу тойгысы яшь гомерен саклау инстинктыннан да өстен булып чыга. Ул, аягы, кулбашы яраланган булуына, хәтсез кан югалтуына карамастан, вагоннан төшеп кала, приговор жыйган өчен бөтен авылны яндырырга, кара күмергә калдырырга, күзе төшеп йөргән Гөлжиһанны—авылның беренче чибәрен—мәсхәрәләргә ниятли. Күренгәнчә, аның гамәле генә түгел, уй-нияте дә яман була. Күпер төбенә килеп житкәч, ул әлеге чибәрнең туен бозу чарасына керешә.

Бу әсәрдә бик мәгънәле бер деталь бар. Жирән кашка, Мифтахның жәзалавына, колынны аерып калдыруына түзә алмыйча, чыгымчылый, сикеренә башлый, егет ат сыртыннан егылып төшкәндә, өстәмә явызлыклары өчен, Мифтахны тибеп очыра. Кайбер иптәшләр финалның болай тәгәлләнүе белән килешмәделәр. Ничек инде, соңгы хөкемне кешеләр түгел, ат чыгара? Ләкин, беренчедән, ана карата кырыс, каты хөкемне иң әүвәл авыл халкы чыгара. Икенчедән, хайванның сабырлыгы төкәнүе повестьта жиренә житкереп, бик оста, ышандыргыч сурәтләнгән. Өченчедән, һәм монысы аеруча мөһиме, ат биредә, гомумән, табигатьне гәүдәләндерә, явызлыкка табигатьнең мөнәсәбәтен белдерә. Реаль тормышта да бит, яшәеш кануннарын сакламаган чакта,

табигатьнең берәгәйле сүзен әйтүе белән еш кына очрашабыз. Димәк, биянең явыз кешегә тибеп җибәрүенең тирән генә фәлсәфи мәгънәсе бар булып чыга. Бирелә гүяки кешеләр карары белән табигать мөнәсәбәте арасында тыгыз бәйләнеш төсмерләнә: ат кешеләрнең хөкем карарын гамәлгә ашырып куя. Укучылар хәтерли булыр, шундыйрак күренешне без Розалин Майлзның «Эдемга кайту» романында да очратабыз.

Ә. Еники әсәрендә Коръәнхафизның кеше атып үтергәне күренми. Әмма дин әһеле, рухани зат хозурына килеп, анда җәнҗал куптаруы, кыз сорау, гаилә кору кебек үтә нечкә, четерекле мәсьәләне наган төзәп хәл итәргә тырышуы, йола-тәртип белән исәпләшмәве күп нәрсә турында сөйли. Автор аның, яңа властька җайлашып, алга таба аның исеменнән бәндәләргә җәбер-золым сибеп йөрү ихтималына басым ясый. Хикәянең ахырында, нәтиҗә рәвешендә, бик хикмәтле сүзләр теркәлгән: «Кем булып чыкты бу кансыз, икейөзле кеше, кая кадәр барыр ул, язмышын кайларда, ничек итеп очлар икән дип гел баш вата идек. Әгәр кызыллар үзләре аның кем икәнлеген сизеп, башын чапмасалар, ул бер төрле кыяфәткә кереп, әллә нинди явызлыклар эшләп бетерер! Бик хәтәр кеше». Күрәсез, гаять җитди, еракларга төбәлгән кисәтү бу! Әсәр гүяки алга таба киң күләмдә таралачак террор, репрессияләрнең тәүге шытымнарын, яралгыларын чагылдыра, беренче аккордларын яңгырата.

Тормышның җанны бимазалый торган якларына текәлеп карау, шуларга җәмгыятьнең дикъкатен юнәлтү Ә. Еники иҗаты өчен гадәти хәл. Ягъни, «Коръәнхафиз»да әдипнең күпчелек әсәрләренә хас булган, зирәклек һәм кыюлык үрелешеннән туган күркәм сыйфат дәвам итә.

Тәүге карашка «Сарут» Г. Бәширов стиленнән беркадәр аерылыбрак тора кебек. Күпчелек әсәрләрендә әдип хаятның унай якларын, шуларның матурлыгын, гүзәллеген чагылдыра килде. Бирелә исә яман холыклы башкисәр сурәтләнә. Әмма асыл хасияте белән «Сарут» та Г. Бәширов иҗатының төп юнәлешендә урын ала. Бу әдип кешенең ниндилеген әхлак сыйфатларына карап бәяләргә ярата иде. «И язмыш, язмыш» (1986) дигән повестенда өлкән яшьтәге гади авыл карчыгы совет учреждениесендә эшләүче коммунист улына болай ди: «Бу яңа тормышта шарт-шорт мылтык шартлатулар озакка бармас ич. Киләчәктә гомер итәргә вөҗдан, ант, мәхәббәт, намус шикелле нәмәстәкәйләр дә кирәк булып чыгар». Автор «Сарут» герое Мифтахта яшәешнең нигезен тәшкил иткән кадерле рухи-әхлакый кагыйдәләрдән тайпылу, читләшүне күрә, аны әнә шундый затлы сыйфатлардан мәхрүм булганы өчен тәнкыйтьли, язмышының үкенечле тәгәлләнүен чагылдыра.

Күрәсез, ике әсәрдә дә кызыл гаскәриләр тискәре геройлар итеп тасвирланалар. Алар икесе дә иҗтимагый вәзгыятьне, илдәге буталыш, чуалышларны шәхси үч алу өчен файдаланалар, кешелек сыйфатлары җуелганлыгын үзләре үк фаш итәләр.

Шул ук вакытта «Коръәнхафиз»да, байтак әсәрләрдән үзгә буларак, автор Искәндәр ахунны каралтып күрсәтердәй бер генә сүз дә кулланмый. Әсәрдә ул ихтирамга лаеклы рухани зат буларак күз алдына килеп баса.

Димәк, әсәрләрдә инсанның дәрәҗәсе, ул еллардагыча, кайсы якта көрәшүе белән үлчәнми, ә бәлки аның асыл сыйфаты, холкы белән, әхлакъ кануннарына, гореф-гадәтләргә, йолаларга мөнәсәбәте белән бәяләнә.

Бу хасиятләре белән әлеге әсәрләр, Нобель премиясе лауреаты Б. Пастернакның «Доктор Живаго» романы кебек, социалистик реализм күрсәтмәләре белән бик үк ярашып та бетмиләр иде. Асылда исә алар ил гаме турында, кешеләрнең рухи-әхлакый сафлыгы хакында кайгырту, дөньяга җитди караш җирлегендә иҗат ителгәннәр.

**Фәрит ХАТИПОВ**

# «ЯҢА МИЛЛИ ЮЛ» ЖУРНАЛЫ ҺӘМ ТУКАЙ

* * *

Мәгълүм ки, күп кенә татарлар, төрле сәбәпләр аркасында, үзләренең асыл Ватаны—Идел-йорттан чит-ят җирләргә күченеп китәргә мәҗбүр булган. Элек-электән башланган бу процесс XX йөзнең беренче яртысында, аеруча Октябрь инкыйлабыннан соң тагын да көчәя төшә. Бу чорда шактый гына милләттәшләребезнең Алмания, Финляндия, Кытай, Япония, Корея, Төркия, Польша һәм кайбер башка мәмләкәтләрдә гомер кичерүе мәгълүм. Алар, гәрчә читтә яшәсәләр дә, Идел-йорттан тәмам аерылмыйлар: ата-баба җире, туган як мөһаҗир милләттәшләребезне төшләренә кереп йөдәтә, җирсү тойгысы бәгырьләрен кимерә. Ана теле, милли моң, дин, гореф-гадәтләр аларда теге яки бу дәрәҗәдә дәвам иттерелә.

Миңа 70 елдан артык гомерен читтә уздырган мәшһүр профессор-тюрколог Әхмәд ага Тимер белән Анкарада берничә мәртәбә очрашырга туры килде. Ул тумышы белән Әлмәттән. Минем дә шул яктан икәнне белгәч, Урсал таулары, Зәй сулары, Бигәш белән Әлмәт арасындагы инеш, өянкеләр турында сораштыра башлады. Үзе сөйли, ә күзләрендә яшь, моң-сагыш... Шунда мин мөһаҗирлектәге адәм баласының рухи халәтен, күңеле ничек җирсүен янә бер мәртәбә күрдем.

## I

Читтәге татарларның туган кавем белән бәйләнешен саклауда, милли рухны үстерүдә китаплар, вакытлы матбугат гаять мөһим роль уйный. Узган гасырның 20-40 елларында, хәтта бераз соңрак та милләттәшләребез яшәгән илләрдә төрле газитә-журналларның чыгуы мәгълүм. «Милли байрак», «Яңа япун мөхбире», «Азат Ватан», «Ерак Шәрекъ», «Идел-Урал», «Шәкердләр таңы», «Белдереш», «Казан» һ.б.—әнә шундыйлардан. Болар арасында аеруча Г. Исхакый мөхәррирлегендә Берлинда нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналы (ул әүвәл «Милли юл» исеме белән басыла) мөһим урынны алып тора. Гарәп хәрефләре белән басылган бу журналның (ул 1928—1939 елларда чыга) барлыгы 136 саны дөнья күрә.

«Яңа милли юл», аның тематикасы, характеры, авторлары хакында инде безнең берничә материалның басылганы бар *(Азатлык көрәшенең мөнбәре // Казан утлары.—1993.—N 3.—122—135 б. һ. б.)*. Журналдагы аерым язмалар, бигрәк тә Г. Исхакыйның публицистик, тәнкыйди, тарихи мәкаләләре, тиешле шәрех-аңлатмалар белән, укучыларга билгеле бер дәрәҗәдә иреште *(Бу хакта карагыз: Х. Миңнегулов. Исхакый мөһаҗирлектә.—К.: Таң-Заря, 1999.—82-83 б.)*.

«Яңа милли юл»—иҗтимагый, әдәби, тарихи, сәяси, педагогик, гыйльми журнал. Ул тематик байлыгы, материалларның төрлелеге, вакыт ягыннан һәм географик җәһәттән масштаблылыгы белән сыйфатлана. Әмма журнал милли рухта. Аның үзәгендә—татар тормышы, бу кавемнең язмышы, үткәне, бүгенгесе, киләчәге, дөнья халыклары арасында тоткан урыны. Игътибар итик: журналның исеме дә аның җисеменә, төп мәсләгенә туры килеп тора.

«Яңа милли юл»ның чыгымнары тулысы белән мөһаҗир татарларның үзләренеке. Аңа бернинди дәүләти оешма да ярдәм итми. Киресенчә, Советлар Берлегендәге иминлек оешмалары турыдан-туры да, башка дәүләтләр аркылы да журналга, аның хезмәткәрләренә, авторларына, хәтта укучыларына да төрле

киртәләр, комачаулыклар тудырып тора. Бу басманы алган аерым зыялыларны, урынсыз гаеп ташлап, төрмәгә утырту очраклары да бар.

Журналны чыгаруга иң күп һәм даими ярдәм күрсәтүчеләр, әлбәттә, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез. «Яна милли юл» сәхифәләрендә Суомидагы татарларның тормышы, рухи дөньясы киң яктыртыла. Биредәге милләттәшләребез—журналның иң актив укучылары да. Хәзер дә бу мәжмуганың күп кенә нөсхәләре Финляндиядәге татар гаиләләрендә бар. Өлкән буын аннан бүген дә хәбәрдар.




Төрки-татарның күренекле әһелләре—журналның даими игътибар үзәгендә. Болар арасында, әлбәттә, төп урыннарның берсен Г. Тукай алып тора. Бу унай белән шунысын да искәртик: мина мөһаҗәрәттә чыккан татарча гәзитә-журналларның шактые белән танышырга туры килде. Аларның һәммәсендә диярлек Тукай мөхтәрәм урынны били. Мәсәлән, 1970—1980 елларда Төркиядә төрек һәм татар телләрендә (нигездә, төрекчә) нәшер ителгән «Казан» журналының (барлыгы—23 сан) һәр санында диярлек Тукай турында материал, аның шигырьләре бар. «Милли байрак», «Азат Ватан» һ. б. гәзитә-журналлар да бөек әдипне читләтеп үтми.

«Яна милли юл»да, әдәбият, сәнгать, мәгариф, милли тел һәм гомумән татар яшәеше хакында сүз барганда, еш кына Тукай исеме, аның әсәрләре телгә алына, шигырьләреннән өзекләр китерелә. Аерым юллары бөтен журналга эпиграф рәвешендә дә бирелгән. Кыскасы, шагыйрь абруйлы зат, татарның бер символы рәвешендә күзаллана.

Мәгълүм ки, мөһаҗир милләттәшләребез гомер кичергән күп кенә илләрдә Тукай кичәләре уздырыла, шагыйрьнең туган, аеруча вафат булган көннәре билгеләп үтелә. Мәсәлән, журнал 1936 елның 10 апрелендә Берлинда Тукай кичәсе булуын хәбәр итә. Мәжмугада әдипнең рәсемнәре дә күзгә ташлана.

Болардан тыш «Яна милли юл»да Тукай турында махсус мәкаләләр, әдәби язмалар да басылып килә. Алар, нигездә, шагыйрьнең туган-үлгән көннәренә, бигрәк тә тууына 50, үлеменә 20, 25 ел тулу мөнәсәбәте белән бирелгән.

Бу төр материалларның һәммәсендә Тукайның бөеклегенә, көчле талантына, халыкчанлыгына басым ясала. Аның татар рухын, халыкның кайгы-шатлыгын, өмет-идеалларын тасвирлавы ассызыклана. Тукай туган телне, туган кавемне саклаучы һәм яшәтүче, милләтне бергә туплаучы, бер бөтен итүче бер көч, куәтле бер энергия чыганагы рәвешендә карала. Әлбәттә, мәкалә-язмалар үзләренең фикри тирәнлекләре, тел-стильләре белән төрле рухта язылган. Авторлары, нигездә, мөһаҗир татарлар, үзебезнең тугандаш зыялылар.

Журналның мәсләге, рухы, әлбәттә, иң беренче чиратта, баш мөхәрриргә, аның талантына, тәҗрибәсенә, эчке тоемына, дөньяга карашына бәйле. Г. Исхакый бу җәһәттән—татар журналы өчен идеал мөхәррир. Ул—бөтен иҗади һәм иҗтимагый сәләтен, тормышын, яшәү максатын милләткә, «милли юл»га багышлаган зат.

Тукай һәм Исхакый... Татарның бу бөек ике әһеле, аларның үзара мөнәсәбәте—һәм әхлакый, һәм инсани, һәм милли ноктадан гаҗәеп кызыклы, гаҗәеп актуаль мәсьәлә. Бу хакта инде мөһим генә язмалар да бар. Мәсәлән, мөхтәрәм Ибраһим ага Нуруллин «Г. Тукай һәм Г. Исхакый» мәкаләсендә *(Шәһри Казан.—1993, 17 июль)* бу ике затның бер-берсенә ихтирами карашлары турында кызыклы факт-мәгълүматлар китерә. Тукай Исхакый шәхесендә «даһи» кешене, милли таңны аттыручы затны, зыялыларның остазын күрә, хәтта аны билгеле бер дәрәҗәдә илаһилаштыра да. Г. Исхакый да, гәрчә алар көндәлек тормышта һич очрашмаса да, Тукайны элек-электән хөрмәт иткән, аны олуг шагыйрь дип таныган, илдә вакытта да, мөһаҗәрәттә дә әдип хакында унай фикерләр әйткән, бай эчтәлекле мәкаләләр язган. Мәсәлән, «Сүз» гәзитәсенең

1916 ел, 3 апрель санында басылган «Мәрхүм Тукай» язмасы *(Эльмира Ханнапова публикациясе.—Мәдәни җомга.—1996.—23 май)*—шуның бер гәүдәләнеше. Шагыйранә тел-стиль белән язылган, эмоциональ эчтәлекле бу мәкаләдә Исхакыйның Тукайга гаять җылы мөнәсәбәте, шагыйрь хакындагы уй-кичерешләре, аның татар тормышындагы бөек роле турында уйланулары үтә дә калку, үтә дә оста итеп бирелгән. Язма авторы шагыйрьнең бик иртә үлүенә, милләтнең аны саклый алмавына тирән үкенеч белдерә. «Сигез ел фәүкыльгадә (гадәттән тыш.—Х. М.) авырлыкта кичергән вакытында, шагыйрьлегенең сабыйлык дәверендә татарның гамәл дәфтәренә шулкадәр Тукай ниләр язган булыр иде! Нинди әсәрләр белән, нинди шигырьләр белән татар әдәбиятын, татар шигырь дөньясын бизәкләгән булыр иде!»—диелә ул мәрсияви мәкаләдә.

## II

«Яңа милли юл» журналында Тукайга мөнәсәбәтле материаллар арасында Г. Исхакыйның шагыйрь турында үзенең дә махсус мәкалә-язмалары бар. Шундыйларның берсе «Тукай истәлеге» дип аталган. Шагыйрьнең үлеменә 20 ел якынаю уңае белән язылган бу материал журналның 1932 елның 11 нче санында дөнья күргән *(1—4 бб.)*. Тукай юбилее,—ди мәкалә авторы,—«Тәрҗеман»ның чыга башлавына 50 ел тулу белән бергә туры килә. «Исмәгыйль Гаспринский бөтен төрк иленең уртак пәйгамбәре булганга, «Тәрҗеман»ның 50 еллыгын бәйрәм итү—аны искә төшерү бөтен төрк кабиләләренең уртак бурычы». Чөнки аларның бер өлеше—Төркия «үз эшенә үзе хуҗа». «Тик Тукайның 20 еллыгын кем искә төшерәчәк?». Ул «безнең Идел буе төрк-татарының шагыйре булганга, ул безнең халкыбызның моңын җырлаучы, безнең дәртебезне күпләүче булганга, аны искә алу да турыдан-туры безнең өстебезгә йөкләнә».

«Әмма,—ди Г. Исхакый,—илдә халкыбыз хокуксыз. Тукай татар халкы өчен аның кайгысын-хәсрәтен әйтеп бирә торган бер халык шагыйре булса да, Совет карашыннан, ул—мулла баласы, милләтче, динче; коммунизм карашыннан, ул—урыслаштыру тәрбиясенә киртә салып торучы бер контрреволюционерчы; илебезне-йортыбызны урыс мөһаҗире берлә тутырырга теләүче кызыл Мәскәү карашыннан, ул—шовинист милләтче; бөтен большевик сәясәте карашыннан, ул,—үзенең халкы кебек, үз илендә бөтен нәрсәдән мәхрүм «хокуксыз—лишинтәс».

Г. Исхакый читтәге татарларны Тукайның үлеменә 20 еллыкны мөмкин кадәр хәзерлек белән тиешле югарылыкта үткәрергә чакыра. Моның өчен мәкалә авторы махсус комиссия төзү, шагыйрьнең әсәрләрен бастыру, Тукай турында җыентык чыгаруны саный. Г. Исхакый фикеренчә, шагыйрьне зурлау, искә алу—милләтнең уртак бурычы.

Баш мөхәррирнең шагыйрь турындагы язмалары арасында аеруча «Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә» мәкаләсе игътибарга лаек *(1938.—4 сан.—1—9 б.)*. Бу материал яшь галимә Алсу Кәримова тарафыннан әзерләнеп, кереш сүз белән «Казан утлары» журналында да басылып чыкты *(1999.—4 сан.—180—186 б.)*.

Г. Исхакыйның гыйльми-теоретик һәм тәнкыйди эчтәлекле бу язмасы шактый кызыклы, полемик рухлы. Мәкалә авторы шагыйрьләрне, «шәхси кабилиятләренә» *(сәләтләренә.—Х. М.)*, иҗади фикерләү үзенчәлекләренә, җәмгыять белән мөнәсәбәтләренә карап, икегә бүлә. Беренчесе—индивидуалист табигатьле, шәхси уй-кичерешләрен генә үзәккә куючы, «бәйнәлмиләл шигырьләр» тудыручы авторлар. Икенчеләре исә үзләрен «тирә-юньнең, мохитның бер өлеше итеп хис итеп, шуның бөтен күңел алышынуларына үзенең йөрәк тибүе берлә катышып, аның шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь ятучылардыр *(язучылардыр.—Х. М.)*». Болар «туган халкы, аның тирә-юне, яшәгән мохитының шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәрҗеманы *(күчерүчесе; тылмачы.—Х. М.)*, «термометры».

Г. Исхакый беренче төркемнең вәкиле итеп С. Рәмиевне күрсәтә, икенчесенә Г. Тукайны кертә. Соңгысын тасвирлап, ул болай яза: «Үзенең мохитының шатлыгын, кайгысын, дәрден шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр. Аның яшәгән, язган дәвере бездә милләтчелекнең иң кайнаган, милли теләкләрнең берсе өстенә берсе үсеп, тирә-якны тутырган вакыт булганга,

ул шул теләкләргә, шул омтылышларга бер шигырь төсе бирүче, чуалчык фикерләрдән туган агымларга тугры юл күрсәтергә теләүче, милләт хезмәтчесе, милли шагыйрьдер... Бөтен кыска гомере буенча ул... милли юлдан һичбер тайпылмаенча, кабергә кадәр милләт ерын ерлап, милләт кайгысын көйләп, милләт көлкесендән көлеп, үзенең милләтчелек калыбына сугып киләдер».

Г. Исхакый Тукай тирәсендәге бәхәсләргә, аны «шагыйрьлек» тәхетеннән төшерергә «маташучы»ларның эшчәнлегенә дә туктала, «Мөнтәкыйдкә» һәм кайбер башка шигырьләрен анализлау аша Тукай мәсләгенең «дөрест вә тугры» булуын янә бер мәртәбә раслый. «Бәрәкәт боерсын,—ди ул,—Тукайны бу ялгыш тәнкыйтьчеләр бу хата юлларга суга алмадылар. Тукай үз юлында баручы, милләт кайгысын кайгыртучы халык шагыйре булып калды».

Г. Исхакый Тукай шигырьләренең, шул исәптән әдәби тәржемәләренең дә тәрбияви әһәмиятенә югары бәя бирә. Шагыйрьнең «Туган тел» парчасы хакында ул, мәсәлән, болай ди: «Милли хис вә милли гакыл бергә кушылып эшләнгән бу шигырь... Тукайның тәрбияви шигырьләренең иң кыйммәтлесеңер... Бу шигырь бөтен мәктәпләребездә милли һәйммнә *(гимн.—Х. М.)* төсен ала алмышдыр һәм бу шигыре Тукайны мәңгегә безнең балаларның иң сөйгән бер ерчысы итеп куймышдыр».

Мәкаләдә Тукайның, тәнкыйтьчеләрдән тыш, икенче «дошманы»—чир белән көрәше дә телгә алына. Авыру халәт «аның шигъри куәтен зәгыйфьләндермәсә дә,—ди Г. Исхакый,—аның бу шәхси дәрде *(авыруы.—Х. М.)*, бу кайгысы аның сазын тагы да нечкә кылларында уйнатып, аның шигырьләрен тирәнәйтте».

Г. Исхакый, Октябрь инкыйлабына кадәр язган мәкаләләрендәге кебек, биредә дә Тукайны саклап кала алмауга үкенечен белдерә. «...Бөтен төрк-татар дөньясы алдында,—ди ул,—Тукай йилдә яна торган шәм кеби көндән-көн аның актык сәгатьләре якынлаша. Ләкин аны саклау тәдбире (уй-нияте.—Х. М.) иң соңгы вакытка кадәр кичектерелә».

Г. Исхакыйның мәкаләсе шушындый юллар белән тәгәлләнә: «Тукайның вафатының 25 еллыгы көнендә үксез иленең бүген кызыл руслык хөкеме сөргән үксез почмагында ятим яткан кабере алдында теземезне чүгәмез. Исән вакытта кирәге кадәр кадерен белмәгән, кыйммәтен танымаган милләтнең бүгенге хөрмәтен, сөйгесен газиз рухына сонамыз (багышлыйбыз.—Х. М.)».

«Яңа милли юл» журналында Тукай турында басылган язмалар арасында Сәгадәтнең мәкаләләре дә игътибарга лаек.Аларның берсе шагыйрьнең тууына 50, икенчесе үлеменә 25 ел тулу уңае белән язылган *(1936.—6 (100) сан.—14—17 б.; 1938.—4 (121) сан.—9—14 б.)*. Һәр ике мәкалә дә «Габдулла Тукай» дип исемләнгән.

Мәгълүм ки, Сәгадәт (1907—1989)—Гаяз Исхакыйның кызы. Ул Алманиядә университет белеме ала. 1932 елда кияүгә чыга һәм аннан соң Чагатай фамилиясе белән дә йөри башлый. Сәгадәт—тормышта, аеруча «Яңа милли юл»ны чыгаруда әтисенең төп таянычы. Гаяз Исхакыйның Ерак Шәрекъка өч еллык сәфәре вакытында журнал белән, нигездә, Сәгадәт Чагатай мөхәррирлек итә. Бу мөхтәрәмә затның соңгы 50 еллык гомере, эшчәнлеге Төркия белән бәйле. Ул анда гыйльми-тикшеренү, педагогик эшләр белән шөгыльләнә, мәшһүр тюрколог-профессор буларак таныла.

Тукай турындагы мәкаләләрендә Сәгадәтнең шагыйрь рухын яхшы аңлавы, поэзияне әйбәт тоемлавы сизелеп тора. Аурупа тормышы һәм университеты аның милли тәрбиясенә, татарлыгына зыян китермәгән, киресенчә, яшь галимәнең офыкларын киңәйтә, милләтпәрвәрлек хисен үстерә, карашларын тирәнәйтә төшкән. Тукайның шигъри үзенчәлеген, татар хәятындагы ролен билгеләүдә Сәгадәтнең фикерләре әтисенең уйланулары, бәя-хөкемнәре белән шактый якын һәм авазадаш.

Сәгадәт язган мәкаләләрдә дә Тукайга хөрмәт, ихтирам бөркелеп тора, аның халык шагыйре, татарны берләштерүче символ булуына басым ясала. «Нә күнелле, нә яхшы ки,—Тукаемыз бар! Халык өчен *(бу)*... бөек юаныч...»,—ди автор. Тукайны Тукай иткән иң мөһим нәрсә—«милли вөҗдан». «Бу милли вөҗдан,—ди Сәгадәт,—Тукайда шулкадәр саф, шулкадәр тирән ки, аның тәэсиренә бирелмәү мөмкин түгел. Галимә шагыйрьдәге аерым житешсез якларны да күрә. Әмма ул бу төр күренешләрне Тукайның яшьлеге, тәҗрибәсезлеге, милли үсешнең торышы белән бәйләп аңлата. Чөнки аның иҗаты—билгеле бер дәрәҗәдә «шул дәвернең көзгесе» дә. Сәгадәт фикеренчә, безнең халык, гәрчә

алга таба шактый зур адымнар ясаса да, «бөтен тулы житешкән бер милләт булып тәмам житмәгән. Әмма ул «югары баскычларга» күтәрелү юлында. Тукай иҗаты исә милләтнең алга барышын җиңеләйтә, безне рухи яктан пакьләндерә, үстерә.

Сәгадәт шагыйрьнең балалар өчен язылган парчаларын аеруча кыйммәтле дип саный. «Тукай,—ди ул,—балалар өчен язып калдырган бик матур шигырьләре берлә үзенең бала сөючән рухын, үзенең халкының балалык дәверен кичерүен вә халык өчен бала тәрбияләү киләчәк өчен иң нык нигез булуын күрсәтеп торадыр». Галимә шагыйрьнең балалар поэзиясе өлкәсендәге уңышларын аның шәхси табигате («вөждан сафлыгы», «керсезлеге», «самимилеге», ихласлылыгы...) белән дә аңлата. Сәгадәт карашынча, Тукайны яшәтүнең, «аның берлә бергә булу»ның иң «тугры» чарасы—шагыйрь әсәрләрен «тагын да күбрәк уку».

Мөһаҗир татарлар чыгарган гәзитә-журналларны, китапларны актарганда, Солтан (Әхмәд Виргаз) исеме күзгә еш ташлана. Ул чыгышы белән Мордовия якларыннан. Ерак Шәрекъта—мөһаҗир. 1929 елда аның Харбинда 27 битлек «Шигырьләр» исемле китабы да чыга.

«Яңа милли юл» журналының 1935 елгы 7 нче санында Солтанның «Габдулла Тукай» исемле язмасы бар (20—22 б.). Ул шагыйрьнең «үлүенә 22 ел тулу унае берлә» басылган.

Солтан мәкаләсенең тел-стиле шактый камил, урыны белән хәтта шигъри. «Милли моңнар» әсәреннән алынган өзекләр, ничектер, язма эчтәлегенең лейтмотивы булып та яңгырый.

Милләт һәм шагыйрь проблемасы—мәкаләнең үзәгендә. Чын әдип үз халкының кайгы-шатлыгын, моң-зарын белдерә, аның мәнфәгатьләрен, язмышын кайгырта. Тукай—нәкъ әнә шундый шагыйрьләрнең берсе. Ул «үзенең иҗаты... берлә халкыбызның әйтергә теләгән тойгыларын җиңел, шома бер телдә әйтеп бирде; ... Тукай шигырьләрендә—халкыбызның тибеп торган күңел чишмәсе». Мәкалә авторы шагыйрьнең үзенчәлеген, популярлыгын нәкъ әнә шунда—халык белән тыгыз бәйләнештә күрә. Тукай иҗаты тормыш белән бергә яши, милләтне дулкынландыра.

Солтан милләтнең, андагы әдипләрнең дөньяга танылу-танылмавын турыдан-туры иҗтимагый-сәяси шартларга бәйләп карый. Кагыйдә буларак, хөр, бәйсез халыкларның әдип-шагыйрьләрен дә дөнья халкы белә.

Мәкаләдә Тукайга мөнәсәбәтле аерым материалларның чит ил матбугатында да күренә башлавы искәртелә. «Тукайның үлүенә 20 ел тулганда *(димәк, 1933 елда.—Х. М.)*,—ди Солтан,—поляк телендә чыга торган «Daleki Wschod» журналы Тукайның рәсемнәрен төшереп, мәкаләләр багышлап, берничә шигырен тәрҗемә дә иткән иде». Минем белүемчә, бу материаллар хәзерге татар фәненә мәгълүм түгел. Димәк, поляк телендәге бу журналны, һичшиксез, табу, гыйльми әйләнешкә кертү, Тукай музеена кую зарури[1].

Мәкалә ахырында Солтан Тукайның Заһир Бигиевкә багышлап язылган түбәндәге юлларын китерә:

Шалыман ул мәркадеңдә *(шат бул кабереңдә.—Х. М.)*!—
без онытмыйбыз сине;
Белмәсәк вактында кадрен, инде котлыйбыз сине.

Бу юлларны ул шагыйрьнең үзенә карата куллана.

Прозаик, драматург, журналист, мөгаллим, режиссер, актер, җырчы Хөсәен Рәхимҗан углы Габдүш (1901—1944)—мөһаҗир татарлар арасында Тукайны өйрәнүгә, пропагандалауга, мөгаен, иң зур өлеш кертүчеләрнең берседер. Мәгълүм ки, 1933 елда Токиода «Матбагаи исламия»дә гарәп хәрефләре белән Тукай әсәрләренең биш томлыгы дөнья күрә (барлыгы—646 бит). Хөсәен Габдүшнең бу игелекле эштә дә катнашы бар. 1932 елда ул Харбинда шагыйрьнең үлеменә 20 ел тулу алдыннан Тукай турында «программ» характердагы бер китапчык та бастыра *(Кызганычка каршы, ул безнең кулыбызда юк)*.

«Яңа милли юл» журналының 1936 елгы 5 санында Х. Габдүшнең «Бөек «Кушлавыч» ятиме» дигән мәкаләсе бар *(4—8 б.)* Ул шагыйрьнең тууына 50 яшь

---

[1] Бу унай белән янә шунысын да искәртик: Төркиядә яшәгән күренекле тарихчы, профессор Хәмит Зөбәер Кошайның да (1897—1978) бер венгер журналында Тукайга багышланган французча мәкаләсе басылуы мәгълүм (Яңа милли юл.—1936.—№ 5; 5 б.).

тулу мөнәсәбәте белән язылган. Мәкалә шактый кызыклы, үзенчәлекле. Анда авторның үз карашы, үз тоемы сизелеп тора. Текст гыйльми-тәнкыйди, публицистик, лирик-эмоциональ башлангычларның синтезыннан гыйбарәт.

Мәкалә шагыйрьнең исеме, тәхәллүсе *(кушаматы)* хакында фикер йөртүдән башлана. Әмма автор шушы билгеле нәрсәләрдә тирән мәгънә, Тукай иҗатының символик асылын, тормышчанлыгын күрә. «Аның исемендән үк,—ди Хөсәен Габдүш,—халкыбызның үзлегендән аерым алынмас бер нота яңгырый: Тукай! Ата-анасы кушкан исеме—халкыбыз арасында иң күп таралган вә сөелеп әйтелә торган исем—Габдулла.

Тукай—бу Габдулланы башка бик күп Габдуллалардан аерып, аны «Кечкенә Апуш»лыгыннан аерып, «зур-зур» төрк-татар шагыйре дәрәҗәсенә күтәргән исеме дә арабызда сирәк очрый торган саф үзебезчә, милли бер исем...

Тукай—... төрк-татар тарихында мәңге онытылмаслык бер исем.

Шагыйребезнең исеме халкыбыз арасында шул дәрәҗәдә киң таралган ки, кайбер вакыт әдәбияттан бөтенләй хәбәрсез, надан кешеләрнең авызыннан да аның берәр шигырен ишетергә туры килә».

Хөсәен Габдүш Тукай әсәрләренең идея-тематик яктан гаять киң һәм күптөрле булуына, милләт яшәеше белән табигый керешүенә басым ясый. «Тукайның яратышындагы *(ягъни иҗатындагы.—Х. М.)* рух халкыбызның күнеле берлә шул дәрәҗәдә, әгәр гыйбарә дөрест булса, игезләнеп беткән ки, халкыбыз хакында фикер әйткәндә, Тукайны искә алганда, милләтебез тугрында сүз сөйләми мөмкин түгел. Алар бер-берләрендән аерылмыйлар».

Хөсәен Габдүш шагыйрьне өйрәнүчеләрдән Җәмал Вәлиди хезмәтләрен, аеруча аның Тукай җыентыгына (1914) кереш рәвешендә язылган «... Мөляхәза»сын *(уйлануларын)* унай бәяли, аннан өзекләр китерә.

Җәмал Вәлиди: «Татар халкында түземлек, ... ерак ноктаны күзәтеп эш күрү юк,—ди.—Аның асаре шигъриясендә хыялый бөтенлек, киңлек түгел, бәлки бер хисси чуарлык, тарлык күрәмез. Хәтта бу тарлык, чуарлык шул дәрәҗәдә ки, ул бөтен ике мисраглык бер җыр җырлый алмый. Һич мөнәсәбәтсез вә туп-тугры Ак Идел буйларыннан үзенең җанкәсәенә күчә, тәрәзә капкачыннан туган иленә килеп төшә». Җәмал Вәлиди шушындый чуарлыкны Тукай шигырьләрендә дә күрә. Әмма Хөсәен Габдүш халык, шагыйрь турындагы мондый фикерләрне сорау астына ала, бу төр мәсьәләләр хакында укучыны уйланырга чакыра. Аның карашынча, милли күтәрелеш чорында мондый «мөляхәзалар» яшьләребезгә, табигый, файдалы яктан тәэсир итмиләр», «Кимчелекләре безне санау гына түгел,—ди ул,—аларның төп сәбәпләрен һәм аларны төзәтү юлларын күрсәтеп, аңлатып бирү—укымышлы сыйныфыбыз өстенә килеп төшкән милли вазыйфаларның берсе».

Гомумән, мәкалә эзләнү, уйлану рухында язылган.

Мәкалә авторы Тукайның «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» мәрсиясендәге юлларын шагыйрьнең үзенә күчереп, язмасын мондый сүзләр белән тәгәлли: «Аның кадерле исеме үлмәячәк. Ул «...милләт яшәдекчә яшәр, милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар»... (Шагыйрь) «үзенең бик иртә өзелеп киткән ялгыз гомеренең соңгы секундларына чаклы талант көчен аямады...»

Хөсәен Габдүшнең үз гомере дә халыкка хезмәт, шагыйрьне аңлау-аңлату юлында өзелде. Бу милләтпәрвәр зат ел саен апрель аенда Харбин һәм гомумән Ерак Шәрекъ татарлары өчен Тукай кичәләре уздыра. Ул шундый кичәләрнең берсенә хәзерлек вакытында сәхнәдә йөрәге тотып үлә. Гомере буе Идел-йортны сагынып яшәгән бу моңлы затның җәсәде дә еракта, Харбин зиратында. Бәлкем инде аның кабере дә юкка чыккандыр?

«Яңа милли юл» журналында Тукай турында, гыйльми, тәнкыйди, публицистик язмалар белән беррәттән, шигырьләр дә бар. Шундыйларның берсе «Габдулла Тукайга» дип атала *(1936.—17—18 б.)*. Аның авторы—Шаһвәли Келәүле *(Илдәр. 1900—1970)*. Бу шигырен ул Мукденда яшәгәндә, «Милли Байрак» газитәсендә эшләгәндә яза.

Шаһвәли Келәүленең тормыш юлы һәм иҗаты Надир Дәүләт мәкаләсендә *(«Казан утлары».—2000.—141—153 б.)* шактый тулы яктыртылган. Биредә бары шуны гына искәртәбез: бу затның Дим буйлары, Идел-йорт (Габдессәлам, Дәүләкән, Келәүле, Кызылъяр...), Себер, Шанхай, Мукден, Истанбул һәм кайбер башка төбәкләр белән бәйләнешле гомер юлы шактый катлаулы,

каршылыклы, фажигале. Әмма шуна да карамастан, ул әдәбиятка мәхәббәтен сүндерми: үзе дә шигырьләр, поэмалар, сәхнә әсәрләре иҗат итә. Аның «Асламчылар» исемле комедиясе милләттәшләребез тарафыннан Шанхайда һәм Төркиядә куела. Әдипнең әсәрләре «Яңа милли юл», «Милли Байрак», «Казан» һәм башка газета-журналларда дөнья күрә.

«Габдулла Тукайга» шигырендә ул шагыйрьне «юл күрсәтүче», кояш кебек нурландыручы, «файдалы орлык чәчеп» калдыручы дип атый. Шигырьнең соңгы юллары болай яңгырый:

Әй Раббым, ник син алдың яшьли аны дөньядан?
Ачы авазлар белән без яд итәбез һәр заман.
Аерылып китсәң дә бездән, данлы шагыйрь, мәңгегә,—
Калды эшең һич югалмас тарихи милләтенә.
Бар төрк-татар бу көндә баш иябез рәсменә,
Рухына оҗмах телимез һәр догада Тәңрегә.

* * *

«Яңа милли юл» журналы һәм Тукай... Билгеле бер күзәтү ясау да бу ике төшенчә арасында тыгыз, табигый мөнәсәбәтләр яшәвен ачык күрсәтә. XX гасырдан башлап татар яшәеше шагыйрь рухы белән сугарылган. Тукайсыз милли юлның яңасы да, искесе дә юк. Шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлаган һәм чынбарлыкка тугры калган журнал нәкъ менә шуңа күрә дә Тукайга үзенең түрен бирә, аны милли үзлекнең мөһим бер символы итеп карый.

Безгә бөек шагыйребез хакындагы һәр төрле мәгълүматны, шул исәптән «Яңа милли юл» журналындагы материалларны да хәзерге укучыга җиткерергә, бүгенге югарылыктан торып анализларга кирәк. Бу—безнең әхлакый, инсани һәм милли бурычыбыз.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

# Солтан[1]

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

*Үлүенә 22 ел тулу уңае берлә*[2]

*Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә*
*Татар күңле ниләр сизгәнен;*
*Мискин булып торган өч йөз елда*
*Тәкъдир безне ничек изгәнен.*

Һәр милләтнең, һәрбер халыкның тарихи язмышына карап, үзенең моны, җыры, көе, зары була. Һәрбер милләт кайгыра, шадлана, моңлана, зарлана... Һәрбер милләтнең моңын, шадлыгын, кайгысын әйтеп бирә торган үзенең шагыйре—халык шагыйре була. Без Идел-Урал төрк-татарларының да, үзебезнең кайгыбызны, шадлыгыбызны, барлыгымызны—халкыбызның еллар буенча күңелендә янган тойгысыны әйтеп биргән шагыйребез булса, ул да—мәрхүм Габдулла Тукай иде. Тукай—халык *(шагыйре)* иде, Тукай теле—халык теле иде... Тукай үзенең иҗады, шигыре берлә халкыбызның әйтергә теләгән тойгыларын җинел, шома, искиткеч матур бер телдә әйтеп бирде. Менә шуна

[1]Солтан-Әхмәд ВИРГАЗ—шагыйрь, журналист. Чыгышы белән Мордовия төбәгеннән. Ул яктагы татарлар арасында Виргаз (Вергасов, Вергазов...) фамилиясен йөртүчеләр хәзер дә шактый. Казанда да Равил, Таһир һ. б. Вергасовлар бар.
[2]Яңа милли юл.—1935.—№7 (90).—20-22 б.

күрә Тукай татар әдәбияты тарихында зур урын алып, «халык шагыйре» дигән исемне алды. Тукай үзенең аз гына гомерендә шундый әдәби җәүһәрләр чәчрәтте, ул җәүһәрләрне җыярга, Тукайны өйрәнергә Казанда һәм башка җирләрдә дә аерым «Тукай түгәрәкләре» дөньяга килде. Кыскасы, Тукай үзенә бер мәктәп тудырды. Тукай төрк-татарның классик бер шагыйре булды. Тукай шигырьләрендә—халкыбызның тибеп торган күңел чишмәсе. Шуңа күрә аның шигырьләре җанлылар... Тукай шигырьләрен укыган саен, мәгънәсе арта бара. Мәгънәсе арткан саен, Тукай югары күтәрелә. Тукай теленең иң төп хосусияте җиңел, шомалыгында булса, шигырьләрен укыган саен мәгънә һәм фәлсәфәнең арта баруы да җанга азык булып, күңелгә утырып калуындадыр. Бу шагыйрь, чын мәгънәсе берлә, каләмен күз яшенә манчып язды:

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.[1]

Идел-Урал төрк-татарларының кайгысын, шадлыгын җырлаган шагыйрьне искә алганда һәм тарихыбызның караңгы битләренә барып төртелгәндә, шагыйрь әйтмешли: «Аh, дисең, без ник болай соң?—Без дә хакның бәндәсе!..».

Бөтен мәдәният дөньясы инглизнең Байронын, алманларның Гетесен һәм башка әҗнәби *(чит)* милләтләр үзләренең милли шагыйрьләрен дөнья күләмендә таныта. Ни өчен соң без—төркләр үзебезнең әдипләребезне, шагыйрьләребезне, гомумән алганда, әдәбиятыбыз берлә дә танышдыра алмыйбыз?! Бу, әлбәттә, бездә начар әдипләр, шагыйрьләр булудан түгел, бонын төп сәбәбе менә нәрсәдә:

—Әгәр Тукай русның залим, канлы кулы астында изелгән, мәхкүм *(хокуксыз)* милләтнең шагыйре булмыйча, үзенең хөр илендә, иркен яшәп, истикълалең *(бәйсезлеген)* алган бер милләт шагыйре булса иде, ул башка милләтләргә дә күптән танылган булыр иде. Тукай хакында да чит матбугатда мәкаләләр язарлар иде. Чөнки Тукай—зур шагыйрьләр берлә тиңләшдерерлек бер шагыйрь. Ләкин гасырлар буенча изелгән, русның җандарм көче һәм безнең бөтен милли хәрәкәтебезгә русның балта чабып килүе аркасында, без Идел-Урал төркләре күңелебездә янган ялкынлы теләкләребезне яза алмый килдек...

«Милләтләр зинданы» ватылып, Русиядә инкыйлаб дулкыннары кубкач да, Русия кул астындагы һәрбер милләт үзенең милли фикерен бәйнәлмиләл *(халыкара)* сәясәт мәйданына ташлап, үзләренең истикъпальләрен даулый башладылар. Һәм кайберләре үзләренә үзләре хуҗа да булдылар. Болар шунын нәтиҗәсендә хәзер үзләренең фикерләрен, шагыйрьләрен, әдипләрен чит милләтләргә яхшы танытып киләләр.

Тукайның үлүенә 20 ел тулганда гына безнең шагыйрь дә чит милләтләргә киңрәк күләмдә мәгълүм була башлады. Бигрәк тә безнең кеби рус кул астында изелгән милләтләр безнең тарихыбыз, әдәбиятыбыз аркылы безнең берлә аңлашмакчы, берләшмәкче булалар. Тукайның үлүенә 20 ел тулганда поляк телендә чыга торган «Daleki Wschod» журналы Тукайның рәсемләрен төшереп, мәкаләләр багышлап, берничә шигырен тәрҗемә дә иткән иде. Шул вакыт башка чит матбугатта да язылып үтде. Болар әле беренче карлыгачлар гына...

Тукай—әле үзебез өчен дә өйрәнеп бетмәгән шагыйрь... Ул елдан-ел өйрәнелә. Тукай шигырьләре татар ләһҗәсендә *(телендә)* булганга күрә, алар халкыбыз тарафыннан сөйләп укыла. Тукай шигырьләре, халык әдәбиятыбыз кеби, җиңел һәм тиз ядлана... Без әдәбият тарихыбызны карасак, Тукайдан алдарак килгән шагыйрьләр бар. Һичшиксез, бу шагыйрьләребез арасында үзенең шигърияте берлә халыкның күңеленә иң якын торучысы Тукай булып килә. Безнең Идел-Уралда Тукайны белмәгән бер караңгы почмак бармы? Тукай каләме астында Идел-Урал әдәбияты чәчәк атды. Тукай татар ләһҗәсенең матурлыгын, рухын аңлатды. Ул халкыбызның сөйгән җырчысы—халык шагыйре булды...

Тукай күп шигырьләрендә көлкү-һәҗү кыйсеменда, «Шүрәле» кеби әсәрләрендә мәүзуг (тема; сюжет) итеп халык хикәяләре, әкиятләре алынган;

[1]Бу һәм эпиграф итеп китерелгән дүртьюллык строфа Тукайның «Милли моңнар» шигыреннән.

менә шуның өчен дә аның шигырьләрендә халкыбызның язмышын, шадлыгын, кайгысын бигрәк тә ачык күрәбез. Тукай шуларны барысын татар ләһҗәсендә бик оста, матур, шома җырлап бирде.

Шадыман ул мәркадеңдә *(шат бул кабереңдә)*!—
Без онытмыйбыз сине;
Белмәсәк вактында кадрен,
Инде котлыйбыз сине.[1]

# Хөсәен Габдүш[2]

## БӨЕК «КУШЛАВЫЧ» ЯТИМЕ

*Шагыйрьгә 50 яшь тулу уңае берлә*[3]

Язганың булса бәкалы[4], ул бәкага тарта ала[5],
Мин дә булдым һич дә онтылмас кеше шул аркада[6].

Тукай.

Аның исемендән үк халкыбызның үзлегендән аерып алынмас бер нота янгырый: Тукай! Ата-анасы кушкан исеме—халкыбыз арасында иң күп таралган вә сөелеп әйтелә торган исем—Габдулла.

Тукай—бу Габдулланы башка бик күп Габдуллалардан аерып, аны «Кечкенә Апуш»лыгыннан чыгарып, «зур-зур» төрк-татар шагыйре дәрәҗәсенә күтәргән исеме дә арабызда сирәк очрый торган саф үзебезчә, милли бер исем. Тукаев түгел! Бу исемнең күнелгә якынлыгы да аның шул «Тукай» дип әйтелүендә. Тукаев диденме, аның бөтен музыкасы югалып, андан паспорт исе килә башлый.

Тукай—бу исем халкыбыз арасында, яшькә-картка карамыйча, иң күп таралган исем. Җәмал Вәлиди әйтмешли, төрк-татар тарихында мәңге онытылмаслык бер исем.

Шагыйребезнең исеме халкыбыз арасында шул дәрәҗәдә киң таралган ки, кайбер вакыт әдәбияттан бөтенләй хәбәрсез, надан кешеләрнең авызындан да аның берәр шигырен ишетергә тугры килә. Тупасрак булса да, кечкенә генә бер мисал: берничә таныш җыелып, әңгәмә корып утырабыз. Уен-көлке арасында бурыч түләмәү тугрында сүз чыкты да, арабызда, әле генә әйткәнчә, шигырь вә әдәбиятка бөтенләй чит булган бер абзый: «Түләмәсәң... түләмәсәң... бит Тукайныкы... ничек әле?..» дип сүзгә катнашмакчы булды. Без ярдәмгә килдек:

Чыгып барганда, деп-деп типкәлиләр,
Яман сүзләр белән дә сипкәлиләр.

«Менә, менә үзе!»—дип куйды Тукай сөюче. Әгәр дә ул Тукайны белмәсә, бу урында сүзгә «әдәби»рәк рәвешдә катнашу өчен, берәр халык мәкале әйтеп җибәрер яисә Хуҗа Насреддин лятыйфәләрендән *(мәзәкләреннән)* берәрсен сөйләп куяр иде. Хуҗа Насреддин димәкдән, сүз җае килгәндә әйтеп

---

[1]Бу юллар «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» мәрсиясеннән.
[2]Хөсәен Рәхимҗан углы Габдүш (1901—1944)—журналист, әдип, режиссер, актер. Октябрь инкыйлабыннан соң Кытайга күчеп китә. Нигездә, Харбин каласында яши. Кабере дә шунда /(Карагыз: Хатыйп Миннегулов. Хөсәен Габдүш хикәяләре// Мирас. —1998.—№ 7.—65-68 б.).
[3]Яңа милли юл. —1936.—№5 (99).—4-8 б.
[4]Бу мисраггагы «бәка» сүзе мәңгелек, дәвамлы мәгънәләрен белдерә.
[5]Тарта ала тезмәсе тартала рәвешендә укыла.
[6]Эпиграф итеп алынган бу бәет шагыйрьнең «Пушкин вә мин» шигыреннән.

узыйк: халкыбызның бөтен катлаулары арасында исеме күп таралуда Тукайның бердәнбер көндәше Хужа Насреддин булса кирәк.

Җәмал Вәлиди үзенең «Тукай шигырьләре хакында «мөляхәзалары»нда *(уйлануларында)* яза: «Тукай мәгънәне, фикерне бик ачык әйтә. Ул сүз астына төрелми, сәнгать артына яшеренми, ачык вә тәкәллефсез сөйли. Аның сәнгать пәрдәсе шулкадәр юка вә шәффафдыр *(утә күренмәле)* ки, аның аркылы **иң гади күзләр дә** *(сызык минеке.—Х. Г.)* үтә». Шунлыктан—Тукай халыкныкы.

Габдулла бәк Батталның кыйммәтле әсәре «Казан төркләре»ндә Тукай хакында шул сүзләрне укыйбыз: «Безем илдәшемез Хәмид Зөбәер бәк *(1897—1978.—Х. М.)* бу шагыйрьгә мөнәсәбәтле француз телендә бер мажар (венгер) мәҗмугасында яздыгы мәкаләдә шагыйрьнең авыр язмышын, аның фәлякатен *(бәхетсезлеген)* дә халыкның язмышына охшата» *(Төрекчә текст татарчага тәрҗемәдә биреләе.—Х. М.).*

Тукайның иҗатышы шул чаклы киң вә төргә бай ки, нинди генә милли мәузугда берәр мәкалә яисә әсәр язма, шуның башына Тукай «Мәҗмугаи асаре»ндән һәрвакыт үзеннең төп фикереңне җыйнап тора торган берәр шигырен язып куярга мөмкин.

Югарыда китергән кечкенә генә мисалыбыз Тукайның көнлек тормышыбызның иң гади *(прозаик.—Х. Г.)* хадисәләрендә *(вакыйга-хәлләреннән)* «тел очында гына» торган нәрсәнне әйтеп бирергә ярдәм итүен күрсәтә.

Тукай үзе дә шагыйрь Сәгыйд Рәмигә язган бер мәктүбендә *(хатында)* шулай ди: «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган шагыйрь генә түгел, мин дипломат, сәяси, җәмәгать хадиме бит. **Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә»**. *(Җ. Вәлиди. «...Мөляхәзаләр». Сызык минеке.—Х. Г.).*

Без хәзер Тукайга 50 яшь тулу уңае берлә кулыбызга аның шигырьләрен алабыз, алар хакында язылган мәкалә вә шагыйребезгә багышланган хатирәләрне укыйбыз. Болар арасында иң мөһиме булып бүгенгәчә, мөһаҗәрәтдә бигрәк дә, мәрхүм Җәмал Вәлидинең шагыйребезнең үлүеннән соң нәшер ителгән «Мәҗмугаи асар»е берлә бергә басылып чыккан Тукайның шигырьләре хакында «мөляхәзаләр» саналып килә. Әдәбият тарихыбыз өчен аерылып торган бу 50 еллык юбилей уңае берлә башыбызга килгән кайбер фикерләрне «Яңа милли юл» укучылары арасында уртаклашыр өчен, кулыбызга каләм алганда, әнә шул «Мөляхәзаләр» берлә файдаландык. Бу «Мөляхәзаләр», сүз уңае берлә әйткәндә, шагыйрьнең вафатыннан соң язылган беренче җитди язмалар булуларынданмы, ничекдер, «Тукай китабы»ның тартып алынмасдай бер өлеше булып киткәнләр һәм аның эченә сеңеп калганлар.

Тукайның иҗатышындагы рух халкыбызның күңеле берлә шул дәрәҗәдә, әгәр гыйбарә дөрест булса, игезләнеп беткән ки, халкыбыз хакында фикер әйткәндә, Тукайны искә алганда, милләтебез тугрында сүз сөйләми мөмкин түгел. Алар бер-берләрендән аерылмыйлар.

Җәмал Вәлиди ачы бер хакыйкать тугрында сүз ачып, шул сүзләрне яза: «Безнең татар халкының бер хасияте һәм хосусияте рухиясе күз алдына килә. Чөнки бу ноктада без Тукайны артык татар итеп күрәбез. Шөйлә ки, татар халкында түземлек, ихатәле *(тирә-юньне)* күреп, ерак ноктаны күзәтеп эш күрү юк. Шуның өчен аның күп куәтләре җилгә китә, аның эшендә дәвам вә сәбат *(ныклык)* булмый. Бона иң кечкенә эшләремездән алып, иң зур тарихи әхвалемез шаһид. Татар куәи мөхәйялләсе *(хыялланy көче)* дә бондан мөстәсна *(чыгарма)* түгел. Ул һичбер башы, ахыры мөгайин (билгеле), бөтен, тулы әтрафлы бер хыял тугдыра алмады. Аның асаре шигърыясендә хыялый бөтенлек, киңлек түгел, бәлки бер хисси чуарлык, тарлык күрәмез. Хәтта бу тарлык, чуарлык шул дәрәҗәдә ки, ул бөтен ике мисраглык бер җыр җырлый алмый. Һич мөнәсәбәтсез вә туп-тугры Ак Идел буйларындан үзенең җанкәсенә күчә, тәрәзә капкачыннан туган иленә килеп төшә. «Иштә *(менә)* безгә Тукайда да иң ачык күренә торган нокталарның *(дөресе, безнеңчә,—ноктә,—сер; фикер; үзлек.— Х. М.)* берсе ошбудыр. Аның әсәрләре бик аз бер кыйсемене истисна *(чыгарма)* иткәндә, кыска нөктәләрдән гыйбарәт. Аларны рәтдән укып барсаң, үзеңне әлеге татар җырларыны тыңлагандагы кебек мең төрле хиснең алмашынуы каршысында күрәсең» *(Җәмал Вәлиди. «Мөляхәзаләр».).*

Тукай көннәренә багышланып язылган мәкалә вә хатирәләрдә *(истәлекләрдә)* шагыйребезгә мактау сүзләре язып кына утыру берлә канәгатьләнү җитми, бу

унай берлә гомумән милли тарих, әдәбият, тормыш вә мәгънәви ихтыяжларыбыз хакында туган фикерләрне матбугат битләренә чыгара баруыбыз кирәк.

Халкыбызның «иң кечкенә эшләребездән алып, иң зур тарихи әхвалебез»нең шәһадәте берлә аерылып торучы кимчелекле хосусиятләрен тикшерер вә җентекләргә безнең, бая әйткәнебезчә, мөһим бер әдәби юбилее уңае берлә, тик бер гади Тукай сөюче уларак кына, «тибрәтү» өчен алган каләмебезнең көче житәрлек түгел. Көчле вә тәҗрибәле каләм ияләребезнең бу гаять дәрәҗәдә кызыклы мәсьәлә хакында игътибарлы фикерләре матбугатыбызга чыга барсалар, яшь буыныбыз өчен бик файдалы булыр иде. «Иң кечкенә эшләребез» дөньясында Җәмал Вәлидинең фикерен куәтләү өчен, үкенечкә каршы, бик күп табыла торган башланып бетмәгән эшләребезнең уңыш берлә нәтиҗәләнмәүләренә нинди сәбәпләр бар? «Иң зур тарихи әхвалебез» галәмендә кайсы вакыйгалар безнең шул күнелсез хосусиятләребезгә шаһид? Чыңгыз «Яса»сындаи калма *(калган)* «Башланып та бетмәгән эш—җансыз эш», дигән шигарь *(өндәмә; лозунг)* безнең өчен буш сүзләр генә булып калдылармени? Җырларыбыздагы хосусиятне, «тәрәзә капкачыннан туган илгә күчүләрне» җырларыбызның аерым матурлыгыннан санаучыларыбыз да бар. Бу шулаймы?

Болар барысы да—үзләренә җаваплар көтеп торучы сөальләр. Көчле бер милләтчелек агымында йөзмәкдә без; бик күп яшь йөрәкләребез, милли кыйблабызга борылып, үтмешебездән илһам көтеп торалар; алар тарих вә әдәбият сәхифәләребездән олуг каһарман вә үз кешеләребезнең исемләрен эзлиләр; милли вә милли ифтихар *(горурлану)* тойгысы аларда көннән-көн үсә бара. Шундый вакытда бондай *(моның кебек)* «мөляхәзаләр» яшьләребезгә, табигый, файдалы якдан тәэсир итмиләр.

Тукайның үзендә дә әнә шул «хисси чуарлык» җимешләре булса кирәк.

Татар бәхте өчен мин җан атармын,
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

*(«Үз-үземә»)*

Шигыре берлә бергә:

Ни диерсең, сүз татар тугрында булса?
Табалмый сүз, диерсең: «ул сакаллы».

*(«Хасият»)*.

Татар халкы, син үләргә мәхкүм *(хөкем ителгән)* инде,
Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм *(агуланган)* инде;
Тиберченмә, терелмисең, юл өстендә
Ятма аунап, үзенне үзең күм инде.

*(«Милләтчеләр»)*.

Егылдык без, ике-өч чакрым да китми,—
Егетләр, бездә көч юк,—ахры булмас.

*(«Яшьләргә»)*.

Сина, дустым, сүзем шулдыр: татарга сатма матбугат,—
Тырактир ач татарга,—сат та тор һәртөрле мәшрубат *(эчемлек)*

*(«Бер гәзитә идарәсе халендән»)*

кеби күңел суындыргыч шигырьләр бар.

Кимчелекләребезне санау гына түгел, аларның төп сәбәпләрен вә аларны төзәтү юлларын күрсәтеп, аңлатып бирү—укымышлы сыйныфыбыз өстенә килеп төшкән милли вазыйфаларның берсе.

Димәк, Җәмал Вәлиди әйткәнчә, Тукай әнә шул тәнкыйтьчебез санаган кимчелекле хосусиятләребездә үзе дә «артык татар», чын татар булып күренә.

Очырмакчы булсам, былбыл күкрәгемдән,
Әллә ничек мыр-мыр итеп мачы чыга.

«Вакыйган *(чыннан да)*, Тукайның шигырьләренә каралса, бонда былбыллык берлә мачылык бер-берсен нәүбәтләшеп кенә тора. Аның коерыгы былбыл, башы мачы булган шигырьләре дә юк түгел» *(Җәмал Вәлиди. Шунда ук)*.

Шулай итеп, без Тукайның яратышы һәм халкыбызның рухи хосусияте арасында бик күп тиңдәш нокталар табабыз. Җәмал Вәлиди дөрест әйтә: Тукай шигырьләрен укыганда, чынлап та, татар җырларын тыңлагандагы кеби бер тойгы сизелә. Тукайның бу хосусиятен жанландырып күрсәтү өчен, мисал итеп, аның «Саташкан» дигән шигырен алырга мөмкин. Шуның берлә бергә күңелгә бер сөаль килә: Тукайның иҗадияте, аның «артык татар» булгандыгыннан гына шундый бер «хисси чуарлык» эченә төрелгәнме? Аның түбәндәге шигырьләре шагыйрьнең шәхси хәятында, эчке дөньясында мәҗбүри рәвештә шундый бер «тарлыкда» булуын күрсәтмиләрме?

Бар иде, ялгыз калып, җырлап җуанган чакларым,
Ярты җырда инде, күкрәкне тотам да, йөткерәм.

*(«Хәстә хале»).*

Җә, минем кайда хикәям? Ник аны читкә борам?
Юк, зарарсыз, мин шулай язган чагында йөткерәм.

*(«Күк сыер»).*

Бу «йөткерү»ләрнең аның яратышына башка яклардан да тәэсирләре юк түгелме?

Тукайны сөеп укучылар: «Тукай китабын кулга алган саен, анда бер яна нәрсә табасың»,—диләр. Гаҗәп түгел. Чөнки, югарыда әйтелгәнчә, «Тукай—күзе күпне күреп, колагы күпне ишетеп» язган шагыйрь... Сәнгать—сәнгать өчен» дип кенә җырлаган бер шагыйрь түгел. Безнең милли аңыбыз, милли хисебез үсә барып, мәгънәви тормышыбызның офыклары киңәя вә тәҗрибәбез арта барган саен, Тукай шигырьләре күбрәк аңлана барачаклар.

Олуг кешеләрнең кыйммәте, карагыз ни дәрәҗәгә җитә! Инглиз Карлейль[1] шулай ди: «Күрәсез, Шекспир безнең өчен кем булып китде. Ул безнең иң бөек бер мәликебез *(патшабыз. Бу сүзне «милкебез» дип тә укырга мөмкин).* Чит халыклар арасында үзебезнең милли шөһрәтебезне таныту мәнфәгате йөзеннән без һичбер вакытта да Шекспирдан кайтылачак түгелбез. Әгәр бездән сорасалар иде: «Инглизләр, сез кайсына разый буласыз: үзегезнең Һиндстанда биләп торган җирләрегездән ваз кичәргәме яисә үзегезнең Шекспирегездән ваз кичәргәме? Бу, әлбәттә, чит бер сөаль булыр иде. Әмма без шулай дип җавап кайтарырга мәҗбүр булганлыгыбызны сизәр идек: Һиндстандагы мөстәмләкәребез *(биләмәләребез)* безнең кулда калырлармы, юкмы,—әмма без Шекспирсез бер вакытта да улмаячак!».

Тукай—төрк-татарның Шекспире түгел; без аны кирәгеннән артык күтәрмибез. Ләкин *(ул)* үзебезнең зур бер кешебез. Аның кадерле исеме үлмәячәк. Ул «...милләт яшәдекчә яшәр, милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар».[2] Чөнки бу халкыбызның иң моңлы баласы милли хәзинәбезнең иң ярлы вә мохтаҗ чагында, шуңар үзенең бер ятим күңеленнән «ярты җырында йөткерә-йөткерә» бер мәгънәви өлеш чыгарып, «иң гади күзләр» өчен дә кыйммәтле булган бер мирас калдырды. Үзенең бик иртә өзелеп киткән ялгыз гомеренең соңгы секундларына чаклы талант көчен аямады.

Кызганыйммы: безнең ярдәм киткән чакла,
Төзәлергә, вәйран булган Кәгъбәмезгә?!

*Харбин, 12 нче апрель, 1936.*

*Текстларны басмага профессор*
**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ** *әзерләде*

---

[1]Карлейль Томас 1795—1881 елларда яши. Күренекле әдип, публицист, тарихчы, философ.

[2]Бу шигъри юллар Тукайның «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» мәрсиясеннән.





# 19—МӘРЬЯМ (МӘРЬЯМ СҮРӘСЕ) СҮРӘСЕ

**Мәрьям сүрәсе 98 аятьтән тора. Бу сүрәдә хәзрәти Мәрьямнең Гайсә пәйгамбәребезне дөньяга китерүе турында сөйләнә, шуңа күрә, исеме дә «Мәрьям сүрәсе» дип атала.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Кяф. Һә. Йә. Гайн. Сад.

**2.** Раббының Зәкәрия исемле бәндәсенә булган рәхмәте турында искә төшерү *(аятьләре)*. **(3)** Ничек итеп ул аулакта Раббысына ялварды. **(4)**

—Раббым,—диде.—Минем сөякләрем зәгыйфьләнде инде, чәчем-башым агарды. Вә мин, Раббым, сиңа кылган догаларыма күрә, рәхмәтеңнән мәхрүм булмадым. **(5)** Дөресе, шулдыр ки, минем арттан *(минем урынга варис булып)* килүче туганнарымнан *(алар тугры юлдан язарлар, дип)* шикләнәмен. Хатыным да кысыр булып чыкты. Тарафыңнан миңа *(мирасчы)* бер угыл җибәрсәнә. **(6)** Ул минем варисым булсын. Ягъкуб нәселенең дә дәвамчысы булсын. Раббым, аны Үз ризалыгыңа лаек ит.

**7.** —Әй, Зәкәрия, без сиңа бер угыл турында сөенче әйтәбез ки, аның исеме Яхъя булыр. Моннан элек беркемне дә аңа *(тиң һәм)* адаш итмәдек.

**8.** Зәкәрия әйтте:

—Раббым,—диде.—Хатыным кысыр килеш, картлыгымның чигенә җиткәндә каян килеп минем углым булсын инде?

**9.** Ул әйтте:

—Әйе, шулай. Раббың: бу эш бик тә җиңел башкарыла. Моннан элек син юк идең, булмасаң да, сине яралттык бит әле,—диде. **(10)**

—Раббым,—диде Зәкәрия.—*(Балам булачагы турында)* миңа бирәр төрле галәмәт белән хәбәр ит.

—Сәламәт булган хәлеңдә син өч көн бер кеше белән дә сөйләшмә,—диде Аллаһ.

**11.** Ул михрабтан чыгып, халык каршысына килеп, ымнар белән:

—Иртә-кич тәсбихтә булыгыз *(намаз укыгыз, Аллаһны олылагыз)*,—дип аңлатты. **(12)** *(Яхъя үсә төшкәч)*:

—Ий, Яхъя, Китапка *(Тәүратка)* бар көчең белән ябыш,—дидек. Һәм аңа сабый чактан ук *(гыйлем)* хикмәтләр өйрәттек. **(13)** Аңа күңел йомшаклыгы вә пакьлек бирдек. Ул—гөнаһ кылудан сакланган кеше. **(14)** Ата-анасына бик тә итагатьле иде. Ул гаугачыл һәм тупас түгел иде. **(15)** Аның туган көне дә, үләсе көне дә вә яңадан кубарылып тереләсе көне дә сәламле-котлы булсын. **(16)** *(Рәсүлем)* Китапта Мәрьямне дә искә ал *(укыганда аның турындагы аятьләрне дә онытма)*. Ничек итеп ул гаиләсеннән аерылып, Көнчыгыш тарафтагы бер җиргә күчте.

**17.** Мәрьям өйдәгеләр белән үзе арасына чаршау корып куйды. Без мәһабәт ир-егет кыяфәтенә кертеп, аның янына үзебезнең рухыбызны *(Җәбраил фәрештәне)* күндердек. **(18)** Ул *(Мәрьям)* әйтте:

—Синнән ярлыкаучы Аллаһка сыенамын. Әгәр дә Аллаһтан курка торган кеше булсаң *(син миңа кагылма)*,—диде.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**19.** Фәрештә әйтте:

—Мин: фәкать пакь бер ир углан табачаксын, дип сөенче алыр өчен Аллаһның илчесе булып кына килдем,—диде. **(20)**

—Мина бер генә ирнең дә кагылганы булмаган көенчә, тотанаксыз булмаган *(гыйффәтле)* хәлемдә *(гыйффәтле)* мин ничек итеп бала табыйм?—диде Мәрьям.

**21.** Фәрештә әйтте:

—Анысы шулай, ләкин Аллаһ боерды ки, бу эш бик тә җинел башкарыла,—диде. Чөнки Без,—диде,—аны инсаннарга бер дәлил вә үзебездән бер рәхмәт буларак эшләячәкбез. Бу эш алдан ук хәл ителгән иде инде.

**22.** Мәрьям *(Гайсәгә)* йөкле булды. Шуннан соң *(карынында яралгы булган килеш)* ул ерак җиргә күчеп китте. **(23)** Тулгак тоту авырлыгы аны хөрмә агачы янына алып килде. Һәм ул:

—Бу хәлләргә тарганчы үлеп кенә котылган булсам, әллә кайчан онытылып беткән булыр идем инде,—диде. **(24)** Тау итәгеннән бер тавыш килде:

—Кайгырма, Раббың синең таутүбән тарафыннан чишмә чыгара башлады. **(25)** Хөрмә агачын селкет, сиңа саф, өлгергән хөрмәләр коелыр. **(26)** Аша, эч, күзләренне салкынайт *(ягъни, үзеңне иркенлеккә куй, ял ит, тынычлан)*. Ләкин берәр кеше килеп чыкса, аңлат:

—Мин мәрхәмәтле Аллаһ өчен *(тел яшерү)* ураза*(сы)* тотамын, бүген беркем белән дә сөйләшмәячәкмен,—диген.

**27.** Ниһаять, ул баласын күтәреп, халкы янына кайтты.

Әйттеләр:

—Аһ, Мәрьям, дөрестән дә, син хәйран калырлык эш эшләдең,—диделәр. **(28)**—Ий, Һарунның сеңлесе, синең атаң да яман кеше түгел иде, анаң да бозык хатын булмады *(ни йөзең белән син ирсез бала таптың)*? **(29)** Шуннан соң Мәрьям баласына ымлады *(аның үзеннән сорагыз, дигән мәгънәдә)*. Кешеләр:

—Бишектәге сабый белән без ничек сөйләшик,—диделәр. **(30)** Шунда сабый телгә килде:

—Мин—Аллаһның бәндәсе,—диде.—Ул миңа Китап бирде һәм мине пәйгамбәр итте. **(31)** Кайда гына булсам да, ул мине мөбарәк кылды, гомерем буена Ул миңа намаз укуны вә зәкят бирүне әмер итте. **(32)** Мине анама игелекле булырга боерды. Мине бәдбәхет залим итеп яралтмады. **(33)** Туган көнем, үләсе көнем, терелеп, кабердән чыгасы көнем котлы-сәламле булсын.

**34.** *(Аның могҗизалы тууы хакында)* шикле сүз сөйләделәр. Менә, аңа карата шик белдерүче Мәрьям улы Гайсә чынлыкта шушы булыр. **(35)** Аллаһның бала атасы булуы хак сүз түгел. Ул андый эштән азат. Берәр эш башкарырга ниятләсә, Ул:

—Бар бул!—ди дә, һәм ул нәрсә барлыкка килә.

**36.**—Шунысы хактыр ки, Аллаһ минем Раббым, сезнең дә Раббыгыз. Шулай булгач, Аңа гыйбадәт кылыгыз. Менә шул булыр тугры юл,—диде Гайсә.

**37.** Шуннан соң алар фиркаларга аерылдылар *(бәхәс-гауга куптардылар)*. Бөек Көндә *(исәп-хисап томканда Аллаһка инанмаганнар өчен)* коточкыч газаплар буласын белсәң иде.

**38.** Алар Безнең хозурыбызга китерелгәндә үзләренә ни булачагы турында ишетерләр дә, күрерләр дә. Ләкин ул залимнәр бүген күрәләтә азгын юлдан баралар.

**39.** *(Рәсүлем)* син газаплар биреләчәк Көн киләчәген һәм хәсрәтләр булачагын искәртеп, аларны куркыт. Алар наданлык эчендә, әле һаман иман китермәгән килеш яши бирә. Баксаң, эш хәл ителгән инде.

**40.** Җир йөзенә вә аның өстендәгеләргә бары тик Без генә варис һәм аларның барысы да яңадан Миңа кайтачак. **(41)** Китап укыганда Ибраһимны искә төшер *(аның турында аятьләрне укы, онытма)*. Чыннан да, ул саф пәйгамбәр иде. **(42)** Беркөнне ул атасына әйтте:

—Атакаем, ни өчен син ишетә белмәгән, күрү сәләте булмаган вә сиңа һичбер файда китерә алмаган бер нәстәгә табынасың?—диде. **(43)**—Атакаем, хакыйкатән, сиңа килмәгән гыйлем миңа килде. Шулай булгач, мине тыңла,

мин сине тугры юлга чыгарачакмын. **(44)** Атакаем, шайтанга иярмә. Шайтан мәрхәмәтле Аллаһка буйсынмады. **(45)** Атакаем, шайтанга дус булып, Аллаһ тарафыннан сиңа җәза бирелер, дип куркам мин. **(46)** Атасы әйтте:

—Аһ, Ибраһим, син минем тәңреләремне инкарь итеп, алардан йөз чөерәсеңме? Әгәр бу эшеңнән кайтмасаң, ант итәмен ки, мин сине таш белән бәреп үтерәчәкмен. *(Яхшы чакта)* син миннән еракка-озакка кит,—диде.

**47.** Ибраһим:

—Сиңа мин иминлек телим. Сине ярлыкавын үтенеп, мин Аллаһка ялварачакмын. Аллаһ миңа мәрхәмәтле,—диде. **(48)**—Сездән дә, Аллаһтан башканы тәңре дип табынганнарыгыздан да мин аерылам һәм Раббыма кылган догаларым, бәлки, бушка китмәс.

**49.** Шулай итеп, Ибраһим алардан һәм Аллаһтан башка тәңре дип табынганнардан да ерак тарафларга киткәч, Без аңа Исхак белән Ягъкубны бирдек вә һәрберсен пәйгамбәр иттек.

*(«Хәзрәти Ибраһим халкыннан аерылып, ерак юлга чыгып китә. Ул Шам (Сүриягә) шәһәренә барганда, юл өстендәге Хәрран шәһәрендә Сара исемле бер кызга өйләнә. Хәзрәти Исхак дөньяга килә. Хәзрәти Ягъкуб исә Исхакның улы, Ибраһимның оныгы була инде».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**50.** Аларга *(Исхак белән Ягъкубка)* рәхмәтебездән өлешләр чыгардык *(пәйгамбәрлек, мал-мөлкәт һәм күп балалар бүләк иттек)*. Бөек шөһрәтләргә мәңгездек.

**51.** *(Мөхәммәд)* Китап укыганда Мусаны да искә ал. Чыннан да, ул ихласлык үрнәге иде. Һәм Рәсүл, һәм Нәби иде ул. **(52)** Аңа тауның *(Турның)* уң тарафыннан аваз салдык *(чакырдык)*, яшерен сөйләшер өчен, Без аны якын арага китердек. **(53)** Рәхмәтебезнең нәтиҗәсе буларак, Без аңа кардәше Һарунны пәйгамбәр сыйфатында бүләк иттек.

**54.** *(Рәсүлем)* Китаптагы Исмәгыйльне дә искә төшер. Хактыр ки, ул сүзенә тугры, Рәсүл һәм Нәби иде. **(55)** Халкына ул намазны вә зәкятне әмер итте. Раббы каршысында ул ризалык казанган кеше иде.

**56.** Китаптагы Идрисне дә искә ал. Хакыйкатән, ул бик тугры кеше, пәйгамбәр иде. **(57)** Без аны мәртәбәле урынга күтәрдек.

*(«Хәзрәти Идриснең чын исеме Ухнух. Ул хәзрәти Нухның өченче буын бабасыдыр. Аңа чаклы кешеләр кием тегүнең ни икәнен белми иде. Тире-яры бөркәнеп яши иде. Хәзрәти Идрис-Ухнух—кием тегүне уйлап тапкан кеше. Ул—беренче булып каләм кулланган кеше, йолдызлар һәм хисап эшләрендә гыйлеме булган кеше. Аңа утыз битлек вәхий иңдерелмеш».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**58.** Менә болар Аллаһ нигъмәтләр биргән пәйгамбәрләрнең берничәсе. Адәм *(галәйһиссәлам)* нәселеннән, Нух белән бергә көймәгә йөздергән, Ибраһим белән Исраил *(Ягъкуб)* токымыннан, тугры юлга күндерелгән һәм Без сайлап алган кешеләрдер. Кин мәрхәмәт иясе Аллаһның аятьләрен укыганда күз яшьләре белән елап сәҗдә иткән шәхесләрдер.

**59.** Алардан соң тагын бер нәсел килде дә, намазны ташладылар, азгынлык нәфесенә иярделәр. Шуңа күрә, алар шушы азгынлыкларына күрә, җәзасын да алачаклар. **(60)** Тәүбә иткәннәр вә игелек кылганнардан башка. Алар җәннәткә керер һәм аларга рәнҗетүләр булмас. **(61)** Ярлыкаучы *(Аллаһ)* үзенең бәндәләренә серле-яшерен рәвештә вәгъдә иткән *(Гаден җәннәтләре)*, һичшиксез, чынбарлык булачак. **(62)** Анда алар буш сүзләр түгел, хуш сүзләр *(иминлек сәламнәре)* ишетәчәк. Вә анда иртә-кич аларга тәгам бирелер. **(63)** Ул шундый җәннәттер ки, аңа бары тик саф мөселманнар гына варис булачак.

**64.**—Без *(фәрештәләр)* Раббының әмере белән генә *(сезнең янга)* төшәбез. Алдыбыздагы, арка ягыбыздагы вә шулар арасындагы һәрнәрсә Аның милке. Синең Раббың *(савабына күрә әҗерен, гөнаһына күрә җәзасын бирергә)* оныта торган түгел.

**65.** Күкләр һәм Җир арасындагыларның хуҗасы Аллаһтыр. Шуңа күрә, Аңа буйсын, Аңа хезмәт иткәндә сабыр һәм чыдам бул. Аның тиңе, алашы *(Аңа охшаган)* башка берәү булырмы? *(Була алмый.)*

**66.** *(Көферлеген итеп)* кеше әйтә:

—Үлгәннән соң мин чыннан да тагын тереләмме? *(Була торган эш түгел ул)*,—ди.

**67.** Үзен юктан бар итеп яралтканыбыз турында кеше уйлап карамыймыни? **(68)** Раббың исеме белән «Валлаһи» дип ант итәмен ки, һичшиксез, аларны мәхшәр көнендә шайтаннар өере белән бергә туплаячакбыз. Аларны җәһәннәм уты тирәли тезләндереп тотачакбыз.

**69.** Иң башта һәр өммәттән рәхимле Аллаһка иң күп гыйсъян иткәннәрне сайлап *(җәһәннәмгә)* чыгарачакбыз. **(70)** Хактыр ки, анда *(җәһәннәмгә)* кереп янарга тиешләрне Без бик яхшы беләбез. **(71)** Анда керергә тиешле булмаган һичбер кеше арагызда юк. Бу—Аллаһның катгыян карар иткән котылгысыз хөкемедер.

**72.** Соңыннан Без Аллаһтан куркып, гөнаһ эшләүдән тыелганнарны коткарырбыз. Гаделсез залимнәрне тезләнгән килеш шунда калдырырбыз. **(73)** Аятьләребезне укыганда инкарьчылар иманлыларга әйтә иде:

—Ике халыкның *(кяферләр белән мөселманнарның)* кайсысы яхшырак *(тормыш шартларында)*, баерак, рәхәтрәк яши?—диләр иде.

**74.** Алардан әүвәл дә мал байлыгы һәм җиһаз ягыннан да яхшы яшәгән *(кяферләр)*не Без күп һәлак иттек. *(Шул турыда да әйт син аларга.)*

**75.** Әйт:

—Юлдан язганнарга да мәрхәмәтле Аллаһ гомер мөддәте бирер. Ниһаять, үзләренә вәгъдә ителгән җәза килгәч яки Кыямәтне күргәч, кемнең малы аз, кемнең яшәү шартлары начар, кемнең гаскәре зәгыйфь икәнлеген аңларлар,—диген.

**76.** Аллаһ тугры юлда йөргәннәрнең һидаятен арттырыр. Өзлексез кылынган игелекле эшләр Раббы каршында алыначак әҗер буларак та, тәкъдирнең соңгы нәтиҗәсе буларак та хәерле.

**77.** *(Рәсүлем)* аятьләребезне инкарь итеп тә:

—Минем малым вә балаларым, һичшиксез, күп булачак,—дигән адәмне күргәнең бармы? **(78)** Ул (Аллаһ янындагы) яшерен серләрне белүчеме әллә? Бәлки, ул *(Ахирәттә малларын, балаларын кайтарып алырга дип)* Аллаһ белән килешү төзегәндер? **(79)** Катгый әйтәбез—юк. Аның сүзләре язылып барачак. Аның газапларын арттырганнан-арттыра барачакбыз. **(80)** Ул әйткәннәргә *(малына, бабаларына)* варис Без булырбыз. Ул үзе дә яныбызга япа-ялгыз *(ялангач)* килер. **(81)** Алар үзләренә бер абруй вә *(яклаучы)* куәт булсын дип, Аллаһтан башканы тәңре иттеләр. **(82)** Юк! Алай барып чыкмас. Алар табынган нәрсәләр аларның ялваруларын кабул итмәс һәм аларга дошман булачак. **(83)** *(Рәсүлем)* күрмисеңмени, Без, кяферләрне вәсвәсәгә салып, юлданяздырсыннар дип, вәсвәсәгә салып, шайтаннарны күндердек.

**84.** Шулай булгач, син *(аларның һәлак булуын)* ашыктырма. Без аларның яшисе көннәрен *(кылмышларын)*, бәйнә-бәйнә санап барабыз. **(85)** Саф мөселманнарны мәрхәмәтле Аллаһ каршысына җыйган Көнне, (86) гөнаһлыларны туплауга куыла торган, кибеккән хайван көтүе шикелле, җәһәннәмгә куганда, **(87)** рәхимле Аллаһ белән вәгъдәләшкәннәрдән башкаларның ярлыкаучысы булмас. **(88)** Алар:

—Аллаһ бала атасы булды,—диде. **(89)** Әлбәттә, сез *(кяферләр)* чирканыч сүз әйттегез. **(90)** Аны ишетеп, күкләр чак кына җимерелеп төшмәде. Җир ярыла, таулар кубарылып, ишелә язды. **(91)** Раббыга бала сылтаганга күрә. **(92)** Гәрчә, Аллаһның бала атасы булырга ихтыяҗы юк.

**93.** Күкләрдәге вә Җирдә булган һәркем кол сурәтендә Аллаһ янына килер. **(94)** Ул аларның барысын да камап ала һәм аларның санын *(ни кылмышларын)* белеп тора. **(95)** Аларның һәрберсе Кыямәт көнендә Аның янына япа-ялгыз гына киләчәк. **(96)** Иман китереп, игелекләр кылганнарның күңелендә мәрхәмәтле Аллаһ **(бер-берсен)** сөю хисе уятачак. **(97)** Аллаһ каршысында гөнаһ эшләүдән курыкканнардан сөенче алсын дип, киребеткән гөнаһкярларны кисәтсен дип, Без Коръәнне җиңел аңлашылырлык итеп, *(гарәпләргә)* Ана телендә иңдердек. **(98)** Без алардан элек яшәгән ничәмә-ничә халыкларны һәлак иттек. Аларның берәрсен син тойдыңмы *(исәннәрен күрдеңме?)* яки, һичьюгында, аларның пышылдаганнарын ишеттеңме *(һәлак булганнарның авазы юк)*?

Kitap küzətü
Китап күзәтү

# ТАТАРНЫКЫМЫ, ӘЛЛӘ...

Гасыр ахырында татар әдәбият белеменә һәм аның мөстәкыйль тармакларын тәшкил иткән әдәби тәнкыйтькә, әдәбият тарихына, әдәбият теориясенә кагылышлы житди хезмәтләр барлыкка килде. Аерым алганда, филология фәннәре докторлары Фоат Галимуллинның «Эстетика һәм социологизм» *(Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 1998)*, Фәрит Хатиповның шул ук нәшриятта дөнья күргән «Әдәбият теориясе» (2000 ел), Марсель Бакировның «Гомумтөрки поэзиясенең яралуы һәм иң борынгы формалары», Марсель Әхмәтҗановның «Татар кульязма китабы» исемле монографияләре татар әдәбият белемен тагын да бер баскыч югары күтәрде. Шулар янына күптән түгел янә бер саллы хезмәт—Казан дәүләт университеты доценты Дания Заһидуллинаның «Әдәбият кануннары һәм заман» дигән, татар әдәбият теориясенең барлыкка килүен һәм үсеш баскычларын өйрәнүгә багышланган китабы да *(Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2000 ел; фәнни мөхәррире: филология фәннәре докторы, академик Тәлгать Галиуллин)* өстәлде.

Бу хезмәт—озак еллар дәвамында алып барылган эзләнүләр җимеше. Автор үзе билгеләп киткәнчә, ул татар әдәбият нәзариясен (теориясен) бөтен килеш колачлап өйрәнә торган беренче системалы тикшеренү. Яңалыгы—татар әдәбият теориясенең формалашу һәм үсеш юлын гомумиләштереп анализлау һәм бәяләүдә. Галимә татар әдәбият нәзариясе тарихын өч чорга бүлеп өйрәнә. Беренче чор—әдәбият нәзариясе барлыкка килүгә әзерлек, эзләнүләр вакыты; икенче чор—татар әдәбият нәзариясе барлыкка килү дәвере (ул үзе ике баскычка: 1907-1913 һәм 1913-1916 елларга бүлеп карала); өченче чор—1920 еллардан марксистик-ленинчыл мәктәп мәйданга чыгу, аның рәсми әдәбият теориясе итеп урнашу дәвере.

Татар әдәбият нәзариясенең үсеш юлын шул рәвешле этапларга бүлү белән бергә автор XX йөз башының иң кызыклы чор—мөстәкыйль фән барлыкка килү, милли нигезләр, законнар һәм закончалыклар табу вакыты икәнлеген раслый. Ул беренче чорга кыскача күзәтү ясау белән генә чикләнүен искәртеп китсә дә, чор шактый тулы, фәнни югарылыкта өйрәнелгән, бу күзәтүләр җирлегендә әһәмиятле гомумиләштерүләр, нәтиҗәләргә ирешелә, ачышлар ясала.

Г. Гобәйдуллин сүзләрен искә алсак, XX йөз башына кадәр татарларда яңа «әдәбият тудырырга зәмин (җирлек) булырлык иске көчләр йөзләрчә еллык икътисадый, сәяси вә рухани изелү аркасында тапталганнар, юкка чыкканнар; татарның иҗади куатенә бер зарбә (удар, бәрелү) орылган; яңа әдәбият тудырырлык яңа көчләр әле житешмәгәннәр һәм аларга мәдәни зәмин дә юк иде». Д. Заһидуллина әлеге фикерне тагын да үстереп, XX йөз башына кадәр татар әдәбиятының әкрен-әкрен үзгәрүен, кискен ыргылышлар ясамавы нәтиҗәсендә әдәби-нәзари фикер үсешенең тоткарлануын дәлилләп күрсәтә: «Яңа әдәби ачышлар күзәтелми икән, димәк, теоретик эзләнүләр өчен җирлек, стимул да юк; яңа әдәби кыйммәтләрне һәм табышларны аңлату, нигезләү дә кирәкми, дигән сүз. Д. С. Лихачев фикеренчә, әдәбиятның алга баруы тыенкы-әкрен булганда, теоретик эзләнүләр әһәмиятен җуя. Ләкин галим икенче закончалыкны да күрсәтә: әдәбиятның,

әдәби-нәзари фикернең озак вакытлар торгынлык кичерүе генә кискен алгарышлар әзерли ала.»

Татар әдәбияты теориясенең тарихи формалашу юлы тулысы белән әдәби үсешне кабатлавын, шул ук вакытта дини-иҗтимагый фикер яшәешенең үзенчәлекләренә бәйле булуын да җитәрлек дәрәҗәдә фактик материаллар нигезендә исбатлануын әйтеп үтү кирәктер.

«Татар әдәбият нәзариясе XX йөз башында фән буларак аерылып чыга. Бу дәвергә килү ягыннан татар нәзари фикер үсеше рус, Аурупа әдәбият теориясенең беренче адымнарын хәтерләткән кебек,—ди автор,— үзенең асылы һәм үсеш законгалыклары белән XX йөз башындагы эзләнүләр, милли үзенчәлекләре, хасиятләр калку күренеп торса да, шул ук рус әдәбияты теориясендәге XIX йөзнең беренче яртысындагы барышны хәтерләтә». Автор татар нәзари фикере XX йөз башында Гареб юнәлешендә баручы милли нәзарияләрнең берсе булуын күрсәтә. Мондый нәтиҗәләрне чор тенденцияләренә сукырларча иярмәүчән, фәнни нигезе ныклы һәм объектив булган галим кеше генә чыгара ала.

Хезмәт белән танышкач, асылда, татар әдәбияты нәзариясенең гарәп-фарсы, төрек, рус, Аурупа тәэсиренең шифасын тоеп формалашуына инанасың, төрле әдәби-нәзари концепцияләр хакында бәхәсләшеп үз йөзен эзләвенә төшенәсең. Хезмәттә нәзари фәне формалашуның милли һәм гомуммәдәни чыганаклары күп яктан яңача ачыла, татар нәзари мәктәпләренең үзенчәлекле позиция булдыруы, төрек йә исә рус нәзари контекстында үз сукмагын табуы ышандырырлык дәлилләнә.

Г. Сәгъдинең «Мохтасар кавагыйде әдәбиягә гыйлавә», «Әдәбият ысуллары», «Әдәбият мөгаллиме», Г. Батталның «Нәзарияте әдәбия», Г. Ибраһимовның «Әдәбият дәресләре (Әдәбият кануннары)» китаплары беренче мәртәбә тикшерелеп, бәя бирелә. «Шура», «Аң» журналларында, «Йолдыз», «Вакыт», «Кояш» газетләрендә басылган күп санлы мәкаләләр әдәби-нәзари хәзинә итеп карала һәм фәнни югарылыктан торып тикшерелә. «Җәмгыятьчеләр» әдәби-нәзари мәктәбенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары», «Рухиятчеләр» мәктәбе: асылы, төп сыйфатлары һәм законгалыклары» кебек уникаль бүлекчәләрнең булуы китапның кыйммәтен тагын да арттыра.

Үтә дә кызыклы һәм файдалы, күләмле хезмәт хакында шактый җәелеп сөйлисе килә дә бит, әмма әлеге фундаменталь мәсьәләләр белән шөгыльләнүче галимнәргә калдырып, авторны куәтлисе һәм китапның «XX йөз башында татар нәзария фәне тулысынча башка милләтләр эшләгән теоретик материалны тәрҗемә итеп, күчереп барлыкка килде, бездә милли нәзария юк» дигән, моңа кадәр яшәп килгән карашны тамырдан кире кагуын, юкка чыгарырга ярдәм итүен һәм галимнең «милли әдәбият нәзариясе» төшенчәсенең үзен үк яңа законгалыклар җыелмасы, милли фәлсәфә, әдәбиятка караштан үсеп чыга торган өйрәтү буларак аңлатуының гаять әһәмиятле икәнлеген ассызыклап китү белән чикләнәбез.

**Фәкил САФИН**

# «ЯШӘҮНЕ УЛ МИНДӘ КАЛДЫРДЫ...»

ШАГЫЙРЬ РАЗИМ ВӘЛИУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Күптән түгел шагыйрь Разим Вәлиуллинның өч шигырь китабын укып чыктым. «Зирекле елга» (1994), «Уч төбендә кояш» (1995) һәм «Ак тулпарда» (1996). Шагыйрь иҗаты белән куанып, шатланып таныштым. Безнең буталчык заманның халәтен, шул шартларда яшәгән актив җанлы кешенең хис-кичерешләрен формуладай төгәл, шигъриятле гәүдәләндерү бар әлеге китапларда.

Бу шагыйрь халкыбызның «урбанизация» дигән давыл дулкынландырган төбәгеннән. Зәй районының Кәдек дигән авылында 1942 елда туган ул. Аннары, Әлмәттә урта мәктәп тәмамлый. 1963-1967 елларда Казан дәүләт педагогия институтының музыка факультетында укый. Шуннан соң Лениногорск музыка һәм рәсем педучилищесында укытучы булып эшләгән. 1970 елдан җәмәгатьчелек тәртибендә Лениногорскиның «Чишмә» әдәби берләшмәсен житәкли. Ә инде 1993 елның октябреннән—Әлмәт язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе.

Разим Вәлиуллин иҗатындагы тәүге кыю адымнар житмешенче еллар башында билгеләнә. Аңа әдәбиятта үзен раслар өчен «әтәч булып кычкыру» вакыты житә. Шагыйрь үзе дә бер шигырендә: «Инде юлдан ничек түгел, нәрсә алып бару булып туа мәшәкатьләр»,—дип белдерә (1978). Әйе, әдәбиятка нәрсә алып килүенне күрсәтергә вакыт. Аның иҗаты шул юнәлешкә керә бара. Шагыйрь буларак, кеше, шәхес буларак, ул ялганга корылган торгынлык чоры чынбарлыгын кабул итә алмый һәм моны шигырь юлына да сала:

Куллар кабарганчы алкышлыйбыз
«Дөрес!», «Дөрес!» диеп ялгышны...
*(1980)*

Традицион темага язылган әсәрләрендә дә шагыйрьнең аерым уңышлары бар. Шундый шигырьләрдән берсе—«Бер назлыймчы чәчләреннән» (1971). Биләүдәге кыз баласын ата кеше хыялында болай күрә:

Күзләрен бигрәк зәңгәр лә,—
Күкләрне көнләштермә.
Яндырма безнең йөрәкне:
Кичләрен соңлап йөрмә.

Яна туган, биләүдәге кыз балага мондый тетрәнүле назлаулар кем күңеленә килер? Сабыйның зәңгәр күзенә соклану—Туфанның «Яшьләрең юа лабаса күзеннең зәңгәрләрен» дәрәҗәсендә сурәтле. Шигъри музыкальлек, тетрәнүле эмоциональлек! Әсәр азаккача шул гаҗәпләндергеч тәэсирлелек дулкынына корылган. Шагыйрь үз аһәнен, үз гармониясен—үз шигырен тапкан.

Әлеге җыентыклардагы бүтән шигырьләргә дә күз салыйк. Менә унбер юлга тартылган бер строфалы «Даимилек». Строфалар саны берникадәр артса да, шул ук калыптагы «Уяну», «Автобусның тәрәзәсе ачык», «Көннәр дә юк, төннәр дә юк», «Яратам дип өч әйтмиләр», «Чулпылар чыңлар әле». Болар—авторның шәхси кичерешләре белән актуальләштерелгән мәхәббәт шигырьләре. Әмма аларда да инде житдилек, унай программа барлыгы төсмерләнә. Бу—авторның чын, зур казанышлар юнәлешендә эзләнүләргә

йөз тотуы. Соңгырак елларда шагыйрь «ирекле үлчәмдәге» шигырьләрдә дә матур гына нәтиҗәләргә ирешә («Хәнҗәр йөзе буйлап» һ. б.)

Хәер, аның бу юнәлештә уңышка ирешүе, беренче карашка композиторлык тәэсире булып та күренүе мөмкин. Шагыйрь белән композиторның кушылуы «үлчәмсез» шигырьне эчке музыкаль ритмика хисабына гармонияле шигырьгә якынлаштыра ич. Бардыр, андый хәлләр дә бардыр. Әмма шигырьне болар түгел, актуаль поэтик эчтәлек шигырь итә. Бу очракта да ул шулай: әлеге шигырьләрдә автор заманының иң үткен проблематикасы юнәлешендә киеренке эзләнүләр психологиясен поэтик гәүдәләндерә. Үзәк проблемалы булулары, зур сәнгатькә йөз тотулары белән мондый әсәрләр житдиләшәләр һәм укучыны җәлеп итүче яңгыраш табалар.

Классик үлчәмле шигырьләрендә ул эчке музыкаль ритмга түгел, халык җырларының сөйләм үзенчәлекләренә мөрәҗәгать итә, шигырен җыр лексик үзенчәлекләре һәм семантикасы төсмерләре белән бизәкли:

Агыйделкәй ага алкын булып,
Сусауларны баса салкын булып.
Чык бөрке дә язның гөлләренә,
Сагышларга каба ялкын булып.

Әмма олы шигърият югарылыгына чыгу өчен, ихлас күңелдән кыйблалы эзләнүләр һәм яңа, бай бизәкләү мөмкинлекләренә мөрәҗәгать итүләр генә дә житми икән әле. Шигъриятнең Туфан үрләренә үтәр өчен 90 нчы еллар башындагы сәяси вакыйгалар кирәк булган. Әмма әлеге җимерелүләр, кешелекнең мәңгелек идеалы дип расланган коммунизмның мәйданнан китүе шагыйрьне сискәндерми, буташтырмый. Зур шигъри талпыныш белән ул шомлы чикне атлап үтә дә, үткәнне ачык күз белән йомгакларга («Без батырлар! дип мактандык, җимергән, яндырганда...», «Тапландык ялган даннарда...», «Сәләмә, ертык әләмнәр,—яңасы нинди булыр?!») һәм киләчәккә чын юнәлешне билгеләргә алына («Уяндык ди. Ярый! Шуннан нәрсә?! Безнең максат бары шушымы?!...»). Ижтимагый тормышның сүлпәнлеге, жансызлыгы аеруча игътибар үзәгендә:

Яңа көн. Яңа төн. Яңа таң,—
Мин ялкын алалмый җанатам.
Тыелып, коелып-оялып,
Җуелган иманны янартам.

Тормыш тирәнлекләрендә барган көрәш киеренкелеген дә шагыйрь күрә һәм масштаблы, төгәл чагылдыра:

Халыклар зинданы капкасын
Ватарга кавемнәр уяна.
..............
Богаулар таркала зыңгылдап,
Кулларда чылбырлар шартлыйлар.
«Ирек!»—дип очынган җаннарны
Караптып, вандаллар таптыйлар.

Разим Вәлиуллин әнә шулай итеп 90 нчы еллар башында, үз заманының, хис-кичерешләрен, вакыйга-фактларын классикабыз төгәллегендә һәм камиллегендә чагылдыру югарылыгына күтәрелә. «Чорлар бусагасында», «Яну», «Милләт», «Бюрократ», «Ялгызлык», «Алгысыйм», «Сүзем бар», «Сабырлык сары алтынмы?», «Маңкорт» шигырьләрендә дә ул әлеге югарылыкта кала.

Әйе, ул елларда халык, җәмәгатьчелек тоталитарлык калдырган «тораташлыктан» чыга алмый интегә. Шагыйрь дә шул социаль жирлек кисәге. Әмма ул әлеге тораташлык урманында, шуларның берсе булган хәлендә, шул тораташлыкны җимерү әфсенен мәйданга атарлык көч, талант таба алган. Осталыкнын Туфаннар ирешкән мәйданын киңәйтә алган.

Разим иҗатының Казаннан читтә үсеп шул дәрәҗәгә ирешүе күңелләрдә дә ышаныч һәм якты өметләр кузгата. Алла аңа яңа казанышлар насыйп булсын!

**Мәсгут ГАЙНЕТДИН**

*Безнең календарь*

# БОЛЫН ЧӘЧӘКЛӘРЕ КҮП БУЛСЫН

## ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙПНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

XIX гасыр азагында, XX гасыр башында шулай булдымы икән, әллә 1905 елгы беренче инкыйлаб тәэсирендә татар халкының уянып, иҗтимагый-сәяси тормышка ургылып килеп керүе сәбәпме, ул чорда туып-үскән дистәләрчә зыялыларыбыз халкыбызның асыл хәзинәсенә бетмәс-төкәнмәс байлык—акыл һәм сәнгать байлыгы, рухи мирас калдырдылар. Журнал укучылар игътибар иткәндер, соңгы елларда юбилейлар артык күбәеп китте кебек. Байтак күренекле затларыбызның йөз дә ун, йөз, туксан еллык юбилейлары билгеләп үтелә. Ләкин моны һич кенә дә күпсенергә кирәкмидер. Чөнки аларның һәркайсының рухи дөньябызга керткән үз өлеше, әдәбиятта һәм сәнгатьтә үз тавышы бар. Иҗат җимешләрен еш кына бакчадагы гөлләр белән чагыштыралар. Гөлләр гел бертөрле генә булмый. Бар зурлары, ачык якты төстәгеләре, хуш исләре белән башны әйләндерерлек затлылары, бар күзгә-башка артык бәрелеп тормаучы нәни генә болын чәчәкләре... Ләкин алар табигать-анабызның кешелеккә бүләк иткән хәзинәсендә бер дә артык түгел, һәркайсының үз урыны, хәтта үз вазифасы бар. Шагыйрь Галимҗан Латыйпны да мин әнә шул соңгылары рәтенә кертер идем. Январь аенда әдәбият сөючеләр аның 90 еллыгын билгеләп үтәчәк.

Галимҗан Латыйп зурлар өчен дә, балалар өчен дә язган шагыйрьләребездән. Иҗат багажында лирик шигырьләр белән беррәттән балладалар, әкиятләр, поэмалар, кыска шигырьләр, җыр текстлары да бар. Аның "Беренче тау", "Тургайлар килде", "Бомбалар кирәкми", "Тәгәрмәчләр", "Безнең яшьлек", "Чайкала иген кырлары", "Акбүз атым", "Бөтен гомергә" кебек композиторлар тарафыннан көйгә салынган шигырьләре инде озак еллар концерт репертуарларыннан төшмичә җырланып киләләр. Шагыйрь рус һәм чит илләр әдәбиятларыннан Демьян Бедный, Сергей Михалков, Самуил Маршак, Александр Твардовский, Пабло Неруда, Никола Вапцаровларның поэтик әсәрләрен зур осталык белән татар теленә тәрҗемә итте. Гомумән алганда, Галимҗан Латыйп татар шигъриятендә туган ил, хезмәт, халыклар дуслыгы һәм тынычлык турындагы әсәрләре белән үз сукмаган салган әдип.

Сүз башлаганда гасыр башындагы бер үзенчәлекне телгә алган идек. Аларның тагын берсен искә төшермичә мөмкин түгел. Хәзерге вакытта административ чикләр буенча Агыйделнең һәм Ыкның аръягында бүленеп калган милләттәшләребез татар әдәбиятына, сәнгатенә, фәненә, гомумән, акыл хезмәте сорый торган тармакларга гаять дәрәҗәдә шифалы йогынты ясадылар һәм ясыйлар. Әдәбиятның алтын баганалары булган Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Нәкый Исәнбәт, Шәехзадә Бабич кебек исемнәрне генә телгә алу да күп нәрсә турында сөйли. Галимҗан Латыйп та әнә шул бәрәкәтле туфрактан. Ул 1912 елның 20 гыйнварында Уфа губернасының Яна Дөмәй авылында (хәзер Башкортстанның Чакмагыш районына керә) туган. Тормыш һәм хезмәт юлы да чордашларыныкы шикелле. Авылда башлангыч белем ала, бүгенге укучыларга сәеррәк тоелучы "кызыл почмак" дигән культура-агарту оешмасы мөдире, китапханәче булып эшли, соңрак налог җыючы, заем таратучы да була. Комсомол активистына нинди генә эш йөкләмиләр. Ләкин җаны-тәне белән әдәбиятка гашыйк егетне бернәрсә дә туктата алмый. Ул татар әдәбиятының мәркәзе Казанга тартыла. Егерме яшьлек егет 1932 елда Казанга килеп рабфакка керә, аннан соң финанс-экономика институтында укый. Хәрби диңгез флотында хезмәт итеп кайтканнан соң Татарстан радиосында редактор вазифаларын башкара, 1941-1951 елга

кадәр Татарстан республикасы контроль органнарында инспектор-ревизор була, 1951-1960 елларда "Пионер" (хәзерге "Ялкын") журналында әдәбият-сәнгать бүлеген житәкли. 1960 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр профессиональ язучы була.

Галимжан Латыйпның беренче шигырьләре 1932 елда "Коммуна" (хәзерге "Кызыл таң") газетасында басылып чыга. Ул—татар һәм рус телләрендә барысы утыздан артык китап авторы.

**Флүс ЛАТЫЙФИ**

# Ğalimcan Latıyp

## Minem nəsel

Babaların kem dip sorasağız,
Cir keşelərе bulğan, bilgele.
Tipsə timer өzgən,
Suqsa taşnı izgən,
Kirək ikən, borğan İdelne.

Yəşəgən ul bөten ğemere buyı,
Cirgə ğaşiq bulıp yəşəgən.
Qayğıların cinsə,
Şatlıq kilsə,
Təbe-tamırı belən yəşərgən.

Qanın birgən,
Xətta canın birgən,
Zarlanmağan hiç tə dөnyadan.
Eçendəge tışta bulğan anın,
Berkemgə də məker qormağan.

Keçelərne ber də keçerəytməgən,
Olılarnı olı itə belgən.
Nindi genə yortqa atlasa da,
Sawmısez, dip,
Sələm birep kergən.

Çuqmar totıp,
Bilgə qılıç tağıp,
Çit cirlərgə basıp kerməgən.

Kilsə doşman anın üz estenə,
Məydan totqan,
Qurqu belməgən.

Napoleonın cinəgən,
İke başlı
Albastısın alıp ırğıtqan.
Reyxstagqa bayraq qadağan da
Qaytır yaqqa taba yul totqan.

Kimsetsələr anın
Nəsel-ıruın,
Ul taw bulıp basqan,
Çikməgən.
Cinayətne,
Yalğan həm məkerne,
Keçləwlərne ğafu itməgən.

Bez kilmeşək tügel bu dөnyağa,
Ügi bala tügel, beləmsez!
Nəsel-nəsəbəsez ber zat tügel,
Yulawçı da tügel, kürəmsez!

Bez bu cirdə gөllər üsterəbez,
İxtiramğa layıq xalqıbız.
Planetanın küpme ğemere bulsa,
Şunın qədər yəşəw xaqıbız!

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАТАР КОНГРЕССЫ—ТӨРКИЯДӘ

2001 елның 3-10 декабрь көннәрендә Бөтендөнья Татар Конгрессының Башкарма Комитеты рәисе **И. Таһиров** һәм Татарстан Республикасы мәгариф министры **Ф. Харисов** житәкчелегендә Бөтендөнья Татар Конгрессы делегациясе Төркиядә булды.

Визит барышында делегация Истанбул, Искешәһәр, Анкара шәһәрләрендә булдылар һәм Төркиянең милли мәгариф министры М. Бостанжиоглу, дәүләт министры А. Чай, Истанбул губернаторы Э. Чакыр, мэры А. Гуртуна, Искешәһәр хакимияте башлыгы урынбасары И. Әрдам белән күрештеләр, шулай ук Русия Федерациясенең Анкарадагы илчелеге һәм Русия Федерациясенең Истанбулдагы генераль консуллыгында булдылар. Моннан тыш, Татарстан Республикасы мәгариф министры Төркия югары уку йортларында укучы Татарстан студентлары белән очрашты.

6 декабрьдә Татарстан һәм Төркия мәгариф министрлары мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек турындагы хөкүмәтара килешүгә кул куйдылар. 7 декабрьдә Русия Федерациясенең Истанбулдагы генераль консуллыгында Татарстан делегациясе хөрмәтенә Татарстан Республикасының тулы вәкаләтле вәкиллеге тарафыннан оештырылган рәсми кабул итү тантанасы үткәрелде. Ана дипломатлар, Төркиянең рәсми һәм эшлекле даирә, татар диаспорасы вәкилләре һәм Истанбулда белем алучы Татарстан студентлары чакырылган иде.

8 декабрьдә Истанбулда Бөтендөнья Татар Конгрессы Башкарма Комитетының утырышы узды. Бу БДБдан читтә үткәрелгән беренче утырыш. Утырышта Төркия һәм Кипр шәһәрләреннән татар диаспорасы вәкилләре катнашты. Утырыш барышында татар диаспорасының Төркиядәге хәле, проблемалары һәм аның чишелеш юллары тикшерелде.

## «ИДЕЛ-ПРЕСС» ЮБИЛЕЕ

12 ноябрьдә республикабыз җәмәгатьчелеге **«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексына 30 ел һәм Татарстан полиграфиясенә 200 ел** тулуны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында тантаналы төстә билгеләп үтте. Юбилярны Татарстан Президенты, Министрлар Кабинеты һәм Дәүләт Советы исеменнән Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева котлады. Ул «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексының иң яхшы полиграфчыларына Мактау грамоталары тапшырды. Нәшриятның генераль директоры И. Әхмәтжанов Татарстан Президентының исемле сәгате белән бүләкләнде.

Республиканың полиграфия промышленносте флагманы хезмәткәрләрен Татарстан элемтә министры Р. Җәләлов, Мәскәү районы хакимияте башлыгы Г. Минкина тәбрикләде.

«Идел-Пресс» коллективын юбилее белән котларга Россиянең төрле төбәкләреннән бу тармакка житәкчелек итүчеләр дә күп килгән иде.

## ЯШЬЛӘР ҖЫЕНЫ

Ноябрь ахырында «Казан» милли мәдәният үзәгендә бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән «Казан» милли мәдәният үзәге оештырган «Читтә яшәүче татар яшьләренең милли яшәеше проблемалары» дип исемләнгән семинар булып узды. Анда Чуашстан, Башкортстан, Удмуртия, Марий Эль, Коми, Мордва республикаларыннан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Мурманск, Новосибирск, Самара, Саратов, Төмән, Әстерхан, Владимир, Ярославль өлкәләреннән, Украина, Белоруссия, Казакъстан һәм Латвиядән татар яшьләре оешмалары житәкчеләре катнашты. Яшьләр башкалабызга телне, гореф-гадәтләрне саклау, заманча сәнгатьне үстерү кебек уртак эшләр турында «түгәрәк өстәл» янында сөйләшү, проблемаларны хәл итү максатыннан җыелды.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК НЫГЫЙ

Истанбулда Төркия Республикасы Министрлар Кабинетының дәүләт архивлары Генераль идарәсе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты янындагы Баш архив идарәсе арасында 2001-2004 елларга хезмәттәшлек турындагы беркетмәгә кул куелды.

Шуның белән берлектә Төркия архив хезмәткәрләре Милли архивка 150 документ тапшырды. Шулар арасында Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасы да бар.

Төркиянең архивлар идарәсе генераль директоры Йосыф Сарынай соңгы елларда Төркиядә һәм Татарстанда табылган документларның төрек, татар һәм рус телләрендәге каталогын булдырырга дигән тәкъдим кертте. Ике дәүләт хезмәткәрләренең уртак хезмәте 2002 елда Әнкарада чыгар дип көтелә.

## УЛЬЯН ЯКЛАРЫНДА

Казакъстанның Жаек (Уральск) каласыннан татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайга һәйкәл ачу тантаналарыннан кайтышлый Язучылар берлеге делегациясе Ульяновск өлкәсендә тукталды. Берлек рәисе Фоат Галимуллин, Г. Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Ренат Харис, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире шагыйрь Харрас Әюптән торган делегацияне өлкә губернаторы Владимир Шаманов кабул итте. Әңгәмә вакытында Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасында мәдәни, әдәби бәйләнешләрне үстерү буенча кайбер мәсьәләләр тикшерелде.

Өлкә үзәгендәге Дуслык йортында тантаналы шартларда Мәләкәстә яшәп иҗат итүче шагыйрь Гакыйль Сәгыйровка Гаяз Исхакый исемендәге бүләк, шунда ук шагыйрә Лена Садыйковага (Иделбикәгә) Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителүе хакында таныклык тапшырылды.

Татарстан язучылары делегациясе Иске Кулаткы, Николаев һәм Барыш районнарында булды. Иске Мостяк, Татар Сайманы, Әхмәтле, Зур Черекле авылларында халык белән очрашулар узды.

Очрашуларның иң әһәмиятлесе Барыш районындагы Зөябашы (Тимошкино) авылында булгандыр. Биредә туку фабрикасы хуҗаларыннан берсе—Хәсән Акчурин чакыруы буенча Габдулла Тукай 1909 елда биш көн кунак булган. Казаннан килгән язучылар ул торган бүлмәне карадылар, авыл музеенда булдылар.

## МИЛЛИ КИТАПХАНӘДӘ АЛМАН ЗАЛЫ

Татарстан Милли китапханәсендә Алмания уку залы ачылды. Шул уңайдан журналистлар белән матбугат конференциясе булды. Анда Русиядәге Алмания илчелегенең мәдәният буенча атташесы Альбрехт Конце, Гете исемендәге институт директоры Вольфганг Майснер, Татарстан Дәүләт Советының фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе Разил Вәлиев, мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиевләр катнашты. Ә уку залын мәдәният министры Илдус Тарханов ачты.

Элегрәк Милли китапханәдә Америка уку залы ачылган иде. Бу очрашуда чит илләрдә Татарстан уку заллары ачуны оештыру зарурлыгы әйтелде. Дөрес, Нью-Йоркта һәм Хельсинкида андый заллар ачылды да инде.

## ХИКӘЯНЕҢ ХИКМӘТЕ

Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай клубында яна китап—«Татар хикәясе антологиясе»н тәкъдир итү булды. Тарихы гасырларга сузылган татар хикәясе турында житди сөйләшүгә әверелгән бу кичәдә Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Д. Шакиров, китапны төзүче М. Хужин, китапны әзерләүдә катнашкан Г. Гыйльманов һәм Р. Корбанов чыгыш ясады. Күренекле артист А. Арсланов төрле буын язучыларының хикәяләрен укыды, радио фондында сакланган «Курай» хикәясе Ә. Еникинең үз тавышында яңгырады.

## ДИНИ МУЗЫКА ФЕСТИВАЛЕ

Төркиядә VI халыкара дини музыка фестивале булып узды. Анда Татарстаннан халык артистлары Зөһрә Сәхабиева, Гөлзадә, Мингол Галиев, Рамил Курамшин һәм Сара Садыйкова фонды рәисе Әзһәр Хөсәенов катнашты. Безнең җырмөнәҗәтләрне фестиваль кунаклары һәм тамашачылар бик җылы кабул итте.

Татарстан вәкилләре шулай ук Гаяз Исхакый җирләнгән зиратта булдылар, бөек әдип рухына дога укытып, каберенә чәчәкләр салдылар. Фестивальдә катнашучыларга «Монсара» телевизион фильмының кассетасын бүләк иттеләр.

## КҮРГӘЗМӘДӘ—ЕРАК ТАРИХЫБЫЗ

Казанның сынлы сәнгать музеенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Рушан Шәмсетдинов**ның шәхси күргәзмәсе булып узды.

Экспозиция рәссамның тууына 55 ел тулуга багышланган. Тамашачы игътибарына сынлы сәнгать, графика һәм каллиграфия әсәрләре тәкъдим ителгән.

Р. Шәмсетдинов әсәрләрендә сурәт һәм шигърият бер-берсен тулыландырып тора. Бу тәнгәллек «Идегәй» эпосында, Кол Гали поэмасы «Йосыф китабы»нда, «Баш баһадир», «Мөселман бәйрәмнәре», «Болгар ханы», «Алтын Урда ханнары», «Казан ханнары», «Үткән заман шагыйрьләре» китапларында ачык чагыла.

## РӘССАМ ИҖАТЫН БАРЛЫЙ

Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам **Шамил Нигъмәтнең тууына—50, иҗат эшчәнлегенә** 30 ел тулуга багышланган күргәзмә эшли.

Шамил Нигъмәт рәссам-монументалист һәм күпсанлы картиналар—пейзаж, натюрморт, портретлар авторы буларак билгеле. Аның очкычлар төзелеше тарихына багышланган иң зур эшләренең берсе КДТУ бинасын бизи. Шулай да рәссамның иҗатында мөһим урынны туган ягы—Буа районы Килдураз авылы табигате, якташларының портретлары алып тора. Авыл темасына кагылышлы хезмәтләр арасында

ташландык авыллар һәм аларда яшәүчеләр хакында сөйләүче монсу картиналар да бар.

**ХӘТЕР ЯКТЫСЫ**

Язучыларның Тукай клубында олуг әдибебез—Г. Тукай бүләге лауреаты, Казакъстан Республикасының иң югары дәрәҗәле «Парасат» ордены кавалеры **Ибраһим Салаховның тууына 90 ел** тулуга багышланган «Хәтер яктысы» дигән кичә үткәрелде. Анда каләмдәшләре, аны якыннан күреп белгән язучылар һәм шагыйрьләр, заманында ул укыган Казан дәүләт педагогика институты (хәзер КДПУ) студентлары, мөгаллимнәре катнашты.

Әдипнең тормышы һәм иҗаты турында диссертация яклаган филология фәннәре кандидаты, галимә Ләйлә Әхмәдиева-Минһаҗева, И. Салаховның «Тайгак кичү» романын русчага тәрҗемә иткән язучы Марсель Зарипов, шагыйрь Мөдәррис Әгъләм, журналист Рәисә Яхина, Кави Нәҗминең улы Тансык Нәҗметдинов һәм башкалар Ибраһим Салахов турында истәлекләр сөйләделәр. Кичәне Шаһинур Мостафин алып барды.

**«ГОМЕР МИЗГЕЛЛӘРЕ» ХАТИРӘЛӘРЕ**

Шәриф Камал музеенең әдәби-музыкаль салонында Әлмәттә яшәп иҗат итүче фронтовик язучы **Әдип Маликов**ның шагыйрә Сажидә Сөләйманова истәлегенә багышланган, «Рухият» нәшриятында дөнья күргән «Гомер мизгелләре» китабын тәкъдир итү мәжлесе үткәрелде. Кичәдә язучылардан Р. Фәйзуллин, Р. Мостафин, Л. Ихсанова, К. Минлебаев, Ф. Гыйззәтуллиналар катнашты һәм чыгыш ясадылар.

**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ ИСТӘЛЕГЕНӘ**

Язучы Тәүфикъ Әйди (ул озак еллар безнең журналда проза бүлеге редакторы булып эшләде) халкыбызның тарихын, аның чит илләрдәге күренекле шәхесләрен, төрки дөньяны барлау һәм әдәби әсәрләрдә чагылдыру ягыннан зур эшчәнлек күрсәтте, үзеннән бай әдәби мирас калдырды. Фидакарь каләм иясе алтмыш яше тулып килгәндә генә якты дөньядан китеп барды. Ноябрьдә Мәскәүнең Асадуллаев йортында Тәүфикъ Әйдинең 60 еллыгына багышланган кичә булды. Анда Русия башкаласында яшәүче татар җәмәгатьчелеге вәкилләре, күренекле хәрби, фән, сәнгать эшлеклеләре җыелды. Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин сөйләде. Кичәдә шулай ук «Идел» журналының баш мөхәррире Рашат Низамиев, Мәскәүдә яшәүче әдәбият белгече Вил Ганиев, Татарстанның Русиядәге вәкаләтле вәкиле Нәзиф Мириханов, язучының хатыны Әлфия ханым, улы Айнур, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев чыгыш ясады.

**ҖЫРЧЫ, МИЛЛӘТПӘРВӘР, ОСТАЗ**

Уникс концертлар залында Казан дәүләт педагогика университеты доценты, Татарстанның халык артисты **Миңгол Галиев**нең 60 яшьлек юбилеена багышланган «Моңнар йөри җаннан-җанга күчеп» дип аталган концерт-тантана булып узды.

Миңгол Галиев Казан дәүләт консерваториясенең вокал факультетын тәмамлаган. 20 елдан артык Казан дәүләт педагогика университетының музыка факультетында эшли. Аның күп кенә укучылары халыкара, бөтенроссия, төбәк, республика конкурсларында лауреат һәм дипломант, ТРның халык һәм атказанган артисты исемнәренә лаек булдылар.

**ЯҢӘ БЕР ФӘН ДОКТОРЫ**

Казан дәүләт университетының диссертацияләр яклау советының чираттагы утырышында **Әнвар Шәрипов** «VIII-XIV гасырларда борынгы төрки һәм төрки-татар әдәбиятында шигырь жанрлары системасы (барлыкка килүе, үсеше һәм яшәеше)» дигән темага филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә диссертация яклады.

Рәсми оппонентлары—филология фәннәре докторлары, профессорлар Н. Хисамов, Р. Ганиева, Г. Федоров (Чабаксар), шулай ук төп бәяләүче оешма—Казан дәүләт педагогика университеты галимнәре хезмәткә югары бәя бирделәр; диссертация һәм диссертациянең авторефератына карата Урта Азия, Башкортстан фәнни үзәкләреннән, галимнәреннән дә уңай бәяләмәләр килгән.

Фикер алышуларда күренекле галимнәр Ш. Абилов, М. Бакиров, Т. Галиуллин, З. Шәрәфетдинов һәм башкалар хезмәтне тирән анализлап, югары бәяләделәр—докторлык дәрәҗәсенә куела торган таләпләргә тулысынча җавап бирә дип таптылар.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Кичке Казан манзарасы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрь Вәзыйх Фатыйхов.

# ЯҢА КИТАПЛАР

"Рухият" нәшриятында танылган язучы һәм публицист **Флүс ЛАТЫЙФИ**ның өч томлык "Сайланма әсәрләре" басылып чыкты



**I томда** төп урынны татар тарихының мона кадәр яктыртылмаган гаять катлаулы дәверен, XVI гасыр урталарында Казан ханлыгында булып узган дәһшәтле вакыйгаларны сурәтләгән "Хыянәт" романы алып тора. «Бәйсез этләрне атарга» роман-нәсере исә укучыны узган гасырның илленче елларына алып кереп китә. Әсәрдә уникe-унөч яшьлек үсмер күзаллавы аша басып алынган ил, яулап алынган халыкның, «Хыянәт» романында сурәтләнгән хөр һәм мәгърур токым варисларының бүгенге көндә нинди хәлгә төшерелүе, ничек яшәве тасвирланган. Китапта шулай ук язучының тормыш юлын һәм иҗатын шәрехләгән күләмле мәкалә белән дә (авторы Ф. Сафин) танышырга мөмкин. Анда болай диелә: "Татар әдәбиятында тарихи әсәрләр язучылар күп булмаса да, аларның милләтнең үзаның үстерүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Ул шуның белән аңлатыла, тарихи әсәрләр язарга алынган әдипләребез укучыда милли иманга нигезләнгән әдәби зәвык тәрбияләп кенә калмыйлар, ә бәлки халык арасында аерым популярлык казанган мәгърифәтче миссиясен үтәүләре белән дә ихтирамга лаеклылар".

**II томга** язучының "Ишелеп төшкән бәхет" романы, "Тамга", "Игезәкләр" һәм "Соңгы кисәтү" дигән фантастик повестьлары кертелгән. "Ишелеп төшкән бәхет"—роман-эксперимент. Ул җир шарының барлык кыйтгаларына сибелгән татар дөньясын колачларга тырышып карау. Татар бәхете кайда? Татарстанда бәхетлеме ул? Чит илләргә күчеп киткән, качып китәргә мәҗбүр ителгән татарлар бәхетлеме? Беренче карашка мәхәббәт һәм Ватанга тугрылык хакындагы сыман тоелган роман тукымасына урыс дәүләтенең татарга карата гасырлар буе дәвам иткән мәкерле сәясәтенең чагылышы да яшерелгән.

**III томга** "Ак-карага тимәскә" повесте һәм язучының төрле елларда иҗат иткән иң яхшы хикәяләре тупланган. "Повестьта сурәтләнгән хәлләрнең "торгынлык" дип аталган чорда түгел, үзгәртеп корулар башлангач булуы нык уйланырга мәҗбүр итә. Чынында система җимерелмәде, юкка чыкмады, киресенчә, повестьның төп каһарманы Рәис Хаков кебекләрне сыта-изә һаман яши, фәкать косметик төзәтенү аркасында йөзен-чыраен гына үзгәртте. Флүс Латыйфи моны сиксәненче еллар ахырында ук тасвирлап бирә алды, кисәтеп куйды, әмма бу нәрсәләргә игътибар итәргә әле безнең вакытыбыз юк" диелә кереш мәкаләдә.

Китапта шулай ук халкыбыз һәм туган телебез язмышы, әдәбият хәлләре турында күләмле мәкаләләр, уйланулар, парчалар да урын алган.

*Китаплар югары зәвык белән "Идел-пресс" полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылган.*

*Басманың җаваплы редакторы **Илсөяр Хәйруллина**, рәссамы **Нияз Хаҗиәхмәтов**. I-II томнар 400 әр бит, III том—528 бит. Тиражлары 3000 данә.*

Индекс 73210



Вәзыйх Фатыйхов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)